ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2000



ЖИҢҮГӘ 55 ЕЛ



Без аз калдык...

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2000*

# 5

(931)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әдип МАЛИКОВ. Хәтер яралары. *Шигырьләр* ..... 5
Рафаэль СИБАТ. Ялгызак. *Моңсу роман* ..... 8
Георгий ИБУШЕВ. Көмеш яңгыр, күк чәчәк... *Шигырьләр. (Р. Фәйзуллинның кереш сүзе белән)* ..... 77
Әхмәт РӘШИТ. Эзли-эзли ул борынгы эзне... *Шигырьләр* ..... 109
Резеда ВӘЛИЕВА. Сүнмә әле, өмет йолдызым. *Шигырьләр (Р. Гаташның кереш сүзе белән)* ..... 122
Рәниф ШӘРИПОВ. Казан утлары. *Шигырьләр* ..... 127

### МӘГЪСУМ ХУҖИНГА 70 ЯШЬ

ЗӨЛФӘТ. Тыкрыктагы аулак сукмак ..... 90
Мәгъсум ХУҖИН. *Хикәяләр* ..... 93

### ҖИҢҮНЕҢ 55 ЕЛЛЫГЫНА

Айсылу КӘБИРОВА. Зур өлешебез бар ..... 115
Шаһинур МОСТАФИН. Батырларыбызны барлар чак ..... 131
Тәэминә БИКТИМЕРОВА. Урман кисте кызлар ..... 138

### ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Мирза МӘХМҮТОВ. Коръән сүзе татар телендә ..... 143

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәридә ХӘСӘНОВА. Ренат Харис шигърияте ..... 155
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Үткәннәрдән безгә гамьнәр калган *(Рецензияләр конкурсы)* ..... 180

### ӘБРАР КӘРИМУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Хуҗи МӘХМҮТОВ. Фәнни библиографиябезгә нигез салучы ..... 171

### ЮМОР-САТИРА

Шамил Маннап. Мәзәкләр ..... 186
Котлыйбыз! ..... 188
Укучы сүзе ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

Журнал выходит один раз в месяц

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман Р. СИБАТА «Холостяк» (*окончание*); стихи Г. ИБУШЕВА (*с предисловием Р. Файзуллина*); стихи А. МАЛИКОВА, Р. ШАРИПОВА, Р. ВАЛИЕВОЙ (*с предисловием Р. Гаташа*).
«К 55-летию Победы»: статьи А. КАБИРОВОЙ «Велика и наша доля»; Ш. МУСТАФИНА «С раздумьем о героях», Т. БИКТИМЕРОВОЙ «Девушки валили лес».
«70 лет писателю М. Хузину»: статья ЗУЛЬФАТА «Тихая тропинка в переулке». М.ХУЗИН. Два рассказа.
«Жизнь и религия»: М. МАХМУТОВ. «Учение Корана на татарском языке».
«Литературная критика»: Ф. ХАСАНОВА. «Поэзия Рената Хариса».
«На конкурс рецензий»: Р. ШАРАФИЕВ рецензирует книгу Т. Галиуллина «Гроздья судьбы».
«К 75-летию А. Каримуллина»: статья Х. МАХМУТОВА «Основатель научной библиографии».
«Юмор-сатира»: Ш. МАННАПОВ. Забавные истории.
В номере отмечается 60 - летие М. Шигапова.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Маликов В. М. Скульптурная часть монумента павшим в борьбе за Советскую власть;писатель Шагинур Мустафин.

# IN OUR ISSUE:

"Prose and poetry": R.SIBAT 'S novel «The bachelor» (ending); the verses of G. IBUSHEV (with FAIZULLIN 'S preface), the verses of A. MALIKOV, R. SHARIPOV, R. VALIEVA (with GATASH 'S preface).
"Commemorating the 55 th anniversary of Victory": articles of A. KABIROVA «And our share is great», SH. MUSTAFIN «With thought about the heroes», T. BIKTIMIROVA «The girls were throwing down trees».
"Commemorating the 70th anniversary of M. Huzin": ZULFAT 'S article «The still path in side-street». M. HUZIN 'S two stories.
"Life and religion": M. MAKHMUTOV «Teaching Koran in Tatar».
"Literary criticism": F. HASANOVA «Renat Harris 's poetry».
"Review competition": R. SHARAFIEV'S review of T. Galiullin 's book «The clusters of the fate».
"Commemorating the 75th anniversary of A. Karimullin": H. MAKHMUTOV'S article «The founder of the scientific bibliography».
"Humour - satire": SH. MANNAPOV. Funny stories.
Readers word.
The diary of social and cultural life.
In our covers: Malikov's piece of sculpture, writer Sh. Mustafin.

The magazin edits monthly

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 17.04.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-162
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

*Жиңүнең 55 еллыгына*



# Әдип Маликов

## Хәтер яралары

Гүрдәгеләр, Сезнең өлешкә дә
Кошлар сайрый, алсу таң ата.
Кабере табылмаган полкташым
Төшләремә кереп ята.

Карыйм сыман минем күзем белән
Сабыйларга, якты дөньяга.
Сөенәдер сыман яхшылыкка,
Вәхшилеккә җаны кыйнала...

Тел тидерсә кемдер ветеранга,
Кан койгансыз диеп, тикмәгә...—
Җаным рәнҗи:
—Кагылма син юньсез,
Изге хәтер—бөек үткәнгә!

Туган илне сатсак, Илсез калсак,
Чыкмас идек коллык, җәбердән.
Туар буын, күзәнәктә килеш,
Керер иде күптән кабергә.

Тумас идең син дә, тәти егет,
Кизәнсәң дә кайчак бабаңа.
Ә ул баскан, җанын аямыйча,
Фашист белән синең арага.

Яшьлегебез утта янды диеп,
Каһәрләмим узган гомерне.

Янсак-яндык, ләкин җиңеп чыктык,
Үтердек без явыз үлемне!

... Хәтер яралары тиз төзәлми,
Аңлатуы кыен сөйләп тә.
Гүрдәгеләр искә төшкән саен
Кан сава да тора йөрәккә.

*1995.*

## Кырык бернең көзендә

Кырык бердә,
 көзге Минзәләдә
Йөргән Муса соры шинельдән,
Чакыру көтеп туган иленнән...

Көндез походларда,
 ә кичләрен
Концерт хәзерләргә алынган.
Бар дөньясын онытып җыр тыңлаган,
Бар дөньясын онытып сагынган.

Шигырь сөйли курсант нәфрәтләнеп,
Авыл сәхнәсенә баскан да.
Ничек җаның түзсен,
 кан дошманың
Сеңелләрне дарга асканда!

Дусай авылы буйлап олау чыга,
Озата бара яше, олысы.
Кызыл олау бара көнбатышка—
Якташларның күңел җылысы.

Дугадагы алсу тасма белән
Көзге ачы җилләр шаяра...
Мусага да бер пар җылы итек
Бастырганнар диген кай ара!

Полигонда Муса.
 Пистолетның
Кайнарлыгын кулда тоя ул.
... Пистолетлар дәшми торганда да,
Җырым,
 сакчы кебек уяу бул!
Уяу бул!

Солдат белән бергә утларга кер,
Оныттыр син окоп салкынын,
Шагыйрьме ул,
 заман давылларын
Уздырмаса йөрәк аркылы!

Кырык бердә,
 көзге Минзәләдә
Йөри Муса соры шинельдән,
Чакыру көтеп туган иленнән...
Ни буласын алда кем белгән?!

*1954. Минзәлә.*

## Офыкларым һаман ерагая

Хәрәкәттән тора бар табигать,
Хәрәкәттән тора тереклек.
Кушылалар бергә агым сулар,
Юлларымда тау-таш эретеп.

Тормыш кичәм иңгә кояш салып,
Сабыйларга узам юл биреп.
Мин илемнең һәр каласы белән
Күрешеп йөрим ике кул биреп.

Офыкларым һаман ерагая,
Буыннарда тоям көч барын.
«Элегрәк килсәң—ни булган»,—дип
Шелтәли күк яңа дусларым.

Баруымны, йөрүемне белә
Заман йөген алга этәреп...
Соңгы чиктә арып егылсам да
Туган илем алыр күтәреп!

*1964*

* * *

Ул дуслык окопта туганмы,
Походта, җырдамы?—онытылган.
Солдатлар дуслыгы кайчакта
Башлана бер бөртек шырпыдан.

Учыңа яшереп җилләрдән,
Сызасың кадерләп соңгысын.
Тайгада кабынган учакның
Тоям мин хәзер дә җылысын.

*1978*

**Рафаэль Сибат**

# ЯЛГЫЗАК

МОҢСУ РОМАН

## III кисәк

* * *

—Дөньяга яз килде...

Тирә-як наз белән тулды: март җиле җиргә ятып кар ашый, кояш күзләрендә унҗиде яшьлек саф кызлар карашы.

Абзарга чыгарылган сарык бәрәннәре үзләрен кая куярга белми, утлы табадагы борчаклар кебек сикеренделәр. Сыерлар күзләрен йомып рәхәтләнеп күшиләр, печәнлектә тавыклар кытаклый, аларга, үз авазларын күкрәктән чыгарып, әтәчләр гайрәт бирә. Чормаларда мәчеләр чинаша, бакча артында этләр өере «бер гүзәл» артыннан чабышып йөриләр.

Менә, һавага шыксыз тавышларын салып, кара каргалар кайтты. Үзләре: «Кар да кар!»—диләр. Күрәсең, әле монда кара җир күренми, аның өстендә ак кар ята диюләредер инде. Кара караны яратыр, ди... Озакламый авыл өсте сыерчыклар сайравына күмелде. Болай булса, кыр җырчылары—тургайлары да күренер.

Иртән яктырып чыккан кояш кешеләрне тышка тартты. Инде Нәүрүз көненнән соң ул тагы да җәелебрәк көлә башлап, кар яткан өй түбәләрен елата башлады. Урам гөрләвекләре үскәннән үсә барып, беркөнне, арык малай-шалайдан гаярь ир-егеткә әйләнгән инсани зат кебек, көчле-куәтле ташкынга әверелделәр. Күч суларын үз өстенә җыйган Шөн елгасы бер кичтә, ифрат ачуы килепме, төбәннән бәргән авыртулы аваз белән тонык-усал пошкырды да өстендәге калын тунын салып ташлады. Ертылган тун меңнәрчә кисәкләргә теткәләнеп инеш өстеннән Нократ елгасына ашыкты...

Көннәр үтәдән-үтә җылыта башлагач, инештәге ташкын, котырган ерткычка әйләнеп, ыспай гына яткан тегермән буасын боз-тешләренә кабып, бер танда үзе белән өстерәп алып китте. Ярый әле тегермәннен үзенә теше үтмәде.

—Иң мөфиме,—диде тегермәнче Йөзмөхәммәт.—Тегермән үзе китмәде, жегетләр. Ну, тегермәнне дә ияртеп китсә, ай-һай! Иң мөфиме—тегермән китмәде... Иң мөфиме шул...

---

Ахыры. Башы 4 санда.

Йөзмөхәммәт «мөһим» сүзен бик ярата иде. Колхоз җыелышында булсын, башка сөйләк тоткан урыннарда, ул «мөһим» сүзен, иң мөһиме санап, аны еш куллана иде. Шунысы бар: ул аны үзенчә әйтә. Нәкъ менә Йөзмөхәммәтчә генә:

—Мөфим!—ди. Шуның белән сүзнен җегәре бермә-бер арта һәм тынлап торган, тырпайган колакларны икеләтә сагайта иде.

Язгы каникулга җибәрелгән малайлар беркөнне, мәчеттән клубка әверелдерелгән ике катлы бина янына килеп, сөрән салдылар:

—Дәр-дәр-дәрәгә! Иртә торып берсекөнгә сөрәнгә... Ай диләр, вай диләр—Заһидулла абыйны бай, диләр...

Клубтан берничә өй генә читтәге йортта яшәгән ирнең колагына бу авазлар үзләренең ишек алдында кычкырылган кебек бик якыннан ишетелә. Ул терсәгенә таянып яткан урыныннан тора, ләкин...

Атлап китә алмый ул...

Төрмә иданнәре юеше аягына бик каты бәргән иде аның. Ята менә хәзер бала карап...

Заһидә өстендә өй эшләренең бар авырлыгы. Шуның өстенә бәбигә дә узган икән...

Йә, Алла!

Заһидулла тешләрен шыкырдатты, үзенең көчсезлегеннән елар дәрәҗәгә житте:

—Үгез күк кеше була торып, ә?!

Исән кешеләргә иртәгә әнә Язгы Сабантуй башлана. Ул Шөн якларында язгы чәчүгә кадәр уздырыла торган беренче Сабантуй. Икенчесе җәйгә чыккач үткәрелә, шуна да ул җәйге Сабантуй дип атала да...

Иртәгә әнә авылның ун-ундүрт яшьлек малайлары Дәрә көнен уздыралар. Һәр йортка такмак әйтеп, сөрән салып керәләр дә он, ярма, йомырка, май, тиен акча сорыйлар. Сорап кына калмыйлар, хәтта таләп итәләр. Бирмисен икән, авылда хурга калдырып, шулай ук такмак әйтеп, сөрән салып чыгарга да күп сорамыйлар:

Иске-моски кәзәки,
Кәзәкинен бавы юк...
Әйбер бирер хәле юк!

Аннан һәр команда авылдагы үзенең билгеле бер кешесендә дәрә боткасы пешерә. «Билгеле кеше»—эшсезрәк яисә балалар яратучы ялгызрак бер әби була инде.

Менә шулай Заһидулла матур вә күнелле язга чыгуга сырхауланды. Тамагыннан ашау үтмәде, төнлә кунакка килә торган сызлануларга ахылдады-ухылдады. Ярый әле аның өстендә бер шәп эш бар иде: бала карау!

Менә шулай, басса жирне янтайта торган көчле-куәтле Алып-ир беркөнне, чиргә тарып, бала караучыга әйләнде. Иң күнеллесе шул: улы бик еламый, әнисе имезә икән, чыпчыклар күк чырык-чырык килә. Дөресе, чырык-чырык көлә. Ә чыпчыклар көлми бугай алар. Бәлки көләләрдер дә. Алар да бит жан ияләре...

Беркөнне шулай сыкранып-сукранып ята иде агач караватында, ишек кактылар. Теге «ишек кагу»ны исендә тоткан ир-зат сискәнеп үк китте: «Тагы алып китәргә килделәрме?»

Ләкин ул ихтыяр көче нык булган кеше иде, аптырап тормады:

—Керегез,—диде.

Тавышы гына нигәдер хәлсез вә дәртсез чыкты. Ни сәбәптәндер, рәттән генә йоклап ятучы улына карады. Галимулла рәхәт изрәп йоклап ята иде. Заһидулла күнеленә изге һәм әүлия кешеләрдә генә була торган илаһи бер тынычлык инде...

Икенче минутта ишек ачылып, аның каралҗым яктылыгына бер жан иясе кысылды...

Алар шактый гына бер-берсенә карашып тордылар. Ниһаять, теге

зат хатын-кыз тавышы белән аңа эндәште:

—Көтмәденме мине?

—Юк,—диде ул турысын гына...

—Менә килдем әле...

—Әйдә, түргә уз!

—Түренә узмыйм, озак та тормыйм. Мин бит сина кунак булырга килмәдем... Син...

—Йомышынны әйт алайса,—диде Заһидулла, кинәт кенә сабырсызланып һәм аякларынын чемер-чемер килгәнен жаны-тәне белән тоеп. Ул хәтта бик нык тирләп тә китте, чәче, муены, култык аслары, күкрәге шабыр тиргә батты. Үзе тагын ерак арага чапкан чабышкы кебек авыр итеп мыш-мыш сулый иде. Чөнки...

Чөнки хатын ана:

—Син ауда Мәкчимне үтергәнсен,—диде.

Һәм бу сүзне ул икенче тапкыр ишетә иде инде. Тегеләр котырткан, тегеләр...

Шул нахак бәлагә ирнен гәүдәсенә алагаем, зур бер пружинабишек сиртмәсе генә түгел—тыктыдармыни. Ул караватыннан сикереп торып аякларына чатырдатып басты:

—Как ты смеешь такое говорить? Это же большой грех!

Мәкчим хатыны елап жибәрде. Ул исерек иде...

Ә анарчы...

* * *

Ә анарчы...

Бер вакыйга тормыштагы икенче вакыйганы тартыр, бер яхшылык алдагы яхшылыкка юл салыр, бер юньсезлек үз артыннан икенче юньсезлекне өстерәр, ди.

Әйе, ә анарчы...

Ире көймәсендә Нократ суын «тегеләр» белән кичеп, Шөн ярына баскан хәмер авызлы хатын алар өенә килеп кергәнче...

Анарчы... Заһидулла башыннан жил-давыллы шактый вакыйгалар узды.

Малмыж төрмәсеннән кайткач, ул беркая да чыкмыйча, үз өендә бикләнеп диярлек ятты. Дөрес, Заһидулла мич башында арка жылытмады, мал-туарны карады, иртәләрен абзарларны чистартты, ишек алларын себерде, бер куллы пычкысы белән Мурзиха болынлыгы ягындагы кара таллыкта үзе әзерләгән утынны кисте һәм турады. Каратал пүләннәре чи иде, аларны алып кереп мич башында киптерде. Гомумән, йорт-жирдә сау-таза ир эшләргә тиешле бер хезмәттән дә йөз чөермәде генә түгел, киресенчә аны яратып, аерым бер тәм-ләззәт белән башкарды.

Төннәрен, улларын йоклаткач, алар бер-берен иркәләп-сөеп туйгач яисә арыгач, озак кына сөйләшеп яттылар, киләчәккә планнар кордылар. Заһидәсе үз өендә, туган авылында калырга дигән уйны сөрсә, Заһидулла, киресенчә, Нократ аръягына чыгып, яңа тормыш кору хыялында иде.

—Озакламый синә бер кыз табып бирермен, Заһидулла жаным. Нигә син шул якта урман аюы булырга ашкынасын икән? -ди Заһидә бераз ачынып.—Аh-аh!

—Сон, чибәрем, үзен төптән уйла әле бер. Акыллы хатын бит син. Надан да түгел. Тартмый минем күнелем күмәк хужалыкларга. Мин дә авылымны яратам, андагы кешеләр дә ошый мина. Хәтта Габдрахман, Ямаш, Сабитларга да бер үчем юк. Хакимияткә куелганнар икән, югарыдан төшкән әмерне үтәми хәлләре юк. Бары карсак Габдулла гына... Маңка башы белән теләсә кая кысылып йөри. Анысы бер хәл әле, камсамул бит, ә менә кешеләрне... Кемнәр бит?! Авылдашларын сатуы... Шайтанлык бу! Һы...

—Ана да үч тотма, жаным...

—Беткә үч итеп тун якмам инде! Яшәсен шунда. Болай... ныгытып борынын кыссам, өч сулыш алырлык арада тәпиен суза, жаны чыга инде.

—Әтинең сүзен беләсеңме?

—Кайсы әти?—диде аптырабрак Заһидулла.

—Сина кияүгә чыккач, синен әтиен минем дә әтием була ич инде!

—Хатын-кыз бәхетле. Кияүгә чыктымы ике әтиле була: үз әтисе, иренеке...

—Алай дисән, ирләр ике бабайлы булалар: үзенеке, хатынныкы...

—Өч!—дип бүлә аны Заһидулла.—Әтинең әтисе—беренче бабай, әнинең әтисе—икенче бабай, хатыннын әтисе—өченче бабай. Нинди байлык! Кемдә бар ул тагын?

Шушы юк кына сүздән рәхәтләнеп көләләр. Гадәте буенча Заһидә башын Заһидулланың кин вә таза күкрәгенә сала, уң кулы белән анда урман булып утырган куе, кара төкләрне сыйпый һәм аны үбеп:

—Йонлачым... Йонлач аюым...—дип пышылдый. Шулвакыт иргә ифрат та рәхәт булып китә, хатынынын теләсә кайсы теләген үтәргә әзер икәненә төшенә, шулай да эчтән генә:

—Бары күченеп китүгә генә каршы килмәсен,—дип, куркынып уйлап куя. Ә хатыны анын әтисенең сүзләрен искә төшерә:

—Әтинең еш кына әйтә торган бер сүзе бар иде: «Кешегә файда китерә алмасаң да—бервакытта да зыян салма!»

—Беләм-беләм... Хәтерлим мин ул сүзләрне—дип, аны жөпләп куя ире.

Йорттан бер-бер артлы ике мәет чыгып, өйдә үлек күпмедер дәрәжәдә үзенең сагышлы рухын каллыручан булса да, яшь таза ир белән яшь матур, сылу хатын бу кайгы сөремен күнелләреннән чистарта алдылар, чарасызлык сазлыгына батмадылар. Монын ин беренче сәбәбе: алар арасындагы мәхәббәт, бер-беренә тартылу булса, икенче сәбәп: бишектә яткан, көннәр узган саен тернәкләнеп-ныгып барган сабыйлары Галимулла иде. И, анын көлүләре! Дөньяда ин матур нәрсә ни ул дисәләр:

—Сабый көлүе!—дип әйтү иң дөрес жавап булыр. Ә иң борчулы, ямьсез нәрсә ни була дисәләр:

—Сабый елавы...—дию хакка туры килер.

Ах, ул сабыйның, бер гөнаһсыз нарасыйның елаулары. Жаныңны өшетә, рухыңны сындыра, күнеленне сөремләтә, бәгыренне үтмәс пычак белән кисә дә учлап-учлап тоз сибә.

Инде менә алар өчен Галимулладан соң икенче зур шатлык булып кызлары туарга тиеш. Чынында алар кем дөньяга киләсен белмиләр дә:

—Кызмы? Әллә малаймы?

Монысын бер Алла гына белә, ләкин шуңа карамастан Заһидә үзенекен тәкърарлый:

—Кыз! Кыз!! Кыз!!!

Икесе дә аерымачык белеп-аңлап торалар югыйсә: кызмы, малаймы—һәр икәвенең бере ир белән хатын өчен уртак сөенеч, фәлән исем-атлы шатлык булачак. Хәер...

Фәлән исем-атлы дигәч тә...

Заһидулла тумаган баласына исем табып куйды инде:

—Фәридә...

Әмма бу турыда хәләл жефетенә әйтергә курыкты егет. Юк, Заһидәсе бу исемгә риза булмас диеп түгел, ул анын һәр эшенә диярлек риза, ләкин тумас балага исем кушып ана күз тидерүдән курыкты ул. Һәр өйнең түрендә булмаса да, тупсасында шайтан торыр ди, ул Иблис токымы моны ишетеп хатынына һәм баласына бозым салырга да мөмкин ич.

Инде төнге сөйләшүләргә кире кайтсак, ике сүзнен берендә диярлек Нократның аръягында Заһидулла узган ел салган йорт һәм анда тормыш кору мәсьәләсе кузгалмый калмый иде.

—Каян кергән ул сина күченү корты?- дип сорый Заһидәсе.—Аһ, аһ!

—Канымда ул минем,—ди Заһидулласы ана.

—Канына каян тамган ул күченү тамчысы? Аһ-аһ!

—Бабаларымнан...

—Кайсы?

—Ерак бабаларымнан...

Ул яраткан хатынын ныграк кочаклап ала һәм күкрәгенә кыса да сөйләп китә:

—Синең, Заһидә, безнең бик борынгы төрки бабаларыбызның Кытай чигендә, Алтай тавы якларында, Урхан-Енисәй елгалары, Байкүл тирәләрендә яшәгәнен ишеткәнең бармы? Ә Азак дингезе болгарлары... Менә алар Азия белән Аурупаны бер итеп яшәгәннәр. Җитез-тиз атларында, коштай очып, ерак араларны «ә» дигәнче узганнар. Безнең татарда күченү каны шулардан килә. Әнә Себер татарлары ханының исеме дә Күчем булган ич. Тамыры шул ук күч, күченүгә барып тоташа. Күченү көч мәгънәсен дә белдергән, чөнки авыру-чирле, көчсез-жегәрсез, үз-үзенә ышанмаган, куян йөрәкле адәмнәр күченү өчен үзләрендә көч таба алмаган...

—Малмыж мулласы васыятенә тугры калып, мәктәпкә эшкә күч син, акыллым,—ди хатыны анын бит очын үбеп.—Аһ-аһ!

—Каян керде әле бу нәрсә башына?—дип аптырый ир.—Мин бит аны сина кайткан көнне генә сөйләдем ич. Бәлки мактанасым да килгәндер. «Кеше сине мактамаса, үз-үзеңне макта—дөньяга кирәклегеңне ныграк тоярсын»,—диде ул мина.

—Менә мин дә сине мактап әйтәм ич. Әнә бит ничек матур сөйләдең күченү турында.

Һәм алар тынып калалар. Һәркем—үз уенда...

* * *

Заһидулла төрмәдән кайтып, бер ай тирәсе узуга, дөньяга чын мәгънәсендә кыш килде. Анарчы, сирәк-мирәк кенә карларын күрсәтеп, сәлам хаты гына язып торган Кыш бабай үзенең барлык вә бөтен галиҗәнаплеге белән, берничә ай сездә булам дип, килде дә төште. Кунакка гына, билгеле. Хәер, мәнге ни бар? Һәрнәрсә вакытлыча. Хәтта таулар да калкалар, баталар...

Дөньяны тоташ аклык басты.

Агачлар ак тун киделәр. Мич башларыннан киез итекләр төште, сәке астында иске әрҗәдә яткан йон бияләйләр үзләренең нәни төрмәләреннән чыкты, сандыклардан жылы кием, мамык шәл, бүрекләр күтәрелде.

Кошларның тавышлары кими төште, алар көньякка очтылар, чыпчык-песнәкләр дә үзләрен туйдагы яшь килендәй тыныч, сабыр, хәтта оялчанрак тота башладылар. Мәчеләр өйгә елышты, этләр—үзләренең ояларына...

Елгалар боз-кием киделәр, күлләр читтән караганда бинихая зур боз-көзге иделәр. Тора-бара аларны да ак кар каплап алды.

Тереклек жәйге яшәү рәвешеннән чыгып, аның Олуг Йөрәге сабыррак, иплерәк, әйтергә кирәк бераз салкынрак та тибә башлады. Менә шул чакта...

Менә шул көннәрне Заһидулланың йөрәге кинәт кенә ярсуланып китте, тамырларындагы кан тынычсыз, ниндидер ташкын елга кызулыгы белән ага башлады. Монарчы аны болытлы сүрән көннәр, пычрак юллар, көзнең үзенә күрә бер кыюсызлыгы тотып килсә, Нократ өстен боз каплауга, жаны үтереп аръякка, андагы урманга, үзе салган йортка һәм якын дусты керәшен Чәпчим Мәкчимгә тарта башлады. Ул үзен өендә читлектәге бүредәй тотты, бәргәләнде, суккаланды, өенә керсә—йортта,

ишегалдына чыкса—анда үзенә урын тапмый башлады. Нечкә күнелле Заһидә дә моны сизенде һәм бу чарасызлыкнын, үз-үзенә сыя алмаунын ахырын тыныч кына, татар хатыннарына хас булган олпат бер сабырлык белән көтә башлады. Анын өчен ин авыры иренен тагы Нократ аръягына китүе—күченүе түгел, ә ике арада низаг-тавыш, бер-беренә салкынаю, мәхәббәт учагында пыскып яткан күмерләр генә калдыру иде. Әгәр шул хәлгә тарсалар, бу йорт беркайчан да Мәхәббәт Чатыры була алмый инде...

Хатын әкрен генә күзәтте. Менә Заһидулла келәттән чангыларын алып чыгып, аларнын каешларын ныгытты, табан асларын нәрсә беләндер майлап куйды. Аһ-аһ!

Әнә чормага яшергән мылтыгын алып төшеп, патроннарын карап, кин бил каешына тыгып куйды. Мылтыкнын үзен бик ыхтыматлап чистартты, аннан, борын астыннан ят бер көй шыншып, бернича мәртәбә сөрткәләде. Теге жырунын кушымтасын, кабатланып килгән сүзләрен генә колагына элә алды Заһидә. Ул болай иде:

> Коелардин су алганда,
> Төшеп калды чиләгем.
> Дөнья безгә—ачы миләш,
> Кемнәр каба жиләген?..

Тагы...

Карават астыннан биштәрен тартып чыгарып, анын эченә шырпы, тоз, кечкенә балта, кәрәчинле савыт, бер-ике китап салып куйды. Бүреген, бияләйләрен, итеген, тунын, эчке жылы киемнәрен караштырды. Күпмедер уйланып йөргәч, көзгесе белән кырынгычын алды, шулар янына сабын өстәргә дә онытмады.

—Жә, жарар! Життеме инде?!—дип чүт ычкындырмады хатын. Ул шулай жикерүле тавыш салса, күкләр ишелер, колак пәрдәләре ертылыр кебек тоелды үзенә. Әмма ул һаман да сабыр иде. Аяз мулла белән Асыл абыстай тәрбиясе нык сизелә иде әле яшь хатында.

Көннәр уза торды, агымсудай ага бирде...

Алар сүзсезләнделәр, бер-беренә дәшү өчен ипле-жайлы бер сүз таба алмадылар. Йоклаганда күкрәкләр күкрәккә терәлмәде, аркалар гына бер-берсенен жылысын тойдылар. Юк, мәхәббәт учагы сүнмәгән иде әле. Заһидулла, дәрте булса да, дәрмансыз карт кебек лышма ята бирде, Заһидә, теләге көчле булса да, күремле чагы кебек, үз-үзен йозак-тотанакта тотты.

Хатын чи утын ягылган мунча миче сымак сүрәнләнә төште, ир гайрәте авызлыклы йөгән кидерелгән сыман ничарадан бичарага әйләнде. Берсе үзен кышларга калган кошлар кебек тотса, икенчесенен йөрәге көзен зәнгәр күкне тутырган кара каргалар кебек «кар-кар» килде, чыгымлады, шашты, жаны белән болытларга ашты:

—Китәм... китәм... китәм...

Заһидулланын йөрәге Сабантуен көткән чабышкыга әйләнде. Ул ничектер сузылып китте, йөзе сула төште, нигә генә тотынса да, кулы пеште. Ин аламасы—өй эшенә жаны жансыз карады.

Бер иртәнге танда, тибеп уяткандай, сикереп торды. Өстәл янына барып утырды. Бер чүмеч салкын суны голт-голт китереп эчте. Гүя эченә бер вагон утлы күмер аткannap.

Тәрәзәләр кара иде әле. Күктә йолдызлар жемелдәде. Аларнын һәрберсе йодрык-йодрык...

Ул шундук хатынынын да уянганлыгын анлады:

—Тынла әле, Заһидә чибәрем...

—Анлыйм... Аһ-аһ!

—Нәрсәне?

—Нократ аръягы тарта сине...

—Мин бит бөтенләйгә түгел.

—Анысын бер Алла гына белә...

Икесе дә тынып калдылар...

Өйдә шомлы тынлык иде. Мич башыннан ата мәче Котсыз сикереп төште. Караңгыда, кара йоннары белән һич тә шәйләнмичә генә килеп, йорт хуҗасының аягына егылды. Ә күзләре! Елык-елык... Җенмени...

Заһидулла аны чүт тибеп очырмады:

—Йөрисең монда!

—Тимә мәчегә, аның монда ни гаебе бар? Онытма, мәчене пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам дә бик яраткан!

—Беләм...

—Кил, ят тагы бераз...—диде хатын назлы гына.—Ah-ah!

Ир аңлады...

Алар тын гына бер-берсен сөештеләр, түшәкләрендә яратыштылар...

—Кит!—диде хатын ачыргыланып.—Ah-ah!

—Кума! Һы!

—Куарга, син—минем ирем, тагы бу өй—сина атаңнан калган йорт.

—Йортта синең дә дәхелең бар...

—Алайга калса, улымныкы да...

—Галимулла—икебезнеке дә!—диде Заһидулла кистереп.

—Икебезнеке дә...—диде Заһидә ризалашып.

—Аңла, гүзәлем. Җаным тарта минем шул якка. Аннан соң... Вакыт-вакыт мин үземне аңламыйм менә... Минем нигәдер ялгыз гына каласым, башыма тулган уйларны тәртипкә саласым килә.

—Алай булгач, ник өйләндең? Яшәргә иде буйдак булып. Ah-ah!

—Һы!

—Хатын кирәк идеме сиңа, ә?

—Сине ратканга өйләндем мин. Теге чишмә янында очрашкач, үземә тынгылык таба алмадым, көн-төн синең турында гына уйландым...

—Ә Мәхәббәт Чатыры? Син аннан качасыңмы?! Ah-ah!

—Юк,—диде ир, аны тынычландырырга теләп.—Мин вакытлыча гына китәм...

Шул сүзләрдән соң Заһидә аның күкрәгенә капланды да рәхәтләнеп бер елады. Ә күнеленнән генә: «Язмышым шулдыр»,—дип уйлады.

* * *

Аh, бу фани дөньяның гүзәллеге!

Бакча артлап кына, авыл очына чыгып, Нократ елгасына илтә торган үзәнлеккә төшүгә, Заһидулланың күз алдында сихри кышкы манзара ачылды: әнә ул тигез кар түшәлгән жан-елга, сул якта—Бәләкин утравы, унда, астарак—Кәримулла атавы. Ул да утрау, елы-елы белән яр белән дә тоташа. Нократның каршыдагы текә ярында урман шаулый, ул шулай ерагая барып, офыкта зәңгәр төс ала. Бу якта таллыклар, эреле-ваклы күлләр. Заһидулла ул күлләрнең күбесенең исемен белә: Олыкүл, Комаяк, Камышлы, Түгәрәккүл, Чуртанлы, Тауасты күле, Торфлы күл, Чишмәкүл, Мәгъсүм күле, Сергей...

Һәр күлнең исеме—аның паспорты. Шуның өстенә нинди шигъри исемнәр! Ну, исем куша белә дә инде безнең халык...

Әнә авыл каршындагы текә тауның исеме—Ярмәкәй. Матур исемме? Хәйран! Әле ул тауның үз легендасы да бар. Имеш, бик-бик борынгы заманда бу урында бер Алып, хәл-көч җыярга утырып, калып-чабатасын каккан. Шуннан икән бу тау-шау. Шулай сөйли бит халык...

Ә аръяктагы болыннарның исемнәре: Озын бот, Зур болын, Өчпәвер, Тугыз, Мурзиха, Каеннар асты, Дулкын, Чуар, Күкре...

Эх!

Бу исемнәр, тирәнгәрәк кереп уйлансаң, үзләренең мистик көче, эчке җегәре белән сине аяктан ук егарга мөмкиннәр. Ләкин... Юк шул!

Алар сине аягына бастыралар. Мәтә, Өчпәвер елгаларына аяк басасын килә, Кәҗә, Зинкә үзәннәрендә йөрисен килә. Ә Кызылъярдан төшеп Нократка кармак салсаң, ә?

Эх! Эх!!

Патшалар яшәр як ич бу!

Урманында—киеге, күгендә—очар кошлары, күлендә—беләк буе балыклар. Чит илләрдә әнә форель дип авыз суы корталар, бездә гап-гади керкә генә ич ул. Көтүче Башкорт Гаязы кебек беркатлы, ачык, талымсыз балык ла ул.

Эх! Эх!! Эх!!!

Яшәргә иде шушы табигать кочагында берүзең рәхәтләнеп, кәеф-сафа корып, чишмәләреннән суын эчеп, Сарапул күленнән балык тотып, көз-кыш кыр үрдәкләре, куян, төлке аулап. Аларын да кирәк кадәрле генә...

Ә бит урманнарга килеп керсәң, андагы шомырт, миләш, чикләвек куаклары. Җый да аша, өзеп ал да кәрҗинеңә сал. Җәйнең җиләкләре! Болында җир җиләге, каен җиләге, урманда мүк җиләге, кура җиләге, бөрлегән, карлыган, нарат җиләге. Җый да—как кой! Ә гөмбә? Әнә безнең татар гөмбә җыймый. Җыяр иде—тәмен белми. Заһидулла Мәкчимдә ашады бит—гөмбәсе артыннан теленне дә йотарлык. Татар урманга күз керсә, ак гөмбәне, каеннныкын, наратныкын һәм башкаларны битараф рәвештә таптап кына йөри. Ә бит Мәкчим әйтүенчә, ашый торган гөмбәләр генә безнең урманнарда уннан артык. Һәр гөмбә үзенә күрә нәни бер гөмбәз булып утыра. Әле ул Казан урамында яңгыр көнне зонтик күтәреп чыккан ханымнарга да бик охшаган. Әнә шул бер «зонтик» артыннан тагылып та китте бервакыт Заһидулла. Марҗага нәрсә, көчле-куәтле, гайрәтле, армас, дәрт-дәрманлы татар икән, зонтигын да ташлый, чишенеп тә ата, кирәк урынга барып та ята...

Һәм:

—Скачи, скачи мой конь!—ди.

—Һы!

Ә Тамара?

Их, Тамара, Тамара!

Үтерден син мине! Кайлардан очрадың Чегән Кызы? Әллә Такташ яшьтәш әйтмешли:

> Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
> Утлы кызыл гөлләр тотып кулларына,
> Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да
> Ник яшрендең, төренеп таң нурларына?

Их, Такташ, Такташ! Бөек яшьтәш, Син дә юк бит инде бу фани дөньяларда. Кинәт киттең, серле киттең, иртә киттең...

Ул шушы уйлары белән Нократ елгасының текә ярына килеп төртелде.

Һы!

Ничек кызу киленгән! Яхшы ат та болай чапмас...

Заһидулла чаңгыларын салды да, биштәрен, мылтыгын аркасында элгән килеш калдырып, текә ярдан өскә үрмәләде. Менеп житүгә үк: «Ах!» ымлыгын гына эшкә жикте. Юк, арганга яисә каты мышнаганга түгел, ә шушы якка аяк басканга. Изге урын бу. Әнә ул кискән зирекләрдән калган кызыл төпләр. Алар инде башларына кар-бүрек киеп утыралар. Менә теге таныш сукмак та. Бу урынга Биектау урыслары юлны өзмиләр икән әле. Алар балыкчылар бит, битель куя торганнардыр. Ә Мәкчим?

Их, Чәпчим Мәкчим!

Тавык тәпие таккан керәшен. Өзелеп сагындым мин сине. Син бит миңа дәү абыем кебек. Әле сине мактап Малмыж мулласына да сөйләгән идем. Ә ул мулла—әүлия кеше...

Шулай үзалдына уйланып, вакыт-вакыт юләрләнгән кешедәй үзе

белән үзе сөйләшеп, Заһидулла урман аланындагы өе янына якынлашты. Ни сәбәптер, аның аяклары киң табанлы авыр чаңгыларны сизмәделәр дә. Гүя аучы чаңгылары үзләреннән үзләре шуып баралар иде.

Менә теге кара еланны үтергән урын...

Әнә, әнә...

Әйе, Тамара белән очрашкан изге нокта...

Их!

Тылсымчы идең мәллә син гүзәл чегән кызы?! Син бит мин беренче күргәндә убырлы карчык идең: ат йөз, сыер гәүдә. Өстеңдә әллә нинди ни ирләрнеке, ни хатын-кызларныкы булмаган катнаш кием. Мин бит сине хөнса (гермофродит) дип уйладым: тегесе дә, монысы да бар, шул ук вакытта анысы да, бусы да юк. Мин күлдән кайтуыма, син әллә нинди адәм ышанмаслык гүзәллеккә ирештең. Ничек? Ни көчләр булышты сиңа? Кемнәр үзгәртте сине шулай? Җеннәрме?

Уйлар куерган саен аяклар ныграк юырта иде. Алда ак куяндай ак кар. Як-якта бөерләренә таянып мәгърур, шәм кебек наратлар карап тора. Бер агачтан мендәре белән кар ишелде. Тиен! Бары ишкәк калагы кадәр коерыгы гына күренеп калды.

Иренеп кенә ябалак кар ява башлады. Каян әле бу? Кояшлы көн иде ич. Әнә кар бөртекләре ишеләләр дә ишеләләр. Һәр бөртек—бер ак күбәләк...

Заһидулланың өс-башын нәни генә кар капламы басып алды. Әллә йөрәге кайнар, тәне эссе булганга, ул карлар акрын гына эри дә башладылар. Нигәдер тундыргандай итте. Менә кызык: үзе кыза, үзе туңа...

Ул урман аланына барып чыкты. Менә аның йорты. Ул нәкъ Тамара белән икесе төн уздырган куыш урынына төзелде ич. Көлгә чыккан куыш урынына. Ут йоткан шалаш урынына...

Ба-а!

Ишеккә аркылы суккан киртәне каерып алганнар икән. Ачылып китмәсен өчен шул ук киртә белән терәтеп куйганнар. Кемнәр йөргән монда, ни адәмнәр кергән аның газиз йортына?

Ул чаңгыларын өйнең тәрәзә ягына бастырып куйды да ишекне ачты. Суык, шыксыз, әллә нинди шөбһәле монда. Бала йоннарың тырпаер!

Идән пычак белән кырып та бетермәслек булып пычракка баткан. Өстәл өстендә ялгыз калай кружка, суган кабыклары, ипи валчыклары. Тәрәзә төбендәге бер сынык икмәкне черек, зәңгәрле-сарылы күгәрек чолгап алган. Монда калдырылган пәке, калай савыт, аш калагы, татарча газеталар һәм ике китап каядыр юкка чыккан.

Кинәт аның күзләре стенага төште:

—Мать твою!

* * *

Хәятта кешене ике нәрсә яшәтә: яшәү теләге, яшәү ихтыяҗы. Яшәү теләге белән яшәү ихтыяҗын бервакытта да бутарга ярамый. Беренчесе, тумыштан бирелгән, ул—инстинкт, ул—җанга салынган. Икенчесе, тормышка анлы рәвештә җайлашу, табигать биргән, кешелек җәмгыяте оештырган-төзегән мөмкинлекләрдән иркенләп яисә яртылаш кына файдалану. Ул—шартлы рефлекс.

Заһидулланың яшәү ихтыяҗы яртылаш кына иде һәм ул бу ягы белән күбрәк кыргый бабаларына, борынгы заман кешеләренә тартым булды. Ул күбрәк табигать биргән мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышты, ә җәмгыять—бигрәк тә октябрь инкыйлабыннан соң төзелгән яна тәртипләр!—оештырган мөмкинлекләргә нәфсе күрсәтмәде, киресенчә: аларны кеше иреген чикләү, хәтта көчләү буларак кабул итте. Дөрес, ул үткен зиһене, анык аңы, ата-бабалардан килгән акылы вә Казан мәктәпмәдрәсәләрендә алган шәп кенә белеме белән дәүләт төзелешенен дә,

хөкүмәт оештырылышларынын да кирәклеген анлый, мона риза, шулай тиешле саный. Ләкин...

Кеше дәүләт өчен түгел, ә дәүләт ил гражданнары өчен яшәргә тиешлеген борынгы грек фәйләсуфлары ук әйткәннәр ич инде. Мәсәлән, бөек Аристотель...

Бер уйлаганда һәркем—үзе бер дөнья, анын йорты—үз патшалыгы ич. Чит монастырьга үз кануннарын белән йөрмиләр, диләр урыслар.

Ә монда...

—Мать твою!—диде Заһидулла аһылдап.

Чөнки...

Ул үзе төзегән йортнын бер стена почмагына кемдер кечкенә генә төссез вә шыксыз Икона (???) элеп куйган иде.

—Мать твою! Матерь божья!

«Мәрьям-Ана»,—дип уйланды Заһидулла—Аны миннән рөхсәт сорамый гына керәшен тәре элеп куйгандыр. Ну, муенына тавык тәпие аскан нәмәрсә! Вәт жык! Синен күнелен ачык кебек иде ич. Анын мин белмәгән карангы почмаклары да бар икән ич әле. Ярый-ярый, Чәпчим Мәкчим. Үз кулын белән элден—үз кулын белән алдырам мин синнән иконаны. Чөнки бу—миннән көлү. Мин бит синен маржалы өендә Коръән калдырып китмәдем. Сина Икона изге икән, мина—Коръән, чөнки һәр татар туганда ук мөселман булып туа. Тумас иде, ата-бабалары Ислам динен тотканнар.

Шушы ярым ачулы, ярым әрнүле уйлары белән ул мич аралыгына керде һәм, аннан каен тузы, чырагач, аз гына калган утын алып, мичкә ягып жибәрде. Чырагач чаерысыннанмы, әллә каен тузы каты төтенләде, мич торбасы тарта алмый азапланды, өйгә төтен тулды. Ул ишекне тибеп кенә ачты да өй янындагы әрдәнәдән бер кочак утын алып керде. Керсә, төтен сирәгәйгән, мич эчен ут алган. Юк, ялгышкан икән, бу арада кемдер мичкә яккан, әнә әрдәнә дә яртылаш кимегән. Ә ягылмаган мич башта озак кына төтен тарта алмыйча тончыгып маташа ич.

Шуна карамастан, анын сизгер күнеле тынычлана алмады, ул эчке хис-тоем белән нindidер авыр бер яналык, киеренке хәл көтә иде. Баш миендә—сораулар: «Кем йә нәрсә бу? Ни көтә аны? Нишләп анын үз куллары белән төзегән йортына хужа итеп йөриләр? Кемнән сорап? Бу бит... Бу бит Казанны басып алган Явыз Иван кимәлендәге адәм... Гамәле дә шул Иванча...»

Ул шул уйларда, утын өстәргә теләп, мич каршына чүгәләде...

Йә, Алла!

Анын китаплары...

Әнә гәжит кисәкләре...

Заһидулланын йортына басып кергән адәмнәр анын китапларын, гәжитләрен утка якканнар ич! Алланын каһәре төшкереләр!

Анын күзләре яшьләнде...

Нигәдер ул Малмыж мулласын искә төшерде. Мулла әйтте ич ана: «Син,—диде,—Заһидулла, тарханнар нәселеннән. Синен нәсел-нәсәбәндә морзалар, муллалар ята. Жидәннәр сибыты—укымышлы кешеләр.

Заһидулла каһкаһә белән көлеп жибәрде:—Йә, тархан, китабынны яктылармы? Нәселен китап укыган әнә... Йә, морза, гәжитсез калдынмы? Ата-бабаларын инкыйлабка кадәр үк гәжитсез яшәмәгәннәр... Йә, укымышлы, 1928 елны, гарәпнекеннән латин графикасына күчереп, Мәскәү агайлары синен ата-бабаларын мен ел буе язган «әлифба»дан аердылармы? Әле анарчы да болгар бабайларда рун язуы да булган...

«Менә син үз алдына кечкенә генә яшәү ихтыяжы куйдын: күмхужга кермичә, Идел аръягында йорт салып, үз гаилән, ишле балаларын белән аерым тормыш алып барырга. Мона ин беренче, күмхужчылар һәм диварга эленеп куйган, үзенә кумир итеп Явыз Иванны сайлаган Сталин каршы төште. Сине зинданга яптылар, юеш таш идәндә яткырып, кыйнап-мәсхәрәләп жәзаладылар. Ин каһәрлесе—жанынны газапладылар. «Мин!»—

дигән горурлыгыңны изделәр, Рух утыңа суык су сибеп, тезләндерергә теләделәр, куркак—өркүчән мәхлук җан иясе, гади бер алаша—эш аты ясарга омтылдылар...

Йә, әйт, Заһидулла! Беттеңме син, изелдеңме? Горурлыгыңны җуеп, тезләндеңме?! Шулай икән, бар, кайт күмхуҗга, кач моннан! Күмхуҗда сине алашалык көтә...»

Ул шул уйлары авырлыгыннан башын түбән иде, күз төпләренә дым инде...

Шулвакыт аңа кемдер дәште:

—Че плачешь, мой татарский конь?!

Ир сискәнеп китте. Аны күпмедер эчке курку биләп алды: «Кем бу? Каян ишетелә бу назлы вә якын бәгыреңне телгәләр таныш һәм иркә тавыш?!»

Ул кинәт өшәнеп куйды, тәне җыерылды, куркуданмы, әллә болаймы, тез башлары калтыранды. Калтыранырсың да...

Тавыш...

Әйе, та-вы-ышш...

Идән астыннан килә иде.

Йә, Алла!

Тамара бит бу! Аның тавышы, шуңа «назлы вә якын», шуна «таныш һәм иркә» ул.

Һай, таныш тавыш!

И, көннәрен дә, төннәрен дә Заһидулланың күңел мөнбәрендә ап-ак күлмәктән, муенындагы алтын чылбыры белән илаһи бер гүзәллеккә тиң булып утырган Чегән кызы! Сөйгәнем, шаштырганым, акылымны югалтканым, мине чарасыз иткәнем, дөньяның иң хәйран хатыны Заһидәгә өйләнсәм дә—төннәрен арага кереп ятканым! Йолдызым-Кояшым! Күзләремне камаштырганым...

—Ай-яй, хәйләкәр Тамара! Син минем йортка—Мине! -эзләп килгәнсең. Әнә стена почмагына Мәрьям ананы элгәнсең. Шулай да ачуым бар сиңа: нигә инде минем китапларымны, гәҗитләремне утка яктың? «Подтопка» дидеңме Пәри Кызы?! Әнә ич мич аралыгында каен тузы. Чык аннан!

Ул баз капкачын ачты...

* * *

Тышта кемнәрдер сөйләшә иде...

Моны ул ап-ачык ишетте. Сөйләшү рус телендә бара. «Инде болай булгач,—дип уйлады Заһидулла.—Тавыш тыштан килгән. Ә нигә соң ул баздан ишетелгән күк булды, ә?!»

Тышта тавышлар:

—Нинди кош очып килгән әле безнең өйгә?—диде гөбе тавыш.—Кара, мич яккан! Өе парахутмыни...

Һы!

«Безнең өй», имеш,—дип уйларга өлгерде Заһидулла.—Өем—парахут, кар диңгезендә төтенләп бара...»

—Ә бәлки бу өйнең хуҗасыдыр...—монысы утын кискәндәге пычкы тавышы иде.

«Хуҗасы!»—дип уйлады Заһидулла, нигәдер үз-үзеннән бик тә канәгать рәвештә. Хәтта... киң күкрәген киереп үк җибәрде.

—Хуҗасымы, түгелме... Безгә торып торырга урын кирәк. Куабыз да чыгарабыз! К еб... матери!—бик каты эчеп, атна буе салкын су белән бугазын юган исерек поп тавышы иде монысы. Бас—ләкин Шаляпинныкы түгел...

—Син үзең, мать твою!.. Безнең әти Гыйбадулла да, урыс сәүдәгәрләре белән аралашкач, аларча сүгенә белә иде. Бер генә сүз: «Ипи—Ана—

Мать!» Әнә шулай ямьсез урыс сүгенүен ул «Ипи һәм Ана, Ана»га әйләндерде, «Ана»ны башта татарча, аннан урысча әйтеп.

Шыксыз каерып ишекне ачтылар һәм өч бәндә, бер-берсен этешеп дигәндәй, өйгә ябырылдылар. Шундук таныды аларны Заһидулла: күзләрендәге шәфкать нурын явызлыкның кара тастымалы сөртеп алган адәмнәр иде болар. Төксе чырай, салкын күз, усал караш.

—А-а-а!—диде әзмәвер шундук Малмыж төрмәсен хәтерләп.—Старый знакомый! Ну, вот попался! Мир тесен...

Нечкә озын эндәшмәде, нидер уйлап бер адым артка чигенде. Аның йөзенә курку йөгергән иде, ул арттан иелеп әзмәвернең колагына нидер пышылдады.

—Не может быть?!—диде тегесе.

—Он самый...

Өченчесе дәшмәде, ләкин ул кесәсеннән акрын гына пәке тартып чыгарды. Таныды Заһидулла: әлеге пәкене ул шушында, тәрәзә өстендә калдырган иде. Каян тапканнар? Димәк, өйне һәр карышлап актарып чыкканнар болар.

—Слушай!—диде әзмәвер, җыерчыклы күз төпләрен угалап.—Син теге вакытта Тамара куышында нишли иден? Безне күрдең дә шыр җибәреп урман ешлыгына чумдың...

—Берни эшләми идем...—диде Заһидулла тыныч кына һәм күз кыегы белән генә стенага эленгән мылтыгына күз төшереп алды. Ул теге вакытта, Тамара куышыннан чыккач, үзен күпмедер танып калганнарын аңлап алды. Бигрәк тә әнә теге кылый—озын сыйрак!

Пәкеле күбенгән, имән чикләвеге ашап симергән дуңгыздай, ак керфекләрен бер күтәреп, бер төшереп, гамьсез бер караш белән ана карап тора. Аның нигәдер сул күз кабагы туктаусыз тарта, җаенке иреңенә пычрак елмаю, мыскыллы көлемсерәү эленгән. Юан булса да, ул һәр икесенә караганда калынрак киенгән. Пәкеле кулын, акчасын яшергән комсыз бәндәдәй, артына куйган.

«Суячаклар болар мине, һич тә уйламый дуңгыз урынына акыртып суячаклар...»—дип уйлады Заһидулла кинәт тәшвишкә төшеп. Ә Аңы тәртиш ясый иде: «Кул белән бергә-бер... Курыкмыйм мин алардан... Казан ханлыгына нигез салган Олуг Мөхәммәд хан кебек... Ул ун мең яугире белән дошманның йөз илле меңлек гаскәрен пыран-заран китергән, сугыш кырын ташлап качарга мәҗбүр иткән...»

Дөрес, бу уйлар аның башыннан бер мизгелдә уздылар. Тагы да дөресе, аның күп уйланып торырга да вакыты юк иде инде...

Мылтык корулы түгел. Ләкин...

Корылмаган мылтык та атарга мөмкин. Куркаклар йөрәгенә... Теге вакытта, Малмыж төрмәсендә күрде ич ул аларның кем икәнлеген.

Ул тиз генә артка ыргылып, стенадагы мылтыгын алды:

—Не подходи, убью на месте!

Тегеләр, сискәнеп китеп, бер мәлгә шыр җибәрделәр. Шүрләүләре йөзләренә үк чыккан иде. Ләкин бер мизгелгә генә. Шушы тәүге мизгел узуга, алар битенә аптырашка калу кунаклады, бары Кылый Күз генә куркудан арына алмый иде.

—А ну, ребята!—диде Әзмәвер.—Окружай яво с разных сторон. Убьет одного, но мы яво явно изжарим...

Теге Озын Сыйрак кына ишек төбендә калды, Әзмәвер белән Күбенгәне ерткыч карашы белән аңа таба сак кына атлый башладылар. Менә бер адым. Ике, өч... Хәзер инде алар бер-берсен ап-ачык ике адым арадан күрәләр иде. Заһидулланың чырае качкан иде, бары аяк асты мускуллары тартыша да, яңак сөякләре шыкыраеп, тимер булып каткан, Әзмәвер йөзендә иман-нур, шәфкать-миһербан күренми. Сизелеп тора: Малмыж төрмәсендәге кыйналуы өчен кичермәячәк ул аны. Шунамы, әлеге хәсистән кан исе генә аңкый.

Дуңгыз Керфек тә үч алырга җай чыкканын сизенә, ә болай нидер-

нәрсәдер бирсәң яисә бүләк итсәң, ул «мокрое дело»га, ягъни үтерүгә кадәр үк бармаска разый кебек. Аның йөрәгенә уч-ачу, гыйбрәт-мыскыл булып җыелганы төрмә камерасында Заһидулланың бот арасына тибеп аударуы да түгел (Аллага шөкер, ул «прибор»ы да исән калды), ә Малмыж мулласының нәҗесле түбәтәйне йөзенә кидереп куюы иде:

—Ну, молла! Менә хәзер минем кулда булсаңмы? Ми-ин си-ине! Үз нәҗесеңне үз йөзенә капласыннар әле...

Дуңгыз Керфектә теге икесендә булмаган бер хәтәр сәләт тә бар иде. Ул—алдан сизенү, интуиция, хис-тоем. Менә шул алтынчы тоемлау аны иң авыр хәлләрдә дә һәрвакыт коткарып килде. Үзен генә түгел, иптәшләрен дә...

Гражданнар сугышы елларында, Биектауга аклар кергәч тә, ул, иптәшләрен дә әйдәкләп, авылда «Кремль» дип йөртелгән янгын сарае каланчасына менеп качты. Юкса... Атачаклар иде аны. Ул бит шул аклар арасындагы штабс-капитанның әти-әнисен көпә-көндез талап чыгып киткән иде. Талавы бер хәл инде: карчыкны карты алдында кочләде бит. Тик шулай да берсен дә үтермәде, исән калдырды...

... Менә хәзер дә ул Заһидулланың мылтыгы корулы булмавын сизенгән бердәнбер кеше иде. Әзмәвергә нәрсә ана, ул бит тун маңгай, үгез кебек теләсә кая бәреп керә дә—кирәксә дә, кирәкмәсә дә сөзә башлый. Юк өчен дә кеше үтереп китүдән дә чирканмый, гомумән, чебен ни ана, бәндә ни...

Дуңгыз Керфек Заһидуллага каш астыннан гына карады да ярым пышылдап, ярым кычкырып катгый гына әйтеп куйды:

—А, ну-ка, ружье на стол!

—Не подходи, убью!

—Оно у тебя не заряжено...

Аңнып китте Заһидулла, ләкин ни дип әйтергә дә белмәде. Әллә шундук аны томаланды инде.

Ике як та, Мамай белән Дмитрий Донский гаскәрләре кебек, сихри томан эчендә сүзсез калып, бер-берләренә күз терәшеп тордылар. Ләкин бу киеренкелек болай каткан килеш озак торачак түгел иде. Нервылар, нервылар. Менә алар шартлап өзеләчәк, көл киләчәк...

Әзмәвер белән Дуңгыз Керфек аңа таба соңгы адымны атладылар. Аралар—кул сузымы гына...

Шулвакыт...

* * *

Адәм баласының яшәве һәм үлеме бер мизгел, бер мыскыл арасына сыенган була, гүя ул Вакыт дигән дәһшәтле көчнең күз ачып йомуга тиң нәни уч төбендә утыра. Сыйдыңмы күз ачуга—син исән... Күз йомуга калдыңмы, әз генә җитешмәдеңме—син инде тереләр арасында юк.

Тегеләр белән ара кул сузымы гына калгач, Заһидулла моны бигрәк тә нык тойды, аңлады, сиземләде...

Төрмәдә ул көч-куәте, сугышырга маһир булуы өстенә кәтелмәгәнлек, кинәтлек, бер һәм берәгәйле итеп беренче сугу, ярсучанлык ыргымына һәм хис-тоемына таянса, менә хәзер шул өстенлеге юк иде. Чөнки дошман аннан кыйналып тәҗрибә алды инде. Ачы тәҗрибә! Ә иң бөек һәм камил тәҗрибә җиңеп түгел—җиңелеп, кыйнап түгел—кыйналып алына. Уяулык, сак булу, хәйләкәрлек—болар барысы да каты җиңелү балалары. Дөрес, алар арасында куркаклык та бар. Ләкин ул хәзерге минутта Озын Сыйракта гына күренә. Ә теге икесе Ачы Тәҗрибәнең көчле, акыллы, хәйләле балаларына таянганнар...

Ике ара кул сузымы гына...

Күзгә-күз, йөзгә-йөз тору бу...

Божра кысыла кила, Заһидулла үз муенында элмәк-бауның ачы салкынын, кытыршы гыклыгын, тынны кыса торган тартылыш-кысылуын да тойды...

Менә хәзер...

Шулвакыт...

—Эй, прекратите, друзья!—дигән үзе тыныч, үзе усал тавыш ишетелде.

Чәпчим Мәкчим!

Әйе!

Ярым ачык ишектә аның мылтыгы һәм... гәүдәсез генә башы иде. Менә гәүдә дә күренде һәм Мәкчим, искиткеч кызулык белән, Салам Сыйракны көлтә урынына селкеп, тышка очырды.

—Ты, крещеный?!—диде Әзмәвер ана карап һәм тәрәзә ягына таба чигенеп. Аның күзләре усал елтырады. Менә аларны кан басты:

—Ты че? Против нас?! Ты, крещеный! За этого мусульманина что ли? За татарина?!

—Да, я крещеный,—диде Мәкчим.—Но я татарин! И этим горжусь!

—Татары!—диде, акырып Әзмәвер һәм ул тагы ярты адым артка чигенде.

—Да, я вас уничтожу! Сотру в порошок!

Ул алга ыргылам дип, жайсызрак янга атлады һәм икенче бер секундта юкка чыкты...

Шул арада Заһидулла, мылтык сабы белән сугып, Дуңгыз Керфекнең пычагын бәреп төшерде. Үзенең аугa йөри торган пычагын.

Ә арттан Чәпчим Мәкчим чакырылмаган «кунак дуңгыз»ның аркасына үзенең мылтык очын терәгән иде. Заһидулла иелеп, кинжалын алды да һәр сүзенә басым ясап, Тәре Керфеккә әйтте:

—Еще раз встречу в моем доме, как свинью зарежу!

«Дуңгыз»ның күз кабагы ныграк тарта башлады, үзе чәй чынаягы кадәр акай күзләрен шап-шоп йома иде.

—Убирайся!—диде Заһидулла ана.

Чәпчим Мәкчимнең мылтыгын аркасында тоеп, теге «дуңгыз» ишеккә атлады.

Ачык калган баз тишегеннән «кисекбаш», ялгыз баш күренде. Заһидулла әлеге шыксыз башны кабат аска тибеп төшерде. Ачык калган базны япты да, теге «баш» аңына килгәнче, баз капкачын кадаклап та куйды. Кадаклар—тәрәзә төбендә, балта эскәмиядә генә иде.

Ул арада ишектә тагы Мәкчим күренде.

—Мәкчим абый!—диде Заһидулла сон дәрәҗәдә дулкынланган хәлдә.

—Чәпчим Мәкчим!

—Кил әле кочаклыйм үзенне...

—Мин дә бик сагындым сине, карендәш!

И, туганым! Чәпчим карендәш... Чәпчим туган...

Алар абый белән энесе кебек беркавым бер-берсенә елышып тордылар. Бер кавем кешеләре ич! Диннәре генә...

Хәер...

Алай дисән, икесе өстендә дә Бер Алла... Аңа тегеләй дә, болай да ышанырга, иман китерергә, кодрәтенә баш иярга, Рәхимлелек һәм Рәхмәт иясе диярга мөмкин. Иң мөһиме: барлыгына ышану-инану...

Теге Башкорт Гаязы әйтмешли:

—И-и! Җегетләр... Инәгезне... Башкортмыни мин, типтәр ич. Менә хатыным Җомабикә—чын башкорт кызы. Ә мин типтәр инде, шул ук татар. Суңы үз гомеремдә бер тапкыр да һу дигәнем булмады. Хатын башкорт булгач, мине дә башкортка яздылар инде. Маржа булса, урыска язарлар иде. Татарның язмышы шул бит аның...

Чәпчим Мәкчимнең уйнак-түгәрәк күзләре өй эчен тикшереп чыктылар да сорауга әйләнделәр:

—Ә?

—Нәрсә?!—Заһидулла.

—Теге?
—Кем?—Заһидулла.
—Ни?
—Пәри...—Заһидулла.
Кычкырып көлеп җибәрделәр.
—Башлыклары кайда?—дим...
—Төрмәдә!
—Кайсы?
—Баз астындагы...
—Ә-ә-ә...
—Кәҗә-ә-ә...

Мәкчим барып баз капкачын күтәрмәк булды. Капкач селкенмәде дә. Менә аны астан төя башладылар. Сүгенү, мат, янау-чинаулар...

—Чыгарыйкмы?—диде Мәкчим.

—Ихтыярың—бәрәнге...

—Син аны кадак белән йозакладыңмы? Чәпчим, кадак белән?

—Кадак белән...

—Әйдә, воля бирик!—дип куйды Мәкчим. Ул бу кешеләрне күптән белә һәм алардан бераз гына шүрли дә иде.

—Мона воля бирсәнме? Бу бит Галәветдин лампасындагы җен генә түгел. Бу—Иблиснең иң якын туганы...

—Шулай шул!—диде Мәкчим.—Аннан соң без икәү генә, алар өчәү була...

—Бездә—тагы ике мылтык! Без—дүртәү...

—Анысы да дөрес. Ну, болар явызлыкта азау ярганнар. Чәпчим, ярганнар... Бу базда ята торганының тешләрен Мәтби Гөргөрич Ыстакан юкка гына... Шикәр вата торган келәшчә белән... Тешләрен суырды ич! Чәпчим, суырды...

«Карале,—дип уйланды Заһидулла.—Дөнья тар». Аннан Мәкчимнән сорады:

—Болар шул бандитлармыни?
—Шулар...
—Тамара куышына шушылар килде инде...
—Беләм...—диде Мәкчим.
—Һы!

Алар аз гына уйланып тордылар. Сүзне беренче булып Мәкчим башлады:

—Без болай итик: боларны калдырып, безгә кайтабыз да кунабыз. Иртәгәсен күз күрер... «Кич—уй, иртә—эш»,—дигәннәр бабайлар. Ә моны үз иптәшләре коткарсын төрмәсеннән...

Энгер-меңгер төшә башлаган иде инде, тик шулай да агачлар ышыгында бер озын, бер юан бәндәне икесе дә ачык күрделәр.

* * *

Юньсезгә яхшылык эшләмә, начарлык белән кайтарыр, аш атсан—таш атар, ди. Бәндәләрдәге явызлык билгеләре алар туганчы ук ата-бабалары җанында ята һәм алар каннан канга, балалардан балаларга, оныклардан оныкларга күчә бара. Ким дигәндә, җиде буынга кадәр. Явызҗаннан—начар бәндә, яхшыҗаннан—әйбәт адәм туа. Халык юкка гына: «Алма агачыннан ерак төшми»,—димәгән. Әле аның мондые да бар ич: «Бүре баласын күпме бүреккә салсан да—урманга карар».

Чәпчим Мәкчим дә, Заһидулла да агачлар ешлыгындагы ике адәм кисәгеннән берниндн мәрхәмәт, кешеләрчә килешү, бер-беренә юл кую, тормышына кысылмау, башкаларга комачау ясамау көтмәсәләр дә, керәшен, килеп туган алама хәлне бераз җиңеләйтү теләге белән, тегеләргә җилкә аша гына кычкырды:

—Барыгыз, коткарыгыз Иванны! Ул базда... Төрмәдә ята, Баз капкачы кадаклап куелган. Мич аралыгында лом бар...

Тегеләр дәшмәделәр, әмма акрын гына Заһидулла йортына таба киттеләр.

—Пештеле уйнама шулар белән. Барыбер берни пешерә алмассың...

—Сун,—диде Мәкчим.—Алар белән этләшеп йөрүдән дә бер файда да юк ич. Чәпчим, файда юк...

Монысын гына Заһидулла үзе дә аңлый иде, шуна ул дәшмәде.

Чаңгылар Биектау тавы астына килеп терәлделәр. Ике ир, аларны салып, кулларына тоттылар да текә үрне тәпиләрендә яуладылар.

Заһидулланың миен бер сорау кимереп тора иде, шуна ул Мәкчимгә дәште:

—Карале, юләр кеше әйтмешли, ничек син нәкъ вакытында безнең өскә килеп кердең? Ату мина хана иде бит.

—Сун,—диде Мәкчим.—Во-первых, мин Иваннарның синең өйдә кунып ятуын белә идем. Чәпчим, белә идем...

—Шуннан?

—Ләкин бит алар мичкә төнлә генә ягалар иде... Саклык йөзеннән...

—Нинди саклык?

—Сун бит алар Малмыж төрмәсеннән качып кайтканнар!

—Һы!—Заһидулла ымлыгы кышкы һаваны кисте.

—Карыйм, көпә-көндез синең өйдә ут яна. Димәк, бу Заһидулла, дим. Ул кайткан, дим. Во-вторых, шул инде. Чәпчим, шул...

—Өйдә ут янмады минем, мич янды...

—Әнә шул бит инде! Каян күрим ди мин өйдә ут янганын? Моржадан аждаһадай каерыла-бөтерелә кара төтен чыкты.

Шунда сүз өзелде...

Алар шыпырт кына урыс капкадан керделәр дә, караклар кебек шым вә сак калып, болдырга күтәрелделәр. Тегеләр белән бәрелешүдән соң күнелләренә шом кергән иде. Шом керсә, шым буласың...

—Кая югалдың син?—дип, ачуланып каршы алды Мәкчимнең хатыны.

—Мин, Аннушка, иске дустым, аучы һәм балыкчы Захидушка янына бардым. Беләсең бит аның өен... Аръяктан чыгып бирге якта йорт салды...

«Захидушка»,—дип көлемсерәде Мәкчимнең бу сүзенә риза булмаган Заһидулла.

—Захидушка бүген бездә куна, үз өе суык, якмаган,—диде керәшен.

—Ярый, ярый,—диде хатын.—Ә анарчы барыгыз, аттырыгыз мунчага! Ненавижу татарскую вонь...

«Һы! Хо-хо! Әйтте бу,—дип, тагы эченнән генә уйланды Заһидулла.— Бер көнгә күбрәк түгелме соң бу? Әле «Татарье», әле «Захидушка», әле «татарская вонь». Дуңгыз болтушкасы исе белән перегар исе тулган «вонь» сизелми аның борынына...»

Шунда ул өй стенасы буйлап чабып йөрүче бихисап тараканнарны күрде. Үзләре кап-кара, җитмәсә әле мыеклы...

Алар мунчага ашыктылар...

Сүзсез генә чишенделәр. Мунча ифрат кызу ягылган иде. Бер олы чүмеч су салганнар иде мичнең кара ташларына, ап-ак пар күтәрелде. Үзләре дә берәр чүмеч су белән коендылар.

—Ха!—диде Мәкчим.—Әйдә, ин беренче сине чабам.

—Давай!

Заһидулла атлет гәүдәсен ләүкәгә салды, Мәкчим аны котырып чаба башлады:

—Хәзер менә... Түз генә... Бөтен тәненне камыр итәм... Чәпчим, камыр итәм...

Чирек сәгать чабуга, Мәкчим шул кадәрле хәлсезләнде ки:

—Җиттеме, татар? Әллә үлденме?—дип сорарга мәҗбүр булды.

—Өстә, керәшен!

—Нәр-с—әә?

—Ташка су сал, дим...

—Син, ананны корт чаккан нәрсә! Коръәненә кадалган мулла! Синең тәнең тимердәнме әллә? Чәпчим, тимердән...

—Менә шуны чабып, үзең әйткәнчә, бодай камыры яса! Тавык тәпие аскан нәмәрсә...

—Тьфү!—диде Мәкчим һәм, себеркесен ташлап, мунчадан чыгып ук китте. Аннан, кире ишекне ачып, иске бүреген ләүкәгә ыргытты:

—Минем хәл бетте. Тимердән камыр ясап булмый. Калганын үзен чабын...

Заһидулла ташка су өстәде дә үзе һәм үзенчә рәхәтләнеп тагы чабынды. Аннан бүреген салып, тышка чыгып йөгерде һәм, ак кар дингезенә чумып, ак аюдай киерелеп аунады. Аның бу мәленә кызыккан Мәкчим дә карга чумды, Ләкин бер-ике аунагач:

—Әллә-лә-лә, бетте әкәлә!—дип, кире мунча эченә йөгерде. Аның артыннан Заһидулла да атлады. Үз аркасында кыздыручан-кызыксынучан караш тоеп.

—Әйдә, хәзер сине чабам...

—Дабай!

Ташка су салдылар. Кара мунчаның кызуы бетмәгән иде әле. Башына бүрек киеп, татар керәшенне чаба башлады:

—Кызуы бармы, Мәкчим абый?

—Булмаган кая! Чәпчим!

—Эссесе тәненә җитәме?

—Җитмәгән кая! Чәпчим!

Ул тагы пар өстәде:

—Ә хәзер?

—Чәп-чим...

—Менә болай?

—Ай-яй! Чәп-чәп-чәп-чим инде...

—Әйләнеп ят әле...

—Әллә-лә-лә... Калмады хәле!

Мәкчим тагы тышка чыгып йөгерде...

... Ашыкмый гына бик ихтыматлап юындылар. Бер-береннең аркаларын кечерәк бишмәт кадәрле мунчала белән ышкыдылар, юдылар. Бу халәттә алар чыннан да ике туганга бик охшаган иделәр.

Мунчадан кайтканда Заһидулла сорады:

—Мәкчим абый, каян таптың син ул юләр сүзне?

—Кайсы сүзне?

—Захидушка... Чүт кенә закидушка түгел...

—Минем маржа сине шулай атый...

—Һы! Захар дип, үзләренчә әйтсә, яхшырак булыр иде. Хәер, нинди Захар булыйм ди мин...

—Сине ошата ул. Менә шуңа син аңа «душа», «душка»...

—«Душа», «душка» булырга хатының мине белми дә ич. Күрүе дә беренче тапкыр...

—Ана синең хакта икенче бер мадам сөйләгән...

—«Тамара!»—дип уйлады Заһидулла эченнән генә сөенеп.

* * *

Йөрәге сулкылдап кайтып керде Заһидулла Мәкчимнәргә. Керде, дип... Мәкчим белән икесе бергә кайтып керделәр. Керсәләр... Әйе инде! Керсәләр...

Өстәл өстендә нинди генә нигъмәт-сый, азык-төлек, ризык-бизәк юк!

Йә, Ходай!

Колхоз дигән нәмәрсә кешене—ач крәстиянне—юньләп ашатмаган көннәрдәме бу? Хәтта Мәкчимнең дә түгәрәк-жете күзләре тиен койрыгы кебек уйнап алды.

Эх!

Өстәл өстендә, дөресрәге, анда җәелгән сары ингән ак эскәтер өстендә тозлы гөмбә, тозлы кыяр, тозлы кәбестә, тозланган дуңгыз салосы, вакланган тозлы суган кыягы, тозлы шалкан, тозлы торма, тозлы мүк җиләге (?), тозлы помидор һәм тоз савыты (??) тора иде. Болар өстенә тозлы «мат»:

—Кайттыгызмы, мать вашу, гололобые?! С легким паром, татарские князья!—Ә ул, бу сүзләрне әйткән маржа, эче-җаны белән әвәлгечә җен булып калса да, тәс-кыяфәтенә килгәндә—хәйрани бер гүзәл зат иде: өстендә зәңгәр күлмәк, ул карасу челтәрләр белән каймаланып алынган. Аксыл-сары чәчләре көлтәләнгән, зәңгәр күзләренә күкнең фирүзәлеге күчкән, әлеге нәни зәңгәр гөмбәзләрдә ниндидер яшен уты елык-елык килә. Ярый әле күкләре дөбердәми...

—«Йә, Алла!—диде эченнән генә Заһидулла-дәрвиш.—Минем бит яшәү ихтыяҗым бик гади генә иде: Табигать-Ана, Хатыным, Балаларым, Урман-Елга-Болын тирәсендә үз Йортым. Башка берни дә кирәкми... Башка беркем дә кирәкми... «Беркем дә» дигәне—башкалар тормышына кысылмыйм, алар да минем яшәү рәвешемә, хәяти омтылышларыма, Кодрәт алдында үземчәрәк баш июләремә, «үзләренчә» мәгънә-фикер эзләп, мин Колында инсани булмаган тайпылышлар табып, яисә үз рәхәт—ләззәтләре өчен Чиста Җаныма тозаклар корып, көчсез булган ихтыяр көчемне сындырып-җинеп, мине теләмәгән гөнаһларга кертмәсеннәр иде. Кешеләрне бит әшәкелеккә шайтан кертми, бәндәләр бер-берсен юньсезлеккә өстериләр...Күр инде менә моны: җаны тулы—усаллык, ә тышкы кыяфәте—әүлия, фәрештәнең үзе...

Өстәлгә самогон кунаклады. Ул өч литрлы шешә белән иде. Мәкчимнең хатыны тагы Заһидуллага кара яндырып карап алды. Менә шунда гына күрде ул: бу хатын бит бөтенләй яшь икән әле, ана күп булса, утыз-утызбиш яшьләр генә булыр. Һәрхәлдә, кырыктан да узмаган әле ул. Чәпчим Мәкчимнең «минем карт маржа» дигән сүзләре дә уйнап кына әйтелгән икән бит. Ә инде усаллыгына килгәндә, ул бу тормыштан бетәшеп калган, яши-яши хәле киткән һәм дөньяга ачуы чыккан. Революция вакыйгалары, гражданнар сугышы, колхозлашу галәмәтләре аның җанына курку белән бергә ниндидер гайре табигый ярсу да салган, күңелен китекләгән, Рух утларыннан кара күмер генә калдырган.

Эх, дөнья! Эх-эх, дөньякай... Бу дөньяларда ничек түзәсең, балакай?

Күр инде Мәкчим хатынын! Әле бер сәгать элек кенә ул бишмәт кигән, олы киез итекле лыбыжгы бер маржа иде. Ә хәзер? Мунча юынып кайтканнан соң, аның йөзенә матур алсулык йөгергән, ун бите бераз кызышып та тора кебек. Күзләре елтырый әнә, колак йомшаклары бик тә нәфис икән...

Дүртенче дистәсен ваклап килгән Заһидулла хатын-кызның шулай кинәт кенә матурланып китүен, аңа ниндидер илаһи бер кыяфәт керүен һич тә аңлап бетерә алмады. Аның Заһидәсе дә, шулай киенеп-ясанып, тиз генә матур халәткә күчә белә иде. Ә Тамара?

Ах! Тамара, Тамара...

Әнә Мәкчим хатынының күзләренә ат тоягы баскан...

Ашап утырдылар. Стаканы белән тутырып бирсәләр дә, Заһидулла самогонга кагылмады. Малмыж мулласы кулыннан тота кебек иде: «Эчмә! Син бит мөселман, ә мөэмин затлар хәмер кулланмый...»

Мәкчим хатынының моңа бик нык ачуы чыкты:

—Син нәрсә, князь?! Үзеңне әллә кемгә санап эчми утырган буласың.

—Ул безнең күек, муенына тәре такмаган,—диде керәшен.—Мөселман буларак эчмәсә дә җарый. Көчләмә!

Ә хатын отыры кыза төште:

—Революциядән соң христиан да, мөселман да юк! Барыбыз да бер төсле, бер тигез.

—Шулай микән?—дип шик белдерде Зәһидулла.

—Нигә шулай булмасын, хәзер безнен илдә урыс га, татар да юк. Без— революция балалары...

—Һы!—ымлык пышылдап кына диярлек әйтелсә дә, аны Мәкчим дә, хатыны да ишеттеләр һәм шушы «һы» аларны өстәл яныннан кузгалырга мәҗбүр итте.

Караңгылык үзенең кара шәлен дөнья өстенә салган иде инде. Тәрәзәләрдәге утлар да сүнгән, бары ара-тирә урам этләренең генә өрүе ишетелә. Шул өрү күңелгә ниндидер сискәнү сала, шом кертә, нидәндер җан куркынып китә. Абзарындагы ат кинәт кенә ялларын селкеп-селкеп, пошкырып куеп, өркеп китә бит әле... Шундыйрак хис кичерде Зәһидулла, үзен өркеп киткән хайван белән чагыштырды...

Гүя Күкләр аңа нидер пышылдады. Ни мон-аһән ул? Ни алхәбәрләр? Аның җаны бу сорауларга җавап таба алмады. Бары ниндидер эчке бер тоем, күңелнең ин нечкә кыллары гына тота алган сиземләү ана бу төндә ниндидер бер үзгәреш буласын сөйлиләр иде.

Мунчадан соң, бигрәк тә каты итеп чабынудан соң тәне изрәгән идеме, ул бик тиз йоклап китте. Ләкин төн урталарында бастырылудан кинәт кенә уянды.

Өстендә җен ята иде...

Ул җен-пәри, гүзәл хатын-кыз кыяфәтенә кереп, аның колагына утлы сүзләр пышылдый:

—Син мина ошыйсың... Мин сине яратам... Мин сина бирелергә телим...

Зәһидулла сикереп диярлек торып утырды:

—Син юләрләндеңме әллә?! Мать твою!

—Мин синең карда аунаганыңны карап тордым. Син—көчле татар! Син—чын ир!

—Акылыңа кил! Һы!

—Юк, юк! Мин сине телим...

—Менә Мәкчимгә әйтсәм, теләгеңне күрсәтер...

—Ул—йомшак ир инде. Аңа балыкка, ауга йөрү дә, самогон гына булсын. Тагы дуңгыз салосы...

Зәһидулла өстендәге япманы атып урыныннан торды. Хатын аһылдап караватта үксеп калды, ул ун кулы белән мендәрне төя иде. Үзе кычкырып диярлек елый...

«Рәнҗеттем. Рәнҗешле хатын-кыз бик үчле була,—дип уйлады Зәһидулла.—Мәкчим кая соң әле?»

Тәрәзәгә баккан иде:—Әне-кәй-ем!

* * *

—Әне-кәй-ем!

Аның өе яна икән бит...

Үз йортына кадәр ара ике чакрымлап булса да, Зәһидулла ут яктысында тәрәзә пыялаларына кадәр күрде бугай.

Ул караватта үксеп-шыңшып яткан хатынның җилкәсеннән тотты:

—Мәкчим кайда?!

—Кит моннан!—дип, тыпырчынып җилкәләрен куырды—җыерды тегесе.

—Мәкчим кая китте, дип сорыйм... Әнә тәрәзәгә кара әле: минем өй яна... Мать твою!

Хатын да, елавыннан туктап, айнып китте һәм урыныннан торып тәрәзәгә бакты. Ул куркынган иде:

—Максимның кая киткәнен белмим, Захидушка,—диде.

Тышта кар шыгырдады. Ул вакытта Заһидулла киенеп беткән иде инде, ишек алдына атылды. Ишектә үк ана Мәкчим очрады.

—Минем өй яна!—дип акырды ул ана. Йорт хуҗасы бераз каушап калган иде, ләкин үзен кулга тиз алды:

—Киттек! Чаңгыларыңны так...

Алар, берара узуга, Биектау үрен шуып төшеп, Заһидулла йортына таба җилдерделәр. Шулвакыт җил чыгып, ут капкан йортны тагы да шаштырып җибәрде. Ялкын көчәйгәннән көчәя барып, алар килеп җиткәндә, түбәгә үк үрмәләгән иде. Җилме, нәрсәдер өзлексез чиный, улый, дулый, сызгыра. «Өйдә берәрсе бар мәллә?»—дип, эчтән генә сызланулы уйланды Заһидулла. Ул кичтән җан елавын, күнеле китеклеген хәзер генә аңлады: аның үз куллары белән салган йорты яначакка булган икән. Әлеге өй күмергә әйләнгәнче үк аның Рухында кара кисәүләр яткан ич! Нәрсә бу? Күкләр кисәтүеме, әллә Заһидәсе күз яшьләре рәнҗешеме? Хатын-кыз рәнҗеше ачы җимешкә әверелер, ди бит. Әнә бүген төнлә Мәкчим хатыны да ана бик нык үпкәләде, рәнҗи-рәнҗи караватта үксеп ятты. Аның да бер каргышы төшәрме? Ләкин Заһидулла үз туганыдай яраткан Мәкчим абзасыннан узып, аның әле шактый яшь булган хатыны белән йоклап ята алмый бит инде. Бу чын мәгънәсендә дуслыкка хыянәт була, мондый эшне оятсыз бәндәләр, кешегә бөҗәк итеп караган намуссыз адәмнәр, иманы-дене булмаган кешеләр генә эшли ала...

Аңламассың дөньяны!

Алар ялкын чорнаган өй янына килеп бастылар...

—Эчтә тегеләр юк микән?—диде Заһидулла пошынып.

—Ишекне ачып карыйк...

—Якын барма! Йә эчтән ялкын бәрер, йә өстенә өй ишелер.

Ул чаңгыларын салды, аларны карга кадап куеп, Мәкчим янынннан бераз читкә китеп, кар өстенә тезләнеп елый башлады:

—И, бу татар башы ниләр генә күрми... Үз кулларым белән, күкрәк көчемне җәлдәмичә салган йортым бит. Йә кемнәргә зыяным тиде инде минем? Бер ел эчендә бер-бер артлы әтәй-әнәй үлүе генә җитмәгән, менә газиз йортым да күмергә әйләнде... Өченче кайгы бу...

Ул сыкрый, хәтта тешләрен шыкырдата иде. Чәпчим Мәкчим аның янына килмәде, берара ыңгырашсын-еласын, диде. Аннан соң тынычланачак ул...

Кышның таңы озак йокылы...

Иртәнге яктылык инеп килгәндә сәгать тугызлар чамасы иде инде. Кара кисәүләр генә калган өй урыны кояш нурларында бик тә ыржаеп, ифрат ямьсез күренде. Баш очыннан ниндидер кошлар канат пырылдатып узды, Заһидулла аларны күрмәде. Көяз наратлар үз ботакларында кар мендәрләре күтәргәннәр, ул моны да абайламады. Ир бераз хәлсез, күпмедер гамьсез иде. Дөньяның мәңгелек түгеллеген, беркөн үзенең газиз гәүдә-тәне дә шушы кара күмерләр кебек кара балчыкка әйләнәсен бөтен күзәнәкләре, каны-җаны, акылы-аңы белән тойды ул. Кара туфракка гына кер...

Шулай булгач, якты дөньяда яшәү үзе үк мәгънәсезлек түгелме? Әгәр яшәү—Олуг Мәгънә икән, аның үлем белән тәмамлануы үзе үк Мәгънәнең Мәгънәсезлеге ич! Ни өчен яшибез без? Яшәүнең Ахыр Максаты нидә? Яшә, яшә дә юкка чык, имеш...

Заһидулланың баш миендә бер умарта бал кортлары гөжли иде. Һәр бал корты—бер четрекле, ахыр җавабы тәгаен билгеле булмаган авыр сорау...

Ә дөнья, бер уйлаганда, гүзәл ич! Бары матурлыкны күрә белергә генә кирәк. Ә моның иң ансат юлы—ямьсезлекне яшерү. Яшәү—барыбер рәхәт. Бу хискә-уйга килү өчен җир йөзендә Матурлык һәм Яхшылыкны күбрәк очратасы иде. Җиһан капма-каршылыклар белән тулган: Аллаһы һәм Иблис, Материя вә Бушлык, Тәртип һәм Хаос, Яшәү һәм Үлем,

Чын вә Ялган, Ак һәм Кара, Яктылык вә Карангылык, Вакыт һәм Вакытсызлык, Яхшылык вә Начарлык, Матурлык һәм Ямьсезлек...

Нәрсә ул Инсанның Яшәү рәвеше? Ямьсезлекне яшерү. Әдәбият-сәнгать тә, шул ямьсезлекне яшереп, матурлыкны купайтып, балкытып күрсәтү. Яхшылык үзе дә матурлыктан тора, алар бер-берсен баетып, Адәми зат Тулы Камиллеккә, Чын Гармониягә омтылырга һәм күпмедер дәрәҗәдә аларга ирешергә мөмкин.

Заһидулланы кемдер җилкәсеннән тотты:

—Ташла авыр уйларыңны! Үзеңне кулга ал! Бирешмә, дәрвиш...

Малмыж мулласы тавышымы бу? Шуңа охшаган ич...

Ул күзләрен ачты. Каршында Мәкчим тора икән:

—Кузгалыйк...

—Кая?

—Биектауга... Чәпчим Биектауга...

—Кайтмыйм мин ана...

—Кемгә?

—Кемгә, дип...

—Мина кайтасың бит,—диде Мәкчим.

—Әйдә ямьсезлекне яшерәбез!—дип куйды кинәттән Заһидулла.

—Нинди... кайсы ямьсезлекне?

Заһидулла кисәүләр өелеп яткан өй урынына күрсәтте:

—Әнә теге...

—Аңладым,—диде Мәкчим.—Чәпчим аңладым.

—Киттекме?

—Әйдә! Ямьсезлекне яшерәбез...

Алар кисәүләр янына килделәр. Кара күмерләр җирнен тән ярасы кебек...

Борылышта ат пошкырды.

Әхмәдулла!

«И, туганым, минем йөрәк ярамны белеп кенә йөрисең инде»,—дип уйлады Заһидулла. Аннан соң куанычына сыя алмыйча, шатлыгын дала буйлап чабучы ат итеп, кычкырып көлеп җибәрде:

—Әхмәдуллау!

—Әү, Заһи, ие, дулла...

—Минем йорт янганын белеп бу якка чыктыңмы?

—Ие...

—Сөенәсеңме минем өй янганга?

—Вәт, юләр! Туганымныкы түгел, дошманымның йорты янса да көенәм мин.

—Ә мин сөенәм...

—Вәт чашкан тәре!

—Бу йортым янды, хәзер үз өемә авылга кайтам. Заһидәм белән Галимулла улым янына. Юкса сагынып-саргаеп үләрмен мин аларны...

* * *

Заһидулла белән Әхмәдулла кочаклашып ук күрештеләр:

—Өйдә бары да тәртипме?—дип сорады Заһидулла.

—Тәртип!

—Заһидә?

—Шәп кенә ята. Ул колхузга керде бит...

—Ә-ә?!

—Шулай инде... Габдрахманнар көчләделәр... Шунсыз...

—Һы!

—Менә шулай...

—Галимулла улым?

—Чалт! Мүкәли, җәяүләп тә ала...

—Синең чанаңда күрәгең бармы?

—Ба-ар...

—Әйдә ямьсезлекне күмәбез.

—Монымы? Бо-ла-ар-нымы?—дип суззы Әхмәдулла, кара кисәүләргә төртеп күрсәтеп.

—Боларны!

—Моны,—диде Мәкчим дә, янган өй урынына ымлап.—Чәпчим, моны...

Өч ир таза гына эшләп алдылар. Өй тирәсен янган бүрәнә, кисәүләрдән арындырып, кара күмерләрне кар белән күмделәр. Заһидулла, бу кара урын юкка чыгуга, иркен сулап куйды. Күнеленә, битарафлык ук булмаса да, нинди дер яктылык керде, жаны жылынып, тынычланып калды.

«Яшибез әле!—дип уйланды ул эчтән генә.—Әле эшлиселәр, төзиселәр дә алда. Яшибез әле, яшибез! Безнең халыкны да, әнә, ни дошманнар гына кысмаган да кемнәр яндырмаган, кисмәгән, асмаган. Һәй, саный китсәңме?! Меннәрчә ел эчендә ничәмә-ничә татар дәүләтләре булмаган. Җимерелгән алар, янә калыккан. Теге, көлдән туган әкияти кош кебек...

Кеше күнеле дә шундый: ул дөрләп яна да көлләр генә кала. Ләкин шул көлдән тагы яна туыш, кабат калку-балку булып ала. Шуңа күнел пычрак су сала торган ләгән түгел, ә ләгыль-якут—янып-ялтырап торучы асылташтыр...

Яшә, Татарым!

Яшә, Татар угылы Татар Заһидулла!»

Шушы уйлары эчендә, Чәпчим Мәкчимгә мылтыгын, балтасын калдырып, ул туган авылына юл тотты. Әхмәдулла атында, билгеле...

Заһидулла чыннан да улын һәм хатыны Заһидәне бик сагынган иде. Бер көн эчендә бит. Теге вакытта Малмыж төрмәсендә күпме ятып та мондый сагыну-саргаюга дучар булмаган, тармаган иде. Ул сабырсызланып, эчтән генә авыр сызланып, очрашу мизгелләрен көтте. Улына ни диясен, Заһидәгә ниләр әйтәсен уйланып кайтты.

—Ку әле атынны!—диде, ниһаять, Әхмәдуллага.

—Болай да шәп юырта ич,—диде тегесе.

—Тизрәк кайтып житәсе килә...

—Тәкатең кордымы? Тәкбир әйт, тынычланырсың,—диде Әхмәдулла, атын куа төшеп.

Көн уртасы житеп килгәнгә, Күктәге Көнбагыш яхшы яктырта иде. Уйларын куертып, берән-сәрән, эп-эре кар бөртекләре төшә. Кыш өчен чагыштырмача жылы һавада изелеп-мәлжерәп кайту үзе үк тәнгә талгын рәхәтлек, жанга үтәли ләззәт бирә. Боларның гаиләсе белән очрашуның алшатлыгы, алкуанычы икәнен Заһидулла бик яхшы аңлый, әнә шул нәни генә сөенечнең йорты яну көенечен Ярмәкәй тавы кадәр таш белән каплый алуына ул бер яктан аптырый төшсә, икенчеләй караганда, үзендә шундый ипле-игелекле тынычлык тууына гажәпләнеп тә куя иде.

Әхмәдулла—сабыр кеше, гадәтенчә артык сөйләшми. Ә менә эшкә дисәң, ул чын мәгънәсендә ирекмәс жан, үжәт, ифрат тырыш, ялкаулыкның ни икәнен белмәгән ихлас татар иде. Берәрсенә файда күрсәтсә, шундук оныта, нидер-нәрсәдер даулап-буталып, кешеләрнең эчен поштырып йөрми. «Кешегә файда китер дә суга сал, адәмнәр белмәсә, балык белер»,—ди халык. Бу әйтем-мәкаль нәкъ Әхмәдуллага карап әйтелгән.

Ат пошкырып куйды, Әхмәдулла колак салды, Заһидулла борын эченнән генә ниндидер бер көйне көйли. Үзе жырларга бик яратмаса да, туганының әлегә монарчы ишетелмәгән бер мон-аһәнне көйләп баруы аны әсәндереп жибәрде, чөнки Жаны-Рухы белән ул йомшак күңелле, дустанә бәгырьле, ачык йөрәкле инсан иде.

—Нинди көй бу?—диде ул Заһидуллага.

—Милли көй,—дип, Тукайча жавап бирде анысы да.

—Милли икәне күренеп, беленеп тора. Кем чыгарган бу көйне?
—Мәкчим!
—Керәшенме?
—Нәкъ үзе...
—Әйдә, сүзләре белән дә суз, көен дә ачыграк итеп җиффәр инде.
—Тынла алайса:

Коелардан су алганда,
Төшеп калды чиләгем.
Дөнья безгә—ачы миләш,
Кемнәр каба җиләген?

Ат тагы пошкырды, йөгән тәнкәләрен уйнатып алды, башын чайкап дугасын селкетте. Ул да җыр тынлый иде булса кирәк, чөнки юыртудан атлауга—адымнарга күчте...

Ә Күктә—Кояш!..

Аның нурлары ак кар дингезендә чагылып китә дә ике юлчының да күзләрен камаштыра. Бәлки атныкын да...

—Шәпме?—ди Заһидулла Әхмәдуллага.
—Нәрсә шәпме? Көнме...
—Җыр?
—Ә, керәшен көе...
—Әйе, Чәпчим Мәкчимнең керәшен көе?
—Менә дигән!
—Әле син аның үзенең җырлавын ишетсәң...
—Шундый матур тамаклымыни?
—Алтын тавышлы ул!

Алар тагы бер кавымга сүзсезләнеп калалар. Һәркем үз уенда... Кеше күңеле—төпсез кое. Бар, аның нәрсә уйлаганын белеп кара! Ул уйларның йөздән туксан тугызын, меннән тугыз йөз туксан тугызын һәркем үзе белән кабергә алып китә. Һәм гүрдә яталар бергә...

Авыл очында аларга күмхуҗ рәисе Габдрахман очрады:

—О! Ах-ха!—диде ул Әхмәдуллага.—Апкайтасыңмы бу мунча пәриен? Качкынны!

—Син үзең пәри,—диде аңа Заһидулла, тешләрен агартып.—Ә качкын булырга мин закун бозган, дәүләткә каршы кеше түгел.

Әхмәдулла сак кына аның аркасына төртте: «Кычкырышма, янәсе. Закуны да, дәүләте дә болар ягында.»

—Син киреләнеп йөргән буласың, Заһидән үз теләге белән колхозга керде. Әнә бик тырышып эшләп йөри. Фермада бер итеп маллар карый. Сиңа да акылыңа килергә вакыт.

—Мин үз акылымда...
—Улың да...
—Нәрсә булган улым Галимуллага?
—Балалар бакчасына йөри...

«Мать твою!—дип куйды Заһидулла эчтән генә.—Сабыйны караучы да юк микәнни? Бу Заһидәне әйтер идем инде. Бала белән утыра алмыймыни ул?!»

«Ә син үзең?—диде аңа эчке тавыш. Син улыңны карарга аңа булышырга тиеш ич. Үзең Нократ аръягында... Качкын, ялгызак!»

* * *

Габдрахманның тәкәллефсезлегенә шактый ачуы килсә дә, Заһидулла әллә ниләр уйлап баш ватмады, Әхмәдулла чанасында өенә ашыкты. Беренче омтылышы—улын күрәсе килү уе булды. Ә менә Заһидәнең колхозга керүенә карата анда начар тойгы, хәтта нindider лышпырдык хис туды. Шушы Габдрахман, Габдуллаларның үз хатынын сүз белән

көчләп жинүләре бу адәмнәргә карата жирәнгеч уйларны да барлыкка китерде. Жаны-тәне белән ифрат ирекле, үзенчә генә яшәүгә гадәтләнгән, шушы яшендә дә чикләүләрне кабул итмәгән, кемгәдер баш иярге өйрәнмәгән ир заты буларак, Заһидәсенен тегеләр коткысына бирелүе, аның белән бер кәлимә сүз дә сөйләшмичә, бер кәррә дә кинәш-табыш итмичә күмхужга керүе анын горур күнелендә, мәгърур жанында ачу уты кабызды, коточкыч ярсу тудырды.

Өй ишеге бикле иде, төштән сон Заһидә эшкә киткән булса кирәк. Улы кайда? Анын бердәнбере, Галимулласы...

Тышта, абзарлары тирәсендә дә беркем күренми. Атлары да тавыш бирми, алар, хет йорт хужасы кайтуга, кешнәп үз яннарына чакыралар, борыннарын пошкырта-пошкырта солы яисә башак ашыйлар, ана сыйпаланып иркәләнергә яраталар иде. Ул авыр сулап абзар ишеген ачты. Әнә, бурлы бия монда икән. Язга ул колынларга тиеш, күмхуж эшендә жигелеп йөрмәс ич. Имезәк сыер да бурабзарда, кечкенә бозавы да янында. Димәк...

Әйе, димәк... Колхозга Заһидә күк айгырны һәм кырыкмыш тайны биреп кергән. Ул сарыклар сараен да ачты. Алар, шөкер, арыклар түгел, бер тәкә һәм өч баш сарык. Яннарында бәкәйләре дә керт-керт сикереп йөри, Заһидә элеп куйган миллек яфракларын чемченгән булалар.

«Ну, Заһидә! Мать твою! Абыстай булсан да, ни әйтим... Берәү әйткән ди бит: «Февраль микән, март микән, гыйшык микән, дәрт микән»,—дип. Гыйшыгын чүпкә очырыйм, сыртынны каезларга дәрт бар барын. Сагынып кайткан идем, сыктап торам. Сон минем бу маллар белән Нократ арьягын күчәсем килгән иде. Яна тормыш башларга. Икебез. Бернинди күмхужларга кермичә ялгызак атаказ булып яшисе теләк көчле иде бит. Әлбәттә, синен белән. Улым Галимулла белән. Планнарны жилгә очырдын.»

Шулвакыт капкадан Заһидә үзе килеп керде:

—Заһидулла! Аһ-аһ!

Ире ана каш жыерып, астан сөзеп кенә карады:

—Ике ат белән тана бозауны кая илттен?

—Калхузга...

—Үз теләген беләнме?

—Габдрахманнар мина колхозга керергә куштылар.

—Син?

—Куркыттылар мине. «Әтиен—мулла, әниен—абыстай, аларны авылдан сөрәбез»,—диделәр.

—Тагы ниләр әйттеләр?

—«Иренне тагы Малмыж төрмәсе көтә, диделәр. Әтиенә дә пулә әзер, әнә Түнтәр хәзрәте Ишми ишанны Малмыжда 1919 елны ук аттылар»,—дип куркыттылар.

Ир бераз тынычланды. Юк, Заһидәсе ана каршы килеп, киреләнеп түгел, ә әти-әнисен һәм аны яклар, саклар өчен күмхужга кергән икән. Шулай, төшенеп житми генә, Бухты-барахты гына чишә торган төен түгел бу.

—Галимулла кайда?—дип сорады ул хатынынннан.

—Әниләрдә...

—Габдрахман: «Балалар бакчасында»,—диде ич.

—Анда ул әни авырганда гына булды бит. Габдрахман күзгә төтен жибәрергә ярата инде ул...

Мәсьәлә ачыкланды, анын ачуы бөтенләй үк басылды. Ул хатынына яратып, ымсынып карады. Заһидәсе дә бу сагынулы-сөюле карашны тиз сизде:

—Әйдә, өйгә керәбез...

—Киттек!—диде ир сабырсызланып.

Чолан ишегенә эленгән иде өй ачкычы. «Әй, хәтерсез баш, керфексез каш,—дип сүкте Заһидулла үзен.—Безнен өй болай гына бикләнә ич,

ачкычы һәрвакыт келәт ишегенең токтасына эленә. Менә бит: ачу өстенә кычу, димәктән...»

Өй алды ишегеннән керүгә, ул хатынының беленнән кочаклап алды. Йомшак-тыгыз гәүдә ана сарылып катты:

—Заһидулла, җаным...

—Әү, матурым...

—Син бездән... бу өйдән мең ел элек киткәнсең кебек тоела...

—Мең ел элек мин хатын-кыз булып яшәдем, ахры...

—Ә мин ир булыпмы?

—Белмим... Моннан миллион еллар элек ат булып яшәдем кебек тоела миңа...

—Мин сыермы?

—Кем белә?! Берничә миллион еллар элек мин абага идем бугай...

—Ә мин абага чәчәгеме?—диде хатын, аның куе-кытыршы кара чәчләрен сыпырып-иркәләп.

—Мин абага булсам, син чәчәге дә чәчәге инде,—диде ир, аның иреннәреннән, маңгаеннан, колак йомшакларын үбеп.

—Мин өзелеп-өзелеп сагындым сине. Аһ-аһ!

—Мин дә сагындым!

Ир хатынын кулларына күтәреп алды да өйгә кереп, түшәккә салды...

... Заһидә бар йөзенә тулы канәгатьлек чыгарып, ләззәт шаукымында түшәмгә карап озак кына ятты. Аның колаклары шаулый иде. Нинди шау-шарлавык бу? Кышкы көндә әллә челтерәп чишмәләр агамы?

Ә-ә-ә!

Ишек токтасына эленгән йозак белән ачкыч бер-берсенә җилдә бәрелеп зеңләп торалар ич...

Йозак һәм ачкыч...

Заһидә вә-һәм Заһидулла...

Ай, озак булды ул Нократның аръягында. Чыннан да тоташ мең ел... Әнә өе дә янган икән. Заһидә аны Әхмәдулладан ишеткән иде. Шул янгында ире үзе дә янып үлмәде микән дип, төне буе керфек какмады, елап чыкты ул.

И, Ир Заты!

Беләсеңме соң син хатын-кызның мондый авыр кичерешләрен? Аңлыйсыңмы син, аның тормыш итешләрен, көнкүрешләрен? Ул бит синнән бернәрсәне дә артыгын сорамый.

—Җылы түшәк...

—Көн итәрлек мал...

Әгәр дә назлау-сөюгә җитмәсә, яисә дәртең булып та дәрманың калмаса—Ул көтәр...

Тормыш итәм дип йөреп тә, көненчә хәләл акчаң, тапкан малың булмаса—Ул көтәр...

Бары аның—Мөэннәс Затының—сиңа булган тулы ышанычын, ныклы өметен генә югалттыра күрмә. Алар югала икән, иң беренче, син—гаепле. Чөнки хатын-кыз нәфисҗан, нечкә зәвык иясе, хисләр колы. Ул акылына каршы эшләр дә эшләргә мөмкин. Син аны рәнҗетмә, үпкәләтмә. Җылы түшәгендә озаграк сөй, күбрәк назла. Ул шуңа мөкиббән китә, коргаксыган чишмә кебек өзелеп-сызылып, сыкрап-сукранып яңгыр яуганын көтә:

—Ник яумый инде бу яңгыры?!

Әнә шулай уйлады җылы түшәктәге Заһидә.

* * *

Үз йортында хатынын назлап-иркәләп, улын сөеп ике атна торуга, Биектаудан ана Мәкчим килде. Үзе чаңгыга баскан, этен иярткән.

—Чык әле,—дип чакырды ул аны ишек алдына.

— Мәкчим абый!—диде ана Заһидулла.—Мин сездә мунча керенеп, тархан-морзалар кебек сыйланып яттым. Син өйгә чәйгә дә кермисенме? Шалишь, брат! Татар татарны мәйгә түгел, чәйгә булса да чакыра ул. Бергә ингә-ин яшәүче урысны да түргә утыртып кунак итә ала. Шунсыз татарның кунакчыллыгына, кин күнеллегенә төкерәм мин. Беләсенме Казан университеты галиме профессор Фуксны? Милләте белән немец булса да, ул татарның кунакчыллыгы, өстәл өстендәге сый-нигъмәте, азык-төгаме турында нинди шәп язмалар калдырган!

Аңлады Мәкчим, «чәпчим» аңлады: чит җирдә, ятрак кешедә Заһидулла үзен тыйнак тотарга яратса да, үз йортында ул әнә патша, хан-солтан икән. Кара инде аның бөердән чыгарып кына сөйләшүен. Юкса үзен мин-минлекле адәм дип тә булмый. Әмма горурлыгы үзенә торырлык!

Заһидулланы иснәштереп торучы эткә ул: «Пшал!»—диде дә, чаңгыларын салып куеп, йорт эченә керде. Өй җылы, янарак кына мич ягылган, кайнап утырган итле бәрәңгедән чыккан пар аз гына түшәм-стеналарны чылатып-сулатып алган. Алгы яктагы караватта сабый уйнап утыра, үзалдына сөйләнә, кинәт кенә чырылдап көлеп җибәрә.

Рәхәт монда! Күнелле!

Йорттагы җылылыкны гына түгел, ниндидер нурлылыкны да сизде Мәкчим. Гадәттә өйгә нур яхшы күнелле, чиста, пөхтә хатыннар белән бер гөнаһсыз нарасыйлардан инә. Гүя фәрештәләр, алар өстендә очып йөреп, нур тараталар. Кояш нурлары гына түгел, илаһи нурлар! Менә хәзер Чәпчим Мәкчим үзенең бабасының ник мөселманча күмәргә кушуына, васыять калдыруына төшенде: мөэминнәрнең гүрләре дә якты, нурлы булыр, ди ич. Алай дисәң, барыбыз да бер Күк астында яшибез дә бер Аллаһыга баш иябез. Христианнар үзләренчә, мөселманнар икенчерәк төрле.

Өйгә угызлы сөт күтәреп Заһидә килеп керде. Чәпчим Мәкчимне ул ишетеп белә иде инде, шуңа кунак белән баш кагып, ягымлы гына исәнләште. Аннан соң ирләрне табынга чакырды. Өстәл өсте күркәм иде: итле бәрәңге, пәрәмәч, эремчек, угызлы сөт, шикәрле чәй, зур-зур арыш ипие телемнәре. Ул телемнәрне Заһидә күкрәгенә терәп кискәндә, Заһидулла аңа карап сокланып утырды: «Менә бит аның хатыны! Эре ак бөртекле зәңгәр күлмәген кигән, ак алъяпкыч япкан. Күкрәкләре тулышып тора, йөзендә нур, күзләрендә нәни монсулыкның сизелер-сизелмәс чаткылары...»

Мәкчим дә Заһидулланың үз хатынына яратып каравын сизенде, тамак ялгап ишек алдына чыгуга, беренче сүзе:

—Хатының чибәр синен!—булды.

—Синен дә хатының матур,—диде Заһидулла.—Бары без үз хатыннарыбызның кадерен генә белмибез, гүзәллекләрен күрмибез. Яшь торгач, алар безгә ияләнгән, көн дә күреп туя башлаган әйбер кебек...

—Сүзен дөрес!—диде Заһидуллага Мәкчим чын күнелдән.

—Йә,—диде анысы Мәкчимгә.—Ни йомыш туды әле синдә? Эт ияртеп, чаңгы тагып, Шөнгә килеп чыгарлык...

—Аю!—диде тегесе кыска гына.

—Аю?

—Әйе, аю бабай...

Мәкчимнең аю белән саташуын, җенләнүен белгән Заһидулла аның бу сүзләрен уенга алмак булды:

Безнең бабай—аючы,
Аю белән баючы.
Без үзебез төлкече,
Булмыйк адәм көлкесе...

—Шаяртмасана!—дип үпкәләде Мәкчим.

—Соң, купец Стакановның өрәге дип, тагы котың ботына төштеменн? Әллә шыр җибәрденме?

—Мәтби Гөргөричнең монда ни катнашы бар? Чәпчим, юк,—диде керәшен.

Һәрхәлдә алар бер-берсен анламаудан җәфа чигәләр иде. Мәкчим шул адашкан аю белән шашкан, өе янганнан соң Заһидулланың нишләптер Нократ аръягына аяк басасы килми. Нишләптер дип... Өе янганга инде. Шуннан соң күнеле суынды анын. Бетәрме бу суык? Ул үзе дә белми әле...

—Ул аюны,—диде Мәкчим, аны уйларыннан бүлеп,—янган өен тирәсендә очраттым. Шомырт агачы астына елышкан иде. Нәрсә эзли ул синен йорт тирәсеннән? Ни калган аңа шомырт төбендә? Төшләремә керә, ашымны аш, йокымны йокы итми. Ни кирәк аңа? Нәрсә эзли ул?

—Тормыш—сораулар, яшәү—шуларга җавап бирү,—диде йорт хуҗасы бик мәгънәле итеп.

—Анламыйммы? Шул зур сорауның берсе—оп-олы аю...

—Нинди тәкъдимең бар?

—Атарга ул аюны!

—Урман хуҗасынмы?

—Урман бабаен.

Заһидулла керәшен дустының халәтен аңламый түгел, үзенчә бик анлый иде: нindидер сихри бер көч Мәкчимне шул аюга тарта. Ләкин бит аю Мәкчимгә тими, килеп өен, каралты-курасын, умарталарын да туздырып йөргәне юк. Ник каныга ул аюга?! Әмма...

Дусты буларак, Мәкчимгә булышырга кирәк иде, котылсын бу шашынып йөрүеннән, арынсын аю сихереннән. Дөрес, Заһидулланын бервакытта да аю аулаганы юк, ләкин өененнән чыккан кышкы аюны урыслар «медведь-шатун» диләр һәм ул кешеләргә ташланырга да мөмкин икән. Ни генә димә, андый чалыш аяк «исерек» җанвар инде ул, ә исеректән бөтенесен дә көтәргә була.

—Өнен таптыңмы син анын?

—Чамалыйм,—диде Мәкчим.—Бояр урманындагы куралык үзәнендә булырга тиеш. Чәпчим, шунда. Анда ауган карт чыршы бар. Анын асты аю өненә җүн урын инде. Чәпчим, җүн...

—Кайчан барабыз?

—Бүген мина чыгып куныйк. Аерым-тоерым йөргәнче...

Заһидулланың йөрәге сулкылдады, кемдер аңа бу хәтәр эшкә бармаска киңәш итә кебек? Кем? Нәрсә? Ул белми. Белмәве белән бәлки бәхетледер дә. Алдагыны Алла гына белә, дигәннәр...

Тәкъдирдә язылганнан да артык эш булмас, Китаплар Анасы Ләүхелмәхфүздән узмыш юктыр, язмыш шушыдыр дип, ул Мәкчимгә ризалыгын белдерде. Тегесе шатлыгыннан аны кочып ук алды:

—Бар, жыен!

Өйгә керүгә, Заһидәсенең сораулы күзләреннән карашын читкә юнәтте.

—Кая жыенасын?—диде, ниһаять, хатыны.

—Аугa...

—Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карар, ди...

—Урман—минем йортым ул!

—Бар инде, бар, урман аюы...

Заһидәсе артык буза күтәрмәде.

Кичке энгер-менгерне ерып, ике ир-ат тагы Нократ аръягына юл тотты.

* * *

Менә ул Бояр урманындагы куралык үзәне. Әнә аста, тирәндәрәк теге карт чыршы. Ул ауган инде, үлгән...

Ә аңарчы...

Мәкчимнәрдә кундылар.

Аннан алда...

Мунча юынып кайттылар.

Таннан—Бояр урманына юл алдылар. Мәкчим юл буенча сөйләшеп, елмаеп-көлеп барды.

—Нигә синең күнелең бик көр әле, тавык тәпие аскан нәмәрсә?

—Белмисенмени? Шуны да чәпчим сизмисенме? Әй, Коръәненә кадалган чалма! Кичә синең хатынына үлеп гашыйк булдым ич...

Шулай ди дә Мәкчим, башларын селки-селки, чангысына абына-абына тагы көлә башлый.

—Мин дә синең хатынына гашыйк,—дип, аны тыймакчы була Заһидулла.

Эх!

Теге төнне аңа сөйләсәнме? Көлүеннән туктап, шундук елый башлар иде. Тик Заһидулла ник сөйләсен бу турыда анарга? Ул дустына хыянәт итмәде, аның хатыны белән йокламады ич.

Ә Мәкчим көлә дә көлә...

Әнә ич алар дусты белән аюауларга баралар. Урман Бабаен...

Ике мылтыкта да аю атар өчен махсус эшләнгән жакан-патроннар. Аю аю инде, ул сина төлке генә түгел. Бүре дә түгел...

Мәкчим генә менә...

Шушындый да житди эш алдыннан бала-чага сыман шаярып бара. Мәкчим көлә дә көлә генә, көлүен һич туктата алмый. Ни шатлык кергән аңа? Нинди куанычлар тулган жанына?

—Көлмәле, Мәкчим абый!

Мәкчим һаман көлә, тагы да шаярта.

—Еласына булмасын бу көлүен...

—Минем бабай,—диде Мәкчим.—Еласын елап бетермәсәң дә, бу дөньяда көләсен көлеп бетереп кит, ди иде.

—Шәп әйткән!

—Мин дә шулай дим. Чәпчим, шулай.

Аннан Мәкчим тагы шаяра:

—Карале, татар! Минем бүрегем шәпме?

—Их, керәшен,—ди Заһидулла, ана сиздерми генә яратып карап.—Берәү чәшке бүреге белән мактанган, ди. Ә шул бүрек астында ахмак баш утырганын-йөргәнен анламый да анламый инде ул дивана, белми дә белми инде ул исәр. Анласа-белсә, үз юләрлегеннән хурланып үләр иде.

—Син миннән көләсенме?—ди тегесе шактый ук житдиләнеп.—Башта үз башыннан бет эзлә, аннан сун гына кешенекеннән.

Бу юлы Заһидулла үзе көлеп жибәрә:

—Ха-ха-ха! Бүсеренә тидеме?

—Бүсерне син үзен үстер!

Чангылар шәп юырта. Әнә Бояр урманының авызы. Менә ул куралык. Карт чыршы астыннан томандай пар бөркелә. Димәк, аю шунда. Ул көндез ял итә, йоклый, төннәрен ауга чыга. Суык баллаткан миләшне дә кабып карый, баланның да ачысын татый...

Ә хәзергә ул өнендә. Аның гәүдәсе жылысыннан нәни генә бөркелеш булып пар күтәрелә.

Аю өненә якынаюга, Мәкчим ифрат житдиләнде, хәтта күзләре сагышланып киттеләр.

—Болай итәбез,—диде, Заһидуллага ярым пышылдап.—Мин озын колга кисеп алам да аны борчыйм, йокысыннан уянуга, теге чыршы артына качам. Син жакан пулә белән шап маңгаена!

—Әллә колга белән аны мин кузгатыйммы? Син—шап башына. Кашып ал!

—Юк,—дип каршы төште Мәкчим.—Минем күзләр кәйрәк хәзер. Эчү аркасында куллар да дерелди. Аюга мылтыктан атарга ышанычлы кеше түгел инде мин. Яшен илледә булгач... Жәш чагында жөрдек әнә. Бүген иң кулай кеше—син.

Мәкчим карны артык шыгырдатмаска тырышып үзән эченә төшеп китте. Чаңгылары өстә калды, ул үзе кулына озын колга алды.

Заһидулла мылтыгын әзер тотып, тирән канәгатьсезлек белән аны күзәтте: «Нигә кирәк инде бу аю аңа? Әллә үз башынамы?»

Ул сискәнеп китте, мондый уйларны башыннан куды. Мәкчим аю өненә тәмам якынлашты. Бу ара дүрт-биш адым гына иде. Заһидулла аңламады, нигә ул аның ягыннан өнгә якын килде соң әле? Чыршының теге ягыннан торып җанварны кузгатырга сүз куештылар бит. Оныттымы ул бу килешүне?

Мәкчим озын колгасы белән өнгә төрткәли, хәтта ярсып-ярсып шөшкели иде. Менә өннән авыр мышнаган тавыш, ризасызлык авазлары ишетелде.

Икенче мизгелдә урман бабае үз оясыннан атылып та чыкты һәм Мәкчимнең баш түбәсенә сугып, аны кар өстенә индерде. Ул аны сытачак, изәчәк иде, Заһидулла мылтыгыннан атып җибәрде. «Бабай» үкереп бер ягына егылды. Торырга азапланганда, Заһидулла аңа икенче мылтыктан да атты. Аю гөрселдәп җиргә ауды. Кар бөртекләре өскә күтәрелде хәтта...

Заһидулла үзән эченә чапты. Аюга борылып та карамады. Мәкчимнең чәшке бүреге әллә кая очкан, үзе кан эчендә иде. Баш түбәсенең тиресе чәче-ние белән сыдырылып төшкән, авыз кырыеннан, колак артларыннан кан киткән.

Заһидулла аның йөзен кар белән юып җибәрде:

—Мәкчим абый!

Керәшен авырлык белән генә күзләрен ачты:

—Ни дисең? Чәпчим...

—Хәлең ничек?

—Мин көләсен көлеп бетердем бүген...

—Йә, Алла!

—Бок диген. Үрдәк тә әнә «бак-бак» ди.

Алар беравык тын тордылар. Мәкчимнең бик авырдан гына, гыжылдап сулаганы ишетелә иде. Үзләренең шушындый авыр хәлгә төшүләренә Заһидулла гаҗиз мәлдә иде: «Нигә бармыйк дип әйтмәдем. Күңелем сизенде ни дә булса бер начарлык булачагын. Тойдым ласа мин бу яман эшне»,—дип, эченнән генә сыкранды ул.

—Әйдә, мин сине яр өстенә алып менәм,—диде ул аңа.

Мәкчим күз кабакларын күтәрде, ризасызлык белдереп, кирәкми, диде.

—Кузгатма мине,—диде аннары. Актык сулышларымны... монда алырга... мөмкинлек бир...

Аның тәне кызыша башлаган, үлем алдыннан гына була торган соңгы көчәнеш белән тәненең һәр күзәнәге ярсып эшләүгә күчкән иде.

—Теге төн-не... минем катын... синең белән булдымы?

—Юк!

—Ә өенә утны... мин төрттем...

Заһидулла шаккатты: «Менә сиңа, мә! Йөр аңа ышанып!?»

Моны ул эченнән генә уйлады, ә Мәкчимгә бер генә сүзле сорау бирде:

—Ник?

—Чөнки тегеләр синең өенә... ут төртәбез дә... үзен утка салабыз, диделәр. Йорт нәрсә ул... Исәнлек кадерле, исәнлек-саулык...

—Рәхмәт!

—Үзенә рәхмәт. Син мине якын иттең, чын дус, әйбәт иптәш санадың...

Менә ул күзләрен йомды, ыңгыраша-ыңгыраша, үз көен акрын гына сузды:

Коелардин су алганда,
Төшеп калды чиләгем.

Дөнья безгә—ачы миләш,
Кемнәр каба җиләген?

Аннан гырлый башлады, гырлавыннан туктауга:
—Китте Мәкчим, чәпчим, китте,—диде дә башын бер якка салды...

* * *

Гомер агышларында Мәкчим—Заһидулланың дүртенче йөрәк ярасы, кадерле бер кешесен югалтуы иде. Әнә Җидән бабасы калдырган теге язмада, васыятьнамәдә: «Һәркем җиде олуг кайгы кичерер, дигән бит. Алга таба яши калсаң, гомереңне Тәңре озынрак бирсә, тагы өч зур кайгы кичерәсе бар икән әле... Йә, Алла! Йә, Раббем!! Юкка гына күрәселәреңне күрми, гүргә кереп булмый, димәгәннәрдер инде...

Әле ул гомереңне шапшак, лыбыжгы, синең ирегеңне кыса торган, иркенлеккә юл куймаган вак тормышка багышласаң, үл дә кит инде...

Хәер...

Үләм дигән кеше күп вакытта үлеп китми ул, ә шыгылаган усак агачы кебек шыңлап-шыңшып усал җилләргә, явыз давылларга каршы тора. Мәкчим дә әнә көлде, көлде дә кинәт кенә үлде. Аягүрә ауган имән кебек... Хәтта үлү дә үлем түгел, чөнки тәннең вакыты чикле булса да, җанның өметендә—мәңгелек ич...

... Менә ни-нәрсәләрне искә төшерде ана хәзер ишек төбендә елап торучы Мәкчим хатыны. Тегеләр белән бәрелешүне дә искә алды ул, үзенең җан дустының аю ауларга баргач, фаҗигале рәвештә харап булуын, үлүен дә...

Аннан соң ул үзенең караваттан торып атлап китүенә хәйран калды. Анналың авыр сүзләре нервыларын какшатып, суык тигән аяк буыннарына көч-җегәр кердеме шунда, әллә башка берәр нәрсә кинәт кенә бик нык тәэсир иттеме? Боларын ул аңлап бетерә алмады, төгәл-тәгаен җавап та юк иде кебек...

Ул йомшак кына итеп ана эндәште:

—Беләсеңме, Анна, мин бит аякка баса алмый җәфаланган идем. Яттым менә караватта, бала караучы нәнкә булып. Син килеп кердең дә: «Мәкчимне син үтердең»,—дип әйттең. Бу коточкыч сүздән мин аякларыма басып киттем. Нәрсәдер буыннарда чемер-чемер килде, гүя аяклар түгел, ә утлы көлгә күмгән бәрәңгеләр...

Хатын еламый иде инде, Заһидулланың соңгы сүзләреннән ул хәтта рәхәтләнеп көлеп җибәрде. И, хатын-кыз күңеле! Бер карасаң—пыяла ул, уала да ватыла. Икенче күр, ул инде алмаз, ташлар белән төйсәң дә—уалмас...

—Нигә көләсең әле син?—дип сорады Заһидулла.

—Көлмәскә ни... Мин—сихерле бит.

—Кит әле!

—Чынлап, Захидушка.

—Кайдан өйрәндең син ана?

—Әбиемнән...

—Ул?

—Ул—чын сихерче иде. Ул мичкә кереп, моржадан да чыгып китә алды, кечкенә генә форточкага да сыйды. Ана тәнен зурайту яисә кечерәйтү берни түгел иде. Бик күп чирләрдән дәвалый белә иде ул. Кеше шифасы тиеп, бөтенләй терелеп китә алмаса да, аның хет чирдән авыртуын баса белә иде ул, Захидушка. Вот так, князь!

—Ә теге төнне минем янга килеп яткач, мин бит сине җен дип уйладым. Валлаһи, менә! Бастырылдым мин...

—Мин бит сине сихерли дә ала идем,—диде хатын тагы кыска гына көлеп куеп.

—Һы!

—Әмма теләмәдем... Мине үз теләге белән яратсын, дидем, Захидушка.

—Һм-мм!

—Сез анадан тума шәрәтән... мунчадан чабынып чыгып... карда аунаганда, мин сиңа... синең тәнеңә... бар жиреңә... гашыйк булган идем... Шуңа бер генә төн булса да синең белән гыйш-гашрәт ясыйсы килгән иде. Онытма: хатын-кызлар һәрвакытта таза-нык ирләрне яраталар... Ир заты түшәктә дә, тормыш иткәндә дә көчле булсын ул!

—Миңа моны берәү әйткән иде инде...

—Тамарамы?

—Әйе. Каян беләсең син аны?

—Без аның белән ахирәтләр идек...

—Хәзер кайда ул?

—Югалды ул, Захидушка, югалды...

—Ах!

—Ул сине бик тә яраткан. Миңа да: «Мировой мужчина ул!»—диде.

—Мин дә...

—Нәрсә?

—Һм-мм...

—Әйтәсең килмиме? Үзеңдә калдыр. Чын ир бар уйларын да сүз итеп чәчеп йөрергә тиеш түгел!

Шунда бер мәлгә тынып калдылар. Теге якка чыгарып куелган (бу хатын килеп кергәч тә—күз тияр!—дип) Галимулла «гы-гы-гы» дип көлә, үсү тәменнән, җылы өй рәхәтеннән ләззәтләнеп утыра. Әнә башлыгындагы күзтидермәс миләш ботакчыгы да төшеп киткән. Сабыйга нәрсә, ул шул чыбыкны авызына тыгып чәйнәмәкче була. Заһидулла олы якка чыгып, Галимулла авызыннан миләш ботакчыгын алды, аны кабаттан сабыйның башлыгына беркетте. Ә нарасый әле тешләр чыгып бетмәгән авызы белән әтисенә карап елмая-көлә...

—Нинди матур малай!—Анна ишеккә башын тыккан иде.

«Чу! Кем әле бу?»—Сабый авызын җыерып торды да елап җибәрде.

—Өстенә әйтмә, Анна!—диде Заһидулла.

—Гафу, Захидушка, ырымы барын да беләм, телемә тилчә чыккыры, тыела алмадым...

Нарасыен көйләп тынычландырды да хатынны ул чәйгә чакырды. Өстәлгә йортта ни азык-ризык бар, шул менеп утырды. Заһидулла белә иде: «тегеләр» белән бергә самогон чөмергәч, хатынның хәзер башы авырта. Мондый чакта иң кулай нәрсә—каты чәй.

Хатынның күңеле ачылган, Заһидуллага үпкәләве беткән, шуңа пышык-пышык елавы да күптән сүнгән, һаваны да үпкәләренә тирән итеп ала, йөзе дә сүрән-көреннән шактый алсулана төшкән иде.

—Ахыргы минутларында минем Максим ни дип әйтте?—дип сорады ул бер тустаган чәен эчеп бетерүгә.

—Ул синең турыда сорашты...—диде ир бер дә ялганга кермичә.

—Димәк, мин аңа яхшы хатын булганмын икән!—диде Анна горурланып.

—Син—яхшы хатын.

—Рәхмәт!

Кыстый-кыстый Заһидулла аңа тагы бер чынаяк чәй ясады, хатын анысын да пәрәмәч һәм каты конфет белән эчеп куйды.

—Максимны,—диде Анна,—безнең Бабушкин дәдә бик ярата иде.

—Кем ул Бабушкин?

—Бәрәч, белмисеңмени? Порт-Артур герое. Теге 1904-1905 еллардагы рус-япон сугышында... Ифрат көчле-куәтле кеше!

—Ул сугышта Россия җиңелгән. Япуннар Цусима бәрелешендә урысларның Тын океан флотының 2 нче эскадрасын тулысынча тар-мар иткәннәр. Хәзер Порт-Артур да юк инде, ул Люйшунь дип атала,—Заһидулла тарихны әйбәт белә иде.

—Сезнең авылның исеме дә «Шунь» бит. Әллә татарлар белән японнар бер телдәрәк сөйләшәме?

—Юк, «Шунь, Шуни» дип безнең авыл урысча гына атала. Ул үзе «Сөн» сүзенең бер варианты: Шөн. Ә сөн, һун кабиләләре—безнең борынгы бабаларыбыз...

—Тамырыгыз ерактан икән, князь!—Анна аңа хөрмәт белән карады.

—Мин князь булмасам да, тархан, морзалар нәселеннән.

—«Тегеләр»дән сак булыгыз, морза!—диде хатын соңгы сүзендә.

* * *

Заһидә эштән кайтып кергәндә, Анна Заһидулла белән саубуллашып, чыгып киткән иде инде. Ирнең колагында хатынның: «Тегеләр» белән сак бул, морза!»- дию генә күңелендә калай каккандай чынлап торды. Хәтта чигә тамырлары кысылып алды.

«Нәрсә эшләрләр алар миңа? Ни начарлык?»—дип, идән таптап йөрде ул йорт буенча.—Авылга килеп, безнең өйгә һөҗүм итәрләрме? Яисә мине, сагалап торып, берәр җирдә суеп үтерерләрме? Бу каралты-кура, йорт-капкага ут төртерләрме?»

Ул үзе куйган сорауларның берсенә дә ышанып бетми, булмастай эш дип саный, артык шикләнүгә, вакчыл тәфтишлегә өчен үзен-үзе сүгә, эчтән генә команда бирә: «Йә, тынычлан! Ну, тынычлан инде! Вәт, мать твою, тынычлана беләсеңме син, юкмы?!»

Аннан азмы-күпме тынычлангач, тагы үзенә-үзе фәрман бирә:

—Йәле, бисмиллаһи, диң!

—Бисмиллаһи...

—Әйдә, аларга төкер һәм зекер әйт:

—Аллаһу әкбәр!

—Аллаһу әкбәр...

—Сөбханалла!

—Сөбханалла...

—Әлхәмде лилләһ!

—Әлхәмде лилләһ...

Әнә шулай үзе-үзен тәмам тынычландырып бетергәндә, Заһидәсе кайтып керде. Аның идән буйлап йөрүенә шаккатты, шатлыгы-куанычының иге-чиге булмады, хәтта күзләренә мизгеллек бәхетнең тозлы-татлы яшьләре дә чыккан иде:

—Заһидулла, җаным! Аһ-аһ...

—Заһидә, матурым!

—Торып киттеңме?

—Бастым әле...

—Фәрештәләр булышкан. Ходайның кодрәте киң аның...

—Анна дигән фәрештә.

—Кем-кем?

—Анна!

—Кем була ул?

—Мәкчим хатыны. Биектау маржасы. Сихергә ия ул...

—Ә-ә!

—Вәт шулай.

—Тәти булгансың!

—Бүген мин улыма көне буе чын әти булдым.

—Ашап алганчы, әйдә, улыбызны юындырыйк.

—Әйдә! Мин чәйләдем инде.

—Миннән башка... бер үзең?

—Икәү идек: Анна да мин...

Заһидәнең көнчелеге кузгалды: ничек әле ул бервакытта да әйтмәгән, исемен дә атамаган хатынның атын тәкрарлап, кабатлап тора: Анна да

Анна, Анна да Анна. Урыслар әйтмешли, «Небесна манна» түгелдер бит ул хатын шулкадәр?!

Анын иреннәре нечкәреп кысылды, ачудан күзенә яшь тыгылды. Туктале, нихәл бу? Ни сәбәптән каяндыр килгән, аларда чәй эчеп киткән хатыннан көнләшә әле ул? Ә-ә-ә!

Юкәдә шул чикләвек, әллә имәндәме?

Бервакытны төнлә, йокы аралаш саташып, аны ире чәчләреннән сыйпап яткан иде:

—Тамара... Тамара... Тамара...—дип.

Менә теге көнчелек уты, анын елан угы, зәһәрле агуы кайсы вакыттан килә. Таманча гына хатынмы ул, бик чибәрме? Заһидә аны белми. Чибәрдер. Ире, йокысында саташып, анын исемен кабатлап ятмас иде. Күрәсен, Заһидулла җаныкай хатын-кыз затына, бигрәк тә ниндидер Тамарага «тамакай». Ул ана тамандыр, тамар тамчысыдыр.

Ире нидер диде, ул ана җавап бирмәде. Дөресе, Заһидә үз уйларына чумып, чукракка әйләнгән иде: «Ә сәгать артындагы теге муенга тага торган алтын чылбыр? Уртасында бриллиант та бар. Ул—алтын кысада. Урманнан тапмаган ич ул алтын белән җәвәһирә-асыл ташны? Кем биргән, каян алган ул аны?»

Хатын нәүмиз рәвештә иренә карады, шик вә көнчелек корты анын йөрәген кимерә, үзен ул җәбер-золымга эләккән кешегә тин саный, хәтта көләч-алсу йөзе дә бер мәлгә зәгъфран төсенә манылып алды.

—Сина әйтәм!

Хатын уйларыннан арына:

—Нәрсә дисен?

—Малайны юындырырга таз белән су куйыйммы? Мичкә...

—Хет мунча як шунда!

—Нәрсә-нәрсә?

—Кәбестә!

Ир бер мизгелгә шаккатып кала: «Туктале, әле генә «Заһидулла, җаным!»—диде түгелме? Аякларыма басып йөри башлауга үлә-үлә сөенде. Ни үзгәреш бу? Кайсы эт борчасы тешләгән аны?»

Хатын да анын турында үз уенда:

—Ата эт!

Ир:

—Мин бит ана бер мыскал да начар сүз әйтмәдем...

Хатын:

—Мине мыскыл итеп, әллә нинди Тамаралар белән йөрмәсән. Без дә, Аллага шөкер, арбадагы дегет чиләге түгел, Аяз мулланын гүзәле—җиләге...

—Улыма жылы су кирәк, хәзер аны пәп-пәп итәбез,—ди Заһидулла.

—Ана жылы сөт кирәк, хәзер «сыерым»ны тып-тып итеп савам,—ди Заһидә.

«Сыерым»ны ди...

Мал бүләме ул?

Әйе, бу сыерны аларга кәләш бирнәсе итеп Аяз мулла бирде. Асыл абыстай да ризалык бирде, йортка иминлек-муллык теләп догасын кылды. Үзләренен бер кыз гына булгач, калганнарына чүпрәсен таба алмагач, кияү йортында «күптин-күп, чуктин-чук балалар» булсын дип теләделәр икесе дә. Әби-бабайга монын өчен бик тә-бик тә, ифрат бик тә рәхмәтле иде Заһидулла. Ә бүген менә Заһидәсе, «сыер—минеке!» дигәндәй, «сыерым» дип шыбырдый. Кая төрттерә ул? Нәрсәгә-нигә тери?

Шушы сораулар астында ир гаҗиз калган иде, хатыны, ирен, баласын онытып, «сыеры»н бик озак саугач, улын, бер үзе генә юындырып, йокларга яткызды:

—Йоклап ал, улым, бераз. Әнкәнен күкрәкләре сөт белән тулышкандыр инде. Уянгач, тәмләп имәрсен. Сина ана сөте дигән мәм-мәм булыр...

Ә Заһидә юк та юк... Нигә керми инде?

Заһидә суга төшкән балта булды. Күрше-тирәгә биләмгә йөрү гадәте дә юк инде, югыйсә...

Бик борчуга төшкән ир, хәлне ниндидер бер яманга юрап, абзарлар тирәсен үзе әйләнергә булды.

Чыгып караса...

Йә, Ходай!

Сөтле чиләк ауган, лапаста—сөт чишмәсе, ә Заһидә тын да алмый ята. Үзе кулы белән ун кабырга ягын тоткан. «Өянәкле түгел иде ич!»—дип шикләнде ир. Аннан хатынына иелде:

—Заһидә, матурым!

—Заһидулла, жаным! Аһ-аһ! Кулларында жан бирәм...—диде хатыны ифрат сыкранып.

## IV кисәк

* * *

Зират эче тып-тын...

Адашып ник бер озынборын яисә черки халкы килеп чыксын. Бу тынлык башны чатната, чигәләрне кыса. Илаһи тынлык кына түгел, коточкыч дәһшәтле вә усалланган тынлык бу. Вакытның туктап калуы бугай бу...

Заһидулла Заһидәсе кабере янына чүгәләгән. Әти-әнисе каберләрен сирәгрәк зиярәт кылса да, бу урынга ул көн дә килә, дога укыганнан соң, тыела алмыйча, күз яшьләре коя:

—И, Заһидәм! Жан-матурым, кемнәр уйлаган болай булыр дип. Бер кабердә ике жан ятасыз ич: син үзең һәм күкрәк астындагы нарасыең, хет ул да туып житә алмады... Иртә иде шул әле, иртә... Ә син? Бик иртә киттең син, сандугачым... Багалмам, сабыең Галимулланы да туйганчы сөя, бага алмадың. Карлыгачым, сөйдем сине—сөярлек яр булгачтың. Былбылым, синнән башка, әйт, кем булыйм? Гомеремне әллә үземә очларгамы?? Үз-үзеңне үтерү гөнаһ булса да...

Мин бау алып лапас киртәсенә элдем, муенымны тыктым, аяк астындагы бүкәнемне этеп аудардым. Хуш, якты дөнья! Заһидәм янына китәм, дидем. Буыла башлаганымны хәтерлим, аннан тоташ караңгылык китте. Кайдадыр бик-бик еракта учак яна иде бугай. Шул учакка барасым килә, атлыйм-атлыйм, һич тә якынаймый нәни учак. Менә инде йөгерә дә башладым...

Шулчак...

Шулчак кемдер янакка китереп сукты:

—Чашкан тәре!— диде.

Күзләремне ачсам, лапаста—жирдә ятам, өстемә...

Кем булсын инде!

Шул!—Әхмәдулла иелгән:

—Мондый мордар үлемгә омтылганың өчен мин сине, чашкан тәре, үзем бәреп үтерәм,—ди.—Нәсел черткеч,—ди.—Кеше үлгәндә дә асылынып түгел, ә асыл булып үләргә тиеш,—ди...

Галимулламы?

Аны хәзер алар карый, Әхмәдулланың да кечкенәсе бар. Хатыны Асия икесен дә имезә, юындыра, киендерә.

Син киткәннән соң минем йорт-жирем, каралты-кураларым зирзәбәр килде. Хәтта: «Үз өемә үзем ут төртим мәллә?»—дип, шашып-юләрләнеп йөрдем. Ике яктагы күршеләрне искә алмасам, бу гамәлгә дә бара идем. Әмма кызыл әтәч минем өйгә кунса, күршеләргә дә очачак иде бит...

Маллармы?

Сыерны бабайга—әтиеңә илттем. «Миңа нәрсәгә ул?»—дип елады картлач. Ул шулкадәрле боеккан, тартылган, йөзендә күзләре генә утырып калган. Бер дә элеккеге олпат, Алып гәүдәле Аяз мулла димәссең. Авыр аңа, икеләтә авыр. Синең үлемеңне Асыл әби—әниең күтәрә алмады ич. Җирләп кайтып, берничә көн торуга, үзе гүр иясе булды. Каберләрегез рәттән...

Малларга килсәк, бурлы бияне Әхмәдуллага бирдем, бабай алмагач, сыерны да аларга илттем...

Эх! Матурым!

Синнән башка миңа берни дә кирәкми. Синсез—дөнья сансыз. Синсез—һәркем юньсез. Мин үзем дә юньсез...

Син үлгәннән соң, йорт җиремне зир-зәбәр китереп, бик каты эчтем мин, ай буе диярлек. Апрельдә һич айный алмадым, майда үземне кулга алдым. Әхмәдулла туганым:

—Үзең өчен яшәргә теләмәсәң, улың Галимулла өчен яшә!—диде.

Менә шулай...

Эх-эх! Матурым!

Теге, сиңа кадалган пычак, миңа дип, явызларның кулларына алынган ул. Бакча артлап кына килгәннәр алар. Икәү булганнар, өченчесе яр буенда каекны саклап калгандыр. Икәү булсалар да, өйгә, минем янга керергә курыкканнар. Малмыж төрмәсендә утырганда, мин аларның өчесен дә ил-умач итеп бәргәләп ташлаган идем. Шунамы минем янга керергә җөрьәт итмәгәннәр, йөрәкләре житмәгән. Җәһәт кенә сиңа пычак калап, бар пычрак эшләрен эшләп, кирегә сызганнар.

Эх! Эх! Эх!

Күңелем нидер сизенде бит. Бу гомер сыер савып утырмастыр ул, дидем. Иртәрәк чыксам, сине коткарып калып булыр иде әле. Озак яткансың син лапас астында. Каның ифрат күп киткән, ап-ак сөтне дә кызартып бетергән ул...

Сине өйгә алып кереп куйгач, мин, үз-үземне белештермичә, мылтыгымны алдым да, тегеләр артыннан чаптым. Очтым гына менә. Юлда эләксәләр, бәреп үтерә идем менә. Чебенне үтерергә кулым тарсынса да. Хәер, чебен бу бәдбәхетләрдән мең тапкыр яхшырак жан иясе ич ул...

... Нократ буена төшеп житкәндә, каек ярда юк иде инде, алар кузгалганнар.

Ул вакыттамы?

Нинди томан иде, нинди томан. Сөттән куе томан иде, хәтта миңа шундук томау төште...

Ишкәкләрнең суны чупылдатуын ишеттем һәм шул тавышка чамалап мылтыкны төбәдем. Аттым да аттым... Ничә тапкыр аттым?—хәтерләмим... Бары Аннаның тавышын ишеткәч кенә туктадым. Ул:

—Захидушка, одного убил уже, хватит,—диде. Дөрес, мин дә кемнендер ыңгырашканын ишеткән кебек булган идем. Патроннар бит аюга ата торган. Мин өч жанварга чамалап аттым...

... Мин синең үлемеңә бәет яздым. Исеме озын аның:

«Аяз мулла белән Асыл абыстайның бердәнбер кызы, Заһидулланың хәләл жефете, сөйгән хатыны, нәни Галимулланың әнисе гүзәл Заһидәнең яшьли дөнья куюы турында»,—дип атала ул. Тыңла, сиңа да укыйм:

Менәм әле биек тауга,
Үрмәләрмен үрләргә.
Күрәсене күрми-йөрми,
Кереп булмый гүрләргә.

Сауган ап-ак сөтләремә,
Тамды кызыл каннарым.
Заһидуллам, кулларыңда
Чыкты газиз жаннарым.

Миңа пычак кадаучылар
Сөенгән, көлгән микән?
Мин үлгәчтен хәсрәтеннән
Әнием үлгән икән...

Галимулла балакаем,
Тулышты имиләрем.
Күз алдымнан китми торды
Яратып имүләрең...

Юк, юк! Алга таба укый алмыйм, мона минем көчем житми. Бу бәет Җидән бабамның васыятьнамәсе белән бергә көзге артында тора. Кайчан да булса бер тулысы белән мин аны сина укырмын. Монда килеп...

Ул, тагы сыкрап, күз яшьләренә тыгылды.

* * *

Менә ничә көннәр инде ул ризык жыймый. Тамагыннан аш үтми. Бөтен җаны ярсынган, күнеле—ярсу. Авызыннан үткәне су да чәй, чәй дә су...

Беркөнне Әхмәдулла аңа пешкән балык белән шулпа алып килде. Сыегырак булгангамы—шулпа үтте, ә балык—юк! Бармый балык. Ә бит ул бик тә балык ярата иде...

Иң газаплысы, акылын томалаганы, аның шаштырганы, уен юләрләндергәне лапаска керү белән теге сүзләрнең ап-ачык ишетелүе иде:

—Заһидулла, җаным! Аһ-аһ! Кулларында җан бирәм...

Йә, Ходай!

Бәгърем! Бу сүзләреңне мәңге кабатланырлык, баш миләремне корытырлык, гомер эссе табада торырлык итеп әйткәнсең икән бит.

Андый вакытларда ул лапастан чыга да йөгерә. Кая таба? Моны ул үзе дә белми. Бары акылдан язмас, тулысынча шашмас өчен каядыр барырга кирәк. Бик тиз югалып торырга, хет чирек сәгатькә генә булса да башны алып кай яккадыр качарга...

Берсендә шулай аңгы-миңге килеш лапаска килеп кергән иде. Караса: сөтле чиләк ауган, җирдә кызыл канлы ап-ак сөт чишмәсе. Рәттән генә Заһидәсе ята:

—Заһидулла, җаным! Аһ-аһ! Кулларында җан бирәм...

Үз-үзен белештермичә өенә барып керде, карават астыннан мылтыгын тартып чыгарды һәм Нократ буена йөгерде. Шундый кызу чапты ки, бер караганда бакча артында иде, икенче мизгелдә—Нократ ярында...

Көне дә кояшлы иде, ае да нинди!—май. Кинәт Нократ өстен куе томан басты, аңа шундук томау төште. Ул мылтыгын күтәрде дә ишкәкләр суны чупылдаткан, нидер шыгырдаган, кемдер ыңгырашкан тавышны чамалап, шул якка карап атты да атты...

Таллыктан бер көтү чыпчыклар чыркылдап күтәрелде, кара каргалар каркылдап узды...

—Нишлисең, чашкан тәре, тилердеңме әллә?—дигән тавыш кына атудан туктатты аны. Караса—Әхмәдулла аның җилкәсеннән тоткан...

Булдымы чынбарлыкта андый хәл? Үтерсеннәр, ул мона, «әйе!»—дип, җавап бирә алмый. Булмады дияргә дә теле бармый. Бәлки бу галлюцинация генә булгандыр?..

Алай дисәң, чыннан да Нократ буеннан аны Әхмәдулла житәкләп алып кайтты ич...

Ах!

Әх-мә-дул-ла...

Беләсең микән җанымның ничек кыйналганын; рухымда кара күмерләрдән башка берни дә юк кебек. Алай дисәң, нидер пыскып кына яна анда.

Ах!

Бу олуг кичереш авазын бөтен дөньяда, барлык-барлык халыкларда бер Заһидә генә ифрат матур әйтә иде:

—Аһ-аһ!

Нинди аһәң белән «һ» авазын әйтә белә иде ул. Әле бит бер генә тапкыр «аһ!» түгел, ә игезәк «аһ» лар.

—Аһ-аһ!

«һ» янгырашын, аның матур ишетелешен!—бары Һиндстанда гына

әйтәләрдер, бәлки. Хәтта алар да Заһидәнеке кебек аһәнле «һ»не әйтә алмыйлардыр. Акыллы телле инглизләр дә, йомшак телле французлар да...

... Менә шундый авыр йөк астында яшәде Заһидулла. Югалту сагышларыннан да зуррак сагыш юктыр. Мәңгегә аерылу хәсрәтеннән дә зуррак хәсрәт юктыр. Шул сары сагыш белән көрән хәсрәт кушылсалар, кеше йөрәгенә кара таш булып кара кайгы утыра. Бар эретеп кара ул кара ташны?! Ана вулкан лавасы, мартен мичләре, ин кызу учаклар да чүп кенә булыр. Бәлки аны тәмугъ утлары гына эретер...

... Заһидулла уйларыннан арынып китә, почмактагы кисмәктән, чупырып алып, бер чүмеч су эчә. Өстәлдә сөтле савыт...

Ул сәерсенеп китә:

—Сөт? Кызыл канлы түгелме ул?

Аннан, саегайган хәтере кинәт яңарып, исенә төшә:

—Ә, әйе! Асия куеп китте бит моны. Су эчкәнче—сөт эч, дип...

Ул шкафтан кружка ала һәм, аны тутырып, голт-голт сөт эчә...

Башында саф бер генә уй кала:

—Нишләргә соң миңа, нишләргә?

Нидер кыланырга, нинди дер эш кирәк. Лапасны сүтеп атаргамы әллә? «Юләрләнмә,—ди эчке тавыш.—Иштең ишәк чумарын! Борынгылар: «Ишәкнең колагын кисеп чапкын итеп булмый»,—дигәннәр. Лапас сүтеп—Заһидә кайтырмы?!

Менә шунда Әхмәдулла килеп керә. Иплә генә исәнләшә, ишек тирәсенә чүмәшә һәм Заһидулланың әтисе Гыйбадулла тавышы белән, ул яраткан сүзләрне кыстыра-кыстыра, сүз башлый:

—Карале, малай! Син нәрсә бетерештен? Бирешәсен, димәк, бирешәсең, ипи-ана—мать!

—Мин күргәнне сиңа күрергә язмасын!—дип кенә сырлап куя Заһидулла.

—Күрәсене күрми...

—Гүргә кереп булмый,—дип, аның авызындагы сүзен тартып-каерып ала йорт хуҗасы.

—Менә без Асия акыллым белән киңәштек әле...

—Ни хакта?

—Синең турыда...

—Кызык!

—Кызык кызганычка әйләнмәсен иде...

—Һы!

—«Һы»сы һыдыр, киңәшебез будыр...

—Тынлыйм,—ди Заһидулла колакларын ифрат сагайтып.

Әхмәдулла дәшми. Ул аз гына уйлана:

—Киңәш бирү рәхәт, эш итүе авыр...

Заһидулла да сүз катмый, рас алар аның хакында нинди дер бер фикергә килгәннәр, ә анарчы киңәшкәннәр икән, димәк, юкка түгел. Хәлбуки ул үзе дә алардан бер киңәш көтә, мәгәр үз күңеле уй-хәсрәткә, хис-сагышка күчсә дә, үз-үзенә мәгъкуль киңәш-табыш бирер дәрәҗәдә түгел бит.

Көттерә Әхмәдулла, көттерә. Әмма ул—акыллы кеше, юктан гына киңәш дип синең өеңә килмәс.

Әхмәдулла нигәдер кесә төпләрен актарды. Тәмәке эзлиме дисән, гомерендә дә аракы-тәмәкене авызына алмады.

—Кит син авылдан!

Шаккатты Заһидулла. Утын тукмагы белән башына ордылармыни...

—Ә улым... Галимулла?

—Ул безнең Хаҗиморат белән үсәр. Алар безнең өчен игезәкләр кебек. Асия акыллым икесен дә тигез күрә...

Вәт киңәш! Авылдан китү турында ул үзе дә уйланды бит.

* * *

Чын бурнын бервакытта да үз исеме булмый. Ул урлый, талый, башкаларга сылтыйлар...

Заһидулланың китәргә җыенуын ишеткәч, «Кызыл лампа» күмәк хуҗалыгы рәисе Габдрахман аның өенә килеп керде. Түргә менде, аяк бөкләп утырды, бөердән генә чыгарып аваз салды:

—Китәм дисең инде, ә?!

—Китәм...—диде Заһидулла, сабырлыгын җуймаска тырышып, чөнки әлеге авыллдашын, шушы адәмне күрүгә, аның саруы кайный башлый иде.

—Качам дисең инде?..

—Башны алып качам!

—Сагынырсың—соң булыр..

—Яшәү бервакытта да соң булмый. Безгә бит билгеле бер вакыт кисемтәсе бирелгән. Ул гомер дип атала. Мин аны үземчә «Йозакланган вакыт» дип атыйм...

—Ха! Йозакланган вакыт, имеш. Син менә сүзләр уйлап чыгарырга да оста, телең дә баллы, теттереп сөйләшәсең. Акылың да Алладан...

—Синең дә искә төшәмени ул Алла?

—Беркем дә аннан ваз кичмәгән. Хәтта: «Алла юк ул»,—дип йөрүчеләр дә...

—Һы!—дәһри тәкъва булып утырсың әле?!

—Заһидә...

—Аның белән аваз чайкама! Беләм бит мин синең нигә килгәнеңне. Телең кортлы синең, ерактан исе чыгып тора.

—Шулай дисең инде?—Кунак ачы гына итеп көлемсерәде.—Тел дисең инде... Бел, бетәчәк ул тел! Безнең газиз татар теле. Күр, әнә бөтен иске Рәчәйне урыс теле басып килә. Ә татар телен казанга салып пешереп ашыйсы гына кала. Тел! Телеңне йотарлык бит ул тел...

—Һы! Карале, Габдрахман, синең дә тел тегермәнең яхшы гына тарта икән. Синеке дә, телне әйтәм, шулай булгач, үзең әйтмешли, бел: бетмәячәк ул тел!

Габдрахман бер кавымга телсез калды. Әмма... Белем ягы сай булса да, аның да акылы бакыр түгел, алтын иде. Шуңа ул, туган теле өчен үзе дә әчтән генә әрнегән кеше буларак, бу турыда башка сүз катмаска, менә хәзер генә булса да тел турында акыл сатмаска дигән уйга килде. Чыннан да, туган тел турында гәпләшергә килдемени ул монда?

Аның бит максаты бөтенләй башка. Ә тел өчен әрнүләр шуннан, районнан берәр нәчәлник кисәге килсә дә, ин беренче эш итеп:

—Хватит тары-барыкать, татары! Говорите человеческим языком, по-русски!—дип, башына авыр имән кисәк белән сугып куя. Хет партячейка, күмхуҗ активы яисә авыл советы җыелышы булсын. Бары күмхуҗның гомуми җыелышында гына бу сүзләрне әйтә алмыйлар, чөнки халык барыбер үз телендә сөйли. Шулай инде халыкны телеңнән, дәнеңнән, гореф-гадәтләреңнән, изге йолаларыңнан аеру бик тә читен эш, хәтта гамәлгә сыймаслык нәрсә...

«Кунак»ның үз сүзен әйтмичә боргаланып утыруы Заһидулланы ярсытып ук җибәрде. Бу көннәрдә нервы киеренкелеге анда хәттин ашкан иде инде:

—Хәшәп булып, сүз сатып утырма, Габдрахман! Мине хафага төшерә алмассың... Заһидәдән соң мин болай да кайгыдан айнымас хәсис адәм...

—Туктале, Заһи...

—Юлчыны юлда туктатмыйлар!

—Юлчыны юлда түгел, авылда туктаталар... Мөсафирны кундыралар, йоклаталар...

—Һы! Беләсең икән...

—Әллә каласыңмы?

—Калмасымны да белеп килдең...

—У-ух!—диде Габдрахман төнге ябалактай ухылдап.—Ялгызак син...

—Аллаһы Тәгалә дә—Ялгызак. Берүзе Галәм, Бөтендөнья белән идарә итә...

—Аның фәрештәләре бар. Улы... хатыны... булмаса да...

—Һәр әйбәт кеше—кешегә фәрештә ул. Булышадыр һәр эштә ул. Безнең Әхмәдулла белән аның акыллысы Асия жаннары белән фәрештә түгелләрмени? Минем жиденче буын Жидән бабам үз васыятьнамәсендә, аның да «Пәнжешәмбе Көнне Ишетелгән Пышылдавы»нда болай диелгән: «Синең колак артында жиде шайтан баласы утыра... Синең белән һәр жиде фәрештә йөрер!»

Габдрахман сискәнеп үк китте. Теге чакта әлеге васыятьнамәне укып ул хәйран калган иде инде. Әлеге Кәгазьдән нindидер Илаһилык, Изгелек кенә түгел, ә усал-каты, ватылмас-нык Өске Кануннар, Күк Закуннары Көче-Кодрәте Сизелә—иде...

Шул төнне уйланып кайтканда, ул үз-үзенә шулай диде:

—Кәгазьдән Өске Кануннар, Күк Закуннары Көче-Кодрәте Сизелә...

Ул кинәт кенә бөрешеп куйды һәм үзен Күк астындагы бер бөжәккә, хәтта гади бер ком бөртегенә тиңли башлады. Аннан күпмегәдер бу халәтеннән арынып, түшәмгә бер ноктага таба карап торды да акрын гына Заһидуллага эндәште:

—Син мине шайтан дисең инде. Колак артындагы жиде шайтан баласының берсе...

—Мин алай димим, Габдрахман. Барыбыз да бер Күк астында йөрибез, бер һаваны сулыйбыз. Уртак Төп Атабыз Адәм белән Төп Анабыз Хавадан башланганбыз. Аллаһы аларны да хөкем иткән, Ожмахтан Жиргә сөргән. Шуңа күрә Төп Хәкимебез дә, Хөкемчебез дә бер генә—Аллаһы Тәгалә вә Сөбеханәкә. Ә фани дөньяда хөкем кылучылар, закун чыгаручылар, идарәчеләр—барысы да вакытлыча...

—Әйбәт әйттең!—дип, нигәдер сөенде Габдрахман. Ни сәбәпле шатлана? Һәм йөзе көләчләнде, Заһидулла моны тикшереп торырга вакыт та тапмады, ә ин дөресе, үзен шул эшкә тартырга тиешле санамады...

Аның уе хәзер күбрәк авылдан чыгып китү утында яна иде.

Габдрахман аягына басты:

—Хуш, сау бул!—дип, аңа кулын бирде.

Заһидулла да аның соңгы сүзләренә разый булып, бу риясыз күңел белән бирелгән кулны ирләрчә нык итеп, каты гына кысты. Үзе дә киләшчә куллы булган Габдрахман, тагы бер мәртәбә йорт хужасының тимер беләкләрен тойды вә көнләшүдән битәр, эчтән яшерен сокланып куйды: «Көчле дә соң, жен! Ай-һай, көчле...»

Ишек төбенә житкәч, Габдрахман аңа борылып карады:

—Син... йорт, каралты-кураларынны колхозга сатып кит. Кайчан кайтасың әле? Һәм, вупше, кайтырсыңмы? Сукбай бит син хәзер...

—Сукбай булсам да—рисвай булмам, Габдрахман! Авылым йөзенә, татар халкының битенә кызыллык китермәм. Ә йорт, каралтыларны күмхужга мин бушка да бирәм. Кирәкми миңа сезнең акчагыз! Син миңа өй-абзарларны күмхужга алуың турында таныклык бир. Бирмәсәм дә—ала идегез сез аларны...

«Хәйләкәр, чукынчык!»—дип уйлады Габдрахман.

* * *

Йәле, Бабам!

Әйт әле, жиденче буын Жидән Бабам! Васыятьнамәңнең Чәршәмбе Көн Ишетелгән Пышылдавында ни диелә?

«Ниләрең бар һәм булыр, Кеше?

Менә болар:

—Барам дисәң, жиде юл сиңа, берсен сайла...

—Кайтам дисән дә, жиде юл сина, берсен сайла...»
И, Газиз Бабакай!
Барам дисәм:
1) Бохара...
2) Байкүл буе...
3) Башкорт ягы...
4) Кырым...
5) Балтыйк иле...
6) Себер ягы...
7) Татар бугазы...

Чәршәмбе көнне әти-әнисенен каберләрен зиярәт кылганнан сон, Асыл абыстай баш очында дога укыганнан сон, яшьли гүргә кергән сөеклесе Зәһидә янында бик озак елап юанганнан сон...—өенә кайтып, биштәренә ин кирәклесен генә алып, анын да эчке кесәсенә Тамара бүләк иткән асылташлы алтын чылбыр-муенсаны һәм Жиденче Буын Жидән бабасынын Изге Васыятьнамәсен, Өске Кануннарны, Күкләр Пышылдавын салганнан сон, Зәһидулла үз гомерендә беренче тапкыр диярлек, әйе!—бу тәүге эш-гамәл иде,—«Йәле, Бабам!»—дип, ул белгән, жисеме күптән туфракка әйләнсә дә, исеме калган, Жаны Жидегән Йолдызларга кадәр очкан, Рух Утлары онык-оныкларында сакланган Олуг-Газиз-Изге Бабакаена мөрәжәгать итте.

«Барам дисәм: Бохара, Байкүл буе, Башкорт ягы, Кырым, Балтыйк иле, Себер ягы, Татар бугазы» дип, ничек тиз генә санап китә алды ул? Әллә монысын да Күкләр Пышылдадымы ана? Һәрхәлдә, юктыр. Монда ниндидер Илаһилыкны кертү хата булыр иде. Гомумән, жаны белән бервакытта да ялганга бара алмаган Зәһидулла туган иленен бу төбәкләрен санаганда, ифрат та аек уй йөртте. Дөрес, бу мәшһүр вә кызыктыргыч исемнәр анын хыялында яшәмәде түгел, яшәде. Ләкин Зәһидәгә өйләнгәннән сон, ул уйларында «Нократ аръягы» дигән кунеленә якын бер төшенчәдән—Тамара куышы куелган тәгаен жирдән!—артык башкаякларны уена да кертә алмады. Кеше гомере—»йозакланган вакыт»,—дип үзенчә фикер йөртсә дә, һәркем өчен аерым бер «йозакланган жир» булуына да төшенде ул. Әйтик, «гомер—йозакланган вакыт», ягъни мәсәлән, синен фани дөньяда ничә ел яшәячәген, шул вакытта ниләр күрәчәген, ни-нәрсәләр эшләячәген генетик код буларак Тәненә-Жанына салынган, ул Ләүхелмәхфүздә-Язмыш Китабында—язылып куелган, алдан билгеле, ди. Шунын кебек синен өчен гомер калып яшәр, эшләр эшләр, күрәсен күрер вә гүргә керер урын да бар. Андый урынны Зәһидулла «йозакланган жир» дип атый. Ягъни мәсәлән, Тәнре тарафыннан мәнгегә сина бирелгән жир. Ожмахмы ул жир, әллә тәмугъмы? Хикмәт хәтта анда да түгел. Адәм балалары жәннәттә дә, жәһәннәмдә дә яши алалар. Бары бу урын синен өчен: «Йозакланган Жир» булсын...

Әти-әнисе, бабалары нигезе анын өчен «йозакланган жир» булмавын Зәһидулла бөтен күнеле, нечкә бәгыре белән сизде. «Бөек Күчеш»ләр вакытында татар жанына сенгән дәрвишлек, дүнгәләклек, үз урынынны, «йозакланган жир»енне эзләү магиясе, Зәһидәсе үлгәч, коточкыч явыз көч-куәт, дәрт-дәрман, йокыдан уянган инстинкт булып калкып чыкты анда. Ул белә, ул сизә, ул тоемлый: хәзер инде бу йортта, әйтергә кирәк, бу изге урында, ата-бабаларынын кендек каны тамган туфракта аны инде беркем дә тота алачак түгел!

Бер түгел, хет йөз, мен Габдрахманнар кал дисәләр дә, күмхужга керергә көчләсәләр дә, бу—Нократны, кирегә борып, үргә агарга кушу булыр иде. Ә Нократ ага, үз юлыннан ага һәм—юлларын үзгәртә-үзгәртә дә ага. Әнә аргы як болыннардагы «Иске Идел» күле нәрсә ул? Халык исемне бервакытта да юктан гына кушмый. Димәк, Нократ кайчандыр «Иске Идел» дигән урыннан, кояш чыгышы ягыннанрак аккан, хәзер көнбатышкарак күчкән. Татарнын ан-фикере, жан-уе кебек...

... И, уйлар-уйлар... Гүя далада куйлар. Күнелемә көтүегез белән

килеп керәсез һәм, «тояк эзләре» калдырып, чыгып та китәсез. Ничек дигән әле бабайлар? «Бер куй аркасында мең куй су эчкән»,—дигәннәрме? Әйе, бер кешедә мен кешелек яхшылык ятарга мөмкин. Шулай ук мең кеше башына җитәр явызлык та...

Тарихка гына борылып бак: моңа мисаллар күктәге йолдызлар санынча...

Авылыннан китәр алдыннан Заһидулла сабыр, иркен сулышлы, аягы җиргә нык басып йөрүче адәми затка әйләнгән иде инде. Ә бит... Әхмәдулла кереп киңәш-табыш иткәнче, тәгаен генә әйткәндә, авылдан кит дигәнче—ул арлы-бирле йөреп, тиктомалдан гына тирән уйларга батып вә томырып сөягән томса бәндәгә әйләнеп, үзен-үзе югалта бара башлаган иде. Бер карыйсың, Акыл Күлләрендә йөзә, икенче күренештә—Кайгы Сазлыгында ятып, һәр таныш-белешенең, якыннарының, туганнарының үзәген өзә. Бигрәк тә Әхмәдулла белән Асия хафаландылар. Әхмәдулла туганнан туганы булса, Асия яшь кыз чагында, унҗиде яшьлек болынында, аңа күзе төшеп, Мәхәббәт чирләре белән авырып, Өмет Дингезләрендә йөзеп алган иде. Дөрес, Заһидулла аңа тартылмады, ул Аяз мулла белән Асыл абыстайның бердәнбер гүзәле Заһидәгә күз салды, аны сөйде...

Сөярлек кеше иде Заһидә!

Тирә-юньдә бер чибәр булу өстенә, ул кара эштән дә чирканмады, акылы да алтынланган, белеме дә бар, шулар өстенә үзен ифрат та гади тота белә иде. Юкка гына авыл халкы аның турында:

—Казаннарга алып барып куйсаң да—менә дигән кәртинкә булыр иде бу!—дип әйтмәгәндер.

Туган ягын ташлап, дәрвишлек юлына күчәр алдыннан, булачак мосафир Заһидулла иң беренче эш итеп бабасы Аяз мулладан, Заһидәнең әтисеннән хәер-фатиха алды. Карт:

—Юлларың Ак булсын, колагың сак булсын, кияү!—диде.—Кирәкмәгәнгә тешеңне агартма, теләмәгәнгә көчеңне чыгартма. Туган ягыңны, изге доганны онытма. Ашыйсы ризыгың алып китә сине, шул ризыгың алып кайтыр...

Әхмәдулла һәм Асия белән дә саубуллашып, соңгы тапкыр улы Галимуллага моң-карашын салып, чәршәмбе көн иртән ул ерак җирләргә, ят илләргә юл алды.

* * *

Олуг Чикләргә барып житү өчен үзеңне чикләүләр кирәк. Бохарага юл тоткан Заһидулла ипи-суда гына утырды. Аз-маз бәрәңге дә эләккәләде. Әхмәдулла кесәсенә көчләп диярлек салган акча, далалы якларга якынлашкан саен, комга сеңгән су урынына юкка чыга башлады.

Ә бит беренче көннәрне Асия төенләп биргән азык-нигъмәтне чемченеп барганда, ул үзен чын тархан, морза, би итеп сизде. Әле ул гынамы? Поездга Швеция короле, француз графы, испан герцогы, итальян князе, поляк паны, урыс генералы утырганмыни! Барысы бергә шушы көчле-куәтле, ат жегәрле Заһидуллада кушылып, ул татар яраткан казылык, пешкән ит, бодай күмәче, каты итеп кайнаткан чәйне тыгыз, эре, ап-ак тешләре белән керт-керт итеп, шикәр ватып кына ашады-эчте. Керт-керт итеп шикәр ваклаганда, күз алдына бурлы биясе килде: ул да печән-саламны, башак-солыны әллә нинди!—җанга рәхәтлек, тәнгә сихәтлек бирә торган бер тәм-ямь белән керт-керт итеп ашый иде...

Аннан уйлары туган авылына күчте, күнеле белән Заһидәсе каберен зиярәт итте...

Улы Галимулланы искә төшерүгә, күз төпләре ирексездән юешләнеп китте, аны гаҗиз итте.

—И, балакаем! Атаң менә шушындый да әшәке кеше инде синең... Үз нарасыең, күз нурын, дәвамчысын ташлап, авылдан чыгып ук качты ич ул, бәдбәхет... Сабыем! Көт мине, исән-сау килеш кенә көт. Әтиең кайтыр...

Ишим елгасы буендагы Петропавел шәһәренә килеп житкәндә, Заһидулланың кесәләрендә жилләр исәләр иде инде...

Юлдашы карт казах бик сизгер кеше булып чыкты.

—Гуй-гуй, нугай,—диде ул.—Провиант жок, ә?

Заһидулла аңа карап, кызыксынып көлеп тә куйды: бу дала кешесенең чи казах сүзләре арасына «провиант» кебек интер-сүзне кыстырып куюы бик тә гажәп иде. Гүя чүлдә кәкре-бөкре саксаул урынына Нократ буендагы текә-төз нарат үсеп утыра...

Карт гажәп тә үткер күзле кеше булып чыкты, берчак Заһидулла, онытылып китеп, биштәренең эчке кесәсен актарып—капшап маташканда, ул аңа әйтә калды:

—Ул кәгазьгә ни язылгандыр, белмим, ә теге сары чылбырыңны читкәрәк яшер. Мина да сары шайтан булып күренә ул. Бер тәңкә өчен кеше үтерүчеләр бар... Башыңны ашамасыннар... Дала бу, дала...

—Аңлыйм, бабай...

Аннан соң карт төенчеген чиште, аңа кымыз эчерде, пешкән ит ашатты...

...Петропавел шәһәрендә әтисенең энесе Шәйхулла яши иде. Эзләнә торгач, тапты ул аны. Кешеләрдән, бигрәк тә татарлардан сораша-сораша.

Тапты да йортын күреп турыга катты: нинди өй булсын бу?! Бу бит иске мунча, ниндидер хибарка, тавык кетәклеге. Ишектән яртылаш бөгелеп керәсе, урам якта уч төбе кадәр ике тәрәзә, ишек алдына «сыңар күз» генә карый. «Кетәклек»нең эче тынчу, идәне гасыр юылмаган, сәкесе, ышкылып утыра—ята торгач, әллә нинди ят төсләргә кереп каралып беткән. Кайчандыр ап-ак итеп агартылган мич корымга батып бара.

Сәке өстендә күзен челт-челт йомып, бохар мәчесе кебек йомылып вә ярым йоклап утырган Шәйхулла абыйсын күргәч тә шаккатты: «Бетәшкән-бетерешкән карт!»

Ә бит гражданнар сугышы тәмамланып, НЭП чорларына кергәч, туган авылына кайткан иде ул. Тазалыгы, матурлыгы, өстендәге затлы киемнәренә карап туя алмадылар. Бер атна кукрайган әтәч, койрыгын җәйгән патшалар кошы тавис булып урамнарда йөрде ул, күршеләргә кергәләп утырды.

Хәзер менә...

Да-а-а, хәлләр!

—Синме бу, абый?—дип сорады Заһидулла, үз күзләренә үзе ышанмыйча.

Карт та аны танымады:

—Кем дим үзеңне? Таныш та кебек...

—Гыйбадулла абыеңның улы Заһидулла бит мин, абый...

Карт аңа шикләнеп карады:

—Танымыйм, һич танымыйм...

Аннан ул урыныннан торды, уң кулын калын-озын-аксыл кашлары өстенә куйды да күзләрен чепиләндерде:

—Картайдым, картайдым...

—Бирешмәгәнсең әле,—дип аны юатты энесе.

—Эх!—диде Шәйхулла.—Картаю—шул аю инде ул...

Аннан чыннан да, аю кебек аякларын чалыш-чолыш басып, аның янына ук килеп терәлде:

—Абый бер көеме?

—Әти вафат...

—Мина да вакыт житте...

Шәйхулла елап ук жибәрде. Өйне кинәт кенә гүр тынлыгы басты. Ни сәбәптәндер, икесенә дә читен иде. Ничә еллардан соң очраштылар,

тегесен-монысын сораштырырга кирәк, сөйләшеп утыруы бик мәслихәт булыр иде кебек тә—сүз сүзгә ялганмый, икесе дә телсез, хәтта туганлык тойгылары да калыкмый, күнелләре бозлы чишмә булып каткан. Бәлки, яшьрәк кеше буларак, Заһидулланың үзенә сүз катарга, йомшаграк итеп дәшәргә кирәк булгандыр, ләкин Шәйхулла абыйсының каткан кара түбәтәе, кырык ямаулы бишмәте, аягындагы иске каталары аңа: «Сөйләшмә! Дәшмә!»—дип тора иде сыман.

Шуның өстенә өстәл өстендәге төсе унган алама самавыр, каткан ипи валчыклары, чәйнәлеп-тешләнеп тә чәйнәлеп бетә алмаган вобла балыгы: «Саубуллаш! Чыгып кит моннан!—диләр сымак тоела. Вобла? Нигә ул аңа?!»—дип уйланды ул.

—Ярый, абый... Хәлеңне белеп чыгыйм әле дигән идем...

—Китәсеңмени?

—Юлчының юлда булуы яхшы!—Заһидулла авыр тойгылар астында ишеккә атлады, карт, лаш-лош каталарын өстерәп, аны озата чыкты.

Кайчандыр Төньяк Казахстандагы Петропавел шәһәренең иң бай сәүдәгәрләреннән берсе булган әтисенең энесе Шәйхулла абыйсының шушындый ялангачлык, барып чыккан ярлылык, хәер сорашуга өндәүче хәерчелектә яшәвенә аның җаны әрнеде, күңеле сыкранды, йөрәге елады. Морза, тархан Җиданнең буыны шушы мескенлеккә, юксыллыкка төшсен әле?! Үл дә кит инде!

—Карчыгым үлде...—диде карт капка төбенә җиткәч...

—Урыны җәннәттә булсын!..

—Балалар таралып бетте...

—Кайгырма, абый, кайтырлар алар, үз аталары янына кайтырлар... Авыр гына хушлаштылар...

Картның кулына гүр суыклары ингән иде...

* * *

Бер кешегә ачу саклаган кешене начар адәм дип әйтә алмыйсың. Берничә адәмгә эчендә пычак йөрткән инсанны үчле бәндә дияргә була, ә бөтендөньяга ачу тоткан ир яисә хатын-кыз туп-туры мәгънәсендә бәхетсез зат инде ул, чөнки хәтта ерткыч хайваннар да хәятне яраталар, барысына да табигать вә тереклек итү ошый, алар үз балаларын күз карасыдай саклыйлар...

Шәйхулла абыйсының капкасыннан чыгып барган Заһидулланың әтисенең энесенә карата бернинди дә ачуы юк иде. Дөрес, мосафир энекәшен адәм рәтле каршы ала алмады. Соң нишләрсең!

Карт бетерешкән, саулыгы-байлыгы да элеккеге түгел. Әйе, олыларга хас олпатлык белән акыллы хан-солтаннарга, һәр соравына җавап табучан кинәшче-вәзирләргә, фәйләсуфлыгы йөзенә чыккан шагыйрьләргә хас булган тиндәшсез сүз, тирән уйларын, үткен фикерен әйтә алмады, ә бит заманында аның теле телгә йокмый иде, чөнки һәр чын сәүдәгәр иң беренче дипломат, аннан соң сөйләкче-оратор һәм шигырь язмаучы шагыйрь дә була. Мондый нәрсә тагы кыз ярәшкәндә яучыларда гына сизелә.

Ул башын кая куярга белми үзенчә кайгырып барганда, аңа кемдер кычкырды:

—Әй-әй! Кем... иптәш, кәнишнә, туктагыз әле.

Борылып караса, кыскарак буйлы, имән төбе кебек бер адәм, юан гәүдәлеләргә хас булмаганча шәп кенә юыртып килә. Заһидулла әлеге адәм затына каршы китте һәм алар ике куллап җылы гына күрештеләр:

—Әссаләмүгаләйкем! Ходай исән-саулык, тазалык байлык бирсен!

—Вәгаләйкүмәссәлам! Сезгә дә шуларны телим,—диде ул да аңа.

—Сез... кем, иптәш, кәнишнә...

—Исемем—Заһидулла, мосафир мин. Нократ ягыннан килдем.

—Әй-әй! Кем, иптәш, кәнишнә... Мосафир икәнегезне белеп

артыгыздан йөгердем дә инде мин, кәнишнә...

—Йомышыгыз ни иде?

—Кем, иптәш, кәнишнә... Сезне, юлчыны үзебезнен татарымызны, кәнишнә, иң әвәле чәйгә чакырам.

—Мин сезне белмим дә ич...

—Үзем дә татар кешесемен, кәнишнә... Исемем Зиннур. Мин—бәләкәй, син—зур, кәнишнә...

—Белмәгән кешене бимазалап, эшен калдырып, гаиләсен ялыктырып йөрү дөрес булыр микән?—дип шик белдерде Заһидулла.

—Китап мосафирны ашатып-эчертеп, йортында кундырып чыгаруны яхшы гамәл, хәтта ки савап диган, кәнишнә,—дип томалады аның авызын Зиннур.

Кәнишнә Зиннурның йорты тыштан гына искерәк күренә икән, ә эченә керсән! Идән тулы паласлар, стенада аллы-гөлле келәмнәр, шкафларда чәй чынаягы, бәллүр вазалар, кытай фарфоры. Өй эче ниндидер хуш ис белән тулган, түгәрәк өстәлнең нәкъ уртасында комганга тартым савытта күз явынны алыр чәчәкләр. Ә бер шкаф китаплар белән тулган...

Һы!—Заһидулланың яраткан ымлыгы ычкынды.

Эх!

Менә болай да яшәп була ич...

Кухня ягыннан башына һәйбәт яулык, өстенә чибәр күлмәк кигән өч иякле таза-матур хатын күренде. Кулында көмеш беләзек, колак йомшакларында алкалар, муенында затлы муенбау. Кырык яшьләрдәге әлеге хатын аның белән ипле-итәгатьле генә, әмма күзе белән ашамыйча гына күреште. Күрәсең, алар йортында ят кешеләр беренче генә түгел.

—Менә, әнисе, кәнишне...—диде Зиннур.—Мосафир адәм. Үзебезнең татарымыз. Бик тә тәртипле, казах әйтмешли, якшы нугай...

Утырып йортка дога кылдылар.

—Йортыгызга-иминлек, үзегезгә—саулык-исәнлек, балаларыгыздан игелек күрегез,—диде Заһидулла.

—Үзебез—исән булыйк та, эшебез үшән бармасын,—диде Зиннур.—Иң беренче, исәнлек, кәнишнә.—Мосафирларны, кирәге чыгып юлга чыкканнарны бәла-казалардан, яман кешеләрдән сакла, Ходаем!—диде хатын.

Зиннур кинәтрәк кеше икән. Дога кылуга хатынына, дорфа итеп булмаса да, фәрман-боерык рәвешендә әйтә салды:

—Шәрифә, жәелеп утырма! Йортта ни нигъмәт-сый, ни-нәмә азык-ризык бар, барысын өстәлгә жый! Коры пычак тешләп утырмас ич ул, кәнишнә...

Өстәлдә чын мәгънәсендә сый-нигъмәт иде. Шөн якларында, Нократ буйларында әйтелгәнчә:

—Туй сые!

Хатын алар белән ашамады, бары аш бүлде, алларына тастымал куйды. Кулларын юганда, көмеш комганнан су агызып торды. Мондый тәртип-тәрбиягә күнекмәгән Заһидулла унайсызланып бетә алмады. Бу йортта ашау да, кешегә хөрмәт тә зурдан иде, күрәсен...

Алар аерым-аерым йокы бүлмәләренә жыенганда, ишектән бер карт килеп керде:

—Зиннуржан!

—Әйе, кем ни, Закиржан абый. Ни йомыш иде, кәнишнә?..

—Жизнән үлгән...

—Вот те на! Кәнишнә, вот те...

—Без картлар төнен сакларга барабыз...

—Мин дә инде, кәнишнә...

—Мин дә калмыйм,—диде Заһидулла.

Кәнишнә Зиннур, ят-йокла, син юл кешесе дип, аны никадәр кыстаса да, ул үз сүзендә тормый калмады:

—Кеше кадәр кеше вафат булсын да, син ял итеп ят?!

—Кәнишнә...—генә дия алды тегесе.

Өчәүләп Зиннурның вафат җизнәсе йортына киттеләр. Күпмедер барып, бер кечкенә генә иске, авышкан капкадан кереп барганда, башын күтәреп караса, ул: «Ах!» итте. Бу мунча-йорт аның Шәйхулла абыйсының куышы, черек бүрәнәләр эчендәге торагы иде.

«Дөнья—тар!»—дип кенә уйлый алды ул. Һәм әлеге «йорт»ка, аның эчендә үлеп, инде мәет булып яткан кешегә ник бик нык тартылганын да тойды. Туган абыйсы тарткан аны монда, бабайлардан килгән изге кан тарткан...

Әллә Җидән бабасының Рухы пышылдаганмы? Ни булса да бар...

Шәйхулла абыйсының мәет салкынлыгы кергән кулын тотып хушлашканда ук, ул нидер сизенгән иде инде. Аның кулыннан иңгән суыклык уч төбендә һаман саклана әле. Гүя йодрык кадәр боз катмары тотып йөри...

Картның өен карангылык баскан иде. Лампасы да өчле генә булган, аны кабызып җибәрергә кәрәчине дә юк. Төнен Шәйхулланың үле тәнен сакларга, ясин чыгарга, догалар укырга килгән бабайларның берсе өеннән лампа маен алып килгән икән. Алар Зиннурдан башка бу йортка, черек умарта оясына керергә генә кыенсынып торганнар...

Лампаны кабыздылар...

Сары ут Шәйхулланың тире дә сөяктән генә калган көрән-соры йөзен комсызланып ялап алды...

* * *

Мазарстанда гомуми тынлык хөкем сөрсә дә, ниндидер мазасызлык бар иде. Әлеге тоем һәркем күңелендә булып, Шәйхулла картны тавыш-тынсыз гына җирләделәр дә, өрәкләрдән өркегәндәй, тиз-тиз генә таралыштылар.

Һәрхәлдә, зират күңел ачу урыны түгел...

Каберлеккә килү—якыныңны зиярәт кылу белән гомереңнең ахырын уйлау ул. Мазарстан—туй урыны түгел, уй урыны. Кеше уе...

Зираттан чыгуга алар дөнья мәшәкатьләренә күчтеләр.

—Өчесен, җидесен уздырмыйча—китмисең!—диде Зиннур Заһидуллага.—Кәнишнә, китмисең...

Кәнишнә, Зиннур Петропавелның мөхтәрәм, мөрәвәтле, яхшы мөгамәләле кешесе булса да, аның җанында эчке бер кискенлек, тыйнак дуамаллык ятканын ул беренче көнне үк сизеп алган иде инде...

—Бүген җизнинең абзарын, каралты-курасын сүтеп атабыз. Утынга, кәнишнә... Тормасын урам ямьсезләп.

—Бик хуп! Мин риза.

—Өе белән капкасын калдырабыз, кәнишнә... Бәлки бер кирәге чыгар...

—Абыйның гомере шул бәләкәй генә йортта узды микәнни?

—Әй-әй!—дип әрнеде Зиннур.—Узмады, кәнишнә... Аның йорты ике катлы иде. Яна влачлар өеннән куып чыгардылар...

Балта, лом, кадак суыргыч алып килеп эшкә тотындылар. Ике таза ир өчен кәкрәйгән-бөкрәйгән, баганалары авышкан, түбә такталары череп беткән тәбәнәк кенә лапасны пыран-заран китерү чүп тә түгел иде: төртәсең—ава, сугасың—егыла, дигәндәй...

Эш бетүгә, әз генә хәл алдылар да, Зиннур аңа эндәште:

—Әйдә, тәрәзәләренә күзлек кидерик инде. Алар хәзер, хуҗа киткәннән соң, тома сукыр булмасалар да, барыбер күрмиләр. Сукыр тәрәзәләр, кәнишнә...

Кәнишнә Зиннур шаян-җор, хәтта бераз мут та кеше икән, әле. Тәрәзәләргә күзлек кидерү—аркылы такта сугып чыгу булды. Ә менә...

Ә менә «сукыр тәрәзәләр» Заһидулланың җанын өшетте... Ул үз

гомерендә ишеткән әллә нинди авыр, явыз, коточкыч сүз иде бу:

—Сукыр тәрәзәләр...

Анын хәтта тәне калтырап китте:

—Сукыр тәрәзәләр? Һы!

Тагы утырып ял иттеләр. Дөресе, утырып уйландылар. Икесе ике уйда иде, ләкин уртаклык та булмый калмады: гомер, анын ахыры, бүген гүргә кереп яткан Шәйхулла карт Жиданов турында уйлар, ни кусан да, өйгә ияләшкән канатлы кырмыскалар сыман һаман баш миләрен тыгызлый иде.

Зиннур тагы сикереп торды:

—Әйдә жизнинен чуланын да сүтеп атыйк инде. Тормасын күз буяп. Тормасын, кәнишнә...

—Хуп,—диде бер сүз белән Заһидулла.

Чоланга керделәр, анда жыелган иске-москыны күрделәр: тишек чиләкләр, ертык капчыклар, ниндидер шешәләр, борынсыз чәйнекләр, күгәргән карават тимерләре, ватык чынаяклар, сабы төшкән таба, аяксыз өчаяклар... Тагы әллә нәрсәләр...

Бу чүп-чарны борын кысып вә жирәнеп кенә ишек алдына ташыдылар. Дөресе, чыгарып ыргыттылар. Ин почмакта ниндидер черегән киемнәр, бүрек, чабата, икегә аерылган камзул, катып беткән түбәтәй астында кендектән биеклектә илле литр су сыешлы мичкә тора иде. Ачып карасалар—ул муеныннан тикле тоз белән тутырылган. Агачтан эшләнгән булганга, анын эчке ягы күгәреп чери дә башлаган.

—Нигә кирәк булды икән аңа бу кадәрле тоз?—дип аптырады Заһидулла.

—Тозлы вобланы тозлап ашарга, кәнишнә,—дип көлде Зиннур.

Чыннан да, юмор-жорлык бар бу Нижгар мишәрендә.

—Нигә?—дип кушылды Заһидулла да уенга.—Минем тозлы килькигә писүк сибеп ашаган танышым да бар иде. Булмас димә!

—И-иһ! Әй-әй! Кәнишнә!—диде дә Зиннур балтасы белән «донк» итеп мичкәнен түбән ягына китереп сукты. Ике такта шундук сынып, мичкә эченнән нидер идәндә яткан черек калайга килеп төште. Чылтырап-чынлап, әллә нинди яңгыравыклы матур авазлар чыгарып. Гүя бәллүр рюмкалар бер-беренә бәрелешеп куйдылар.

Билфаразлап тормадылар, икесе дә тоз катмары дип уйладылар. Зиннурлар өенә кайтабыз дип, караңгы чуланнан ишеккә таба киткәннәр иде, Заһидулланын жиненнән кемдер тарткандай булды. Нәкъ менә: «Борылып кара әле...»—дип.

Караса...

Әйе, борылып караса...

Мичкә янындагы черек калайда тоз катмары түгел...

Юк, ул түгел!

Ә кояш утында янып берничәме, әллә берәү генәме сары нәрсәләр ята иде.

Зиннур инде капкага житкән, аны көтеп тора. Заһидулла, ике адымда сикереп килеп, сарытүшне уч төбенә кысты:

—Тоз гына түгел бу...

Тагы биш сикереп, Зиннурны куып житте. Анысы урамга чыгарга дип, исерек капканы ачкан иде инде, бары «катырак япсан, авар бу» дигән бер шик-шөбһә белән теге якка атламыйчарак кына тора.

—Зиннур абый!

—Әй-әй!.. Кәнишнә...

—Кара әле...

Заһидулла уч төбен ачты.

—Вот те на! Кәттә бу... Алтын муенса...

Анын күзләре зурайды, мангае жыерчыкланды, авызы бәлешләнде:

—Карун! Кәнишнә, карун. Кәнишнә, жизни үзе... Ну, карун...

Зиннур тынсыз гына беравык торды да беркавымнан өстәп куйды:

—Алтыны да булган... Үзе чүплектән шешә, чүп-чар җыеп, шуларны юып-рәтләп, сатып тамак туйдырды. Баллы чәй эчмәде, юньле ризык капмады. Апам-канәтемне дә ачка үтерде. Ни әйттем бит, безгә генә килеп торыгыз, хет тамагыгыз тук булыр дип...

Зиннур еларлык дәрәҗәгә җиткән иде инде, хәтта бер зәррә вакытка алтынны да онытып торды. Зәр (алтын) кадерен зәркан гына белер ди, бит...

Кердeләр чоланга, карадылар, тозны бушаттылар. Мичкәнең дүрттән беренә чыннан да алтын тутырылган иде. Иң хәтәре: Петропавел чиркәвенең бер потлы алтын тәресе дә монда сыйган. Ул дүртәр килолы, ягъни унар гөрәңкәле дүрт кисәккә аерылган. Һәр ун кадаклы алтын аерым-аерым җәелеп ята.

—Кәттә!—диде Зиннур.—Әй, әй! Кәнишнә, ә?! Бу алтын тәрене юлбасарлар урлаган иде ич. Җизнигә алып килеп сатканнар, кәнишнә...

—Кая боларны? Дәүләткәме?—дип сорады Заһидулла.

—Ә дәүләт безгә кукишмы?! Кәнишнә, ку...кукиш...

—Нишләтик соң?

—Бүләбез! Җизни өлеше—сина, аның җәмәгате өлеше—миңа...

—Ә ике өлеш?

—Финляндия татарына чыккан кызына һәм Швециядәге улына...

... Заһидулла үз өлешен алып тормады...

* * *

Менә ул Бохара!

Аның җире—аяк астында, ә мәчетләре—Күктә.

2000 яшьлек шәһәр бу. Уналтынчы гасырдан Бохара ханлыгы, Бохара әмирлегенең башкаласы. 1920 елда ул совет республикасына әйләнгән...

—Һы!—диде Заһидулла.

Эх!

Бохара—шәһәр генә түгел ич, шәһәр-музей ул. Мондагы архитектура истәлекләрен, ай буе карап йөрсәң дә, карап бетерерлек түгел. Менә Поп-Калян, Ләби-Кауз, Кош-мәдрәсә ансамбле. Чат саен базар, һәр базарда меңәр кеше. Борынгы һөнәрчелек, сәнгати әйберләр...

Әнә яулыгын кашына кадәр төшереп бәйләгән чибәр вә япь-яшь үзбәк кызы, авызын нәфис кулы белән томалап, ана күзләре белән генә елмаеп узды. Эчтән кигән озын ыштаны белән ефәк күлмәге арасында җил дә адашып алды.

Эх-ма! Эх!

Заһидулла күзләрен йомды. Заһидәсе вафатыннан соң ул гүзәлләргә күз салмый башлаган иде инде. Ә шулай да бу хур кызын, оҗмах кошын бер генә тапкыр назлап карасаң, дөнья бермә-бер яктырып китәр иде.

Исмәгыйль Самани мавзолеен карап кайтканда, аңа тар гына тыкрыкта тау кадәрле үзбәк очрады. Каян, ничек ишелеп төште ул? Монысына Заһидулла төшенмәде, ничектер төштә генә күргән кебек булды. Җан кебек йортлар артыннан, карак сымак агачлар арасыннан килеп чыктымы шунда.

—Сән Рәхимуллага кәлдеңме?—диде үзбәк.

—Әйе...

Ул Зиннур кодасының кәгазь-юлламасы, Дәрдмәнд, Тукай, Такташ шигырьләре салынган биштәре белән Бохара татары, элеккеге шәп кенә сәүдәгәр, сату эшләрендә күп аркадашлары булган Рәхимулла Гыйззәтуллин йорты ишеге төбендә аяк киемен салган иде. Күрәсең, бу үзбәк арты белән дә күрәдер, чөнки бу гәүдәне каршы як йорт янында күргән иде кебек ул.

—Казан татары? Шимал төркиеме сән?

—Нократ татарымыз...

—Нухратны белмәем...—диде үзбәк.—Татбригадада болдынмы?—дип сорады шундук.

—Юк!

—Казан татары... Татбригада күп үзбәкне үтерде...

—Мин ул турыда белмим. Бу якка беренче генә килүем. Бохараны бик күрәсем килгән иде...

—Нә сәбәптән?

—Монда бит иң беренче төрки кардәшләр яшиләр. Тагы... Безнең борынгы бабаларымыз мондагы мәдрәсәләрдә укыганнар, шагыйрьләремез үз әсәрләрен тудырганнар...

Икесе ике телдә сөйләшсәләр дә, уртак сүзләр хисабының унае белән алар бер-берсен яхшы ук анлашалар, бернинди дә тәрҗемә кылып торучы кирәкми иде. Хәер, әвәлгеләр белми әйтмәгәндер:

—Татарга тылмач кирәкми!

Симез йөзле, ачулы күзле үзбәк аңа карап кына йомшармады, киресенчә кызганнан кыза барды:

—Мән сәне үлдерәмән!

—Гаебем нидә?

—Казан татары мәнем агамны үлдерде...

—Кем ул?

—Татбригада гәскәрие...

—Ә абыең кем иде?

—Басмач...

Тымызык жил исәр вакытлык кына тынлык туды. Хәтәр тынлык иде бу.

—Сезнең Аксак Тимер Бөек Болгарны жимерде, Алтын Урданы хәрабәләр хәлендә калдырды. Без татарлар аңа үч тотмыйбыз ич,—диде Заһидулла.

—Тимерләң—бөек жиһангир. Ул бөтен дөньяны яулады.

—Беләм. Укыганым бар...

—Мәйле, хуп...

Тагы Азия жиле исеп куйды. Кайдадыр шырлап кечкенә елгамы, яисә арыкмы ага. Һәрхәлдә Заһидулла колагына шулай ишетелде.

—Сез татарлар—начар халык. Беләсенмән сән бер кыйссаны? Ожмах төбенә жыелгач, Аллаһы адәмнәрдән сорау аша жавап алган ди:

—Кемем?

—Үзбәген...

—Кер, жәннәткә үт—үз бәгем...

—Кемем килгәндин?

—Татарын...

—Йөрмә! Ботыннан тотып атармын.

Заһидулла көлемсерәде:

—Юк, боздын!

—Иэ...—диде үзбәк.

—«Татармын» дигәч, Хак Тәгалә: «Кер, ожмахка, иң-иң түрдә ятарсын»,—дигән.

—Ах, сән!—диде тау-гәүдә үкереп.—Мән сәне пычаклимән!!

Кай арада халат-хөббәсенә кулы кереп киткәндер, һавада пычак ялтырады. Бу хыянәт-алдашуны, үзбәкнең үзен юри сөйләштереп торуыннан сизенгән Заһидулла үз өстенә үлем булып төшеп килүче кулны үрелеп беләзегеннән тотып алды һәм әлеге адәмнең аяк астына коточкыч каты итеп баш белән бәрде. Баш белән ору аның иң куркыныч сугуы булып, бу каты башны татыган кеше галәттә аңсыз ук кала иде. Бохара кешесе акырып-үкереп жиргә ауды, Заһидулла аның жиргә төшеп киткән пычагын алды да елга шарлап аккан якка ыргытты. Бәлки, ул елга да, арык та түгелдер, гади бер чишмә генә булгандыр. Боларны тикшереп тору аның уенда да булмады.

Тар гына тыкрыктан кинрәк урынга, артык зур булмаган мәйданга, дөресрәге, базарчылар утырмышына килеп чыкканда, ул, үз артында аяк тавышлары ишетеп, шигәеп калды: «Тегенең иптәшләреме, әллә үзе шул арада аякка басканмы?»

Ләкин...

Аның йөрәген йон урынына тетеп, кырыннан чеметеп, әллә нинди хатын-кыз тавышы ишетелде. Чәрелдек идеме бу тавыш? Юктыр...

—Эй-эй!—хатын-кыз аңа дәшә иде.

—Тынлыйман...

—Я по-узбекски не знаю.

—Слушаю вас.

—Мужчина, я видела как вы дрались.

—Ну и что?

—Мне сильный мужчина нужен.

Анлады Заһидулла...

Ана көчле ир-ат квартирадагы әйберләрен күчерергә кирәк икән. Бохарадагы йорт-җирен калдырып, бу ханым Читага күчәргә йөри. Үзе—ак эштә, провизор, әптиктә дару-марулар белән сату итә икән. Тулы исеме Элеонора Абрамовна Гельтшулер. Яһүдә, ягъни мәсәлән...

Заһидулла бу куе бөдрә чәчле, күзләре уйнап торган, гәүдәсенең һәр бөгелешендә дәрт кайнаган утыз биш яшьләрдәге ханымны бер күрүдә үк ошатып җибәрде. Хатын да, майлы ит күргән мәчедәй, аннан күзләрен алмады. Ниндидер эчке бер көч, яшәү теләге, рәхәткә ирешү инстинкты аларны, магнитка ябышкан тимер чүбедәй, бер-берсенә тарта иде. Шуңа ул кичтән үк Рәхимулла абыйсына кереп саубуллашып чыкты..

Эх! Сәмәркәндне генә күреп булмады. Моннан ике мең өч йөз утыз еллар элек бөек юлбашчы Искәндәр Зөлкарнәйн аяк баскан җирне...

Сау бул, Бохара!

* * *

Кемнәр әйтер, татарга урын тар, дип?

—Дөньяда татарга урын тар?!

—Һы! Әнә Читада да—чи татар...

Заһидулланың эше ярыйсы иде, ул Элеонорага дарулар ташый, тегенди-мондый әрҗәләрне чыгарып ташлый. Бер сүз белән әйткәндә, тамак туйдырырлык хезмәт урыны бар.

Көннәрдән беркөнне шулай, ниндидер дару сорап, кырык яшьләрдәге бер ир Элеонора аптекасына килеп керде:

—Пужалуйста, маз,—диде ул.

Бер почмактарак дару тартмаларын тезеп торучы Заһидулла аңа шундук борылып карады: «Татар бу, чукынчык!—дип уйлады.—Юкса урысча «мазь»не татар гына шулай «маз» дип кенә куя.»

Теге ир «маз»ын алгач, ишеккә юнәлде. Заһидулланың аяклары аның артыннан тартты:

—Кардәш, туктале!

«Маз», кабердәге әтисенең кайтып кергәнен күргән бәндә баласыдай, катып калды. Нигәдер бер тын эндәшми торды.

—Син татар бит, милләттәш,—диде Нократ улы.

—Ие... Татар...—дип куйды Чита кешесе.

—Күрәсең, мин дә—татар...

«Маз» жанлана төште:

—Минем әти-әниләр Арчадан. Үзем Казахстанда, Петропавелда тудым...

—Бәрәч!—дип куйды Заһидулла.—Син, Петропавелдагы Зиннурны белмисенме?

—Әй-әй!—дип, Арча ымлыгын сүз сөрешенә тыкты «Маз».—Зиннур

безнен жизни лә! Минем әнинен кече сенлесе Шәрифә апа анда кияүдә ич!

Һы!—диде Заһидулла.

Ә эчтән генә уйлап куйды: «Дөнья тар! Жир шары дигән бу читлек тар...»

—Зиннур—мина да кода тиешле кеше. Үзе ул Нижгар мишәре, ә анын анасы, вафат инде, урыны ожмахта булсын, минем әтинен энесе Шәйхулла абыйнын жәмәгате иде. Шәйхулла абый да күптән түгел генә вафат. Үз кулларым белән жәсәден күмдем. Өчесен—жидесен Зиннурларда уздырдык.

«Маз» аны кочып ук алды.

—И, туганым!

Анын күзләренә яшь бәрде, чиксез хисләнеп, ул сүзен дә әйтә алмыйча торды.

—Менә таныштык та!—диде Заһидулла.—Без, чыннан да, кардәшләр булып чыктык.

—Үзен кайсы яктан?—дип сорады «Маз».

—Нократ татары мин...

—Теге, урманда... Себердә ятучы татарлармы?

—Юк! Нократ елгасы буенда яшәүче татарлар. Нократ урысча Вятка дип атала.

—А, понятно! Поезд белән үтеп чыгасы ул елганы. Казанга яисә Арчага кайтканда, чуен күпер аша...

—Нәкъ шунда без торабыз инде!

—И, энем!—дип, «Маз» аны тагын кочып алды.—Исемен ничек?

—Заһидулла. Ә синеке, абый?

—Мазлум...

—Карасана!

—Нигә аптырадын әле?

—Мәзлум—изелгән, кимсетелгән дигән сүз бит ул...

Мазлум беравык үзе дә сәерсенеп торды, аннан, шатлыгын белдергәндәй, кычкырып көлде:

—Ә мин, дөресен дә, шундый кеше ич.

—Ничек?

—Сон, шахтада басылдым-изелдем, пенсиягә калгач, кимсетелдем. Пенсия—күзгә сия ул...

—Һы!

—Елата...

—Анладым... Ә син шахтер иденмени?

—Кайда шахта—шунда татар. Кайда татар—шунда шахта...

Заһидулла бу кешене бер күрүдә яратты. Ана илле тула икән инде, ә йөзгә яшь күренә. Яратырлык матур кеше иде ул: куе кара кыска чәчләр, матур түгәрәк йөз, калын кара кашлар, мангае шактый биек, кашлары тирәсендә калкынып-күпереп алган, борыны туры, авызы зур түгел, ләкин калын-тыгыз иреннәр белән каймаланган, ияге кинчә, уртасында матур гына чокырлыгы бар. Андый ике чокырчык битенен ун вә сул якларында да шәйләнә.

—Киттек, энекәш, мина!—диде ул.—Бүген мин сина кунак сые оештырам. Чәй эчәрбез...

Татарнын, әлбәттә, таза тормышлы татарнын чәе: токмач салып пешерелгән тавык ашы, бәлеш, кабартма, чәкчәк, казылык, каймак, бал, коймак, һәм дә килеп кенә шул «чәй» була. Заһидулла моны «Маз» Мазлумнарда күрде. Өе дә үзенеке, жыйнак кына матур татар йорты. Тәрәзә пәрдәләре ап-ак, мендәрләр өем-өем, һәр таучыгы сөттәй ак челтәрләр белән капланган. Өйалды, болдыр идән-такталары гына түгел, бәдрәф идәннәре дә сап-сары итеп юылган иде боларнын. Шуна читенсенепме, әллә кемнән-нәрсәдән оялыпмы, Заһидулла олы түгел, кече йомышын башкару өчен дә бакча ягындагы урманга кереп чыкты.

Барып килергә ерак ара түгел—ике йөз адым гына...

Аны тагы исәндергәне «Маз» Мазлумның хатыны иде. Бирсә бирә икән Ходай кешегә матурлыкны! Яше белән кырыкка якынлашса да, аңа егерме биш тән дә арыны бирмәссең. Тез астына житкән озын кара, куе шомырт чәчләр. Айның туып килгән чагындагы сымак кыйгач кашлар, Күкнең зәңгәрлеген үзенә жыйган күзләр, борынгы татар сөңгеседәй озын керфекләр, чиядәй кызыл, сусыл, уймак иреннәр, Хак Тәгалә үзе уеп ясаган ияк, Клеопатра көнләшерлек озын, грек скульпторлары алиһәләренеке итеп ясаган мәрмәр муен. Ул жилкә, ул куллар, ул бил, ул аяклар!

Болар барысы да Хатын-кыз алдында баш игән, Мөэннәс затының гүзәллегенә таң калган, Мәңге Мәжнүн, Тоташ Таһир, Гашыйк Заһидулла өчен бер минутлык әкият, беркавымлык төш, бер тынлык Гүзәл Рәсемгә карап тору белән бер булды. Кырымнан урыс патшасы Иван III кә хатлар язып яткан Нурсолтан белән Казан ханбикәсе Сөембикә дә бу кадәр үк чибәр булмаганнардыр! Өченче Иван Нурсолтанга хатларны татарча язган, Явыз Иван IV дә, әнә, Сөембикәгә гашыйк булган, аңа юхаланып, ханбикәнең янына керүгә үк, тоткын затның ана телендә сөйләшкән. Иваннар элек татарчаны шәп белгәннәр! Белми хәлең юк: татар—көчле, дәүләтле, әле бу урыс патшаларының әниләре дә татар нәселеннән...

Заһидулла «Маз» Мазлумның хатынына тагы бер күз сирпеде дә карашын читкә алды: «Житәр! Калганы Мазлум өчен... Эх япун, кытай, һинд рәссамнары күрсә моны, ә?!»

Мазлум үткер күзле, тирәнтен кеше икән: сизде Заһидулланың үз хатынының матурлыгына таң калганын һәм хәләл жефете ишек алдына суга чыгуга, әйтә калды:

—Актаныш кызы ул Актәния... Исемен дә яратам—Ак тәнгә ия... Ак тәнле саф жан... Менә бүген дә, иллегә житкәч тә, мин аңа үлепләр гашыйк! Син ни... Мәй эчәсеңме? Әлбәттә, Актәниядән качып кына. Исен дә сөйми, хәтта янына да якын китерми: «Әнә сиңа келәт, ди, шунда йокла»,—ди... И-иһ! Балалар юк безнең...

Заһидулла эчми дә исерек иде инде...

Матурлык—таң калдырса, Гүзәллек сине хисләрең белән дә чын-чын исертә икән!

Ләкин...

Ул бүген эчәргә булды...

Шахта баскан, изелгән, балаларсыз «Маз» Мазлум өчен...

Актанышның яңа танышкан Гүзәле Актәния өчен...

...Төн...

Караңгы...

Чита урамнары буйлап икәү бара. Берсе гармун тарта, икенчесе моңлы итеп жырлый:

—Шахтер егет күмер чаба...

Эх! Эх!

Гармун авазлары якынайтты, Жырлап кайтты, жырда—чи татар. Чита буйлап килә ике татар, Шушы татарларга Чита тар.

Ә Актәния елый иде...

* * *

Тузынды Элеонора:

—Син нәрсә, эшең барын оныттыңмы?

—Һы!—диде Заһидулла.

Чита елгасының Ингода суына коя торган урынына барганнар иде алар. Мазлум белән. Бер көн вакыт шунда югалды...

Югалсын! Кичәге—бүген юк ул... Бүгенге иртәгә булмаячак. Гомер

бер генә булган кебек, бүгенге көн дә бер генә, әнә ул офыктагы алтын-сары, алтын-кызыл тәлинкәгә утырып китеп тә бара...

Ә бит ул Мазлум белән балыкка барды, көнне милләтәше белән бик матур уздырдылар. Бу сина дару исе сенеп беткән әптикәдә яту түгел инде! Монда—сулап туймаслык һава, монда—рәхәтләнеп агучы елга, монда—якты дөньяда яшәвенә сөенеп туя алмыйсың, монда—бар сагыш-хәсрәтләрең онытыла. Әлеге елга буенда син үзеңне Кеше, Чын Инсан итеп тоясың...

Заһидулла Читаны йөреп чыкты инде. Карар урыннары калмады бугай. Нәрсәсе белән истә калды ул? Өч йөз еллык шәһәр. 1826-30 елларда декабристларның төрмә урыны бу. Чита ана чит булып тоела башлаган иде инде...

Элеонора да кай ягы беләндер дару тартмасына тартып тора. Ә теле? Әнә бит нәрсәләр ди:

—Сез ирләрнең жиде кимчелеге бар!

—Тыңлыйм!—дип куя Заһидулла.—Белик әле үзебезнең кимчелекләрне...

—Иң беренче, хатын-кыз кәефенә чамалап искән жил була алмыйсыз! Комплимент, матур сүз әйтә белмисез, ә бит хатыннар колагы белән ярата...

—Тагы?

—Көндезләрен маңгайдан үбүгә, ә төннәрен иркәләүгә ялкау...

—Дәвам ит...

—Ирлек күрсәткечегез кирәк чакта таш кыя кебек басып тора алмый. Исерек кеше сымак әле абына, әле егыла ул.

—Һм!—ди Заһидулла аңа астыртын гына карап.—Эт урынына улап, мәче кебек мыраулап ятканыңны оныттың дамыни? Әллә туемсыз нәмәстәме синдә?..

—Шулай түгел мәллә?! Кармагыгызны салуга, суалчаның ташлап, тиз генә тартып аласыз...

Заһидулла тагы көлемсерәде:

—Син минем өчен беренче булмадың, соңгысы да булмассың! Мина биргән бәя булса, дөрес түгел...

—Мин, гомумән, ирләр турында әйтәм,—дип, тагы да кыза төште Элеонора.

—Әйтеп бетер, минем колаклар түзә...

—Үз рәхәтегезне генә уйлап, хатын-кызга ничек тә ярый дип ялгышасыз.

—Ә сез безне уйлыйсызмы соң?—инде Заһидулла кайнарланды, шуңамы чиләктән алып су эчте. Чүмечне тутырып ук, чөнки үзенең сабыр савытлары тулып килә иде. Ә Элеонора,—провизор-фармацевт, эт нәрсә икән!—әясе чүбен-чарын өя генә бит:

—Әз генә читкә китегез—өйләнмәгән кешегә әйләнәсез.

—Мәсәлән?

—Ике көн кайда кунып кайттың?

—Мазлумда...

—Кем ул?

—Шахтер... Хәзер пенсиядә, аны шахта баскан...

—Беләм мин аны,—дип бүлдерде Элеонора.—Аның хатыны—Читаның иң матур кызы...

—Сез яһүдләр барысын да белеп торасыз.

—Без сезнең кебек беркатлы халык түгел. Барысын да белеп яшәргә кирәк!

—Аңлыйм-аңлыйм... Сез бит ифрат акыллы, бер-берегезгә ярдәм итүчән, башка милләт кешеләренә караганда үзегезне өстен куярга яратасыз, болар өстенә—әле хәйләкәрләр...

Элеонора гажәпләнеп бот чапты.

—Каян беләсең боларны?

—Мин Казанда укыдым... Шунда ишеттем һәм күрдем сезләрне. Башка урында да...

Элеонора тагы тузгып алды:

—Ә сез... Ә сез бер-берегезне сатасыз! Сез дә хәйләсез түгел. Үҗәтлек, тырышлык, сабырлык та юк түгел үзегездә...

Заһидулла торып басты:

—Йә, ярый! Бер-беребезнең аяк тырнагыннан башлап башка—чәчкә життекме? Тарадыкмы чәчләрне?

Кичке энгер-менгер төшкән иде инде. Заһидулланы бу сөйләшү туйдырды: тулы бер халыкка тел тидерергә бу дөньяда беркемнең дә хакы юк! Ул үз халкына каршы сүз әйткән үзбәкне Бохарада күрде инде, менә хәзер Читада да—шул мәсьәлә. Шуна күрә ул сүзне икенчегә бору өчен Элеонорадан сорап куйды:

—Мин бит әле без ирләрнең жиденче кимчелеге турында ишетмәдем?

Элеонора да сүзнең сөрешен үзгәртергә теләгән булса кирәк:

—Иң бай хатын-кыз да ирләр бүләгенә мохтаж. Төн күлмәге буламы ул, очсызлы йөзекме, матур чынаякмы—барыбер!

—Һы!—диде эченнән генә Заһидулла.—Минем биштәрдәге Тамара истәлегенме—муенсаны күргәнме әллә ул? Алтын чылбырлы, асылташлы муенса...

—Минем сиңа бирердәй бер бүләгем дә юк,—дип кистерде үзе Элеонорага.

—Ә биштәреңдә?

—Ул әйберне миңа бүләк иттеләр, ә бүләкне бүләк итмиләр...

Заһидулла карават астындагы биштәрен актарды: эчке кесәдә алтын муенса юк иде. Жидән бабасының Изге Язуы гына...

—Актарындыңмы?!—диде ул Элеонорага.

—Хәтерсез!—дип кычкырды аңа тегесе.—Беркөнне кулыңа алып күзгә каршыңа килеп утырдың бит шул муенсаң белән.

—Ә, әйе!

Эх!

Нигәдер бер-бер артлы Заһидә белән Тамара искә төшкәннәр иде ул вакытта. Әллә нишләп китте, Нократ буйларын сагынып үлә язды. Заһидәнең кием-салымы Әхмәдуллада калса да, Тамарадан бердәнбер һәм кыйммәтле истәлек-бүләкне ул үзе белән алды бит. Юк, юк! Тамара якынрак булганга яисә аны ныграк ятратканга түгел, Заһидәгә ул чын сөю белән өйләнде, ә Тамара күңелен өтәли, исенә төшеп интектерә иде. Жен Кызы!

Китәргә кирәк аңа Читадан. Монда аңа һава житми башлады. Анын бик-бик күптәннән Байкүлне күрәсе килә...

... Элеонора белән алар матур гына аерылыштылар, чөнки Заһидулланың күңелендә бу хатынга карата бер генә кара почмак, начарлышпырдык хис юк иде. Ул хатын аны үзе белән Читага алып килде, хезмәт хакы булмаса да, тамагын туйдырырлык эшкә урнаштырды. Дәрвишкә тагы ни кирәк? Бер кат кием, азмы-күпме ашау-эчү, баш очында—түбә. Хәер, чын дәрвишләрнең түбәсе—Күк Гөмбәзе ул...

«Килдем, күрдем,—дип уйланды ул Юлий Цезарьчарак.—Әмма жинмәдем...»

* * *

Исәнме, Байкүл!
Жирдә иң сай күл:
Тиргәмә, Байкүл—
Син бит—иң тирән!!
Кыя-ташлар тирән...

Кочагына ал,
Дулкынына сал...
Тик озак тотма:
Иң зур балык син—
Масаеп йотма...

Байкүл аны чыннан да исәндереп-хисләндереп җибәрде. Өч-дүрт метрдан төбендә яткан ап-ак ташлар күренә, шулардан өстәрәк беләк буе балыклар йөзеп йөри. Ярларындагы кыя-ташлар ана мәгърурлык өсти, җиргә бик тирәнгә иңүе өстенә, Күккә омтылган җанын да шәйләгән кебек буласын.

Байкүл—тирән диңгез ул...

Бу сина Нократ ягы болыннарында көзгедәй җәйрәп яткан туган як күлләре генә түгел! Озаграк карап торсаң, үзеннең ничектер кырмыскадай кечерәеп калганыңны да сизәрсең. Байкүл—бөек күл, олуг диңгез, изге күл, бай күл...

Нигә килде монда Заһидулла?..

Кайчандыр борынгы бабалары—бөек төркиләр яшәгән яклар бит бу. Шушы күлдән чумырып-кушучлап су алып эчүе вә чиста-көмеш суында коенып чыгуы үзе генә дә ни тора! Гүя кан тамырларын бабаларыныкына барып тоташа, үткән гасырлар, меңъеллар бүгенгә кайта сыман.

Колак яныннан уклар сызгырып оча, атлар чабышып үтә кебек. Борынгыдан килгән тавыш-тынсыз дәһшәтле оран ни-нәрсә хакында кисәтә? Нинди Рухлар изге җан авазы салалар?

Мондый бөек урынны күрү—үзе бер гомер кичерү. Бу күл янында тәнен сихәтләнә, җаның Күкләргә күтәрелгәндәй була...

«Яшәсен мәңге җиргизәр сәяхләр! Оясыннан чыгып киткән дәрвишләргә, Ходаем, исәнлек-саулык белән кабар ризык бир!»—Шулай уйланды Заһидулла...

Менә ул һаман, инде дүртенче дистәсен куып барса да, үзенең «йозакланган җир»ен таба алмый әле. Ә бит дөньядагы һәркемгә андый җир тәгаен генә бирелгән.

Байкүлдә тәнен дә, җанын да хушландырып, Заһидулла Урал буйларына юл тотты: бераз акча да эшләп аласы иде, ә ул якларда шахталар күп. Мазлум белми генә әйтмәде:

—Кайда шахта—шунда татар. Кайда татар—шунда шахта...

Ә акча бит аның үсеп килә торган улы өчен дә кирәк, ай саен булмаса да, күбрәк эшләп, мулрак акча алганда, юллап торуын—бик мәслихәт.

... Оп-озын, ямьсез, шыксыз баракларда үзенең якташларын да шактый очратты ул. Шактыйлары гаиләсе белән торалар иде. Эш көннәрендә ярый әле—түзәргә була, ял көннәрендә әлеге баракларда савыт-саба тавышы, балалар елавы, салып алган ирләрнең кычкырып-сүгенеп сөйләшүләре—барысы да ярты чакрымнан ишетелеп тора. Әле боларга үзара талашып киткән хатыннарның чәрелдек тавышын да кушсаң—күз алдына тәмугъның үзе килә дә баса.

... Әнә бүген дә шундый көн...

Хатын-кызлар чаршау-чыбылдык белән генә аерылып куелган сәке-ятакларында бала имезәләр, бишек тибрәтәләр. Кайберләре кичкә һәм иртә беләнгә аш әзерләп йөриләр.

Ирләр клеенкасыз, инде шомарып-каралып беткән озын вә киң өстәлгә ашау-эчү тезгәннәр, нәкъ уртада йодрык-йодрык пилмәннәрдән бу-пар күтәрелә. Пилмән—табагы белән. Ир-ат, сирәк-мирәк булса да, бу табакка күз төшерә:

—Суынсын әле бераз...

—Әйдә суган белән җибәрә торабыз...

—Монда барыбызга да кружкалар җитми ич!

—Ә без аны чиратлап...

Заһидулла аз гына эчә. Анысы да, үзе уйлаганча, кәеф өчен генә. Ял икән—ял булсын, ал икән—ал булсын! Ул үзе бу баракта тормый, аны монда башкорт Гозәернең курайда уйнавы тарта. Әй, моңлы да уйный соң! Әле бит ул кубыз да тарта белә...

Ирләрнең кулы бер табак пилмәнгә ешрак үрелә башлауга, хәмерле

кружкалар да куерак тавыш белән ченли-зенли башлый. Исерүләре життеме: хәзер һәр ике кеше үзалдына дигәндәй генә сөйләшә. Бер-берсенең сүзләрен, печән үләнен чалгы белән чапкандай, кисеп кенә торалар:

—Туктале, тукта!

—Юк, син минекен тыңла!

—Менә инде, бу сүзеңне йөзенче тапкыр кабатлыйсың бит...

Инде телгә ачы сүзләр дә керә башлый, алары да хәзер төче булып ишетелә: башлар түнтәрәйгән, акыл сыегайган, аң томаланган. Тәннәре ишелеп килүчеләр дә бар. Әмма...

Әле кызмача күзләргә карасаң, ачылы-төчеле сүзләрне тыңласаң, барысы өчен уртак бер нәрсәне дә тоймыйча кала алмыйсың.

Бумы?

Бу—Жирсү...

Бу—өзелеп-өзелеп туган авылыңны сагыну, карга оялаган карт тупылларны искә төшерү, кырда үскән бодай, арышны, зәңгәр чәчәкле житен басуын хәтергә китереп, эчтән генә үкереп-үкереп елау...

Жирсү-жирсетү—иң олуг сагышлы сагыну ул. Жирсү—тавышсыз жырлар, сүзләрен дә, көен дә әле беркем дә язмаган жырлар.

Менә Гозәер кубызына тотына, ана татар яраткан «Вараксин» гармуны кушыла, Заһидулланың якташы Әлтаф жыр башлый:

Урал бит ул, Урал бит ул,
Урал бит ул, киң бит ул.
Кемнәрнең кайтасы килмәс—
Туган-үскән ил бит ул!

Өстәл буендагылар жырны күтәреп алалар.

Кемнәрне-ең ка-айтасы килмәс—
Ту-га-ан үс-кә-ән и-ил бит ул!

Татар күңелендәге күчеңү холкы, дүңгәләклек, дәрвишлек Заһидулланың йөрәге аша сызгыра торган ук булып чыга, күпмедер вакыт башын миңгерәтеп-миңгерәүләтеп тора, аның бер сулыгып елыйсы килә. Кинәт кенә өзелеп-өзелеп улы Галимулланы сагына башлый...

Ул үзенең бу халәтенә озак түзеп яши алмады. Аның югалганын сизми дә калдылар...

Икенче көнне Заһидулла эштән китте, башкорт далаларына килеп, атна буе кымыз эчеп, курай тавышын туйганчы тыңлады, кобаерларның—чәчән-жырчыларның озын-озын моңлы жырларын ишетеп таң калды. Аннан...

Тагы еракка юл алды...

* * *

Кырым...

Татар ханлыгы жире. Россиягә аны 1783 елны гына кушалар. Өч-дүрт гасыр аерым ханлык булып яшәгәннән соң...

Ярларын Кара һәм Азак диңгезләре юган бу ярымутрау кайчандыр татар теленнән гөрләп торган. Анда кечкенә генә елгалар ага: Кара инеш, Белбәк, Кача, Алма, Салгир, Очан-су....

Әкияти яклар бу!

Пушкин үзенең данлыклы «Бакчасарай фонтаны» поэмасын язарга, шушы ожмахка тиң урыннарны күргәч, дәртсенә. Һәй, Кырым турында жыр-шигырьләрме? Күп алар!

...Заһидулланың да Кырымны бик тә күрәсе килгән иде. Бигрәк тә Казанда укыган чакларында хыялы—әлеге ярымутрауга барып, барлык-барлык матур, кызыклы урыннарын күрү иде бит. Менә Ходай насыйп

итте. Хосусан, Бакчасарайны күрү теләге зур иде, ә монда ул Әзмәвер белән очрашты...

Дөрес шул—дөнья тар!

Күпмедер акча эшләп алу нияте белән ул бер кырымлы кешегә җимеш җыярга ялланды. Ә андагы җимеш—дингез!

Мәхмәт үзе дә, хатыны да, балалары да яхшы кешеләр иде: аны верандада йомшак, чиста урында йоклаттылар, ашавы да әйбәт, ин күнеллесе—Заһидулланы алар чит итмиләр.

—Үз татарымыз!—гына диләр.

Шундый көннәрнең берендә ул, урамга чыгып, агач күләгәсе астына чүгәләде. Карый: урамнан бер кызмача ир килә. Салмышлыгы шәп, аяклары алыш-чалыш киләп сарып бара.

Таныды ул аны: теге—Биектау зобаныйларының берсе бит. Малмыж төрмәсендә Заһидулла ин беренче ана тамызды, мулла абзыйны мыскыл иткәне өчен.

Болай да Кырым кояшыннан нык кызган тәне тагы да кайнарланып китте Заһидулла, гүя эченә бер чиләк утлы күмер тутырдылар. Ул өч сикерүдә Әзмәвернен каршына килеп басты һәм, якасыннан диярлек өстерәп, күләгәле урынга алып керде.

—Очраштыкмы?—диде ул ана.—Качып котылырмын дигән идеңме?!

Исерек баштарак аны һич кенә дә таный алмады, соңгы елларда Заһидулла йөзгә-биткә бигүк үзгәрмәсә дә, аның иягең, яңакларын куе кара сакал баскан иде.

—Малмыж төрмәсен хәтерлисенме?

—Ну?—диде Әзмәвер.

—Нократ буендагы минем йортка кергәнегез хәтерендәме?

Теге тагы: «Ну?»—дип кенә куйды. Аның бу «Ну»ы да чын «ну» түгел иде, чөнки ул очкылык тотудан азаплана, авызында төкерекме, селәгәйме шунда. Күзләре әйле-шәйле килә.

Заһидулла аның яңагына каты гына чабып җибәрде:

—Сволочь! Дуга белән печән чабып маташма, барысы да исендә синең.

Әзмәвер коймага нык итеп төртенде, аннан кесәсеннән нидер актара башлады. «Пычак эзли»,—дип уйлады Заһидулла. Теге борылып пәкесе белән ана селтәнгән иде, яшен тизлеге белән бот арасына типте. Әзмәвер, җан ачысы белән үкереп, җиргә ауды, пычагын ташлап, ике кулы белән кендектән түбән җирен тотты. Авыртудан, күрәсен, аның күзләре дә яшьләнгән иде.

—Мин синең үзенне суям хәзер!—дип куркытты Заһидулла, аны бугазыннан алып. —Сез, заразалар, адәм имгәкләре, әтрәк-әләмнәр, минем хатынымны... Заһидәмне үтердегез... Пычак белән кадап...

Әзмәвер чыннан да куркуга төшкән иде:

—Мин...—диде, еш-еш сулыш алып...—Мин синең хатынынны үтермәдем, Мин... ни... Вятка ярында көймә... саклап калдым. Максимның көймәсен...

—Ә кем үтерде?

—Пузан...

—Нигә хатынымны үтерделәр, мине түгел?

—Синең янга керергә курыкканнан...

—Курыккач? Нигә бакча артлап килгәннәр минем йортка?!

—Аның сиңдә үче бар иде...—диде Әзмәвер укшый-укшый.

—Нинди үч?

—Ул... синең аны сугып егуына бик аптырамады, ә менә...—Әзмәвер тагы укшый башлады.

—Әйтеп бетер!—дип, бугазыннан кулын алды Заһидулла.

—Менә тизәкле түбәтәйне йөзенә каплап куюны һич кичерә алмады. «Малмыжга, барып теге мулланы суеп кайтам!»—дип тә йөрде. Безгә ни... Көлә идек...

—Тагы бер сорау. Мин мылтыктан аткач, берәрегезгә тидеме?

—Пузанның иңбашына һәм минем ботыма...

—Хәзер кайда алар?

—Колга бездән качты, Пузан төрмәдә бугай...

—Ни өчен утырттылар?

—Бу—бер хәйлә инде! Үтерү өчен утыртмасыннар дип, бурлык белән керәсең дә тыныч кына ятасың. «Мокрый эш»тән соң югалып торасың, сине төрмәдән кем эзләсен...

Әзмәвер тагы укшуга күчте. Менә күп тә үтмәде, ул кинәт косып җибәрде. Бер чиләк ашаган икән, симез дуңгыз! Косык Заһидулланың чалбарына кадәр чәчрәде. Ул йөзен чытты, чирканып читкәрәк тайпылды.

—Икенче тапкыр күземә күренмә!—диде Җидән оныгы, —Кырымны нәҗесләп йөрмә, хәшәп. Муенына таш бәйләп суга гына салырга кирәк сине.—Ул эре-эре адымнар белән китеп тә барды.

Шушы дуңгыз кыяфәтле, аңа зыян салган кеше монда яшәгәнгәме, Кырым аны тартмый иде инде. Бу әтрафтан китәргә кирәк!

Мәхмәтнең хатыны юлына ризык әзерләде, эшләгәне өчен акчасын санап бирделәр.

—Кайда юл тотышың?—диде Мәхмәт.

—Балтыйк буена...

—Һәй! Анда минем балыкчы дустым бар ич. Ул да кырым татары...

Мәхмәт аңа дустының адресын язып бирде. Бүрене аяклары туйдыра, ди, дәрвишне дә...

...Заһидулла Балтыйкта, дингез акчарлакларын күзли-күзли, балык тотты. Башта ишкәкләр белән ишеп-ишеп, уч төбе кабарып, тиресе төшсә дә, соңыннан ияләнде, ә беләкләрендә көч артуын сизде.

Эстония иде бу.

...Эстлар—озын буйлы, матур халык. Саргылт чәчле, зәңгәр күзле. Урлауны, кеше әйберенә кагылуны белмиләр. Үзләре таза-мул тормышта яшиләр.

Бер эстон кызы аңа гашыйк та булды бугай. Анын тезләренә утырып:

—Үз гомеремдә татар кешесен күргән юк иде, кая, туйганчы бер карыйм әле,—дигән, иде.

Сонрак, Заһидулла бу яклардан китеп байтак вакыт узгач, эстон язучысы Антон Таммсааре үлгән елны (1940) Советлар бу илне басып алды. Биш томлык «Дөреслек һәм Гаделлек» роман-эпопеясының авторы иде ул язучы. «Кайда монда дөреслек»?—дияр иде Заһидулла.

* * *

Себер язын да күрде ул...

Әйе, яңадан Себергә барып чыкты.

Шул якта җәй башына кадәр яшәде. Бөтенләй колхоз оештырылмаган бер кечкенәрәк авылда эшләде. Боларның эшләре: аучылык, чолыкчылык, җиләк-җимеш, эрбет чикләвеге җыю. Кустарь тормыш, булганына риза-разый булып яшәү.

Эх!

Кайчандыр, берничә еллар элек кенә ул кызыккан, ул яшәргә теләгән тормыш иде бу. Менә бит: «Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына»,—ди.

Тора-бара Анфиса дигән ялгыз хатынга йортка да керде. Ләкин...

Башта алар, яшьтәш булгангамы яисә хатын ир назын тансыклагангамы, әйбәт кенә яшәсәләр дә, сонрак аралары бозылды...

Сәбәбеме?

Анфиса бала тели, ә Заһидулланың җиде ят җирдә тагы бер ятимне калдырасы килми.

—Кем булып үсәр ул? Милләтен ничек диярләр: урысмы, татармы?

Ул тагы, бөтен жаны белән сулкылдап, улы Галимулланы исенә төшерә һәм жирсү-сагынудан исерә үк башлый:

—Улым, күз нурым! Ничек син анда?

Төшләренә Нократ буйлары кереп жәфалана, улының сәламәтлеге, исән-сау үсүе турында уйлап хафалана...

Ә Себер—матур...

Стенадай йортына килеп терәлгән урманнар. Ул эрбет, нарат, карагай агачлары. Күрсән, һичшиксез:

—Кара, агай, бу карагайны!—дип куярсың.

Жәнлек-жанвар—миллион, дигәндәй. Ул елга-күлләре, андагы балык, хет сәнәк белән генә чәнчеп ал. Елга төбендәрәк дуңгыз баласы кадәрләре йоклап ята. Үзләре симез, аз хәрәкәтләнәләр, ә елгалар югары агымнан азыкны—корт, суалчаны, башка бөжәкләрне аларның «өстәле»нә үк китереп сала бугай.

Мондагы иркенлеккә, матур табигатькә рәхәтләнгән иде Заһидулла. Ямь-яшел калын урманнар, чип-чиста елгаларның хозурында күп йөрде ул, үзенең исән-саулыгына, әле һич тә картаюга бармавына сөенде, бу әтрафны: «Ожмах!»—дип атады. Кая гына барса да, көньякка яисә төньякка, көнчыгыш якка яисә көнбатышка юл тотса да: «Их! Мондый байлык тагы мең елга житәрлек!—дип шакката торган булды.—Менә бит без нинди илдә яшибез!»—дип шатлыкка бирелде, үзен бәхетле тойды...

Әмма... Анфиса белән аралары суынганнан суына барып, беркөнне ул үзе ашкынган якка юл тотты.

Аның кара куе сакалы муенын каплап торгангамы, күңеле Татар бугазына, Сахалин ягына тарта иде. Әле бит ул якларда әнисенең кече сеңлесе белән Әхмәдулланың апасы да тормыш корып яшәп яталар иде.

Юл-гүр газапларын күреп, барып төште ул бу әтрафка. Нигә куркырга, ди?! Татар сәүдәгәрләре Кытай, Һиндстан белән дә сату иткәннәр, Гыйрак, Төркиягә дә барып чыкканнар.

Татар бугазындагы океан суында аякларын югач, бу якларда кызыл балык ашап туйгач, китте апасы йортына. Монда кайгы: жизнәсе үлгән икән. Башкорт жизни Зиннәтне алар үз якларында, ягъни мәсәлән, Нократ буенда бер генә тапкыр да күргәннәре юк иде. Әнисенең сеңлесе биш елга бер булса да кайткалап йөрде, ә башкорт жизни—юк!

Менә ул да ошбу дөньяны куйган икән, үпкәләре нык булмаган...

Йортта елашалар.

—Ничек, кайда күмик?

—Гроб белән урыс зиратынамы?

—Кәфен белән поселоктан шактый ары татар мазарстанынамы?

Яшьләр:

—Гроб,—ди.—Урыс зираты,—ди.

Олыраклар:

—Без бит мөселманнар,—дип каршы төшә.

Менә шундый хәлгә тап булды Заһидулла. Аны күргә, апасы чүт аягына егылмады:

—Нишлик?

—Әлбәттә, татар зиратына дәфенлибез. Мөселманча!—диде ул ана.

—Син оештыр! Син дини мәдрәсә, шкулалар бетергән. Син—мулла...

Барысын да татарча—мөселманчага туры китереп эшләделәр: мәетне яхшылап ук юдылар, кәфенләделәр, ясинын чыктылар һәм егерме чакрымдагы татар зиратына алып барып жирләделәр. Болай булмаганда—башкорт жизнинең жаны рәнжеп, рухы үпкәләп йөрер иде. Исеме генә Зиннәт түгел, үзе дә зиннәтле, зәвыкле, затлы кеше булган ул. Заманында кирәк белемен дә алган, гомер буе гыйлем эстәгән инсан...

... Бер ай тирәсе апасында торып, аны тынычландырып-юатып, үзе бер эшкә йөреп маташа иде, көннәрдән беркөнне Әхмәдулланың апасы Сара, ире немец Вольдемар Финк һәм...

Кем, дисез?

Заһидулла үз күзләренә үзе ышанмады—аның туганы Әхмәдулла килеп керделәр.

—Һы!—дип кенә әйтә алды ул бу очрашуга тыны кысылып һәм хәйран калып.—Булса да булыр икән!

Валлаһи, дөнья тар!

Бөтен Рәчәй, Союз , дөнья буенча сибелгән татар үз милләттәшен генә түгел, ә туганын, татар кандашын әллә кайдагы, ун мең чакрымнар ераклыктагы Татар бугазы тирәсендә тапсын, очратсын әле. Кемгәдер бу турыда сөйләсән, ышанмый да торуы мөмкин. Ә монда?!

—Эх! Эх! Эх!—дими, ни диярсен, ә?

—Эх! Эх! Эх!-лар бу вакытта, гажәп бер тамашада, әфсен укып, тылсым өреп, ике туганны кавыштырганда, күкрәк читлеген дә бәреп чыгарга мөмкин.

Алар Әхмәдулла белән гадәттәгечә кочаклашып күрештеләр.

—Сине алырга килдем!—диде Әхмәдулла.

—Алырга?—дип шаяртты Заһидулла, аның учларын кысып һәм дә яратып карап.—Мине алырга, син—тилгән, безләребез—бәбкә түгел.

—А-лыр-га булма-са-а,—дип сузды тегесе.—Ал-лыйп кайтырга.

—Ятим Апушны,—Тукайны, дим,— Алты-биш Сапый Уральскига алып киткән кебекме? Мин ятим түгел ич.

—Улың Галимулла синнән башка ятим.

Заһидулланың йөрәгенә бу сүзләр хәнҗәр булып кадалдылар:

—Аһ! Аһ! Аһ!

Бу «аһ»ны ул Заһидәсе кебек ифрат аһәнле итеп әйтә белми, ләкин һәр «аһ» саен аның яше туганының җилкәсенә тама торды...

...Поездда кайтканда, алар сугыш башланганын ишеттеләр...

Әйе, туган Шөненнән чыгып киткәненә дистә еллар чамасы узып та киткән икән...

И, гомер агышлары...

* * *

Вакытка сыймау—кешелек өчен коточкыч нәрсә. Ул шахматчылар өчен генә түгел, дөньядагы һәркем өчен гаять куркынычлы. Ә Кешелек Цейтноты—дөньякүләм фаҗигалар...

1941 елны, немецлар сугыш башлап җибәргәндә, безнең ил хәрби цейтнотта иде: армиягә үзгәрешләр кертеп бетерелмәгән, күп кенә юлбашчылар 1937-38 елларда атып үтерелгәч, яна хәрби техника булдыру, аның белән көчне югары сыйфатлы итеп тулыландыру эше башланган гына—Буденный атлылары белән генә,—бар, җинеп кара!—немецны...

Шуна күрә сугышның беренче елларында, ике-өч солдатка бер мылтык булып, коралы булу өчен иптәшеннән үлүен көтү кирәк була.

Безнекеләр чигенә дә чигенә, дошман аларны көненә алтмышар чакрым куа. Аларга ни: ут—үлемне автоматтан гына сиптерәләр, велосипедка атланып йөриләр, мотоцикл-машиналарда чабалар, танклар белән окопларны үтүклиләр, траншея тирәләрен актаралар.

Менә шулай фашист дигәннәре «мунча керендереп куганда», полк командиры майор Кормушкин Заһидулланы үз янына чакырды:

—Сержант Жиганов!

—Жиданов, товарищ майор.

—Ты что? Жид что ли?

—Никак нет! Татарин я, товарищ майор.

—Слушай приказ!

—Есть!

«Вәт каһәре! Һы!—дип уйлап куйды Заһидулла.—Син калдырып кач, мин табыйммы, дуңгыз!»

Нинди приказ иде?

Полк байрагы штабта калган икән. Ашыгып чигенгәндә, билгеле. Байракны саклыйм-югалтмыйм дип, кемнен үләсе килсен. Ә менә хәзер майор Кормушкинның шул исенә төшкән, төшмәс иде, байракны югалткан, бигрәк тә ташлап калдырган өчен: Воентрибунал!

Хәрби трибуналның җәзасы да бер генә—атып үтерү...

... Ике көпчәкле арбага жигелгән ат белән чапты кирегә Заһидулла. Ул үлем, немецларга әсир төшү уйларын башыннан чыгарып ташларга тырыша, шуна аны бер генә уй-корт кимерә: «Нишләп бу ат ап-ак? Нишләп? Нишләп шундый ак ул?! Тирә-юнь—бомба чокырлары, пычрак юл. Һавада көйгән металл, төтен, шартлагычлар, мәет, кан исе... Тирә-якта янгын...

Ә ат ап-ак!

Дөрес аның да бәкәлләре пычранган, ләкин кара сөремле сугышта бу ак ат нишләп йөри? Кемнәр керткән аны бу гарасатка?? Атка сугыш нигә?

Эх! Кешеләргә дә кирәкми ул сугыш:

—Кирәкми! Кирәкми! Кирәкми!

Ә шуны гел китереп чыгаралар. Нишләп бәндәләр «кирәкми» белән «ярамый»га ымсынып-омтылып яшиләр?

Әнә штаб йорты...

Ул яртылаш җимерелгән. Бер почмагы, бер тезенә чүгәләгән кеше кебек, янтайган. Истә-истә! Аның әтисе, әле ул малай чагында, бер тезенә тезләнеп «пес» итә иде...»

Заһидулла таратайкадан сикереп төште дә тиз генә каерылып ачылган ишектән кереп китте. Кайда байрак? Идәндә чүп-чар, төрле кәгазьләр, ертык гәҗит кисәкләре. Ярыклары ачылган түшәм такталарыннан идәнгә балчык коелган.

Байракны ул көзгесе ватык иске шкаф эченнән тапты. Сабын алып атып, ниндидер журналлар астына төреп куйганнар. Гимнастеркасын чишеп кызыл-сары йолдыз төшкән байракны биленә чорнады, атылып тышка чыкты.

Урман юлы ягыннан немецларның мотоцикл-машина тавышлары килә иде инде.

Ашыгырга, ашыгырга кирәк!

—Әйдә, Агатым, жилдер!—диде ул, атына пышылдап кына.

Ак ат кош урынына очты. Шунда аның күнеленә Малмыж мулласы, аның кучеры, шәп аты килде: «Нишләп яталар икән? Исәнме икән мулла абзый?»

Артта автомат тавышлары ишетелә иде инде. Ана аталармы? Әллә ул кергән хуторда тавык куып йөриләрме? Күрде бит ул бер сарай астына кереп поскан әтәч белән тавыкларны...

Ул арбасына чүгә төште...

Ак ат кушаяклап чаба...

Тагы автомат тавышлары...

Ак ат чабып барган унайга башын чайкады. Гүя чебеннәр бимазалый. Аннан кинәт кенә сөртенеп китте һәм, Заһидулланы арбасы-ние белән очырып, сазлы юлга гөрселдәде.

Кара сазда—ак ат. Ул—сугыш корбаны. Башын кызыл кан сарган...

Боларны Заһидулла бер мизгелдә генә күреп алды. Ул тиз генә аягына басты да урман ешлыгына чапты, аны хәзер коткарса—урман гына коткара. Бөтен өмет житез аякларында һәм урман куелыгында...

Бер атна эзләде ул үз полкын. Һаман чигенү дә чигенү бит. Ничек куып житәсен, ди...

Бер атна болганчык судан башка бернәрсә эчмәде, ә ашарына—урманда ни бар шул иде. Ә үз полкын тәки тапты. Майор Кормушкин башта аның белән бик кырыс вә усал сөйләште, хәтта байрак турында сорашырга онытты:

—Мин сине фашистларга сатылгансын дип уйлаган идем инде!

—Ә ни сәбәптән сатылырга тиеш әле мин?—диде Заһидулла да шактый ачу белән. Ул ачуын яшереп тә тормады:—Мин—илгә ант биргән солдат!

—Анты-ант, атың кая?!—диде майор.

—Үлде ул...

—Яндырдыңмы? Ашыгып яндыргансың син аны! Йөрәге ярылып үлдеме?!

—Пуля тиеп һәлак булды. Сугыш корбаны ул.

Майор, нидер уйланып, аңа телеп-текәлеп торды да кинәт кенә сорап куйды:

—Байракны син таба алмадың инде, кәнишне? Немецлар күренүгә кирегә сиптерден, ә?!

Заһидулла гимнастеркасын салды. Байрак аның күкрәк астында иде. Майор Кормушкинның күзе акайды:

—Таптың?!

—Әйе!

—Молодец!

—Служу Советскому Союзу!

—Мин сине бу байрак өчен Сугышчан Кызыл Байрак орденына тәкъдим итәчәкмен,—диде ул, Заһидулланың җилкәсеннән дусларча кагып.

Полк байрагы табылды, әмма Заһидулланың түшенә Кызыл Байрак ордены гына тагылмады.

* * *

Бер кешене алдау—җинел, берничәне авыррак, зур төркемне тагы да читен, ә халыкны—мөмкин түгел! Мондый алдау булса да—вакытлы гына...

Бәлки идарәчеләр: «Халык—шул ук сарык» принцибыннан чыгып, аның күзенә төтен җибәрүне чүпкә дә санамыйлардыр. Ләкин тулы вә бөтен бер халык бервакытта да ахмак була алмый. Нәкъ менә шулай: «Булмый» гына түгел, ә «була алмый». Чөнки...

Чөнки «була алмау»—аның яшәү инстинкты, тормыш итү теләге, исән калу омтылышы. Тагы...

Әнә шул идарә итүче түрәләр халыкның аларга карата булган бәясен генә ишетсеннәр иде! Билләһи, егылып үләрләр иде. Юк, үлмәсләр иде... Чөнки аларның намуслары юк.

Ә мәзәк, сөйләкләрдә күпме ирония, сатира, сарказм—мондый даһилыкка әле дөнья йөзендә бер генә язучының да ирешә алганы юк һәм...

Ирешмәячәк тә!

...Сугыш бетеп, берничә еллар узуга, авыл халкы, үзенең хәерче тормышын уйлап, үзен бик бәхетсез тойды, Сталин колхозларының кабат феодализмга кайту икәнен жаны-тәне белән сизенде. Салымнар—шул ук оброк, җирдә эшләү—феодализм барщинасы—барысы да туемсыз дәүләт корсагына бит. Икмәк үстер дә—үзең туйганчы ипи ашый алма. Бу бит мәгънәсезлекләрнең дә мәгънәсезлеге, кешене изүнең иң оятсыз ысулы, башка сыймас хәтәр бер Гамәл... Кычкыртып талау, йөзенә төкерү.

Шуна күрә, илленче еллар башында халык авылдан кача башлады. Хәер, җае килсә, ана кадәр дә! Мең сәбәпләр табып булса да. Әнә, шәһәрнекеләр иген дә икми, ат та җикми, сыер да саумый, үзенә йорт та салмый—яшиләр ич. Авыл кешесеннән күпкә яхшы тормыш итәләр кебек... Пролетариатка нәрсә ана, «богавыннан башка югалтыр нәрсәсе юк!» Иртән барып кичкә кадәр эшлә дә, калган вакытында ят түшәмгә төкереп: абзарында ашау сорап сыер мөгрәми, бакча артында койман аумаган, су ташыйсы, утын кисәсе-ярасы юк, җәен берәр санаторийга

чап, әллә өч ай буе малларга печән әзерлисен бармы?

И агылды авылдан халык төрле төзелешләргә, шахталарга, ин авыр, ин зарарлы эшләрне башкарыр өчен дөнья читләренә! Әле болары—чын татарлар иде. Эшчән, нык, сабыр, чыдам, тырыш, үҗәт татарлар. Ин мөһиме, милли асылын җуймаган саф татарлар. Менә аларнын балалары, бигрәк тә оныклары... Болары инде—телсез, татарча ипи сорап алырлык өч сүз белмәгән манкортлар, гибридлар, мутантлар.

Милләт шулай бетүгә юл тотты...

...Сугышка кадәр шактый гына дәрвишлектә йөргән Заһидулла инде авылдан беркая да китмәскә дип ант кылды. Шуна карамастан, «йозакланган вакыты» кими барган саен, анын Нократ аръягында, йорт каралты-кура салып, ялгыз тормыш алып бару теләге дә көчәя генә төште.

Ә гарасаттан кайткан 1946 елда аны ике нәрсә сагалап торган икән. Беренчесе—шатлык, олуг сөенеч: улы унбиш яшьлек егет булып житкән. Кыяфәте, йөзе-бите нәкъ әнисе Заһидә инде. Бу кадәр дә каплаган да куйган булыр икән... Бары тик гәүдәсе әтисенекенә тартым: таза-нык, беләкләре хәзердән үк ишеп куйгандай матур, тыгыз...

Сокланып туя алмады Заһидулла аңа карап:

—Күз тидермим тагы!—дип куркынып та куйды.

Теге сагалап торган нәрсәнен икенчесе—кайгы, мон-сагышлы хәсрәт: Мәскәү янында сугышларда Әхмәдулла һәлак булган. Йә, Алла!

Шундый да ипле, шундый да сабыр, шундый да ярдәмчел, шундый да эшчән-тырыш кешене сугыш аждаһасы йотсын әле. Ана яшәргә дә яшәргә, эшләргә дә эшләргә иде. Чебен үтерергә дә базмаган кырык яшьлек ир шулай итеп «йозакланган жир»ен мәнгелеккә башкала астында тапты...

Анын Әхмәдулла йортына керүе дә кызык кына башланган иде югыйсә.

—Әче балга шикәр зимләргә кирәк. Балы житми, балы, балакай,—дип, Асия уллары белән мәш килә иде.

Тегеләре дә «жегет булган»:

—Артык баллысы рәтсез була анын, әнәй. Әллә артык шикәребез бармы?—диләр. Анын Галимулласы белән Әхмәдулланын улы Хажиморат.

Вәт жегетләр, ә?!..

Үсеп житкәннәр бит. Сугыш вакытында барлык авыл-колхоз эшенен авырлыгын үз жилкәләрендә күтәргәннәр. Болардан рәт чыгар, болар чынылып үскән, шул ялангач вә килеп ач тормыш кына бик каты кыскан аларны...

Әче бал пары бәрдеме, уй-хисләр күл булып тыгылдымы, карангы төшкәч, Заһидулла лапас артындагы тирескә ятып елады. Әхмәдулланы жәлләп, аны искә алып, игелекләрен санап. Әхмәдулланын үлеме—анын өчен ин зур кайгы, алтынчы олуг бер хәсрәт иде.

Лапас артыннан аны Асия табып алды. Житәкләп өйгә алып керде, урынга яткырды. Заһидулла Асияне бер ышаныч, тормыш итү терәге санаса, анысы бар күнелен ана салган иде. Дөрес, иренә хыянәт итеп түгел, балаларны укытып чыгарып, олы юлга этәрүче итеп.

Хәер...

Ул үзе Асия белән ирле-хатынлы торуны күз алдына китерә алмый. Моны туганы Әхмәдулла рухыннан көлү, анын жанын рәнжетү дип уйлый. Мәгәр яши-тора мондый мөнәсәбәтнен дә икесенә дә авыр, читен, жайсыз булачагын да анлый.

Анын йортын, каралты-курасын, мунчасын Габдрахманнар, Габдуллалар таратып бетергәннәр. Габдрахманнын да язмышы ачы, гомере кыска булган: НКВД үзен алырга килгәч, янгын сарае каланчасыннан инештәге, Ярмәкәй тавы янындагы амбар-амбар зур ташлар өстенә сикереп үлгән. Хатыны итәк тотырук балалары белән калган икән. Фронттан сугышчы солдатлар кайткач, Габдулланы да колхоз рәисе вазифасыннан алып атканнар.

Менә шулай инде ул тормыш. Аны «ананны ормыш», дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Кем генә булма, нинди генә биеклекләргә күтәрелмә, Ләүхелмәхфүздә язылганны күрәчәксен—үтәчәксең. Шуңа да ул Язмыш Китабы, Китаплар анасы дип атала.

...Галимулла белән Хажиморат ун классны тәмамлап, Казан университетына укырга кергәннән соң, Асия Заһидулланы ачыктан-ачык үзе белән торырга чакырды:

—Булганы уртак булыр, балаларны да укытып чыгарасы бар...

—Өеңә керсәм, Әхмәдулла килеп чыгар кебек...—диде Заһидулла, аңа башта кыенсынып.

—Исәнне үтереп булса да, үлгәнне терелтеп булмый...

—Балаларга ни диярбез?

—Аңламас яшьтәмени алар?..

—Төркиләрдә туганыңның хатыны белән өйләнешү элек тә булган анысы. Үлгән туганыңның...

—Соң?

—Соң дип, әйдә соң булганчы—уң булсын!

* * *

Ни эзли кеше дөньяда?
Нәрсә эзләнә ул?

Соңгы көннәрдә Заһидулла еш кына камытлар өенә, Ильяс хәлфә янына төшеп утыра. Аның янында Димәкки Мансур, яшь егет Канәфи, Телсез Хәсән, хәтта ат караучы Шамилә дә еш була.

Ник җыелалар Ильяс хәлфә янына? Ул бит Сталин лагерьларында булып, төрмәләрдә череп, кем әйтмешли, «утырып, срогын тутырып» кайткан кеше. Була шундый адәми затлар, башкалар ни сәбәпле икәнен дә белмичә һәрвакыт аларга тартылалар, һәр сүзенә игътибар итәләр, уй-фикерләрен күңелләренә сеңдереп калырга тырышалар. Андыйлар сирәк, йөзгә-меңгә бер генә...

...Менә бүген дә...

Ильяс-хәлфә мичтә пешкән бер табак бәрәңгене алларына куйды, китек җәләүгә тоз салып, аны җылы су белән эретте, мәтрүшкә, тагы әллә ниләр кушып ясаган чәен, дөресе, үләннәр төнәтмәсен, булган яшел кружкаларга агызды һәм барысына берьюлы карап: «утырыгыз»,—диде. Аннан күкрәгенә терәп үзе ясаган чалгы пәкесе белән түгәрәк арыш ипиен кисте һәм, бисмилласын әйтеп: «Яле тамак ялгап алыйк»,—дип, табынга чакырды.

—Өстәл түгел, дәүләт бу,—дип көлемсерәде Димәкки Мансур. Ул—колхозның склад башлыгы, ашыйсы килсә, теләсә нәрсә таба, ләкин Ильяс хәлфә табыны кебек урынны, жанга рәхәт почмакны нигәдер һич очрата алмый. Нәрсәсе белән артык инде бу ярлы өстәл? Димәкки моңа җавап таба алмый. Ләкин күңеле белән сизенә: монда сиңа бер табак бәрәңгене дә, телемләп киселгән ипине дә, мәтрүшкә чәен дә санап-килограммлап, чутлап-тиенләп бирмиләр. Ильяс карт иң беренче, ифрат ихлас. Ул ялганны белми, уенда ни—телендә шул сүз, илендә ни—авызында да шул ризык. Азык-төлек дип егылып китми, бирәннәрдән эчтән генә көлә, берничә көн ашамаса да, уфтанып йөрми, зарланып яшәми:

—Зар зәр китермәс!—аның сүзе.

Ягъни мәсәлән, зарланып кына алдыңа алтын салмаслар...

—Ходай ни бирәсен үзе генә белә, вәләкин Хак Тәгалә бирәсе кадәрен генә бирер, ди. Әмма да ләкин өметсезлеккә төшмик, өметсезлекне, чарасызлыкны Иблискә калдырыйк.

—Бу дәүләт беләнме?—дип көлә тагы Димәкки Мансур.—Бу дәүләт белән нинди өметсезлек ди ул?!

Анын сөйләшәсе килә, алар әле генә склад эчендә Телсез Хәсән белән берәр чәркә «тере су»ны бугазларына коеп керделәр.

—Безнең «Бәрәнге Дәүләт»кә әйләнүебезнен үз сәбәбе бар,—дип тыныч кына дәвам итә Ильяс хәлфә.

—Яле, тынлыйк,—ди Заһидулла, теге «пәрәмәч авызлар»ны сүзләренәнән бүлдереп. Бары Телсез Хәсән генә:

—Гы-гы-гы!—дип көлә дә көлә.

Кружкасыннан мәтрүшкәле чәй эчеп, Ильяс хәлфә дәвам итә:

—Бер нәрсәне онытмыйк! Менә «дәүләт—нигъмәт» дибез дә... Һәр халык үз тормышын көйләр өчен, ин беренче, анын үз жире, бабалары туган-үскән жире, аннан сон шул жирдә,—кечерәкме ул жир, әллә зурмы,—үз дәүләте булырга тиеш. Үз дәүләте булмаган халык шәүлә генә ул, кара шәүлә. Андыйга яшәргә мәдәт бирсен! Мин үзем күбрәк әнә шул, яисә дә килеп, шундый дәүләт турында уйлыйм.

—Тирән алдырдың!—диде Димәкки Мансур.

—Җир йөзендә халыклар менәрләгән, ә дәүләтләр йөзләгән генә ич,—дип, бәхәсне куерта Заһидулла.

—Сүз электән үк дәүләтле булган вә дә үзләре аерым дәүләт—көчле дәүләт!—тота алырлык халыклар турында бара.

—Һы!—Заһидуллага бу гаҗәбрәк иде. Ул үзе ялгызлыкка, иркенлеккә, «үз йортым—минем патшалыгым»га омтылса да, тулаем бер милләттә дәүләтчелеккә омтылу юк, алар коллык богавында яшиләр, алларына салам салгач, ашыйлар да күшиләр, дип уйлый иде. Ә менә Ильяс хәлфә? Хәер, тарихта «мондый хәзрәтләр» булган. Әнә Батыршаны гына ал!

—Без инде татар халкы гына түгел, ә фашизмны бергә җингән совет халкы,—дип, сүзгә кушыла тагы Димәкки Мансур:

—Димәкки...

—Менә син, Ильяс абзый, «һәр көчле милләткә—дәүләт!»—дисен дә... Ә бит... Һы! Тукайча әйтсәк: «Как ты будешь отвечать там, Тотса Мәскәүләр якан?»

—Алар минем якадан гына тотмады, бугаздан буды инде,—ди Ильяс хәлфә тәрәзәгә карап...

Тышта—җил...

Пыскак янгыр ява...

Тәрәзә арты күмердәй кара. Гүя янгын кисәүләрен әрдәнәләп-сыртлап өйгәннәр...

Беркавым барысына да бик ямансу булып китә. Бу эчке сагыш кына түгел, ә каяндыр күкләрдән ингәнме яисә баз астыннан чыкканмы монсулык.

Күзге янгыр кебек пыскаклап кына, үзалдына карап кына, үксеп елыйсы килә. Ләкин нидер тота, кемдер: «Кирәкми!»—ди.

Заһидулла күз төбен сөртә:

«Нәрсә инде?.. Тозлы булсалар да күз яшьләре саф бит, төссез бит. Бәлки аларнын сары сагышны юарлык кына көчләре бардыр,—дип карыша эчке «Мин».—Бу—иблисле-шайтанлы-дәҗҗаллы дөнья. Ана хәшәп-хәшәрәтләр тулган. Анда—алдау вә ялган... Анда—бер-беренне кыерсытулар, үзара рәнжешләр. Гүя кешеләр бер-берсенә комачау ясау өчен генә шулай күпләп туалар. Бирергә иде, Ходаем, жир йөзендә мең парга мен утрау. Артык үрчемичә генә, һәр халык аерым бер телле, аерым бер дәүләтле милләт булып, жир ожмахы ясап ятсыннар иде...»

Ул бу уйларыннан үзе үк куркынып китә: «Йә, Алла! Мин ахмак ниләр уйлыйм? Һы! Мең пармы? Әле анын бер парыннан киткәннәре дә бүген бер-беренсен суешып-сугышып ята ич. Адәм белән Һаува балалары... Кызыл Балчык һәм Кабырга ул-кызлары... Мең пар белән тереклек башланган булсамы? Бүген яисә мең ел элек үк бәндәләр бер-берсен пешереп ашарлар, бер-беренен каннарын эчәрләр иде...

Авыр уйлардан арыну өчен Заһидулла башын күтәрде. Әнә—һәркем уйда...

—Әллә нәрсә житми шунда,—дип куйды Димәкки Мансур.—Эчеп алсаң, кәефләнеп китәсен аңысы, димәкки. Ә иртәгәсен эч поша, күңел борчыла, жан әрнешә. Димәкки, нидер житми...

—Жан тынычлыгы житми бәндәләргә,—дип куя, камытын тез өстеннән алып Ильяс хәлфә.

—Менә мин,—диде Заһидулла,—Рәчәйне аркылыга-буйга йөрдем. Бер жирдә урын таба алмадым, йөрәк һаман туган якка тартты. Кайттым менә... Һы! Нидер житми, ошамый күк. Күңел барыбер нәрсәдер эзли. Ә нәрсә эзли ул?

—Кеше нәрсә эзләгәнен үзе дә белми,—диде Ильяс хәлфә.

* * *

Сүзенне үзеңдә йотма, гамәлгә әйләндер... Теге «йозакланган жир» тагы калкып чыкты. Күп еллар узгач... Ул вакытта Асия вафат булган иде инде... Галимулла белән Хажиморат та теге «жәш жегетләр» түгел, ә югары уку йорты профессорлары, фән докторлары!

...»Ирек жилләре» исә башлагач, Заһидуллага Франциядән хат килеп төште. Ул үзе дә анламый калды: почта аркылымы, әллә эшмәкәрләр, төрле туристлар, эреле-ваклы башлыклар кулы ашамы? Зиһене чуалган, аны йомшарган бер мәлжерек хәлдә иде бит ул.

Алды, укып карады...

Хат русча язылган иде. Артык озын түгел, телеграмма күләмендәрәк кенә:

*«Здравствуй, мой милый Загидулла! С приветом к тебе твоя Тамара. Не забыл ли меня? О себе кратко: после того, как мы познокомились, а эти бандиты сожгли наш райский уголок, я с золотом отца перешла кордонную линию и после долгих мучений да страданий устроилась во Франции. Потом вышла замуж за барона Анри Шенье. Правда, фамилия Шенье звучит как название ваши деревни Шунь? Через семь месяцев барону родила мальчика и в твою честь дали имя Заги. Ты сейчас понял, наверно, почему именно Заги. По-правде говоря, это твой сын! Вот так, любимый, во Франции живет твой сын Заги де Шенье, барон. Он—писатель и философ.*

*По какой причине я написала тебе это письмо? Знаю, что мои дни сочтены, скоро отправлюсь в мир иной. Ты—мой первый и последний самый любимый человек. Ты—настоящий мужчина!*

*Я всю жизнь любила только тебя.*

*Прощай! Твоя Тамара.*

*Париж. 29 мая, 1989 года.»* Имза.

Шаккатты Заһидулла. Күзлеген рәтләбрәк киеп, тагы бер кат укып чыкты. Биш кат, ун кат укыды, Коръән аятьләре-сүрәләре кеби инде яттан белә башлады, ләкин бу хатны көн дә бер укымыйча калдырмады.

Их, Тамара, Тамара!

Сизенә идем мин синең исәнлегенне, кеммедер-нәрсәмедер мине һәрвакыт кисәтеп килде:

—Ул исән! Онытма...

—Ул исән! Хәтереннән чыгарма...

—Ул исән! Исеңдә тот...

Кара инде, минем малай француз язучысы булсын, ә? Европа әдәбиятынын Анасы булган француз китап байлыгынын, бер вәкиле, диген!

Эх!

Мин дә бер шәп роман язарга хыялланган идем дә, барып чыкмады, нидер кулдан тотып килде. Женме, өрәкме, албастымы? Шайтанмы, Иблисме, Дәжжалмы?? Укуга бит мин жөдәү-ябык-ялкау адәм түгел идем. Менә хәзер дә өч имланы да яхшы беләм: гарәпнекен дә, латинныкын да, кириллицаны да...

Тормыш дәвам итә әле болай булгач. Яшибез әле, чөнки яшәргә дип

килгән ич. Үлем безнең эш түгел, Әҗәл килер, алыр... Үз чиратында...

Менә син генә, Тамара...

Заһидәмнең дә яшьләй килешендә яшәү тамырын кистеләр. Ярый инде, аның төсе булып Галимуллам калды...

Ә синеке? Синең һәм минем Заги де Шенье кемгә охшаган икән? Әнә, Себердәге Анфиса да: «Мин синнән бала тудырам»...—дип елап калды ич. Орлыгы урынына-җиренә төшсәме?..

Эх! Эх!

Карт көнендә күбрәк булсын икән балаларың. Без яшьлектә күбрәк үзебез өчен яшибез шул. Бигрәк тә без—ирләр... Элеонора Читада бу турыда бик кенә дә белепләр әйтте.

Нишләрсең?!

Яшьлектә яшьлек турында уйлыйсың, дигәндәй, ул вакытта гомер очсыз-кырыйсыз тоела ул. Гомер агачы Күкнең үзенә кадәр үсәр кебек тә, тик тәнне калдырып күтәрелә шул ул. Мәңгелек-Үзгәрмәс-Бөек Канун.

—Балчыктан ясалган балчыкка керәчәк!

Гомер җебе резин-кереш түгел, озакка сузылып тормый, шартлый да өзелә. Сизми дә каласың...

Карт боекты...

Таягына таянып, зиратка менеп төште. Ата-анасының, Заһидәсенең каберләрен зиярәт кылды. Аяз мулла, Асыл абыстай каберләре янына да утырып дога укыды. Хәтере шәп иде әле аның. Вакыт-вакыт зиһене генә чуалып китүчән. Ләкин анысы да берничә мизгелгә генә, көтмәс эшләр, кискен сүзләр булса гына...

Ә теге «Мәхәббәт Чатырын» бик тә саласы килә иде аның. Нәкъ Тамара белән бергә кунган куышы өстенә. Берне салып карады әнә, яндырдылар. Дөресе, Мәкчим, теге бандитлар мине үтерерләр дә утка атарлар, дип үзе үк ут төрткән. Аларда кунган көнне. Икенче «Мәхәббәт Чатырын» төзеп булмый инде, чөнки гомер бер генә. Һәрнәрсәнең үз вакыты: Таң Атуның да, Төш Туруның, Кояш баюның да...

Әнә бит аның гомере дә баеп килә. Вакытны кире борырга, яисә туктатып торырга Берниндә дә Кодрәт юк! Булса да—ул Аллаһы Көчендә генәдер...

Ә шулай да...

Теге ымсынган йортны салдылар алар. Дөресе, пенсия яшенә якынлашкан профессорлар салды. Галимулла белән Хажиморат. Җәйге яллары вакытында саф һава суларга, балык тотарга, иркенләп ял итәргә кайтырбыз, диделәр. Әз генә аның янган йортыннан читтәрәк...

Карт үзе әйтте:

—Менә монда төзегез!—диде.

Профессорлар ризалаштылар. Аларга барыбер иде. Нократ буе гына булсын! Өлге суына да машина белән барып килеп була, Ямул елгасы да ерак түгел.

Ник беренче нигезенә салдырмады ул йортны?

Иң беренчедән, бу урында ул өзелеп сөйгән хатынына хыянәт итте ич! Хыянәтне карт олыгаеп беткәч кенә, туксанга аяк басып килгәндә генә аңлады. Малмыж мулласы дөрес әйтте бит:

—Син нәрсә, Заһидулла энем?! Мин поп түгел бит, мулла. «Отпущение грехов» кирәк икән, Малмыж попы янына бар. Аларда, кеше үтерсәң дә, гөнаһыңны ярлыкыйлар.

Карт, соңгы елларда авылның мулласы булып торса да, хәзер генә анык төшенде:

—Юк! Бер дә вәгазь укып, башкаларга хөтбә сөйләп йөрисе түгел. Иң тәүгедә тәүбәгә кил, үз гөнаһларыңнан арын, чын мәгънәсендә Тән-Җан-Рух Чисталыгына иреш. Шуннан соң гына...

Шуннан соң нәрсә? Ул монысын уйлап тормады.

* * *

Адәм баласы олыгайган саен еллар агышы тизләнә бара икән. Менә дөньяның чып-чын (әллә юриме?) бер пародоксы. Югыйсә, картайган кеше өчен вакыт акрынрак үтәргә тиеш кебек тә. Юк икән! Балачакта айлары түгел, көннәре дә озак уза кебек. «Кайчан үсеп житәрмен?»—дип чәбәләнә кеше баласы. Яшьлеккә житкәч, еллары булмаса да, айлары кызулык елгасына әйләнә. Ир уртасында еллар елдамрак хәрәкәт итәләр. Ә картлыкта таң ата да кич була, иртә эссе, кичен суык мич була.

Йөрәк туза, картая...

Күнел генә менә, күнел генә. Ул гел күңеллене эзли. Күнел шундый инде ул!

Авылдан тагы бер мәет чыкты менә. Мәнгелек йортына күчте. Яшь кеше бит әле үзе. Эчеп үлгән, эчеп. Хәзер заманасы шундый: яшьләр күбрәк эчеп үләләр...

Йортына кайтып керсә, ишек алдында оныгының улы уйнап йөри.

—Здравствуй, бабайка!—дип сәламли оныгы аны.

—Бирермен мин сиңа бабакайканны. Бабай, диген! Телсез малай...

—Здравствуй, бабай...—малай борынын лышкылдатты.

—Исәнме, бабай, дип кабатла әле...

Карт малайны елатмас өчен йомшаграк эндәште:

—Йә, әйт инде, улым...

—Сянмы, бабай...

—Булдырдың!

Аның кесәсендә һәрвакыт берничә конфет була иде. Күлмәксезе, шәрәсе түгел, ә затлысы, киемлесе, матур кәгазьлесе. Берсен алып оныгына сузды:

—Ну, профессорлар!—диде ул үзалдына сукранып.

Ә өйгә кереп чәйләгәч, Галимулла белән бәхәс чуманына чумганын да сизми калды:

—Менә син, улым, үзең әдәбият—әдәп профессоры. Әдәбияттан, үзебезнең татар әдәбиятыннан шәкерт халкына лекцияләр сөйлисең. Ә үзеннең улың Камилнең татар теле камил түгел. Урысча сүзләр кыстырып сөйләшә. Оныгың Шамил бөтенләй диярлек татарча белми. Йә, нәрсә инде бу?! Әйт әле, мантыйкка сыямы бу нәмәрсә?

Галимулла атасының турылыгын белсә дә, сүзне кискенләштерүгә алып бармады, йә тегеләй, йә болай жайлады-көйләде:

—Соң әтәй, будто сиңа таныш нәрсә түгел: аның бөтен иле урыс теленә күмелгән ич...

—Дөрес әйтәсең, урыс теленә өйрәнсеннәр, булдыра алсалар—инглиз, нимеснекенә дә... Тагы... Әйе, французныкын да...

Шундук хәтеренә Тамара, аның улы барон Заги де Шенье килде. Теге хат юлларын искә төшерде...

—Бездә телләр өйрәнү бик начар тора әле,—диде улы аны уйларыннан айнытып.

—Шулай булса да, туган телеңне белмәү—үзе үк зур гөнаһ ич. Әнә фин татарлары шведча, нимесчә, инглизчә, французча яхшы беләләр дип укыдым бер гәжиттә. Шуның өстенә алар бит үз татарчаларын да онытмаганнар...

—Сөйләү—жинел, эш—кыен! Як-яклап кыссалармы? Ил башлыклары да юньләп үз телендә сөйләшмәсәләрме? Коры кашык авыз ерта, ди...

Бәхәскә сүз калмаган иде инде.

Карт алгы бүлмәгә чыгып икенде намазын укыды. Улы, Шамил-Камилләр китәргә җыендылар. Иртәгә эш көне икән.

Заһидулланың күңеле чыртлап куйды. Гүя анда ниндидер бер яшәү ботак-тармагы, төбе-тамыры сыныбрак китте.

Аның улын, оныкларын үз яныннан җибәрәсе килми иде. Ялгызак бит ул, ялгызак... Йорты да ничектер хөжрәгә охшап калган. Килене бик сирәк кайта. Шәһәр кызы булгангамы, яратмый ул авыл эшен. Югыйсә,

кайта калса, йөз адым арадагы кибеткә дә машинасыз йөрмиләр. Камилнен хатыны әнә икенче бәбигә узган, өендә генә утыра...

Йә, ярар!

Зарланып зар китмәс, зәр килмәс.

Карт чыгып тавыкларына жим бирде, ашатыла торган корбан тәкәсенә печән салды.

Аннан кереп өстәл лампасын кабызды да килгән гәжитләрне караштыра башлады. Әһә! Кара әле, нинди матур кыз рәсеме! Яшьлегенә масаепмы, үзенең чибәрлеген белепме, кыланыбрак та төшкән: «Менә мин кем, янәсе!»

Күкрәкләре ярым ачык, тар мини-юбка кигән. Бар жире килешле чукынчыкнын...

Һы!—яратылган ымлык авыздан ычкынмый түзә алмады.

Эх! Эх! Эх!

Үтте гомерләр...

Ялгызак гомерләре...

«Гомер—жил»,—дигән бер шагыйрь,— дөрестән дә шулай...

Киселгән имәннәрдәй авасы бар бит. Ә бу дөньяны калдырып китәсе килми әле. Күпме генә хурламасыннар, ни кадәрле генә каргамасыннар—Шәп Дөнья бу! Ифрат Шәп!! Карт моны үзенең михнәтле-мәшәкатьле озын-озак гомере белән раслый ала һәм мәңгегә киткәндә дә анын соңгы сүзе:

—Бу дөньяда яшәп туймадым әле,—булачак.

Ул жылы су салып юынды, яхшы күлмәген, әйбәт кәчтүм-чалбарын, матур түбәтәен, елык-елык килеп торган яна галушларын киде. Көзгегә карана-карана, колак яфрагы артына аз гына хушбуй тигезеп алды:

—Менә хәзер чистый кияү!

Көнбатыштан ажаган күз кыса иде...

Карт үз уйларынын ак-саф челтәренә керде:

—Әйе! Яшиселәр бар әле... Яшь бит әле мин! Нәсел башы бабамнын гомеренә житәргә дә күп әле... Жидән бабамнын...

«Яшь бит әле мин» диюгә, анын колагына узгандагы ерак елларнын назлы-ләззәтле, сихри-рәхәтле, ымсындыргыч-татлы авазы ишетелде:

—Дави, дави меня, мой татарский конь!

Барам әле Парижларына!!—диде ул уенда гына.—Наполеонны жингән татар-башкорт атлылары кебек барып керәм! Анда минем Тамарам бар. Анда минем... Үзенең татар икәнен дә белмәгән улым бар...

Эх! Эх! Эх!..

Ә күпмедер ул француз хатыннарынын каны белән сугарылган татар ире орлыклары?! Бу шытымнар үзләрендә татар каны да акканнарын беләләр микән? Әйтик, Атилла заманнарыннан башлап француз макилары белән партизанлык иткән татар сугышчыларына кадәр ике арада. Әз түгелләр алар.

Жир шары башкаласы—Бөек Пәйтәхеттә дә бар без! Татар кайда да бар ул...

Барам әле Парижыбызга!..

Анда минем Тамарам бар...

Улым бар анда...

Яшиселәр бар әле!

Картнын атлаулары жинел, хәрәкәтләре төгәл, уе якты иде. Гүя ул Күккә үк ашып бара...

—Яшиселәр бар әле!!!—диде ул инде ничәнче кабат, бу уй-сүзенә ихлас ышанып.

## Автор сүзе

*Хөрмәтле укучы!*

*Ин беренче, «укучым» дип мөрәжәгать итмәгәнгә гафу үтенәм. Әмма... «укучым» дип дәшү дә ихласлыктан читкә китү булыр иде, чөнки бер тапкыр да күрмәгән, һич тә белмәгән кешегә ниндиләр якынлык билгеләре белдерү—кыланчыклыкка охшап калыр сыман.*

*Сина атап бу юлларны язуымнын сәбәбе бар: күпмедер дәрәжәдә анлашырга теләү. Романны тәмамлап, ин сонгы ноктаны куйгач, мин уйлана калдым:*

*—Монда язылганнарга укучы ышанырмы? Тормышта мондый хәлләр буламы?*

*Нишләп болай уйландым әле мин? Шактый еллар элек, төгәлрәге сиксәненче еллар башында, без бәндәгез үзенен бер романын күренекле генә язучыга укырга биргән иде. Соныннан карыйм: ул кәгазьнен читенә ике урында «тормышта болай булмый» дип язып куйган. Ә бит... Әсәр тормыштан алынган иде. Аннан сон... Тормышта-яшәештә әдипләрнен хыялына да килмәгән вакыйгалар, күренешләр дә була. Шәхсән үзем тормыш материалына нык таянам. Болай итү язганда ышаныч өсти. Дөрес, теге яки бу вакыйгалар әдипнен фантазиясе белән куертыла, баетыла. Инде тормышта булган хәлләр дигәндә, анын берничәсенә генә тукталыйк...*

*Клубта сәхнә түренә эленгән Сталин портретын аркасы белән ышкылып идәнгә төшергәне өчен күршем Биктимер абый Гайнетдиновны төрмәгә япканнар. Бу турыда клуб мөдире әләкләгән. Алар икесе бер кыз артыннан йөргәннәр иде булса кирәк. 1953 елнын мартында мин дә ул портретны күрдем: кара тасма белән каймаланган иде. Үзенә нигәдер карарга куркыныч...*

*Малмыж төрмәсендә бер үзе өч урысны кыйнаган кеше дә реаль тормыштан. Ул—Шөн якларынын гажәп куәтле, батыр йөрәкле кешесе Зиннур абый Фатихов. Алар вафат инде, урыннары җәннәттә булсын.*

*Малмыж мулласын моннан утыз еллар элек, Киров—Казан поезды белән кайтып барганда, үзем очраттым. Бик тә акыллы, мөлаем йөзле, иманлы-нурлы житмеш яшьлек кеше иде ул. Юл буе сөйләшеп кайттык. Петропавел шәһәрендә алтынын мичкәдә саклаган сәүдәгәр татар да—тормыштан.*

*Романнын төп герое Заһидулла образы да жилдән килгән түгел: андый кеше турында мина классик көрәш буенча спорт мастеры Сергей Дубровин сөйләде. Икебез дә спортнын бу төре буенча тренер булып эшли идек. Бер үзе урман эчендә, су буенда йорт салып, ялгызак булып, күп итеп мал-туар асрап яшәгән бер кеше хакында ул хикәят кылды. Без фәкыйрегезгә бу хәл бик кызык, гыйбрәтле тоелды һәм мин Серегага ул кеше турында роман язачакмын дип вәгъдә бирдем.*

*Дөресен әйткәндә, Заһидулла—жыелма образ ул, дөньяда нәкъ анын кебек кеше яшәгән дип әйтә алмыйм, ләкин мондый язмышлы адәм баласы булырга мөмкин. Әсәрдә анын өе яна, Дубровин сөйләгән кешенен дә йортына көнчел-хөсетле бәндәләр ут төртәләр. Заһидулланын хатынын үтерәләр, иренә үч итеп хәләл жефетенә пычак калаган хәл турында да ишеткән бар.*

*Кызыл Төпләр авылы да хыялда тумады, урысча ул Красные Пеньки, татарча нигәдер Панки дип йөртелә иде. Апам Мөнжиянен ире, минем жизнәм Мулланур Заһидуллиннын туган авылы. Хәзер бу авыл юк, жизнәм дә вафат инде.*

*«Ялгызак»—монороман, ягъни бер кеше турында. Мин аны концентрацион роман дип тә атыйм: әсәрнен идеясе бер геройда туплана дигән сүз бу. Идея дигәч тә, ниндидер яналык ачтым дип әйтә алмыйм, сүз Кешенен Иректе, Хөр Күнелле булуы турында бара. Нинди генә авырлыклар килмәсен—Инсани Зат чыдам, түземле, чөнки аны Яшәү Көче тота, шул саклый һәм ныгыта.*

*Хөрмәтле укучы!*

*Тиздән без 2000 елга аяк басачакбыз. Димәк, яна—Егерме Беренче гасыр туарга да бер генә ел кала. Кемгә ничектер, шәхсән үземә Яна Егерме Беренче гасыр Тәүбәгә килү вә Чистарыну еллары булырга тиештер кебек тоела. Бәндә балалары хатадан хали түгел, гөнаһка да керергә мөмкиннәр. Ләкин Тәүбәгә килү бервакытта да сон түгел һәм ул—бердәнбер дөрес гамәл.*

*Саулык-сәламәтлек, игелекле гомер теләп: автор.*

*28 май—28 октябрь, 1999 ел.*

*

# ШИГЪРИЯТ

## ҖЫРЧЫ ШАГЫЙРЬ

*Талантлы җырчы Георгий Ибушев турында берничә кәлимә сүз-фикер әйтү теләге күптәннән күңелдә йөри иде. Сәхнәдән яки эфирдан җырын ишетсәм дә, газет-журналларда шигырьләрен укысам да... Өстәвенә, ул әле миңа якташ та, туган авылларыбыз арасы нибары егерме чакрымлап кына (элеккеге Кызыл Йолдыз районына керә иде безнең авыллар). Ниндидер якынлык, уртаклык бар: сөйләштә дә, гадилектә дә, фикерләүдә дә. Сирәк кенә булса да, концерт-чыгышларда күрешкәләгән дә булгалады. Шул кыска гына аралашу мизгелләрендә дә якты хис-хатирә калган. Ясалмалык юк бу кешедә. Садәлек, эчке чисталык, яхшы мәгънәсендәге авылча беркатлылык... Күрү-аралаша алу үзе ходайның бер бүләге булса, җаныңа иш кеше белән сөйләшү үзе бер бәхет. Керәшен егете Георгий белән күрешкәч, йөзгә елмаю куна, күңелгә нур иңгәндәй була. Күрәсең, бәхетледер ул, фәкать бәхетле кеше генә шундый аура тудыра ала. Һәрхәлдә «язмышым—җыр» дигәнне ул яшьли үк аңлаган, максатына әкренләп кенә ирешеп барган шәхес. Тормышта бу кадәресе дә инде аз түгел.*

*Георгий Ибушев—чишмә тавышлы җырчы. Белгечләр андый тавышны югары регистрдагы җиңел альтинотенор диләр. Табигатьнең сирәк бүләге. Шулай булгач, аның кадерен белеп яшәү һәм иҗат итү сорала. Ә моның өчен акыл, белем һәм инану да кирәк шул. Георгийда боларның һәммәсе дә бар, минемчә. Җырчының йөзен аның репертуары билгеле. Халык җырлары җәүһәрләре, классик композиторларның әсәрләре—менә аның иҗат мәйданы. Ышанычлы, ныклы юл. Бәхете (күбрәк без—тыңлаучылар бәхете)—җырда сезонлы кумир булу юлын сайламавы. Чорның һәм Җырның символы булырга омтылу хәерлерәк бит! Һәрхәлдә Георгий Ибушев соңгы егерме еллар эчендә татарның асыл җырларын, көйләрен халыкка җиткерүдә, эстрада елъязмасында бер якты сәхифә булдырды дип уйлыйм мин. Аның җырлавында сүз аша көйнең матурлыгы ачыла, көй аша сүзнең мәгънәсе зурлана.*

*Артистлар, гадәттә, хискә бай, сүзгә тапкыр булсалар да, араларында үз сәнгатьләре, эш-хезмәтләре турында уй-фикерләрен кәгазьгә төшерә алучылар сирәк. Ә бит инанган идеалыңа ирешү өчен, үз сүзеңә, эстетик принципларыңа иҗтимагый яңгырыш биреп, аны киң җәмәгатьчелеккә ирештерү—кирәк һәм мактауга лаек шөгыль. Г. Ибушев моны яхшы белә, һәм—сүзе, көе, шигыре, гомумән, бар гамәле белән шушы юлда туктаусыз хәрәкәттә.*

*Җырчы шагыйрь буларак, аның тәрҗемәи хәле, иҗат кредосы турында тәфсилләбрәк язу нияте белән, үзеннән анкета сыман мәгълүматлар сораган идем. Ул үз кәгазьләрен китергәч, минем эшем бөтенләй җиңеләйде, бу хакта язып торуның хаҗәте калмады. Сүзне Георгий Ибушев каләменнән төшкән язмалар дәвам итсен.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**
*Март, 2000*

* * *

Ибушев Георгий Мифодей улы булып мин 1957 елны элеккеге Кызыл йолдыз районының (хәзер Мамадыш районына керә) Владимир авылында туганмын. Мин туган өй бик кечкенә, салам түбәле, җил капкалы иде. Аның каравы авылның иң матур очында ул. Безнең өйдән 15-20 метрдан чып-чынлап гүзәллек дөньясы башлана иде. Ул колач җитмәс таллар, тупыллар, каен, шомырт агачлары гаҗәеп бер матурлык, купшылык белән безнең очка сокланып туймаслык ямь биреп торалар иде. Бу матурлыктан бүгенге көндә аз нәрсә калды инде. Дөресен әйткәндә, мин чәчәкле болын, матурлык, җыр һәм кешелеклелек тирәлегендә үстем. Безнең өйдән кеше өзелмәс иде, нинди генә кызык хәлләр, мажаралар турында сөйләшмиләр иде алар! Боларның барсы да күңелемдә якты истәлек булып сеңеп калдылар. Әти белән әни колхозчылар, без дүрт малай, бер кыз үстек. Безнең бик матур тавышлы тальян гармунызбыз бар иде. Мин филармониядә эшли башлагач, фамилиям буенча ул гармунны сорашып килгән кешеләр булгалады. Кызганыч, мин бу гармунның ничек юкка чыкканын хәтерләмим. Шушы гармунда әти еш кына уйнап җырларга ярата иде. Җырчы буларак тавыш әтидән күчкәндер дип уйлыйм. Апам, бер абыем бик тә матур җырлыйлар минем, җырга әтәргеч булуга аларның да йогынтысы булгандыр. Ул вакытта бөтен авыл җырлап яшәгәндер кебек тоела миңа, җәй көннәрен бигрәк тә. Гармунчылар да күп иде ул елларда. Җәйге төннәрне алар бер-берсен уздырырга теләгәндәй ярышып уйнарлар, ә яшьләр аларга кушылып җырлар иде. Бөтенләй башка иде ул вакытта авыл, кешеләре дә күпкә мәрхәмәтлерәк, кешелеклерәк, садә һәм гадиерәк иде. Үземне белә башлаганнан бирле җырлыйм мин. Кечкенә вакытта җыр эзләп интекмәдем, күзем нәрсә күрә, колагым ни ишетә—шул турыда җыр итеп җырлап йөрер идем.



1964 елны үзебезнең Владимир сигезьеллык мәктәбенә укырга кердем. Укытучым Роза Шагеевна Сафина минем җырга булган сәләтемне бик тиз анлап алып, җыр өлкәсендә миңа беренче нәни канатлар куйган кеше. Роза апам мине—кечкенә генә малайны, күрше авылга конкурс-смотрларга алып бара иде. Авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, без күрше Усали (Өчиле) авылына йөреп укый башладык. Бишенче класста укыганда беренче мәртәбә шигырь яздым мин. Кечкенәдән үк шигырь чыгарып сөйләп йөрсәм дә аңа кадәр аларны кәгазьгә төшергәнем юк иде. Шул көннәрдән башлап җыр белән генә түгел, шигырь белән дә женләнә башладым. Көненә 4-5 әр шигырь яза идем. Бик кызганыч, беренче шигырьләремнең берсе дә сакланмаган. Усалидә укыганда мине язмыш гаҗәеп гүзәл кешеләрнең берсе—әдәбият укытучысы Мәрьям апа Мозаффарова белән очраштырды. Мәрьям апа миңа канатның зурырагын, ныгырагын куйды. Ул миңа поэзияне тирәнрәк тоярга, шигырьнең төзелешен аңларга булышты. Җырның шигырь аша эчтәлеген тирәнрәк ачарга ярдәм итте. Беренче мәртәбә шигырьләремне «Яшь ленинчы» газетасына җибәреп карадым. Аларны басмасалар да миңа редакциядән бик җылы эчтәлекле берничә хат килде. Җиденче класста укыганда бу газетада беренче шигырем басылып чыкты, аны бүген дә яттан беләм.

Әтиләр бик күпне күргәннәр,
Әтиләр утларга кергәннәр.
Сугышта үлсәләр үлгәннәр—
Дошманны барыбер җиңгәннәр
Әтиләр—җирдә иң көчлеләр,
Әтиләр—үлемсез кешеләр.

«Яшь Ленинчы» ул елларда минем 5-6 шигыремне басып чыгарды, мин дә инде үсеп үсмер егеткә әйләнә башладым һәм шигырьләремне үзем өчен генә яза башладым дияргә була. 1974 елда көтмәгәндә газета редакциясе үзенең 50 еллык бәйрәменә чакырды. Бу минем Казанга беренче килүем иде. Мине бу юбилейда Мактау кәгазе белән бүләкләделәр. Икенче елны тагын Казанда булырга туры килде. Бу юлы инде мин җыр бәйгесенә бардым. Бу бәйге «Комсомол җыры—75» дип атала иде. Мин монда җырчы Мингол Галиев белән таныштым. Конкурста дипломат булдым. Мингол абый миңа «син укырга тиеш, бик матур, әйбәт синең тавышың»,—дип мине дәртләндереп җибәрде. 1975 елда Усали урта мәктәбен бетереп, зур өметләр белән Казанга килдем. Ният—консерваториягә керү иде. Соңга калып килгәнмен икән, имтиханнар алу беткән иде инде. Шулай булуга карамастан, Н. Г. Җиһанов үзе тыңлап, әзерлек курсларына кабул итте. Ләкин «тулай торакта урын юк, яшәү җирең үзең табасың» дигәч, мин куркып калдым. Русчам да бик чамалы, Казанны гел белмим һәм мин Мингол абыйдан качып (аларда туктаган идем) кире авылга кайтып киттем. Аннан соң армиягә алдылар. 1975-77 елларны Самара якларында армия сафларында булдым. Аннан кайтуга Түбән Кама шәһәренә урнашып, химзаводта эшли башладым, ярты елдан соң мине Казанга чакырып алдылар. Чакыручы—Мингол абый булып чыкты, зур рәхмәт аңа. Шулай итеп 1978 елда мин Казан Дәүләт консерваториясенең әзерлек курсларында укый башладым. Музыкаль белемем булмау сәбәпле башта бик авыр булды. Җыр буенча беренче укытучым Чувашстанның атказанган артисты Михаил Федорович Кольцов булды. Ачык күңелле, бик тә ярдәмчел укытучыга күңелемдә бик зур рәхмәт хисләре саклана. Михаил Федорович каты авырып эштән китү сәбәпле, мин Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Әлфия Гафиятуловна Загидуллина классында укый башладым. Мин бик бәхетле җырчы: укытучылардан бик уңдым. Алар минем тавышымны гына түгел, күңелемне дә аңладылар. Әлфия апа укучылары өчен әниләре кебек кеше ул.

Консерваторияне уңышлы гына тәмамлагач, 1985 елда солист итеп Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясенә алдылар. Шул ук елны Бөтенроссия халык җырларын башкаручылар бәйгесендә катнашып «Бөтенроссия конкурсы дипломанты» дигән исем алып кайттым. 1989 елда Бөтенсоюз «Татар җыры» бәйгесендә катнашып лауреат булдым, ә 1990 елда С. Сәйдәшев исемендәге республика бәйгесендә аның беренче лауреаты булдым. 1991 елда Татарстанның атказанган артисты исеме бирделәр. Унбиш ел филармониядә эшләү дәверендә (соңгы елларда опера һәм камера бүлегендә солист) инде меңнәрчә концертларда катнашырга туры килгәндер. Шушы вакыт эчендә зур репертуар тупларга өлгердем. Халык җырларын, композиторларыбыз әсәрләрен. Бигрәк тә романсларны яратып башкарам. Татар композиторларының әсәрләре белән бергә, рус, чит ил композиторларының җыр, романс, арияләрен дә бик теләп җырлыйм. Шулай ук шушы вакыт эчендә байтак кына шигырь, берничә эссе, парчалар, күп кенә зур күләмле мәкаләләр белән республикада чыга торган газета, журналларда күренгәләп киләм.

Безнең гаилә, музыкантлар гаиләсе ул, хатыным Әдилә, ике малаем Алеша белән Сережа да музыкантлар. Аларның өчесе дә скрипкада уйныйлар. Менә 20 елдан артык инде Казанда яшим. Бик яратам мин Казанны. Ләкин барыбер мин монда үземне вакытлыча гына кебек хис итәм. Бөтен җаным, тәнем белән авыл баласы мин.

**Георгий ИБУШЕВ.**

*

## Георгий Ибушев

### Көмеш яңгыр, күк чәчәк

*Жыр*

Шигырь язды шагыйрь төн йокламый,
Яше белән аны чылатты.
Йөрәгеннән алып хисен салды,
Кат-кат укып күңелен юатты.

Жыр язучы күрде бу шигырьне,
Укыганда шагыйрь китабын.
Йөрәгенә үтеп сихри сүзләр,
Тетрәндерде йөрәген аның.

Күңел кылы кинәт җавап бирде,
Тирбәнде дә чыкты көй ташып.
Сүзләр җырлый һәм ул көйне инде
Булмый иде һич тә туктатып.

Жырчы отты көйне, бәгъреннән
Өзеп алып моңны өстәде.
Ул сүзләргә җылы бөркеп алды,
Ташты хисләр, әллә нишләде.

Таралды җыр хискә, моңга тулып—
Күңелләргә килеп кушылды.
Кешеләргә шатлык бирер өчен
Таң чыгыдай чиста җыр туды.

*

Су өстендә ник бер дулкын
Кагылсын камышларга.
Бөдрә таллар черем итә,
Талганнар сагышларга.

Еракта оеп, офыклар
Күгелҗем төскә кергән.
Матур хисләр ургып чыга,
Шигырь булып, күңелдән.

Сөялдем каен-сеңлемә,
Уйларым—еракларда.
Бу сукмаклар илтсен иде
Унсигездә чакларга.

Хыялым мине сагышка
Кай ара керде алып?
Күгелҗем офыкка карап
Калдым кебек югалып.

Югалып торган арада
Яшьлекне урап кайттым:
Хыялда булса да, яшьлек,
Юлымда сине таптым.

## Әнкәйгә

Әскертләргә сыек томан сарган,
Таллар чумган сагыш эченә...
Әнкәй бүген никтер уйга калган
Һәм тутырып яккан мичен ә.

Тәрәзәмне каккан җылы җилләр
Инде киткән ерак киңлеккә.
Пошкырышып, инеш аръягында,
Акрын гына атлар су эчә.

Кырау булып күзләр төсе төшкән.
Төркем-төркем кошлар күчен ә...
Әнкәй менә никтер уйга калган,
Сөялгән дә җылы мичен ә.

## Торналар үттеләр

Торналар, сез кайдан, еракмы юлыгыз.
Бу нинди моң сезнең агымда?
Туктадым, түзмәдем, эндәште йөрәгем:
—Таныш моң бу,—диеп,—җаныңа.

Сезнең бу тавышта, үпкәме язмышка,
Әллә соң юлларның газабы?
Давыллар аерган, канатын каерган
Парларның юксыну авазы?

Сез әнә биектә, тезелеп бер җепкә,
Чит якка, ят җиргә юл салган.
Булсам да илемдә, көнләшеп мин сездән,
Күз алмыйм сез очар юллардан.

Минем дә бар иде, канатым пар иде,
Мин аны тиң күреп яраттым.
Тик язмыш аерып, алды шул каерып
Иңемнән шул ап-ак канатым.

Торналар үттеләр, юатып киттеләр
Әрнегән, сызланган җанымны.
Тик калды моң гына, тибрәнеп тын гына
Дәште күк, тап, диеп парыңны...

## Көмеш яңгыр

Җем-җем килеп, су өстендә
Якты нур уйный.
Ай талларның бөдрәләрен
Көмешкә буйый.

Үзәннәрдә дулкын-дулкын
Тибрәнә томан.
Тал толымына уралып,
Җил йоклый сыман.

Яфрак очында, җемелдәп,
Тамчылар яна.

Чык яңгыры, көмеш яңгыр
Тып та тып тама.

Бөдрәләргә кагылып алсаң,
Көй чыгар сыман.
Гаҗәеп чың таралыр күк
Һәрбер тамчыдан.

## Күк чәчәк

Арышларның җитеп килгән чагы,
Тиздән менә урак башлана.
Арыш арасында күк чәчәкләр
Акрын гына җилдә чайкала.

Күк чәчәкләр, күктәй күк чәчәкләр
Рәшәләргә бирә зәңгәрлек.
Зәңгәрлеккә кереп сукмакларның
Ерагыннан килим әйләнеп.

Арыш исен, салам исен сулап,
Чикерткәләр җырын тыңлармын.
Питрау узган, тургай инде тынган—
Башак тутырыр чагы кырларның.

Чисталыкка керәм, күңелемдә
Башак шавын саклап йөрермен.
Төшләремдә, бәлки, күк чәчәкле
Шушы сукмакларны күрермен.

Бу сукмактан әле минем кебек
Сагыш баскан күпләр үтәчәк...
Каршы алыр, озатып калыр сезне
Бәхет теләп, күктәй күк чәчәк.

## *

Узып бара менә тагын бер көн:
Тау битләрен соры нур сарган.
Су буенда таллар оеп калган,
Күләгәләр сәер озайган...

Яфрак арасына йокы төшкән,
Эңгер яткан юллар өстенә.
Ерактагы каен рәтләре дә
Кара-кучкыл тасма күк кенә.

Кемдер көлде. Чыңы ерак китеп,
Болыннарга җитеп коелды.
Яшел үрләр иркен сулап куйды,
Үләннәргә энҗе чык кунды.

Ашыкмыйча, атлы юлчы узды,
Нидер көйләп—көе сагышлы.
Чеметтереп җанны, арт урамнан
Ишетелә тальян тавышы.

## Көнләшү

Дулкынланып, Иделкәем
Тирбәтә көймәләрне.
Ак җилкәннәр, ак канаттай
Талпынып куяр да әле.

Акчарлаклар белән бергә
Зәңгәрлеккә юл алыр.
Мин калырмын биек ярда
Ә Идел дулкынланыр.

Ярсып тибәр шунда йөрәк,
Карап ак канатларга.
Эх, әйләнә алсам иде
Җитез акчарлакларга!..

Җилпенеп куяр идем дә,
Кагып ак канатларны,
Куып җитәр идем кебек
Ап-ак акчарлакларны.

## Тынлык

Көн кызуы сүрелеп, эңгер төште,
Хуш ис белән тулды бар һава.
Офык сүнде, урман өстендәге
Болыт кына бераз аллана.

Тынды дөнья. Әйтерсең лә бар да
Арып талган тирән йокыга.
Талгын җилдә юкәләрдән татлы
Чәчәк исе сарыла тын гына.

Гаҗәпсенеп, күңел талгын гына
Шул тынлыкка кереп күмелә.
Нәрсә булды соң бу! Хисләр ташый,
Мөлдер, мөлдер булып түгелә...

Азга гына югаласы килә
Шул тынлыкта—эреп, кушылып.
Табигатьне тыңлыйм рәхәтләнеп,
Җаным-тәнем белән онытылып.

Олы тынлык кинәт, күкне биләп
Җанга үтеп, йөрәккә керә.
Мизгел генә булып, шул чак җирнең
Сулаганы ачык ишетелә.

## Музыка

Шундый йомшак, җылы сагыш булып,
Моң агыла—бу кем сагышы?
Айкап ала, канны чеметтереп,
Скрипканың уйчан тавышы.

Әнә, нидер әйтеп, вәгъдә итеп
И, биешә елгыр клавишлар.
Алар сөйли, алар ышандыра:
—Җирдә олы сөю, бәхет бар.

Ә виолончель, үткәннәрдән килеп,
Сәлам әйтә кебек яшьлектән.
Яңагымны яндырып нәрсә узды?
Син, музыка биргән яшь икән.

# И ҖЫР ГЫНАМ, ҖЫРЫМ...

Ерактан, бик ерактан акрын гына бер җыр агыла. Аһ, бу нинди йөрәк өзгеч моң?! Кайда ишеткәнем бар соң әле минем бу җырны? Нишләп әле ул минем җанымны шулай өтеп ала? Ул каядыр чакыра, дәшә, ымлый.

Безнең ил—сандугач сайрар җир,
Безнең ил—гөл-чәчәк арасы

Күңелем сихерләнеп, моң агылган тарафка йөгерәм. Ул—якында... Бәгырьләремне телгәли, елыйсыны китерә... Елыйм, рәхәтләнеп үксеп-үксеп елыйм. Һәр күзәнәгемне сихри наз иркәли, йөрәккә җылы нур коя. Бөтен күкрәкне тутырып, тирән итеп сулыш алам да: «Син кем, син кем?»—дип өзгәләнеп кычкырып, уянып китәм. Карале, күзләремнән һаман яшь ага.

Безнең ил—уйнар, көләр җир,

—дип җырлаган матур йомшак тавыш бөтен Ястык урамын, югары очны чорнап алган. Яшьле күзләремне учларым белән угалап алам да, ниндидер бер булачак могҗизаны кабул итеп алырга әзер булган кебек, шушы моңлы агымга ияреп китеп барам.

Әй, язмыш, рәхмәт сиңа бу төнең өчен! Рәхмәт сиңа, дүрт тәрәзле, җил-капкалы, салам түбәле өең, шул өйнең, әтинең иске тунына күмеп йоклаткан өйалдысы өчен! Рәхмәт сиңа! Шыгырдап торган нык бүрәнәләрдән салынган зиннәтле өй эчендә, мамык юрганнарга чумып ятсам, миңа бу сихри аһәң кагыла алган булыр идемени? Мин аны ишетеп, төшләнеп, үксеп уяныр идемме? Юк, җыр төнге тынлык аша болын-тугайларга китеп таралып эрер яки кемнедер, башканы сайлап кагылып, назлап үтәр иде. Җыр, шушы төнне син мине иркәләп, ап-ак канатларың өстендә тибрәтеп, нәни җаныма, үзем дә аңлап бетерә алмаслык чиста моң салып, кире кайтардың. Халкым аһәңенә төренгән көенчә, мин ул төндә беренче мәртәбә җылата торган көч барлыкны, ул бетмәс көчнең йөрәк аша чыгып, яңадан кешеләргә сафлык, моң булып, аларны чистартырга, елатырга, авыр чакта көч бирергә әйләнеп кайтуын аңладым. Бу җыр—син идең, син...

Безнең ил—сандугач сайрар җир...

Бөтен тирә-якны янгыратып, шушы җырны аңлап, аны тагын да матуррак, тулырак итәргә теләгәндәй, чынлап та, сандугачлар сайрый иде. Мин үземне Ходай



*Сулдан уңга—Георгий Ибушев, композитор Алмаз Монасыйпов, пианистка Мөнирә Хәбибуллина.*

күктән иңдергән кодрәт астында калгандай хис иттем. Бакчадагы юкәләрдән хуш ис тарала, талгын җилдә аларның яфраклары лепер-лепер килеп, «тыңла, тыңла» дип әйтәләр иде сыман. Мин тыңладым. Бу җыр, әйтерсең лә, моң ташып торган күңелдән генә чыгып калмый, бәлки төнге күктән, Киек каз юлыннан күңелләргә, болынтугайларга, урман-кырларга җылы нурдай сирпелә иде.

Рәхмәт сиңа, язмыш, син миңа шушы төнне җыр бүләк иттең. Ул гади җыр түгел, ә бәлки, якты йолдыз сыман төнне яктырта алырлык нурлы җыр иде. Күпме еллар узса да, ул җыр мине һаман үзе белән яктылыкка, матурлыкка, чисталыкка әйдәп, ап-ак нурлы канатлары өстендә алып бара. Әллә нинди мин ишетмәгән, белмәгән бары җаным белән сиземли, тоя торган җыр дулкыннары аша ерак үткәннәргә алып чыгып җанны тетрәндерерлек борынгы җырлар белән таныштыра. Шушы җырлардан әсәрләнеп китеп, шушы моң назыннан айнып өлгергәнче, болыннарга сыймастай булып җәелгән, тибрәнеп, дулкынланып торган җырын бөҗра түгәрәк уеннар эченә китереп төшерә. Миңа бала-чагымнан таныш, кадерле булган Раштуа, Нардуган, Олы көн, Торойсын кебек керәшен бәйрәмнәрендә йортта, гаҗәеп матур җырдан гына торган керәшен туйларында шушы җырларның камиллегенә, гүзәллегенә сокландырып елата. Нинди асыл җырулар җырланыла бу бәйрәмнәрдә, туйларда. Нәкъ менә шунда җырланылган җырлар туганлыкның кадерен белергә, туган җиреңнең бөеклеген аңларга ярдәм итә. Шушы бөек могҗиза-җырның көче, сере нәрсәдә соң?

Җыр—әниләрнең безне дөньяга китергәндә кычкырган изге тавышы ул. Җыр—таңнарның алсулыгы, чыкларның җемелдәве ул. Җыр—сабыйларның көлүе, төркем-төркем күперенеп килгән ап-ак болытларның агымы ул. Җыр—«сөям» дигән серле пышылдау, иреннәрнең иреннәргә кагылгандагы назы ул. Җыр—җылы дулкын булып игеннәргә сарылган рәшә чыны, чишмәләрнең челтерәве ул. Җыр—серле төндә йолдызлар булып коелган керсез карларның аклыгы, Киек каз юлларыннан иңгән яктылык ул. Җыр—минем, синең ярсып типкән йөрәк тибеше, халыкларны азатлыкка чакырып дәшкән көчле аваз ул. Җыр—ятимнәрнең күз яше, тормышта адашканнарның, чит җирләрдә юксынганнарның сагышы ул. Җыр—халыкларны халык иткән, аларны берләштергән, һәрберсенең үзенә генә хас төсмере ул. Җыр—язгы җылы яңгыр астында хуш ис бөркегән сирень, шомыртларның шавы, кеше җанының бетмәс-төкәнмәс матурлыкка, чисталыкка, кешелеклелеккә, изгелеккә ия булырга тиеш икәнлеген дәлилләүче бөек рух ул. Җыр—берни белән дә чагыштырып булмаслык, Ходай кешеләргә бәһасез җан авазы итеп иңдергән изге моң ул.

Әгәр дә мин өздереп, җыр менә шушы инде ул, дисәм, минем белән килешеп ризалашып бетмәүчеләр дә аз булмас иде. Чөнки җырны аңлаган, яраткан һәр кешенең җыр турында үз фикере, үз сүзе бар һәм бу бик дөрес тә, чөнки җыр бит ул—тере нәрсә, җан моңы. Шуңа күрә аны һәр җан үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә.

Җыр ничек туа соң? Мин композитор түгел, ләкин минем сиземләвем буенча чын җыр бик тә бәхетле чакта, яки өзелеп юксынганда, нәрсәдәндер кинәт кенә күңел нечкәреп, ташып киткән чакта туадыр. Җыр болай гына бер сәбәпсез тумыйдыр ул. Тукта, җыр языйм әле дип кенә җансыз язылган җыр, чын җырдан бик ерак тора. Чөнки иҗат вакытында була торган ләззәтле бер дулкынлану, газаплану, ярату, тойгылар, хисләр белән сугарылмый ул җыр. Бары тик чын йөрәктән язылган җыр гына арган күңелгә җиңеллек китерә, җанны чистарта, көрәшкә дәшә, матурлыкка ишек ача. Зур, чын җыр иксез-чиксез көчкә ия. Ул таныштыра, кавыштыра, авырудан дәвалый, хәтта бер-берсен дошман күргәннәрне дә татуландыра җыр, елата, юата җыр.

Чү, тыңла, ишетәсеңме? Миллионлаган аналар тавышы Җир шарын уратып алган. Күпме телләрдә тибрәлә өмет катыш бу тавыш. Бәхет теләп җырланучы бишек җыры ул. Һәр бишек, гөнаһсыз сабый янында ап-ак канатларын кагып, һәрбер нәни йөрәккә кагылып алырга омтыла. Күр-күр, әнә, кечкенә генә шушы зат әнкәсенең күкрәгеннән иреннәрен алган да, бишек җыры астында йокымсыраган килеш елмаеп куя. Күр, ул башын ничек матур итеп артка ташлаган, ә алсу яңагы буйлап әкрен генә, ап-ак сөт тамчысы тәгәрәп төшеп бара, тагын бер мизгел—шушы тамчы тып итеп каядыр төшер дә, бөтен Җир шарына без аңламый, ишетми торган телдә җырга рәхмәт әйтер, чыңлап куяр. Әй, керсез нәни йөрәк, шушы чынны югалтмыйча саклап кала алырсыңмы син? Еллар үтү белән безнең бу тормыштагы ялган, ялагайлану, акчага, чүпрәккә сатылу синең йөрәгеңдәге бу нурны сүндермәсме? Сүндермә син ул нурны, сүндермә! Ул сине «Әллүки»ләргә, «Тәфтиләү»ләргә алып чыгар, «Безнең ил»ләре, «Кара урман»нары белән иркәләр. Җирдә ялганнан, пычрактан башка Матурлык дигән тагын бер төшенчә—

жырлы, моңлы, кешелекле дөнья бар әле. И жыр гынам, нигә без, кешеләр, бу дөньяга Матурлык жыярга туасы урынга, бер-беребезгә шул кадәр күп әшәкелек эшләргә киләбез?! Бер уйласаң, без бу дөньяга кунакка гына килгән бит. Шушы мизгелдә бер-беребезгә әйтерлек жылы сүзләребез юкмыни соң? Күзгә-күз карашып, назлы сүзләр әйтеп сөешерлек намусыбыз да калмаганмыни инде? Әй, сабый, кичер мине мондый сүзләрем өчен! Жирдә бөтен нәрсә дә нурдан, изгелектән генә тормый шул әле. Кеше жанын каралтырга, түбәнсетергә, таптап узарга әзер торган күп әшәкелек, гаделсезлек бар жирдә. Ләкин син күңеленә әнкәннең бишек жыры аша кергән шушы изге нурны сүндермә, югалтма! Шушы нур, якты маяк булып, бөтен гомереңбуена жемелдәп, алга—матурлыкка, камилләшүгә таба дөрес юл күрсәтеп, чакырып торыр. Син курыкма гына, курыкма! Алга—яктылыкка бар, камилләшүгә таба—кешелеклелеккә атла. Әгәр дә син кешене кеше итүдән туктатучы шушы карангылыкны узып, яктылыкка чыга алсаң, үзеннең кеше дигән бөек исемеңә лаек булырсың. Азмыни әле, бүген шушы карангылык эчендә адашып, буталып беткән, «без—милләтнең аны, жаны» дип кычкырырга яраткан, бер-берсе белән тарткалашып арыган шагыйрьләр, язучылар, «милләт өчен көрәшәбез» дип, теләсә кайда шар ярып йөрүче, үзен генә кайгыртучы шарлатаннар, сәясәтчеләр, галимнәр?! Алар бу караңгылыктан чыга да алмаячаклар. Данга, властька, байлыкка сусау аларны күптән сукырайткан инде, күбесе нәрсә кычкырганын, ни теләгәнен үзе дә аңлап житкерми. Менә нәкъ шундыйлар аркасында жирдә милләтләр арасында ызгыш-сугыш чыга, тетрәнүләр була. Чөнки алар әнкәләре бишек жыры аша күчергән нурлы маякны күптән сүндергәннәр инде. Ләкин иң авыр чакта «килеп тераллдем», «беттем» дигәндә генә, иң кешелексез жан да, әгәр дә мөмкинлек бар икән, мәрхәмәтлелеккә сыеныирга омтыла. Инстинкт буенча булса да, беренче жырның—бишек жырының яктылыгын эзли. Беркемнең дә жирдә жылылык эзләп, таштай, салкынлык бөркеп торган жанга сыенганы юк бит әле. Шулай булгач, «кешелеклелек, изгелек, матурлык дип сөйләнү—әкият ул» дип әйтүчеләр тагын бер кат ялгышалар, чөнки аларның үзләренә үк жан жылысы житми.

Оч, жырым, оч! Ап-ак канатларыңны жилпеп-жилпеп ал да, бу тормышта адашып аптырап беткәннәр, дөреслеккә сусап та аны таба алмыйча өметсезләнгәннәр, матурлыкка, гүзәллеккә омтылганнар күңеленә якты нурыңны сирпе. Көчсезләнгәннәргә терәк, адашканнарга маяк, өметен жуйганнарга өмет бир. Бөтен тирә-якта гаделсезлек тулып яткан шушы дөньяда Матурлыкка алып чыгучы нурлы юлыңны күрсәт. Юк, бу кеше нәфесен канәгатьләндерү өчен түгел, ә бәлки, кешенең эчке дөньясын баетуга алып бара торган юл. Кеше жанының чисталыгы, сафлыгы байлык белән дә, дәрәжә белән дә үлчәнми, аны сатып алып та, алыштырып та булмый, ул һәркемгә кылган гамәлләренә, намусына карап бирелә. Юк, бу һич кенә дә кеше затлы киенмәскә, мул яшәмәскә, матур, иркен йортларда тормаска тиеш дигән сүз түгел! Намуслы тырыш хезмәт белән эшләп тапканны кияргә дә, булган белән горурланырга да мөмкин. Ләкин мал колы булырга ярамый. Чөнки жан кол булу өчен яратылмаган. Юк, мең тапкыр юк. Жан изгелек кылу, матурлыкка омтылу өчен яратылган лабаса. Жан, әнкәсе кулында оеп, башын артка ташлап йоклап киткән сабый кебек керсез булып туа түгелмени? Хәтерегездәме алсу иңак буйлап тәгәрәп төшеп баручы ап-ак сөт тамчысы? Кешегә көч бирүче изге тамчы, тере тамчы ул. Ана күкрәгеннән чиксез сөю белән баласына бирелә торган бу тамчыда өмет, ышаныч тулы. Бу—үзе матур жыр. Жыр гына да түгел, ә бәлки жан, күңел ачкычы. Балачак хыялларын, чисталыгын, жылылыгын хәтта балалыкның үзен дә аз гына булса да саклап кала алган күңелләргә ул тамчы зың итеп килеп кагылыр да, нурлы юл буенча әйдәп, Матурлык иленә ишек кагар.

Атла син бу юл буйлап. Матурлык, гүзәллек, моң, жыр иленә керергә лаексың. Син түгелмени ул, ата-ананы хөрмәт иткән, кайда һәм кем булсаң да, кече күңелле, кешелекле булып кала алган кеше?! Таныш булмаганга абынганда кулын сузган, бер телем икмәкне урталай бүлешкән, чит кайгыны уртаклашырга ашыккан, зур булмаган шатлыкка да чын күңелдән сөенә, шатлана белгән кеше син түгелмени ул? Син. Син ул. Матурлыкка омтылган, бишек жыры кабызган якты, жырлы маякны сүндерми саклаучы изге күңелле кеше. Шушы маяк сине караңгылык аша комсызлыктан, кешелексезлектән, жанны данга һәм дәрәжәгә сатудан саклап калды, Гаделек, Матурлык, Жыр иленә алып чыкты. Күрәсенме, шифалы нурларын чәчеп, дөньяны иркәләп кояш күтәрелеп килә. Болын-кырлар өстендә рәшә дулкыны уйный, нидер көйли-жырлый. Узган төннең каракучкыл дулкыннары офык читенә кереп күмелә, югала. Күр бу матурлыкны, жыр әнә шулай туа.

Уяна иркен болыннар,
Ачыла гөл керфекләре,—

дип кычкырып жырлыйсы, гүзәл табигатьнен иртәнге жырына кушылып, моң булып эрисе килә. Әнә, ул жыр, утлы тамчы булып, гөл керфекләре өстендә яна. Җил уйнап узар да, бу тамчылар, бәллүр чыңыдай бер-берсенә кагыла-кагыла, жиргә сибелерләр. Кем белә, бәлки, бу чың таң жырының кушымтасы булыр. Әнә, жыр үзәннәр өстендә, үтә күренмәле жиңел япма булып, әкрен генә дулкынланып ята, ә йомшак жил шаярырга теләгәндәй, шушы купшы япманың бер читенә кагылып ала да, сылу яшь каеннарның бөдрәләрен капларга теләгәндәй, шушы аклыкны үзән читенә таба иярте алып китә.

Жыр кешене матурлык алдына китереп бастыра: күзең бар икән, күр, жаның бар икән, той. Матурлык бу үр, еракдагы офык чите белән генә чикләнми. Ул чиксез, бер туктамый үзгәреп, яңарып тора. Шуңа да шагыйрь:

Үрләре дә зәңгәр дулкын-дулкын,
Ул үрләрнең чиге кайда соң?—

дип юкка гына хозурланып, ләззәтләнеп язмаган. «Ул үрләрнең чиге, әнә, монда, якында гына»,—дип әйтелсә, жырның кыйммәте югалыр; ул тәмамланмас, кешене уйландырырлык көчкә ия булмас иде. Жырның бөеклеге шунда ки, ул һәркайсыбызны үз дулкынына алып, без күрмәгән зәңгәр үрләр артындагы матурлык дөньясына илтә, Жир-Ананың йөрәк тибешен тоярга ярдәм итә. Якты хыяллар, яңа хисләр, тойгылар эченә урап ала. Жыр яңгыраганда гына иң бөек көченә ия. Жыр—кәгазьдә ноталы тамга,



*Георгий Ибушев концерт вакытында*

ә күңелдә бикләнеп ятканда жылы тойгы гына, кеше күкрәгеннән ургылып чыкканда исә сүз, көч, моң, яктылык ул. Күңелендә аз гына кешелеклелек хисе сакланып калган булса, таш бәгырьне дә эретерлек, аңа жан өрерлек көче бар аның. Жыр туганда бишек жыры булып каршы ала, көчләләр жанын үлем аша үлемсезлеккә алып чыга.

Ләкин жыр уенчык түгел, жыр белән уйнарга-шаярырга ярамый. Юк, сүз бүген көннәр буе яңгырый торган вак-төяк жырлар турында бармый. Алар ялтыравыклы уенчыкларны гына хәтерләтәләр. Без бүген жыр дип, ни сүзе, ни көе булмаган йөзләрчә-йөзләрчә бер-берсенә охшаган уенчыкларны атый башладык. Ни өчен уенчык, ә жыр түгел соң? Чөнки алар яшәр өчен тумаган. Без алар белән вакытлыча уйныйбыз гына. Берничә айдан инде аларның беркемгә дә кирәге калмый—алмашка яңа төрле бизәкле уенчыклар килә. Шыгрым тулы залларда жырланыла торган буш сүзле, чиле-пешле жыр дип атала торган гарип көйләрне тыңлап, эреп-оеп утыручы зыялыларыбызны күреп

кызганам мин. Җырны уенчыктан аера башларга вакыт түгелме? Әлбәттә, вакыт. Бүгенге көндә зыялыларыбызның күпчелеге иң гади җырдан, такмактан тәм табып, катлаулырак, эчтәлеклерәк җырны кабул итәргә әзер түгел икән, гади халык турында нәрсә әйтергә мөмкин соң? Без үзебезне шушы мескен хәлгә тартып төшердек. «Зөлхиҗә»не, «Гөлҗамал»ны, «Уел»ны, «Рәйхан»ны халык күнеленә ирештерерлек ничә генә бөртек җырчыбыз бар соң? Ләкин ул җырлар яңгыраган вакытта да бик күпләрнең аларны ахырына кадәр тыңларга түземлеге җитми. Без моңлы, эчтәлекле җырны тынлаудан бизә барабыз. Әйе, андый моңны кабул итү өчен аз гына уйланырга, күнелне ачып, ана үтеп керергә, җырчыны хөрмәт белән тыңларга өйрәнергә кирәк. Без бәгырьнең түреннән, йөрәк аша ургып чыккан бу изге аһәңнең җан авазы икәнен онытткыкмы әллә? Тынлыйк әле ул тере, йомшак авазны. Бу аваз кешене таң калдыра, көтмәгәндә генә биеклеккә омтыла, тәннәрне чемер-чемер китереп ала, сандугач кебек җилпенергә, сайрарга тотына, йә булмаса киң Идел сыман тулып, салмак кына агыла башлый. Яки көтмәгәндә генә, җылы май кичен искә төшереп, шундый тыныч, үтә күренмәле нур сыман эленеп кала. Кеше тавышы иң затлы уен коралларыннан да матуррак, нәфисрәк. Чөнки аның кыллары җан шул. Ә җан кояшлы, моңлы, назлы, кирәк икән нәфрәтле, көчле һәм горур ул.

Ләкин бүген булыр-булмас, карлыккан, «дерек-мерек» килеп торган тавышларны йолдыз дәрәҗәсенә күтәреп, данга күмделәр. Күпме тавышың булмаса, шул кадәр яхшырак. Әгәр дә селкенә, ритмга өлгерә алсаң яки чыш-пыш итеп моң чыгара белсән, син—йолдыз. Әйе, җирдә йолдыз белән тиңләрлек гүзәл тавышлы җырчылар да бар, алар үзләренең тавышлары, иҗатлары белән үзләрен генә түгел, Ватаннарын да данлыйлар, зурлыйлар. Әмма нигәдер безнең йолдызларның ни нуры, ни тавышы калын кесәле әфәнделәр яныннан еракка китми. Без Сәйдәш белән Р. Яхинны аңламаслык дәрәҗәгә төшеп җитүебезне сизми дә калдык. Кайберәүләр: «Дөрес түгел»,—дип кычкырырга ашыгырлар. Юк, дөрес, йөз кабат дөрес. Бүгенге тамашачыны вак-төяккә күнектерделәр. Ул сәхнәдән бик еш ишетелә торган пычрак, әдәпсез шаяруны шау-гөр килеп, кул чабып кабул итә. Шуңа күрә дә бүгенге көндә сәхнәгә арзан җыр белән бергә шакшы юмор үтеп керде. Боларның барысы да халыкның зәвыгын төшерүдә зур роль уйныйлар. Радио, телевидениене сәнгатькә өч тиенлек тә катнашы булмаган тавышсыз, талантсыз җырчылар басып китте. Әгәр дә без шушы юлны сайлап, сәнгатебез шушындый булырга тиеш дибез икән, безнең бик тиздән кыргыйлар хәленә төшүебез мөмкин. Менә шуңа күрә дә талантлы чын сәнгать әһелләрен дәүләт үз канаты астына алырга тиеш. Шулай булганда гына, вакытында талантлы җырчыга бәя бирә белгәндә генә талант үсә, ныгый ала, чөнки җырчыга зур югарылыкта җырлау өчен бирелгән вакыт бик аз ул. Без чын талантлы шәхесләрнең милләтебезнең йөзек кашы, горурлыгы, рухи байлыгы икәнлеген онытып барабыз. Әгәр дә без милләт булып сакланырга, көчле дәүләт булып оешырга телибез икән, безнең бөтен яктан да нык үскән мәдәниятебез булырга тиеш. «Кайбер күршеләребез бездән дә начаррак хәлдә бит әле»,—дип уйлаучылар табылыр. Кайсы дәүләт бүген беренче булып, чын-чынлап, мәдәнияткә кул сузса, шул отачак, шунда гына намуслы эш, хезмәткә хөрмәт, бер-береңә кешелекле караш, үз милләтең белән горурлану хисе, өлкәннәргә игътибар булачак. Без, милләт буларак, Р. Яхинның җыр-романсларын аңларлык биеклеккә күтәрелә алмыйбыз икән, аләм рәтле, чын дәүләт булып беркайчан да оеша алмаячакбыз. Чөнки искиткеч эчкерсез, чын йөрәктән язылган бу җәүһәр бөртекләрен аңламаган, кабул итәргә теләмәгән милләт ул югалуга, таркалуга дучар була. Милләтебезнең бу бөек улы юк инде, аның керсез, чиста җанын җыр үзенең ап-ак канатларына алып, бу исемне үлмәс җыр итеп, үлемсезлеккә күтәрде. Әмма без нинди югалтуга дучар булуыбызны бөтен тулылыгы белән аңладыкмы икән? Юк. Без төсле җырлар белән мавыгып, милләтебезнең нинди тирән югалту кичерүен аңламый да калдык. Ләкин иң куркынычы: безнең мәдәниятебез, җыр сәнгатебез ваклана, үзенә генә хас булган йөзен җуя барган саен кешелек үзе дә үзгәрә, мескенләнә, кырыслана. Тирән аһәнле җырларның кадере бетсә, кешенең дә кадере югала. Чөнки җыр шул ук җан бит ул. Ә кадерсез җан башканы кадерли, җылыта алмый. Җырны талантлы кешеләр язарга тиеш, әле шулай булганда да яхшы җырлар гел туып тормыйлар. Яхшы җыр йолдыз кебек балкып туа ул, монда инде бар нәрсә дә үз урнында була. Шуңа күрә аларны классик әсәрләр дип атыйлар, һәм мондый җыр, романсларның халыкны тәрбияләүдә әһәмияте бик зур. Мондый җырлар халыкның зур рухи байлыгына әверелеп, җыр хәзинәсенең алтын фондын тәшкил итәләр. Берничә генә шундый әсәрне искә төшереп китик әле. Н. Җиһановның «Зарыгу», Р. Яхинның «Күнелдә яз», «Сандугач», С. Сәйдәшевнең «Әдрән дингез», «Батырҗан җыры», Ә.

Бакировның «Иртәнге серенада», Ф. Әхмәтовның «Таң йолдызы», Р. Еникеевның «Дулкыннар» жыры һәм башка, һәм башка әсәрләр. Болар безнең чын-чынлап зур байлыгыбыз, горурлыгыбыз. Без бу композиторларыбызның исемнәрен атап зур җыелышларда мактанырга яратабыз, әмма тормышта бөтенләй башкача килеп чыга. Әгәр дә алар безнең горурлыгыбыз, классикларыбыз икән, нигә аларның җыр, романсларын, опера әсәрләрен җырлаучы җырчыларның кадере юк, нигә алар эт типкәсендә соң? Күз буяу өчен сайлап алынган бер-ике җырчыдан башка. Нигә алар көчкә очны-очка ялгап, зур кыенлыклар күреп яшиләр соң? Зурдан кубып уйласаң, җиде миллион татарга безнең ун чын тере җырчыбыз да юк бит. Әгәр дә дәүләт ун бөртек җырчысын да кешечә яшәтә алмый икән, нинди дәүләт соң инде ул?

Әгәр дә профессиональ җырчыларга караш үзгәрмәсә, без ун-унбиш елдан татар классик композиторларының җыр романсларын югары осталык белән башкаручы җырчыларсыз калачакбыз. Бу шаяру түгел, безнең чын-чыннан җырчыларсыз калу ихтималыбыз бик зур. Бүгенге көндә бездә Сәйдәшне, Яхинны җырлап бай җырчы булып булмый шул. Без бүген кешенең кадере беткән чорда яшибез түгелме? Безнең җыр сәнгатебез чиле-пешле булмасын дисәк, олы җыр турында, һөнәри җырчылар турында дәүләт кайгыртырга бурычлы. Әгәр милләтнең хәзинәсе, горурлыгы булырга тиешле матур тавышлы җырчы кадерсез, хәерче хәлендә икән, без киләчәктә яңа яшь сәләтләр туар, милләтнең олы җырын биеклеккә күтәреп башка халыкларга да ирештерер, ишеттерер дип өметләнә алабызмы соң? Юктыр. Әгәр дә синең иҗатың, талантың кирәк дип табылмый икән, кадерсез җиргә нәрсә өмет итеп килергә кирәк.

Җыр—кеше фикерен матур, нечкә итеп җиткерүче иң гүзәл, иң югары нокта ул. Без тормышта бер-беребез белән гади сөйләм телендә аңлашабыз. Күтәренке, саф хисләребезне шигъри юлларга күчерәбез. Ә инде шигъри тел белән дә аңлатып булмаган нечкәлекне бары тик җыр гына күңелләргә җиткерә ала. Ләкин шигырьдәге сүз ничек кенә көчле булмасын, ул җыр түгел әле, ул әле матур, мәгънәле сүз генә. Әгәр дә шушы көчле сүзгә талантлы көй кушылса, җыр барлыкка килә. Җырның тәэсир итү көче сүзнекенә караганда күпкә көчлерәк аның. Телнең тәрәге һәм бизәге—җыр. Җыр барда тел, халык бар. Олы җырны башкарырлык җырчыбыз, аңларлык халкыбыз калмаса, ап-ак канатлы җыр бездән китәр. Ә милләт моңсыз, җырсыз яши алмый. Ләкин безнең җыр сәнгатебез гел моңлы, елак җырлардан гына торырга тиеш түгел, моңга гына салынып сагышланып ятсак, без бөтенләй йомшап, җебеп бетәрбез. Безнең җырларыбыз моң, сагыш белән бергә, күтәренке рухлы, тирән эчтәлекле һәм якты яңгырашлы булырга тиеш. Андый җырлар күбрәк булса, без үзебез дә җаныбыз белән чистарынып, яктырып, сафланып китәрбез. Менә ни өчен җырга бары тик күңел ачу өчен генә тудырылган нәрсә итеп карарга ярамый. Җырны аңлау өчен югары уку йортын тәмамлау кирәкми, ул безгә тумыштан бирелгән. Шуны тоя, ишетә белү генә зарур. Тыңла да җый: каеннар шавыннан, тургайлар җырыннан, кечкенә энгердән, болын гөленнән—бары да җыр бит. Каеннарга сөеп, гөлләргә назлап карарга өйрән. Каенга бары тик буласы утын, болын гөлләренә, яшел хәтфәсенә печән итеп кенә караудан узмасак, ничек күңел матурлыкка омтыла алсын ди?! Матурлыкны тойган күңел генә яхшыдан начарны аера белә. Ә яхшы җыр безне олы музыка дөньясына алып чыгар, опера, симфония, балет белән таныштырыр. Бу өлкәдә белгечләр булмасак та, зур сәнгатькә җан белән кагылып алу бәхет түгелмени? Почмактагы чаршау читеннән генә карап, «Сәнгатьнең бу төре безгә кирәкме, юкмы»,—дип ятсак, «Безгә мөнәҗәттән башка берни дә кирәк түгел»,—дип әйтүчеләр дә табылыр. Ә зур сәнгать ул диңгез кебек. Шул диңгезгә курыкмыйча керсәк, башка халыкларның да күңел хәзинәсе белән танышырбыз. Күңелдә сакланып калган бишек җыры безне моң дәрьясына алып керсә, зур сәнгать дөньясына да юл ачылыр.

Ап-ак канатларыңны җилпеп-җилпеп оч, күңелләргә өмет, ышаныч бир, җыр! Безгә кешеләргә бәхет, тугрылык, сөю, матурлык турында җырла! Матурлыкка, чисталыкка сусаган җан шушы серле дөньяга тартылып торсын.

Олы җыр—сер дә әле ул. Беркайчан да ачылып бетмәячәк татлы сер. Җырның тагын бер бөек көче—аның серлелегендә. Менә шушы серлелек башкаручы йөрәгә аша узып таныш, бик тә таныш җырга да яңа яңгыраш, яңа бизәкләр өстәп, таң калдыра, кешедә ләззәтләнү, рәхмәт хисе тудыра.

Рәхмәт сиңа, җыр, рәхмәт! Синең телеңне, әйтер сүзеңне аңлый алу зур бәхет ул. Бәхет ул—яраткан эшеңдә, сәнгатьтә горурланып, чиста намус белән кеше күзенә карый алуда, үзеңне кеше итеп тоюда һәм күңелеңдә син йөрткән олы җырда.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

*Мәгъсум Худҗинга 70 яшь*

# ТЫКРЫКТАГЫ АУЛАК СУКМАК

Мәгъсум абыйны беләбез, әлбәттә. Һәрхәлдә, 1990 елда чыккан "Ерактагы кыялар" исемле китабы әдәбият яраткан кешеләрнең китап шүрлекләренә менеп кунаклагандыр. Һәм шахмат уенын яраткан кешеләр аның бөек шахматчыбыз Рәшит Нәҗметдинов хакындагы "Солтанатлы каһарман" исемле очерк-хикәясен укып та кинәнгәндер *("Татарстан" № 4, 1997 ел).* Аның "Чөй" дигән повестен укып пошынгандыр. "Авылым урамнары", "Урманлы үр" дигән китапларны укып, үз гомере-яшәеше хакында уйланучылар да җитәрлектер.

Әмма бүген бүтән Мәгъсум Хуҗин хакында сөйләшәсем килә.

Ул "Чаян"га җаваплы сәркәтиб булып эшкә килгән елларда язучыларның сабан туе бәйрәме оештырыла иде. Иң кызыгы, әлбәттә, татар көрәше. Мин дә көрәшкән булдым. Хәтта батыр асты калдым. Мәгъсум абый – судья. Миңа иң кадерлесе – аның соңыннан әйткән сүзләре: "Гадел көрәштең! Рәтен беләсең икән!"

"Көрәш" дигәннең теге йәки бу мәгънәсен Мәгъсум абый яхшы белә. Ул, әлбәттә, шахмат остасы буларак ("күп кешегә – бер кеше" уенында, хәтта Рәшит Нәҗметдиновны откан кеше!), ул көрәшләрдә күп йөрешне алдан чамалый сыман.

Аның гомере тере иҗатка багышланды.

Фатыйх ага Хөсни язучыларның һәр җыенында, мөнбәргә менеп, шәрран яра иде:

— Олы, хәтәр язмышлы хикәяләр кирәк, җәмәгать! Язмышсыз хикәя – хикәя түгел!

Язмышлы хикәя – сүз сәнгатенең үтә дә зарыктыргыч, сагындыргыч бер төре.

Чын хикәя яза белгән классикларыбыз китеп бара. Әмирхан ага Еникинең китүе ул бөек чорга нокта куйгандай булды. Мөгаен, чынлап та шулайдыр ул.

Мәгъсум Хуҗин дигән хикәя остабыз сүз хикмәтен белгән әнә шул асыл затларның таләбен гел исендә тота сыман.

Аның хикәяләрендә кемнәр яши? Котсыз заманның бичара кешеләре, бичара килеш тә зирәк булып кала алган иплe кешеләр.

Андый кешеләрне идеаллаштырып, уйлап чыгарырга да мөмкин. Әмма Мәгъсум абзыегыз сине үзе язган затлар белән очраштыра, сөйләштерә ала. Һәм ул мондый очрашуларны бик тә ярата. Шул кешене тыңла да үзең хөкем ит –шыттырганмы Хуҗин әллә хагын сөйләгәнме? Хагын сөйләгән, әлбәттә. Ышандым мин аңа.

Мәгъсум Хуҗин чоры... Тәртә арасына керергә теләмәгән үгез шикелле тискәре, авыр, үҗәт чор.

Абзыебыз күмәк хуҗалык кору чорларын җентекләп өйрәнгән һәм шул хакта күп язган икән, бу – очраклы хәл түгел. Керәстиян язмышы, җир хәле — аның йөрәген борчый торган иң зур мәсьәлә. Бүгенге мәхшәр киләсен дә ул Горбачев тәхеткә утырган көннәрдә үк алдан күреп әйтте...

Мәгъсум абзыйны сәер кешеләр кызыксындыра. "Дурак" дәрәҗәсендәге

сәер түгел, "бөек" дәрәҗәсендәге сәер. Аның әлләкем булуы да мөһим түгел. Шул гап-гади Арча, Балтач, Саба төбәгендә җир сөреп гомер иткән гап-гади кешеләр җанына кереп, хәтта Тукайның үзе белән үк сөйләшү бәхетенә ирешә әдип. Тукайга багышланган хикәяләр бәйләме бөек шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләрне дә сискәндереп куярлык. Күрәсең, хикмәт абзыйның шигъриятне җаны-тәне белән яратуындадыр. Аның хикәяләре ифрат та салмак, туктап-туктап укылышлы тел белән язылa. Аның үзе белгән хәлләрне йөгертеп-йөгертеп кенә сөйләп үтәсе килми. Аның сөйләшәсе килә!

Мәгъсум Хуҗин белән якыннан аралашкан кешеләр абзыйның сөйләү рәвешен яхшы белә. Ярар, телгә килгән теләсәң нәрсәне искә төшерик. Әйтик, елан. Әлегә кадәр сүз Конституция хакында барса да, Хуҗин бик еракларга чигенеш ясый һәм һәр кыйссасында Шәүкәт Биктимеров туып үскән авылны искә алмыйча калмый. Ул, әйтик, болайрак сөйли:

— Менә сез, конституция, дисез. Син – Зөлфәт – минем конституция – хатыным Фирая дисең инде... Синең хатын елан була алмый, чөнки ул – син диванаyның тирәсендә сайрап торган бичара сандугач. Бусы булдымы – бер? Ике! Ә агачның астында гына җылынып ятарлык еланнар агачның очында җылына! Менә шул еланның өске ботактан таш өстенә шапылдап төшкәнен адәм баласына сөйләп бирик. Кемнең кулыннан килә бу?!

Әйе, Мәгъсум Хуҗинның кеше белән аңлашасы, күзгә-күз карап сөйләшәсе килә.

Без һаман өйрәтергә яратабыз. Абзыебызның әткәсе – Хәмидулла агай үзенең улын агачлар утыртырга, иген үстерергә, хуҗалык итәргә, балаларга-онықларга сабак бирергә, кыскасы, яшәргә өйрәтеп китеп барды. Мин үзем аны бик яхшы хәтерлим. Саба районында әдәбият атналыгының соңгы очрашу кичәсен район мәдәният йортында оештырдылар.

Сибгат ага Хәким һәм аның дәрәҗәсендәге классиклар янибызда иде.

Һич тә көтмәгәндә генә мөнбәргә салмак хәрәкәтле, саллы гәүдәле һәм күрер-күрешкә үк зирәк бер агай күтәрелде. Һәм әдәбиятның киләчәге хакында, агын карага аерып, ярды да салды абзый! Сибгат ага иелеп кенә колагыма әйтә куйды:

— Менә сез, яшь әтәчләр, милләт бетә, дисез! Мондыйлар барында милләт бетә ди мени?!

— Әдәбиятның кызыгы – язмышта!– диде Хәмидулла абзыебыз.

Ярар, хәзерге әдәбият-сәнгать дөньясына күз салыйк. Шәп җырлар, шигырьләр, повесть-романнар муеннан, әмма чын язмыш юк. Шуңа күрә дә безнең әби-бабаларыбыз, йомшак күңелле хатын-кызларыбыз Марианналар өчен тәгәрәп үләргә әзер. Димәк, эчке тәрбия юк. Борылып карый белү сәләте юк.

... Татарстанның күргәннәре хакында татар үзе сөйләмәсә, кем сөйләнсен?

Хикәя жанры шигырьгә бик тә якын.

Шуңа күрәдер инде, һәйбәт хикәяне һәйбәт шигырьгә тиң күрәм мин. Шагыйрьлек шәп кеше итеп йөртә бугай бу дөньяда Мәгъсум Хуҗинны!

Бүген тарихи хәлләр хакында язылган күләмле әсәрләр күбәйгәннән күбәя бара. Әмма аларның һәммәсе дә тарихи шәхескә, аның язмышына багышлана. Чынлап та, язмыштан узмыш юк!

Шулай да, ни дисәң дә, әйтик, роман күп язмышларны сурәтли, ә хикәя исә, гадәттә, ике кеше, өч кеше язмышын. Һәм ул шуның белән кадерле дә.

Хикәятче өчен, әлбәттә, иң мөһиме – вакыйга. Ә вакыйга – язмыш! Шигырьдә, әлбәттә, язмыш ике-өч юлга да сыя. (Хәтердән язам, хата булса, кичерегез):

...Кыр казлары китеп бара...
Кош канатлары кагылгач,
Болытларның күңеле тулды...

*(Р.Фәйзуллин.)*

Чын хикәя менә шундый авыр йөкне күтәрергә тиеш.

Әйе, кем әйтмешли, әдипне аңлар өчен аның туган ягын күрергә кирәк икән шул. Мәгъсум абзый:

— Син Миңгәрнең Биктимер Шәүкәте белән бер йортта яшисең. Ул ничек бөек булмасын?! Безнең белән күрше кара баганалы авылныкы бит ул!

“Кара баганалы авыл”ның ни икәнен беләсеңме син? Менә шул авылга баргач...

Һәм башлана кыйсса-хикәя!

Нишләп шулай озаклап, тәфсилләп чигенә-чигенә сөйләргә ярата соң әле бу абзыебыз?

Каян тибеп тора аңа дигән иҗат чишмәсе?..

Бераз тарихка кучик әле. Саба ягында Тенеки дигән бер авыл бар. Сабадан ара ерак түгел – биш чакрым. Беләсегез килсә, мәшһүр рәссам Тавил Хаҗиәхмәт туган авыл – Йосыф-Алан – шушы Тенекидән күчкән. Мәгъсум абзыйның ерак бер бабаена – Габделкаһһарга егерме биш еллык солдат хезмәтенә китәргә кирәк булып чыккан. Бер шарты бар – җиреңнән ваз кичсәң, солдатка алмаячаклар! Габделкаһһар абзый карар кыла: патша әрмиясендә өшкерелгәнче, көмеш коюың, көмеш чүкүең кадерлерәк!

Үзе шикелле шундый осталар хакында үз оныгының оныгының оныгы гаҗәеп хикәяләр язасын белми әле Габделкаһһар абзый.

Мәгъсум Хуҗинның әтисе Хәмидулла агай да көмешкә йөргән. Нәрсә ул “көмешкә йөрү”?

Үзебезнең Мөслим якларына “көмешкә”, “итеккә” йөрүчеләрне бик яхшы хәтерлим.

Мәгъсум абзыйның әтисе Хәмидулла төп Саба ягыныкы. Бу абзый хатын-кыз колагына килешле зиннәтле алкалар ясаган, “көмешкә йөргән”...

Һөнәрчеләр ягы! Мәгъсум абзыйның атасының атасы да калак ясап көн күргән. Җирсез булган. Чөнки, җиреңнән баш тартсаң, дәүләт һөнәрең өчен салым түләтми... Әмма, җиреңнән колак кагуга ук, йәки батрак булып ялланасың, йәисә төшемлерәк берәр һөнәр белән шөгыльләнә башлыйсың! Менә шундый шартлар сиңа, агайне... Бүтән юк. Һәм Мәгъсум абзыйның ерак бабае байга хезмәтчсе булып ялланырга мәҗбүр булган. Әби шушы байларның йорт-җирен җыештырып-карап торган.

Мәгъсум абзыйның бабайларыннан калган төп йорт Тенеки авылында. Хәмидулла абзый безнең Татарстан тирәсендә үсәрдәй һәр агачны үстереп, җимешләрен җыеп яшәде. Мәгъсум абый, үзе әйткәнчә, Әмрикә чаганы белән крыжовник кына булмаган анда. Ул бакчадан калган карлыганнар да хәтта юк икән инде...

Нинди таза авыл – Тенекине дә кычкыртып талаган мәшһүр замана! Кайчандыр авылның 170 хуҗалыгыннан нибарысы 46 хуҗалык кына калган...

Мәгъсум абзый – Тимершык авылында тай көтүе көтеп үскән малай.

Әйтергә кирәк, Саба ягы гомер-гомергә үзенең маклерлары – ат сату-алу арадашчылары белән дан тоткан. Саба һөнәрчеләре ясаган сын-бизәкләрне Казакъстанга ук алып барып сатканнар. Инде тимер юл да ачылгач, бу һөнәр аерата көчәйгән. Бүген дә казакъ якларында зиннәтле урындыкларын кадерләп саклыйлар икән. Мәгъсум абзыйның ата-бабалары шул урындыклар хисабына ат көтүләре куып кайта торган булган.

Гыйлемгә-әдәбиятка тартылу безнең Мәгъсум абзыйга әтисеннән килгән. Хәмидулла ага үзбәк якларында «көмештә» булып шәп кайткан, хәтта үзе өчен үзбәкчә-татарча сүзлек тә төзегән.

Кешеләргә җылы сүз – җылы ризык өләшү хакында сүз чыкса, шуны истә тотырга кирәк: Мәгъсум абзыйның туган авылы атаклы күмәччеләр авылы да әле.!

Кыскасы, осталар ягы!

Әйткәч, шуны да әйтим инде: Мәгъсум абзыйның ерак бер бабае сувенир самавырлар ясаган икән. Теге шомлы елларда аның 28 (!) самавырын талап алып чыгып, каядыр юк иткәннәр.

Бу кеше – Мәгъсум абзыйның әтисенең энесе. “Кеше күңеле – үзе бер кояш” дигән хикәяне укыганнар бу кешене бик тиз танып алыр. Әдип аның исемен дә үзгәртмәгән – Нигъмәтҗан.

Һөнәрчеләр ягы, дип сүз башлаганбыз икән, әдип сурәтләгән кешеләргә дә күз төшереп алыйк инде. Ярар, ул сурәтләгән палас сугучыларны, күбәләкле келтерәвек арба ясаучыларны санап та тормыйк. Мәгъсум Хуҗин хикәясендә Бичи дигән берәү бар. Ә нишләп “Бичи”?! Баксаң, бу кушамат “биш өй” дигән сүздән чыккан икән бит!

Көмешче оста “Бичи Габдулла” Тукай белән аралашкан зат. Ул үзе йөргән якларда нинди матур йорт күреп кайтса, нәкъ шундыйны авылда

төзеп куя икән. Менә шуңа күрә дә "Бичи Габдулла – биш өйле Габдулла!"

Менә шундый инде Мәгъсум Хуҗинның әсәр каһарманнары! Бу Габдулла абзый ифрат та тынгысыз бәндә булган. Авылда "Аяк чанасы" дигән ярышны оештырган кеше дә бит әле ул. Өязләргә китәр алдыннан ул "аяк чанасы" – кәнки ярышын уздыра торган булган. Һәм үзе гел беренче чыккан!

Көрәшчеләр-ярышчылар токымын бар иткән як бу! "Чөй" повесте эчендә бер хикәят бар. Балта остасы үзенең эч серләрен сөйли. Аның бу дөньяны саф, төзек, гөнаһсыз итәсе килә. "Бөтен хикмәт шунда – бездән дөнья гүзәл калсын!" – ди ул. Кешелек шагыйрьләренең хыялы түгелме соң бу?

Авылдан чыккан әдипләргә илһам дигән тылсымлы көчнең каян килгәнен белү өчен әллә кая барасы юк. М.Хуҗин болай ди: "Туктагыз әле, сәяхәт дигәнегез илләр буйлап гизү генә түгелдер... Алтынчы класста укый башлаганда дүрт авылның урам-тыкрыкларын йөреп чыккан идем инде мин..."

Минемчә, хикмәт нәкъ менә шунда – туган як тыкрыкларында. (Мәгъсум абзыйның "Тар тыкрык сукмагы" исемле хикәясе дә бар). Кичке тымызыкларда әнә шул сукмактан – ике ягын кычыткан сарган тыкрыкларда уйланып-моңаеп йөргән кешедән көт син асыл сүзне!

**ЗӨЛФӘТ**



# Мәгъсум Хуҗин

ИКЕ ХИКӘЯ

## АК ТӨЕНЧЕК

Сәрвиназ өйнең түр почмагындагы эскәмия-урындыкларга тезелгән гөлләр янынннан гармунын алды. Гармун каешын ашыкмыйча җилкәсенә элде, баскан килеш кенә уйнап җибәрде. Йөрәкне тамырыннан суырырга җитеп ташыган көйне, эчкәрге өйдә мышкылдый-мышкылдый, әнисе Хәйрия тынлый. Йортта бүтән кеше юк. Сәрвиназның энесе һәм сеңлесе мәктәптә, әтисе икенче атнасын район үзәгендәге шифаханәдә, йокысызлыктан интегә. Сәрвиназ аның янына да туктап тормады, авылына тыелгысыз ашкынып кайтты. Кызының җомгада ук, өстәвенә, төшкә чаклы ук кайтуына әнисе сәерсенде. Институтында ике көн дәресен калдыра икән бу бала, дип уйлады, әмма әрләмәде. Сәрвиназына килгән кайгының зурлыгын аңлый ана, тик ярдәм итә алмый.

Кыз уйнавыннан туктады, аннары акрын гына җырлады, тагын гармунын уйнады, кинәт гөлләргә карады да, шигырь юлларына охшатып, сөйләнеп куйды:

—Нигә кирәк хәзер гөлчәчәкләр, өзеп бирер кешең булмагач... Гайфар! Гайфар, дим! Син...

Бу сүзләр өй эчен күкрәтте.

Авылның борынгы урамы Шушмага карый. Ул бер яклы, монда йортлар гадәти, зур-биек түгел, монда яна йортлар житкерүчеләр дә олыдан купмыйлар, хөсетләнеп, башка урамнар белән узышуга кушылмыйлар. Әмма шунысы бар—башка урамнарда борынгы урам йортларының тәрәзә йөзлекләре охшашларын күрә алмыйсың. Бизәкле йөзлекләрне Гайфарның әтисе Хисаметдин ясый, елына бер йортка гына, Гайфар булышса да, артыгына көче житми, житмешенә бара, сәламәтлеге какшау, сугыш бүләкләре яман ук сиздергәли. Башка урам осталары бизәк сызуда-кыруда Хисаметдиннән калышалар. Өйрәнмәделәр бит, берчак һөнәрнең кадере бетеп торды, хәзер адәм баласы әштер-өштерне ташламакчы була да, ләкин кул дигәнең тиз генә сөялләнми дә, шомармый да шул. Хисаметдин үз малайларын кырмачы һөнәренә өйрәтте, Казандагы ике малаеның фатирлары, шөкер, агач йомычкасына еш тула. Төпчеге Гайфар да әтисе һөнәрен ташламас нияттә, әле, мин сиңа әйтим, Хисаметдин абзагызны сөендереп, кала сарайларында үз күргәзмәләрен оештырып жибәрмәгәе! Гомерне бирсен дә шуларны күрергә язсын...

Гайфарларның йорт-жире бер яклы урамда, Шушмага төшкән тау уртасындагы буралы чишмә турысында. Арттагы урам ике яклы, киң. Монда йортлар биек, ике катлылары күп, башкалары да шуларга тин—беренче катына таш келәт өелгән. Гайфарның бу урамга йомышсыз кергәне юк. Урамның байлыгын өнәмәүдән түгел. Мондагы йортларның ике катлы итеп салынуы сәбәбен ул үзенчә аңлый—арткы урам кешеләренең дә Шушманы тәрәзәдән күреп торасылары килә икән. Барыбер дә Гайфарның яраткан урамы бүтән.

Ул белгәндә, арткы урамнан басуга чыккач, ат абзарлары бар иде, утары иркен иде дә соң, ат чабыштырырлык. Малай чакта әтисенә ат жигешергә баргалаганда, киң урамнан йөрделәр. Авылда атлар азаеп, аларны сыер фермасына күчергәч, абзарларны сүттеләр дә алма бакчасы утырттылар. Чаңгысын тагып, этен ияртеп, алма бакчасына куян куарга барганда, киң урамнан уза иде Гайфар. Куяннар алмагачларны кимереп бетергәч, узган жәйдә шунда кирпечтән ике катлы мәктәп житкерделәр. Унынчы класска Гайфар шул киң урамнан йөри.

Иртәгә язгы каникулга туктыйлар. Бүген класс житәкчесе дәресләрдән соң таралышмаска кушты. Каникул алдыннан үгет-нәсихәт бирергәдер, дип уйлады Гайфар. Алай түгел икән. Мәктәпне тәмамлагач, кемнең кая барасын тәгаен белергә боерганнар икән, район житәкчеләренә шундый мәгълүмат бик тә тиз кирәк булып чыккан. Ашыгычлыкның шушы серен яшермичә әйтте укытучы.

Гайфар аска карап, парта кырына учларын ышкып утырды. Ул күзләрен усалландырды, башын чайкады. Гәүдәсен турайтты, жиргә ябышкан зур ташны куптарып йөккә салган кешедәй иркенәеп уфылдады һәм укытучыны:

—Ни хасияте бар икән яшьләр турында хафаланган булып кыланунын?!—дип бүлдерде. Һәм, ялгышын аңлап, укытучы эндәшүдән элек, торып басты.—Һәркем үз теләгәнен сайлар. Инде райкомолдан, колхоздан, башкасыннан йөз тапкыр килеп сораштылар бит.

Класс житәкчесенең үзен тотышыннан ук Гайфар белән килешүе сизелә иде, шулай да ул:

—Тәгаенләргә кирәк,—диде.—Менә син, Тугиев, кем буласынны класска хәзергәчә әйтмисен.

—Моны әйтәсе дә юк! Мин авылда калам. Быел жәй тракторда эшләп торам. Көзен солдатка алынасы. Әти-әнине ташлап, шәһәргә китмәсем билгеле. Мин армиядән кайтканчы түзәрлек алар. Аннары минем ярдәмнән башка булмаячак. Моны сез мин әйтмичә үк беләсез.

Мәктәптән Гайфар белән Сәрвиназ бергә чыктылар. Аларның бергә йөрүләрен авылда олысы да, кечесе дә гаепләми. Аларның дуслыгын авыл гадәти хәл итеп кабул кыла, чөнки бу ике жанның бер-берсенә тартылмавын мөмкин түгел саный. Аларга бөтен авыл кешеләре үз балалары итеп карый. Алар турында сүз чыкса, исемнәрен әйтеп тормыйлар, авыл балалары, яки, алар, диләр.

Арткы урамга борылгач, Сәрвиназ:

—Укытучыга тупас әйттен түгелме син, Гайфар?—диде.

—Юк,—дип кисте Гайфар һәм баруыннан туктады, Сәрвиназ анын каршына чыгып басты.—Безнен яшьтә кешенен үз фикере булуы гына аз, анын фикере инде ныгыган булырга тиеш. Укытучы мина ачуланмады, фикеремне ачыктан әйтә алуыма сөенде бугай.

Алар яз изрәткән юлда кара-каршы басып торалар. Кояш кызудан туктарга жыена. Егет озынчарак гәүдәле, жилкәләре салынкырак, шулай да жилкәләренен йөкне шудырмаячагы сизелә. Карашы исә тәбәнәк буйлы, күнеле нәфислеге йөзеннән бәреп торган кызда. Хәзер Сәрвиназдан башка бер нәрсәне дә күрмидер ул. Егет кызнын ак юка шәле астыннан бөдрәләнеп чыккан кара чәчләренә кагылып алды, мизгелнен дә мизгелендә булды бу. Кыз Гайфарнын шома ялтыравык битенә бармак очларын тидерде, монысы да мизгелнен мизгелендә булды. Сәрвиназ Гайфарнын укытучы белән сөйләшкәндә үзен әдәпсез тотмавына ышандыруын таләп итеп карый иде. Егетнен шуна дәлиле житмәсә, шушы көчсез кыз гайрәтле егетне тез чүктерер кебек иде. Алар класстагы кыска сөйләшүне кабатладылар, тик Гайфар анлатмаларын өстәде.

—Укытучы сина, теләгән институтына керә алыр иден, диде.

—Мин, теләмим, дидем. Теләмим дә. Ихлас.

—Кырмачы һөнәренне онытырсын, ди.

—Онытмам, дидем. Онытмам да. Чөнки бу һөнәр мина әйберләрне әйбер итеп ясау өчен генә түгел, бизәп ясау өчен дә кирәк. Жан азыгы өчен.

—Ә-ә...—дип класстагы сөйләшүдән читкә тайпылды Сәрвиназ.—Ә-ә... минем жан азыгым нәрсә булыр икән алайса?

—Мине яратуын!

—И-и инде! Шундый сүзне кырыс итеп әйтәләрме инде, Гайфар... Алайсамы?—дип үз соравына жавапны үзе үк башкача кайтарды кыз.—Алайса синен мине яратуын мина жан азыгы булсын!

—Килештек! Тик...

—Нәрсә бар, Гайфар?! Син мине гел, гел яратмассынмыни?..

—Тик синен нечкә күнеленә минем ратуым гына аз булыр.

—Житә, Гайфар!

—Ашыкма. Синен олы күнеленә, мәхәббәт янына, мон кирәк. Монынны жуйсан, мәхәббәт тә яшәтә алмас сине, Сәрвиназ. Шуна күрә табигать сине гармунда уйната, жырлата. Сөйләгәнен шигырьгә охшап киткәли.

—И-и шигырь юлларынын китаптан укып күнелгә сенгәннәре дә бар ич! Гел үзем чыгарганнар гына түгел. Гайфар, дим, Гайфар, син гомер буена болай кырыс булмассын әле, яме? Әй, нәрсә сөйлим сон мин, син йомшак холыклы ич, минем кебек үк.

Егет көлемсерәде.

—Ничек булса да, без бер-беребезгә охшашлар.

—Ә син миннән эшчәнрәк! Ләкин укытучы сина, әйбәт укыдын, Тугиев, әмма бөтен тырышлыгынны куеп укымадын, диде.

—Мин, тырышлыкны өлешләргә бүлгәләп булмый, йә тырышасын, йә юк, дидем. Тырышмыйча бер гамәл дә кылып булмый, бигрәк тә укуда, дидем.

—Укытучы сине шунын өчен ачуланыр, дип курыккан идем, ә ул, рәхмәт, диде.

—Мин ни әйтергә дә белмәдем. Укытучы мина ышанды, дип уйладым. Безнен мәктәпнен укытучылары әйбәт. Син дә алар кебек булырсын.—Егет класстагы сөйләшүгә нокта куйды.—Сәрвиназ, син бүген чишмәгә суга киләсенме?

—Юри сораган була инде,—дип Гайфарнын янәшәсенә чыкты кыз.

Алар тыкрыкка борылдылар. Ингән сукмак Сәрвиназны күтәрә, ә Гайфар адымы саен тез тинентен бата иде. Егет сүзне дәвам итмәгәч, кыз чишмәгә суга киләсен анык кабатлады.

—Ике дә, өч тә киләм әле бүген. Безнен Аргы як кешеләре язгы ташу

алдыннан суны күп китереп куялар бит.

Авылның Аргы як дигәне Шушманың сулында, елгадан өч йөз адымнар чамасында. Монда бер генә урам, ул озын. Мондагы йортлар тау башындагыларга охшамаган, монда йортларны аркылысын-буен тигез диярлек итеп салалар, кирпечтән өелгәннәре ишле. Аргы якта элек авылның хәллерәк кешеләре яшәгән. Авылның гомум биналары монда. Хәтта кибет авыл сәүдәгәре салдырган таш бинага хәзергәчә сыеп тора. Шушма ягындагы бакча башларыннан елгага хәтле—чабылмый торган болын. Шундагы түмгәкләр баш калкыткан, төше-төше белән язгы күлләвекләр ялтырый. Ташу суы монда җәелми, бу тирә авылның башка болыннарыннан күтәренкерәк. Авылның Тау ягы белән Аргы ягы арасында әле сугыштан соң да ташуда юл өзелеп тора торган булган. Аргы якта чишмәләр юк, һәр ихата саен кое казылган казылуын, әмма тау уртасыннан бәргән чишмә суына җитәме соң... Шуңа күрә аргы яктагылар чәйлек-ашлык суны, ташу тынып, Шушмага басма салганчы җитәрлек итеп китереп куярга гадәтләнгәннәр. Сәрвиназның бүген чишмәгә күп мәртәбә киләсенә ишарәләве, Шушма күперен Аргы як белән дамба тоташтырса да, шул гадәтнең онытылмавыннан иде. Борынгыдан килгән гадәтнең.

—Быелга күперне ташу алып китә алмас,—диде Гайфар.—Тузып бара. Сәрвиназ,—дип туктады егет, бер яклы урамга кергәч,—бүген мин чишмәдән бергә су алырга чыкмыйм.

—Нигә инде? Ачуландырдым мәллә?

—Әти белән Казанга китәбез. Олы юлга чыгып, кичке автобусларның соңгысына булса да өлгерербез. Шәһәрдә икене генә кунабыз. Абыйларның хәлен белергә кирәк.

—Фәрданә апа бармыйдыр ич?

—Әти белән икебез генә, дим бит. Аларның берсе барса, икесе дә барган кебек була инде. Сәрвиназ, суны мин иртән ташыдым.

—Синең барысы да алдан уйланган да, эшләнгән дә булыр. Чишмәгә терәлеп торган йортка бер-ике көянтә су кертмәс идемме инде мин? Беләм инде, Фәрданә апа белән мине рәхәтләндереп сөйләштерәсең килми. И-и йомшак та күңелле кеше инде Фәрданә апа, ул сина, юк, син аңа бөтенләй дә охшамаган.

—Сиңа үтенечем бар бит. Әни янына куна менсәң иде.

—Ә... Фәрданә апа гаеп итмәсме соң?

—Үзе әйтте.

—Әйтте инде бик! Ялганлый тагын!

—Әйтмәсә, хәзер мин әйтермен. Тик син бездә кунасынны әти-әниеңә хәзер кайтуыңа ук кисәтеп куй. Аннары,—дип кашларын сикертте Гайфар,—мин югында синең бездә куныуың кирәк. Кич клубка чыгарсың да берәрсе алып качмагае үзенне...

—И-и шушы Гайфарны!—дип буш кулын йодрыклады да егеткә янаган булды кыз.

Гайфар, капка баганасына таянып, Сәрвиназ Шушма күперен чыкканчы карап калды.

Сәрвиназның җомгада ук кайтасын белмәгәч, Хәйрия таба ризыгы пешермәгән иде. Төшке чәйгә кыстыбый өлгертте. Тәмле булган, авылда һәр туйга табын әзерләүче аш остасы шул Хәйрия. Кызы Сәрвиназ белән Гайфар туена нәрсәләр пешерәсен алар сигезенче класста укыган чактан—аларның бер-берсен яратыша башлауларыннан бирле уйлана иде Хәйрия. Авыл кешеләрен тәмле ризык белән сыйларга күнеккән Хәйриягә шунысын насыйп итмәде. Гайфар белән Сәрвиназның туе булмаячак.

Ана, мәктәптән йөгерешеп кайткан малае белән кече кызын уенга чыгарып җибәргәч, Сәрвиназ белән сүзне нидән башларга белмичә, кызын күргәч тә туган фикерен әйтте.

—Ике көн дәресен кала икән, кызым.

—Сагындым бит, әни! Нишлим соң... Дәресләрдә куып җитәрмен,

әни. Сорап кайттым мин. Авылда Гайфарны очратырмын кебек иде...

Ана, мышкылдап, аралыкка кереп китте.

—Әни, әле гыйнварда кышкы сессиянең соңгы имтиханын тапшырыр алдыннан, төш күргән идем.

Ана кызы янына килде, мич каршындагы сәкегә утырды, Сәрвиназның төшен йөзен яшереп тыңлады.

—Әни, Гайфар тракторы белән безнең турыдан узып бара икән, дим, име...

Хәйрия, ул тракторы белән безнең тирәгә беркайчан да килмәде, димәкче булды, ләкин әйтмәде.

—Тракторының гөрелтесе юк, ә үзе бара. Мин капка төбендә торам. Турыма житүгә үк туктыйсың беләм. Гайфар сикереп төшәр дә минем каршыма килер, синең нәни кулларыңны юарга бер сәбәп булыр, дип, кулларымны майландырып кысар, дип көтәм. Ә ул туктамады. Кабинасын ачып кына япты. Гәүдәсе, хәрәкәтләре аерымачык, тик йөзе әйле-шәйле күренә, йөзен томан каплаган. Тракторы шуып кына бара, үзенең гөрелтесе юк...

Гайфар армия хезмәтен ноябрьда тутырды. Кайтышлый Казанда тукталды, институтка барды, Сәрвиназны очрата алмады, иптәш кызлары, ул сине авылда көтә, диделәр. Егет абыйларының хәлен белеште дә автовокзалга ашыкты. Аны Сәрвиназ көтә, олы юлга чыгып ук каршылар Гайфарны Сәрвиназ! Тиле, дип күнелендән үзен әрләде аннары егет, синең кайчан кайтасыңны төгәл белмичә, нигә олы юлга чыгып торсын ди инде ул...

Ә кыз солдаттан кайтучы егетен нәкъ шунда көтеп алды.

Беренче көнне ниләр сөйләшкәннәрен Сәрвиназ хәтерләп бетерми. Клубта булдылар, Гайфарларга бергә керделәр. Гайфарның әти-әнисе моңа бик сөенде. Фәрданә Сәрвиназ утырасы урындыкка яңа киез салгач, кыз уңайсызланды, әмма каенана буласы кеше:

—Сәрвиназ, иялөнә тор. Әле, боерган булса, бусагадан яңа түшәккә басып атлап керәсең дә бар,—дип җайлап җибәрде.

Ләкин кече киленгә дә йомшак түшәккә басып керергә насыйп булмаган икән.

—Өй кысанрак, анасы,—дип утка май салуны кирәк тапты каената буласы кеше.—Безнең өйгә килен сыяр микән, олы киленнәр туры үзебезгә төшмәгәч, киленнәр таләбен белеп бетермибез.

—Юкка хафаланма, Хисаметдин,—дип картына каршы төште Фәрданә.— Минем киленем буласы кеше үзем кебек тәбәнәк буйлы, үзем кебек кин күнелле.

—Шулай дисәң инде.

Өлкәннәр Сәрвиназны хәзер үк килен итәргә ризалыкларын шулай астыртын сиздерделәр. Гайфар тыңлап кына торды. Хәйлә коруны белмәүче, кешеләрнең беренче сүзенә үк ышанучы Сәрвиназ:

—Өегез кечкенә түгел ич, Хисаметдин абый,—дип ихластан гажәпләнде.— Тыштан гына кечкенәрәк күренә, эчтән бик иркен сезнең өегез...

Сәрвиназларга да бергә төштеләр. Монда Хәйрия ут уйнатты, монда ул үзе генә диярлек сөйләде. Ара-тирә, кияү, дип тә ычкындыргалады, моны Гайфар һәм Сәрвиназ белән әтисе Газим ишетмәмешкә салындылар. Кешеләр белән еш аралашып, табын тотуда шомарган Хәйриягә каршы төшү файдасыз, аның кушканын тыңларга-үтәргә генә кирәклеген бөтен авыл белә. Кыз белән егет кергәндә көйләп утырган самавыр сүрелергә өлгермәде, янарды, кыз белән егет өстәл янына утыруга каплаган ашъяулыгы ачылган табынга яңа сыйлар өстәлә торды. Димәк, Хәйриянең Гайфарны тиз генә җибәрер исәбе юк икән.

—Әллә кулымның тәме китеп бара инде,—дигән булды Хәйрия,— ризыкларым уңмады бугай.—Ул да, Гайфарның әнисе кебек, кылны читтән тартты.—Уңмаса да, ризыкны гаепли күрмә, Гайфар. Сәрвиназ пешергәннәре унгандыр әле, вак бәлештән авыз ит менә. Кул да китәр шул. Быел көз авылда бер генә туй да булмады бит. Ничек кулың китмәсен ди?! Болайдан

барсамы, Сәрвиназның туена аш остасын каладан ук чакыртырга туры килмәгәе. Газим, дим,—Хәйрия иренә эндәшкән итсә дә, Гайфарга төбәлеп сөйли,—мин әйткәннәрне ишеттенме син?

—Юк. Колак томаланган. Авызны чылатсаң, ачылыр иде, колакны әйтәм.

—Күрми дә торам икән ич!—дип сүзне борды Хәйрия. Аннары турыдан бәреп салды.—Шешәле хәзинәләренне туйга хәстәрли тор, Газим, дим. Сәрвиназның укуын бетереренә ике ел ярымлап кына калып бара, узганы да сизелмәс вакытның. Газим,—диде Хәйрия һәм, яшьләргә сиздермичә, мич куышына ымлады. Анда яртылаш кына хәзинәле стакан тора иде.—Газим,—дип кабатлады Хәйрия,—Гайфарның Игәренә ашарга биреп керче. Эт мескенкәй хуҗасына тугры шул, Гайфардан калмаган, ияреп төшкән. Газим, карангыда бәрелә‑сугыла йөрмә, кайчак күзенә төртелгән әйберне дә күрмисең. Туйга чаклы ишегалдына прожектор куйдыртасы булыр. Гайфар, синең андый һөнәрең бар, ишегалдың, капка төбен гөлт иттерерсен әле, яме.

Гайфар монысына җавапсыз калмады.

—Туйга мине чакырырсызмы соң?

Авызын ачкан килеш тыны кысылып калды Хәйриянең. Ишек төбеннән Газим Гайфарга баш бармагын бастырып күрсәтте, бу ымлауны инде Хәйрия күрмичә калды.

—Ходаем ла!—дип сүзе атылып чыкты Хәйриянең.—Сәрвиназ, ни сөйли синең бу солдатың?—Кыз эндәшмәде. Хәйрия Гайфарның көтмәгәнчә шаяртуын хәзер генә аңышты, шулай да аны, Гайфар мондый сүзләрне уйлап әйтүе дә ихтимал микәнни, дигән шөбһә сискәндерде.—Ах, сине!—дип егеткә бармак янады ул.—Газим сынары мәллә соң син?! Шулайдыр. Исемнәрегезнең дә баштагы ике хәрефе туры килә сезнең... Ике... ике хәйләкәр җаннар...

Тау ягындагы йортта Хисаметдин белән Фәрданә булачак киленнең тел төбен тартканда, Гайфар сөйләшмичә утырса, инде Аргы яктагы йортта Хәйрия булачак кияүдән туй вакытын тәгаенләргә теләгәндә, Сәрвиназ сүзгә катнашмады. Егет белән кыз өлкәннәр каршында аерым‑аерым имтихан тоттылар. Бүген арадан кемнең бәхетлерәк булуын үлчәүгә салып та белеп булмый. Шулай да Сәрвиназның йөзеннән бүген елмаю аз гына вакытка да китеп тормады. Самимилектән, изгелектән иң якын кешеләрен янәшәсендә генә рәхәтләнергә мөмкинлеген ул ныграк тойды кебек.

Сәрвиназ төш күргән төндә әнисе Хәйриягә дә төш керде. Ана бу төшне бераүгә дә сөйләмәде. Сәрвиназның төшенә каршы шуны сөйләргә жай гына канә, ләкин ана бу юлы да тыелды. Дөньяны шаулатып йөргән Хәйриянең шул сәер төшне күргәннән бирле тынычлап йоклаганы юк, йокысызлыктан элек үк интеккән Газимына бу җәһәттән тиң ул хәзер. Ана күнеленә төш тынгылык бирми, бу төш ананың күз алдыннан китми.

...Шушманың көмеш суы яр өстеннән чыгарга җиткән, тын гына ага икән. Акмый да бугай, югыйсә төнбоеклар белән бизәлмәс иде. Яшел болынны бормаланып ярган Шушмада кинәт күк ат күренде. Суда батмый, елга уртасыннан томырылып чаба, тугайларда да акрынаймый, ялы әләм кебек жилпенеп кенә ала. Җайдак жиз тәңкәле иярдә төз утыра. Тезгенне буш тоткан, чабышкыны тыймый. Икенче кулын сөңге тотып алга сузган. Түгел лә, кулында сөңге түгел, ак төенчек икән. Ат өстендә Гайфар икән ич! Күк чабышкысы Шушма күперен сикереп чыкканда, ак төенчекне Хәйриягә очыртты Гайфар. Аның йөзе күзгә чалынмыйча да калды. Шушманың күпердән өске ягын ялтыравык боз каплаган икән. Чабышкы анда таймый. Алар ерагаялар. Гайфар ичмасам бер генә дә борылып карамый. Шушма түрендә кара болытлар болганып куера. Күк ат калкан болытларга керде, Гайфар төз утыра. Алар ерагаялар, ерагаялар, һаман кечерәяләр... Югалдылар. Артларыннан, жайдаклы ат сурәтенә охшап, аралык кына калды. Болытлар тавындагы сихри өн аерымачык күренә. Тик анда күк чабышкы да, Гайфар да юк инде.

Әллә соң Гайфар Сәрвиназның йөрәген, ак төенчек итеп төреп, Хәйриягә калдырдымы?.. Изге жанны калдырырга анадан бүтән кешегә ышанмадымы егет...

Икенче көнне иртән Шушма күперендә очраштылар алар. Егетнең Сәрвиназларга төшеше, кызның Гайфарларга менеше иде. Гайфар кичәге солдат киемнәрен алыштырган, гел дә элеккеге, әле, бик беләсегез килсә, Сәрвиназ гашыйк булган чактагы—сигезенче класста укыган чакларындагы үсмергә охшап калган иде ул. Алар авыл урамнарында йөрделәр. Аларның көпә-көндез бергә йөрүләрен авылдашлары тыйнаксызлыкка санамадылар. Киресенчә, мона сөенделәр. Әгәр алар бергә булмаса, авыл кешеләре хафага калыр иде. Сәрвиназның студент иптәшләре дә кызның егетен онытылып сагынуын акылы да, хисе дә тирән булудан икәнен аныштылар. Гайфарның солдат дуслары да егетнең кызны сагынуыннан ялгышып та көлмәделәр. Әллә кешеләр, бу ике жанның барыбер кушыла алмаячакларын сизенеп, аларга мөнәсәбәттә шулай киң күнелле булдылар инде тагын. Юк. Сәбәп бүтәндә. Кешеләр олы жаннарны аңлый беләләр. Кешеләр алиһәлеккә һәрвакыт баш ияләр.

—Гайфар, ике ел солдатта булдың, ә мин синең янымда юклыгыңны бөтенләй дә сизмәдем,—диде Сәрвиназ.

Бу сүзләрдә хата юклыгын тоя иде егет, ул сөенеп елмайды да:

—Мин дә шулай,—диде.

—Сагынуга түзеп була ла ул, име, Гайфар. Сагынган кешеңне гел янәшәңдә итеп күрә белергә генә кирәк. Тик мин син югында бер тапкыр да елмаймадым бугай. Кызык, име, Гайфар!

—Мин гел елмаеп кына йөрдем. Син мине белмисең бит, мин үземне генә ярата торган кеше. Сәрвиназның елмаюын миннән башкалар күрмәсен әле, дидем дә, синең елмаюыңны үзем белән алып киттем.

—Карале, әйбәт иткәнсең! Ә минем шуны аңларга акылым житмәгән. Син алдан уйлап эшлисең шул. Минем ачуланмасымны белгәнсеңдер инде, име. И ярабби ла, синнән башка елмаерга язмасын!

Егет күпер таянсасын селкетте, кызның сүзләренә жавабы юк иде.

—Гомерен кичергән икән бу күпер.

Кызга аның мондый күчеше сәер тоелмады, егете белән сагыну турында гына түгел, тормыш мәшәкатьләре турында да сөйләшергә риза иде ул.

—Әти белән Хисаметдин абый күпергә бүрәнәләрне быел жәйделәр,—дип яңа сүзне дәвам итте Сәрвиназ.—Бу күпер авылда безнең әтиләрдән башкаларга әллә кирәкми инде шунда. Әти әйтә, багана-әрлекләре черегән, ди. Яңаны салырга икесенең генә көчләре житмәс шул, име.

—Салырбыз яңа күперне, Сәрвиназ.

—Безнең ара өзелмәсен өчен, име.

—Безнең ара өзелми, Сәрвиназ. Син дә әнә-ә,—дип үз йортларына төртеп күрсәтте Гайфар,—анда булачаксың. Тугиевлар нәселен дәвам итәрсең.

—Шушы сүзне йомшаграк итеп тә әйтеп була ич, Гайфар. Әллә мине куркытмакчы булып сынавың инде. Түгелме? Түгел икән, күзләреңнән күреп торам, Гайфар! Ә күпер... Әйе шул, күпер башкаларга да кирәк.

Арткы урамда мәктәп турысына житкәч, Сәрвиназ:

—Гайфар, әллә укырга керәсеңме соң? Мин көтәрмен,—дип сүзне яңа эздән башлады.

—Юк. Тормышта мин белергә теләгән нәрсәне китаптан укып кына белеп булмыйдыр.

—Нәрсә ул, Гайфар?

—Кара туфракта үскән ашлык нигә ак икән, дим. Аннары, кулыңа диплом алгач, син миннән барыбер йөз чөермәссең бит.

—И-и инде, сине ташлыйм диме инде.

—Аннары,—дип ары укымавының сәбәпләрен санауны дәвам итте егет,—институтларда һөнәргә каратып торгызып өйрәтмәкче булалар. Карап торып өйрәнә алса, әнә, Игәр һичшиксез кассапка әйләнер иде. Мал суярга да карап торып кына өйрәнеп булмый.

—Алайса мин дә институттан диплом күтәреп кенә чыгаммыни инде?

—Синең һөнәрең үзгә, Сәрвиназ. Укытучы булу өчен, белем алудан тыш, тәрбияче булып туарга кирәк.

—Сагынганга күрә генә мактавыңдыр әле, Гайфар,—дип иркәләнде кыз.—Әйеме? Юк, диген! Йә, йә, әйт әле! Юк, диген!

—Әйе.

—И-и шушы кырыслыкларыңны! Әти сыңары!

—Син—әни сыңары.

Егет кызның чәч очларына мизгелнең мизгелендә генә кагылып алды. Алар мәктәптән соңгы каникулга чыгып кайтышлый туктаган төшкә житкәннәр иде.

Гайфарлар урамына керделәр. Игәр өйләренә чапты. Егет белән кыз якынлашкач, каршыларына чыкты, Сәрвиназга сырпаланды, безгә кермичә узма, дип чакыра кебек иде. Кыз аның башыннан сыйпады. Гайфарларга кермәделәр. Аларның Аргы як урамын да әйләнәселәре бар иде. Игәр алардан калмады.

—Гайфар, син нигә этегезгә, Игәр, дип исем куштың? Игәр үзе, эт, дигән сүз бит ул, ау эте.

—Мин аның белән ауга йөриячәкмен.

—Ауга?! Куян атаргамы? Ю-ук, Гайфар, бер генә җәнлек-җанварны да атмыйсың! Бая, кассап, дигәнең дә колагымда һаман яңгырап тора. Нигә малларны чалалар икән ул?

Егет кызның соңгы соравын җавапсыз калдырды.

—Ир заты ауга чыкмыйча түзәрме соң?! Ау—безнең халыкның борынгыдан килгән һөнәре. Аусыз булмый. Игәр җаны да ау тели. Игәр белән чыгып китәрбез дә, ау уңып, кайтып та керербез! Син безне елмаеп каршы алырсың.

—Алайса, Гайфар, син җәнлек-киекләрне атмыйча, тотып кына алып кайтырсың. Без аларны асрарбыз.

... Гайфарларга бәхетсезлек килде. Яндылар. Декабрьга кергән төндә. Ут күршеләреннән чыкты, аларның барлык каралты-куралары янды, Гайфарларның Сәрвиназ күркәмгә санаган йорты көлгә әйләнде. Шөкер, үлем-житем булмады, малларны һәм кош-кортларны чыгарып өлгерделәр. Колхоз йорт салмакчы булгач, Гайфар каршы төште. Әти-әнисе, без колхозда билне бушка күп бөктек, дигәч тә, ризалашмады.

—Сезнең өчен булышсыннар, шулай дөрес,—диде ул.—Ләкин колхозда эшләп күрсәтмичә, минем түләү алуым теләнү булыр иде. Мин теләнмим.

Сәрвиназның вакытлыча үзләренә төшеп торырга чакыруын да кире какты Гайфар.

—Әти белән әни үзләре әйтте,—дигән иде кыз.

—Юк!—дип кашларын сикертеп көлемсерәде Гайфар.—Иске куышта яшәрмен, әмма йортка кермим!—дип кырт кисте.

Страховой акчасына һәм абыйлары биргән акчага үз урамнарында хуҗалары шәһәргә күчкән йортны сатып алып, шуны күчереп салдылар. Шул буш йортта язгача, күчермичә, яшәп торуны да өнәмәде Гайфар.

—Төп нигезне алыштырмыйлар,—диде.—Хәзергә безгә шушы йорт житә. Кирәге туса, зурайтырбыз.

Ата-ана мона бик теләп килеште. Гайфар яшисе йорт ич, ул теләгәнчә булсын. Йортны элекке нигезгә өймәделәр, эчкәрәк утырттылар. Шушмага түрен каратып. Йорт өлгергәнче, сул күршеләренә өйдәш булдылар. Янучы ике хуҗалыкны йортлы итүдә авылдашлары, читтәге туганнары ярдәмнәрен кызганмадылар. Гайфарлар йортка гыйнвар тугач, януларына ай тулган көндә күчтеләр.

Йортның эшләнеп бетмәгән төшләре шактый, болары инде җәйгә кала. Тәрәзәләргә йөзлекләрнең элеккеләрен кактылар. Хисаметдин үзе ясаган йөзлекләр. Ләкин аларны җәен алыштырмакчылар, Хисаметдин яналарын ясый башлады, Гайфар да булыша.

—Булыр, барысы да булыр,—дип тынычландыра Фәрданә карты белән

малаен.—Исәнлек кирәк тә Ходай берүк ярдәменнән ташламасын. Сәрвиназ өйгә җиһазлар менгерде менә. Шимбәдә кайтам, диде. Әниләрнең хәлен беләм дә туры сезгә йөгерермен, диде.

Хисаметдиннең кулыннан кыргычы төшеп китә язды. Гайфар зур учлары белән йөзен каплады. Гайфарның күзләренә хәтта сөенеч яшьләрен дә күтәрергә-төшерергә көчләре чамалы ике җан гына—Фәрданә белән Сәрвиназ гына китерә алалар.

... Хәйрия мал-туар карап кергәндә, Сәрвиназ альбом актара иде. Әнисенең:

—Кызым, Шушманың шавы көчәйгән. Әллә ташу карап менәсеңме соң? Күпер төбенә кеше күп җыелган. Боз кузгалгандыр,—дигән сүзләрен әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә игътибар итмәде шунда.—Сәрвиназ...

Ишетмәгәндер кызы, ул үзалдына сөйләнә башлады.

—Гайфар, Гайфар, дим, чәчләремә гадәтенчә кагылып кына китсәнче... Бармак очларыңны гына чәчләремә тидерүең дә мине озаклап иркәләвең кебек булыр иде. Кыюсызым минем... Ир-ат арасында сиңа тиңләшерлек зат юк. Мин синең чәчләреңне үзем сыйпыйм, яме, Гайфар...

Ана, кабат сүз әйтеп, кызын уйларыннан бүлдермәде. Урта ишекне йомшак кына япты да учак-казан тирәсендә кайнаша башлады. Аның хәрәкәтләре салмак иде, элек казан тирәсенә якынаюга кулы уйнар, авызында җыры бетмәс иде. Хәзер бисмилласын да күңеленнән генә укыды. Кешеләр белән аралашып яшәргә күнеккән Хәйрия хәзер урам-кибет тирәсенә бик хаҗәте төшкәндә генә чыга.

Сәрвиназ, урта ишекне ачып, бусагада басып калды. Әнисе аны күрмәде, токмачка камыр җәя иде. Кызы аралыкка кереп кулларын юган тавыш ишеткәч кенә шул якка борылып карады. Сәрвиназ әнисе кулыннан пычакны сүзсез генә алды, вак итеп токмач кисте. Шөгыле беткәч:

—Әни, сиңа сөйләгәнем юк, гыйнварда соңгы имтиханны тапшырганда, мин бүлмәдән чыгып йөгергән идем,—диде.

Ана аптырап торды.

—Борчылма син, укытучы миңа «бишле»не хак куйган иде. Мин билеттагы сорауларга җавапларымны сөйләп бетереп килә идем. Кичә шул имтиханны кабат тапшырдым. Укытучы, сез әйбәт җавап бирдегез, белемегез «бишле», дип, сынауны кабат алмаска теләгән иде. Бик үтенгәч, ризалашты. Бөтен фәнне сорап чыкты. Шул имтиханны кабат тапшыруым шатлыгыннан да бүген үк кайттым мин. Бурычым калмады. Гайфар бурычтан бик курка иде. Йортлары янгач, уттан-судан курка башлады. Үзе шуны миңа сиздермәскә тырыша иде. Гөнаһсыз сабый иде инде Гайфар...

Ана, кызының теге чакта имтихан ташлап йөгерүе сәбәбен белергә теләп, Сәрвиназга текәлде.

Гайфар, армиядән кайткач, «Беларусь» тракторына утырды. Кулдан-кулга күчеп йөри торган трактор бу, егет армиягә киткәнче дә шунда эшләп алган иде. Тартуы хәзер тагын да кимегән, шуңа күрә Гайфарга авыл тирәсендәге эшләрне генә кушалар. Тимер юл станциясенә ташкүмергә бер генә тапкыр җибәрделәр, икенче барудан Гайфар үзе баш тартты, юлда калуың ихтимал иде. Фермадан басу читенә тирес чыгарып өяләр, шунда ук торф ташыйлар—черемә ясамакчылар. Язгы эшләр башланганчы, Гайфар тракторын әйбәтләп ремонтларга исәп итә, яшь кешегә яңа тракторны тиз генә тоттырмасларын белә.

Колхоз, килешенеп, шәһәр урамына керер кыяфәтле машиналарын Казан заводына кышка биреп тора. Авылда калтырчалары гына кала. Бүген, менә, берсе дә юл чыкмады, ватылганнар. Фермага тегермәннән фураж ташырга Гайфарга куштылар. Тегермән Тау ягында (су тегермәненең Шушмада урыны гына калды), авылның югары башын чыккач, амбарлар янында. Иртән бер тапкыр фураж төяп төште, икенче йөгенә менде, төшкә чаклы өлгерәчәк әле. Йөк төяп йортлары яныннан узганда, Игәр аны капка төбендә карап

калды. Гайфар тимер атка утырып йөргәндә, хуҗасына иярми эт, аты чын булса, кусан да калмас иде.

Күпер төбендә тракторын туктатты Гайфар, күпернен ныклыгын куш аяклап сикереп тикшерде. Йөкле тракторны чыдатыр кебек. Тракторын озын күпергә акрын гына, сак кына алып керде Гайфар. Күпернең ыңгырашуын, сызлануын ишетми егет, ыңгырашу-сызлануларны трактор тавышы баса.

Трактор күпернен уртасына житә, уза, инде күпер уртасында йөк төялгән арба. Кинәт...

Күпер тарала-ишелә башлады. Гайфар тракторын алга ыргылдырды, ләкин арба кыйшая-янтая аска шуышты, үкереп азапланган тракторны үзе белән сөйрәде. Күпер астындагы боз ватылып инде дә арба суга чумды, аның турына ук трактор чалкан капланды...

Имтихан тотучы Сәрвиназ нәкъ шул мәлдә:

—Гайфар...—дип пышылдады.

Укытучы күзләрен зур ачып сәерсенде.

Сәрвиназ:

—Гайфар үлде!..—дип тамагын ярып кычкырды да бүлмәдән чыгып йөгерде.

Гыйнварда булды бу.

Күперне төзәтмәделәр. Машиналар, атлылар боз өстеннән юл салдылар. Боз йомшаганчы, колхоз терлекләренә фуражны житәрлек ташып куйдылар. Инде ташу купты. Жәяүлеләр йөрергә кемнәрдер күпернең исән баганалары башына басма корып куйган, таянсалары да бар. Әмма монысы Хисаметдин белән Газим эше түгел, алар боз нык чакта да бер яктан икенче якка чыгып йөрмәделәр. Икесе ике ярда торып кына хәл белешәләр иде. Икенче атна инде кода буласы кешесен яр буенда очрата алмый Хисаметдин. Газимнең шифаханәдә икәнен белә, шулай да Шушманың жимерек күпере төбенә көненә бер тапкыр төшеп менә. Хәер, ташу купкач, бер-берсен күрсәләр дә, Шушма шавы тавышларын ишеттермәс иде.

Хәйрия аш булдырырга торганда, Сәрвиназ ашыгып киенә башлады.

—Кызым, кая җыенуың?

—Әни, мин Гайфарларга менеп төшәм. Хисаметдин абый белән Фәрданә апа кайтканымны белсеннәр. Аннары аларда Гайфарның солдатта төшкән менә бу фотосы калмаган иде.

—Кызым, караңгы инеп килә. Басма бик хәтәр, диләр. Күпер төбеннән кешеләр таралышкан бугай,—дип тәрәзәгә сузылып карады ана.—Иртәгә менәрсең. Иртәнге якта ташу кимегән була.

Сәрвиназ бу кисәтүне әллә ишетмәде, әллә мона игътибар итмәде инде. Аңына барып житмәгәндер.

—Әни, дим, күр әле син Гайфарның ничек елмаеп торуын! Солдатта гел елмаеп кына хезмәт иттем, дигән иде ул.

—Сәрвиназ, иртәгә менәрсең, дим,—дип тавышын күтәрә төште Хәйрия. Әмма шунда ук йомшады.—Иртәгә бергәләп менәрбез. Хәзер аш булдырам. Син токмачны тәмле кисәсең. Тәмләп ашыйк. Фәрданә кодагыйны... Фәрданә апаны минем дә атна буе күргәнем юк. Яме, кызым, иртүк менәрбез.

—Әни, син борчылма, сынар тактадан да йөгереп кенә чыгам мин! Әнә, басмадан кешеләр йөргәләп тора. Мин, Гайфарларга менеп житүгә, утларын сүндереп яндырырмын. Бик сагынышкач, Гайфар белән шулай хәбәрләшә идек...

Кызны теләгеннән тыеп булмасын аңлады ана, Сәрвиназның башына ак юка шәлен үзе бөркәде.

—Әни, дим, Гайфар бигрәк тә беркатлы иде инде, име. Мина солдат бүләге итеп шушы шәлне алган бит. Минем нәкъ шундый шәлем булуын белә иде ич ул, нәрсә алырга белмәгән инде. Туктале, әни, шәлне бик белеп алган икән бит ул, мине гомер буена гел шундый шәл бөркәнсен дип уйлаган.

Сәрвиназны әнисе һәм, дәрес әзерләүләреннән бүленеп, энесе белән

сеңлесе, дәү лампочка яктырткан капка төбенәчә озата чыктылар.

Кыз, өй турысыннан узганда, пәрдәсе тартылмаган тәрәзәдән гөлләрне күрде. Иртәнге якта үзалдына әйткән шигырьне бу юлы көйләде:

—Нигә кирәк хәзер гөлчәчәкләр...

Һәм кинәт көлеп җибәрде, тынын кысып кинәт туктады.

—Гайфар, дим, Гайфар, кичер, синнән башка көлдем бит...—дип пышылдады.

Сәрвиназның җыр көйләвен, көлүен, пышылдавын әнисе, энесе һәм сеңлесе ишетмәделәр. Алар капка төбендә үк калган иде.

Кыз күпер төбенә җиткәндә, анда кеше калмаган иде инде. Сәрвиназны күреп алды бугай, зират ягыннан Игәр чабып төште. Гыйнвардан бирле зиратка көн саен барып кайтырга гадәтләнде ул. Кар яуган көннәрдә зират капкасына тикле бата-чума сукмак салды Игәр. Зират капкасыннан эчкә узмый. Зиратка Гайфарның гәүдәсен күтәреп кереп китүчеләрнең эчкә узмаска боеруын искәреп калгандыр ахрысы. Хәер, күбесенчә этләр болай да зиратны әйләнеп узалар, өергә берләшсәләр генә, зират коймасы аша сикерәләр. Игәр, басма төбендә җиргә борынын тидереп иснәнде дә, Сәрвиназның каршысына сак кына бара башлады.

—Игәр, кермә! Суга егылырсың! Мин үзем синең янына чыгам! Мин сезгә барам бит! Гайфар абыеңның карточкасын алып менәм!

Ләкин эт кызга таба ашыгып атлый бирде. Алар якынайдылар. Сәрвиназ, таянсадан кулын ычкындырмыйча, Игәр алдына иелде.

—Балакай, ярда көт, дидем ич мин сиңа. Ишетмәгәнсеңдер шул. Башың әйләнер бит, ничек борылырсың икән соң син?

Игәр Сәрвиназның битенә борынын тидерде, чинап куйды. Теләгәнен теле белән әйтә алмый шул...

—Игәр, син миңа Гайфар абыең янында булуыңны әйттеңме? Аңладым мин сине, Игәр. Син берүк кабалана күрмә! Мин сиңа Гайфар абыеңның карточкасын күрсәтермен, яме. Син борчылма, Игәр, егылырсың. Монда егылырга ярамый, егылырга бөтенләй дә ярамый. Мин борылам, син турыга бар, дөрес этәсең син мине. Әлгәре безнең якка чыгыйк. Аннары борылырбыз. Менә шулай, алдыма төш. Акыллы шул син...

Сонарган боз күпер-басманың урта баганасына шартлатып бәрде. Күпер дигәннәре чөелеп таралды. Такта-колгаларга кушылып, Сәрвиназ белән Игәр дә очты...

—Гайфар!.. Игәр!..

Эт Шушма шавын басмакчы булып чинады.

... Шушманың суы урынына утыргач, тонгач, Сәрвиназның гәүдәсен элекке тегермән арыгы алдыннан таптылар.

Игәрне әлегәчә тапмадылар.

... Боз күпергә бәргәнче кызның Тау ягына барыбер чыгып җитә алмаячагын белеп керде бугай Игәр Сәрвиназ каршына, аргы ярга араның кыскарак булуын чинап, Сәрвиназга борыны белән төртеп аңлатырга-ашыктырырга теләде бугай тугры дускай...

Шушма бүген тын ага. Әмма агымында шом куера. Яңа хәвеф килмәгәе...

*1989, 2000.*

# ӘМАНӘТ

Күнелгә бер хикәя килде. Кылт итеп килде. Әйе, шулай да булгалый—кайчакта хикәя вакыйгасы синнән рөхсәт-мазар сорап вакланмый, күнеленә бәреп керә. Еш очракта исә хәтер хәзинәндәге хикәялек хәлләрне кат-кат барласаң да, үтенсәң-ялварсаң да, хикәя киреләнә, тыңлаусыз холкын күрсәтә, күзалдына аерымачык басмый. Ә менә монысы кыстатмады.

Тик, кайтадан уйлагач, бу кечкенә әсәр эчтәлеге мина таныш кебек булды. Күптән-күптән үк, малай чакта ук, мона охшаш әсәрне укыган идемме? Әллә ишетеп беләмме аны? Әйе, мона тартым сюжетны, инде бер тапкыр искәрткәнемчә, мина шагыйрь Зөлфәт биргән иде һәм «Йонтәс» исемле хикәя язган да идем.

Шулай да монысы үзгәрәк кебек, монысында яманлык яхшылыкның якасына ябышырга теш ыржайтып ажгыра сыман.

Әллә... Әллә соң этләр холкындагы килешсезлек кешеләргә дә хас икәнлегенә үзем шаһит идемме? Шулай да кебек. Бу вакыйга турында үзем ишетүемнен, анын кайбер ваклык-нечкәлекләрен үзем күреп торуымның хәтерем агымы сайлыгы уртасына туры килүе бик тә ихтимал бит. Хәер, хикәям эт һәм этлек турында гына да түгел ләбаса...

Өченче ел бәрәнге казып бетергән көнне кичен Габдияр картның сул күзе бәбәге тәмамынча томаланды. Йорт-нигезне хәлдә тотучы төпчек улы белән килене каршы төшсәләр дә, тынламады карт—көченәчә бәрәнге чүпләште. Оныклары житезлегенә тинләшә алмаячагына сөенде ул—шөкер, көч салып эшләргә өйрәнәләр балалар.

—Сезнең чиләкләрегез чөмәләкәй тулганда, минекенең төбе капланып ук бетә,—дип шаяртты Габдияр. Ә бәрәнге төбен каерып куптарып, селтәбрәк чәчүче улы белән киленен:—Тыймагыз,—дип йомшак, әмма кире каккысыз кисәтте.—Бала чагыма кайтыймчы...

Бәлки, иелеп бәрәнге чүпләү дөм сукырайткандыр Габдиярны. Ләкин күрүе һаман начарланучы күзенең каплануы сәбәбен мона сылтамады, бала чагына алып кайткан шөгыльне гаепләүне гөнаһ санады карт.

—Вакыты житкән,—дип улы белән килененең шелтәләвен иплэп тыйды Габдияр.—Тәндә жан барында шушылай яшәрмен.—Уйланып торгач:—Яшәрбез,—дип төзәтте.—Сез мине нинди хәлемдә дә имгәккә санамаячаксыз. Тик...—диде дә, кирәкмәс тарафка борыла башлавын абайлап, сүзен йотты.

Улы белән килене, ниндидер хәлнең яшерелеп торуын искәрсәләр дә, бу хакта сорамадылар, тиеш санаса, әти-әткәйнен үзе әйтеренә ышаналар иде алар—кадерле кешене беркайчан да нәрсәгә дә булса мәжбүр итәргә ярамый, анын жаен һәрчак жайлау үзе мәжбүри ич.

Габдиярнын уң күзе исә моннан биш ел элек сукырайган иде. Вакытында операция ясауга кыстауларга ул:

—Күпме вакыт якты дөньяны күрергә язган—шул кадәресен күрермен,—дип каршы төште.—Тәнгә пычак тидертмәм, дигән сүзем булды бала чагымда. Кешеләргә һәм дә үзенә-үзең биргән сүзеңдә тору тиеш. Ант, вәгъдә һәм әманәт—алар иш.

Күрмәс булгач, Габдиярнын ерак дигән сәфәрләре капка төбендә чикләнде, явымсыз чакта шунда чыгып утырды ул. Узган-барган кешеләр белән хәл-әхвәл белешеп әнгәмәләшү авылдашларыннан ерагайтмыйча тотты, түшәккә буйсынудан коткарды аны.

Жир тунды, хәйран ук ныгытты, шулай да кар төшәргә ашыкмый иде. Көннәр аяз торды, шулай да такыр сукмакларны лыжырдатырга кояшнын куәте житми иде инде. Шундый чакта—көз белән кыш алышынганда—басу-кырларда турыдан кистереп йөрергә, урманга менгәләргә ярата иде Габдияр. Бу гадәте бала чагыннан ук килә. Шуна күрә авылда анын мондый сәфәрләренә гажәпләнмиләр. Әгәр:

—Инде урманына мен дә ди, ә менә басу буйлап титаклаунын ни кызыгын табасын?—дисәләр:

—Басунын үз матурлыгы, ә урман шулай ук бүтән,—дияр иде ул.

Ярый ла йөреп калган, хәзер менә ни теләсә дә капка төбеннән уза алмый.

Беркөнне, улы белән килене эшкә киткәч, оныклары мәктәпкә йөгергәч, Габдияр, инде гадәтенчә, капка төбенә чыгып утырды. Әмма анын янына бу көндә, гадәттәгечә, башлап авылдашлары тукталмады, узучы-китүче нигәдер булмады. Ә бер көчек анын аякларына йомшак чинап сырпаланды.

—Син, яшьтәш,—дип эндәште ана сукыр карт,—нигә болай сонардын сон әле? Эт кавемнәре кышка карап балаламый иде бугай. Бар, үз юлында булчы. Анаңа сыен.

Ләкин көчек китмәде. Габдиярнын аяклары арасына керде дә, бәләкәй башын арткарак яшереп, алгы аякларын картнын киез итекләре өстенә уңлап-суллап салды. Гомерендә эт асрамаган-тотмаган Габдияр көчекне куып җибәрмәкче иде, тик аякларын кымшата башлауга ук көчекнен йомшак чинавы аны мондый миһербансызлыктан тыйды. Агаем, мин сиңа кирәгрәк, дигән кебек тоелды көчекнен үз итеп тавыш бирүе, шул йомшак чинау, чын әгәр, буйсындырды да куйды картны. Һәм ул көчекне алдына утыртты, аны башыннан һәм сыртыннан сыйпаштырды.

—Йомгак хәтле генә икәнсең син. Нәселен шундый кечкенәдәнме? Шаять, шулайдыр.

Көчеккә шушы илтифат җитә калдыдыр, ул Габдиярнын күкрәгеннән югарыга житез үрмәләде дә картнын шома битенә (улы этисен иртән әйбәтләп кырган, сакал-мыегын кыскарткан иде) юеш борынын тидереп алды. Мондый кыюлыкка карт ачуланмады, шулай да кайбер теләкләрен шелтәсез генә искәртте—кеше белән сөйләшә диярсең, әй.

—Базымчан икәнсең,—дип дерелтәнә башлаган көчекне пәлтә изүен чишеп җылыга кертте ул.—Вәләкин бер-беребезне бимазаламаска сүз куешыйк. Кыек-кыеш гамәлләр кылмыйк. Фәһемле булырсын, яме, сезнең эт халкына да зирәклек бик кирәк. Минем белән дуслашырга теләсәң, иренчәклекне бөтенләй дә белмә. Их-х, икәүләп ерак-еракларга сәфәрләр кылырбыз әле...

Көчек тагын йомшак тавыш бирде, әллә ризалашуын белдерүе булды тагын.

—Кем сон әле син—иркәкме, инәкме? Җенесең нинди, дим. Шулаймы... Әмма ки тагын бер хакта әлгәредән килешик—беркайчан да текә кыланмаска, миңа бу юеш борыныңны чөймәскә, дим. Исемең юктыр әле синең. Нинди исем кушыйк сон сиңа, ә.

Габдияр көчекнең башыннан озаклап сыйпады, көчек, хуҗалы булу сөенеченнәндер, картнын тонык күзләреннән карашын алмаска тырышты, әллә, аның күрмәвен сизеп, мона гаҗәпләнүе булды тагын.

—Сине тышта калдырып булмый. Керик соң өйгә. Бүтән хуҗаларын кайтканчы, сине өй эче белән таныштырыйм. Ә-ә, исем тапмадык бит әле сиңа, Йомшакҗан. Туктале, миңа исемен дә булды ич—Йомшакҗан!

... Бу вакыйгадан соң ике кыш та бер җәй узды. Эт, Габдияр аны беренче иркәләвендә сиземләвенчә, тәбәнәкләр нәселеннән икән, карт ана хәзер дә кайчакта, Йомгак, дип эндәшкәли. Йомшакҗан бу исеменә дәияләнде, хуҗасынын төрлечә атавына да күндәмләнде. Тик баштарак аңа муенчагы ошап җитмәде, аны салып ташларга тырышкалап карады. Карт, муенчакка озын каеш эләктереп, аны бушатмыйча тартып йөри башлагач, бәйне артыкка санамады тагын, хуҗасын әйдәләү бурычы үзенә йөкләнүен аңладыдыр.

Алар—Габдияр белән Йомшакҗан—баштарак авыл урамнары буйлап кына йөрделәр. Карт, борыласы тирәне алданрак чамалап, этне, иелеп, шул ягына чыгарды. Йомшакҗан монын сәбәбен баштарак төшенмәде, әмма мондый боерукларны хәтеренә сендерә алды. Шуннан соң картка эт ышанычлы кулавыз булды.

Җәен алар басу юлларына чыккаладылар, урманга да баргаладылар. Соңгыларында Габдиярнын оныклары аларга баштарак ярдәм иттеләр. Беренче тапкыр урманга менгәч, оныкларына карт:

—Урманчынын ташландык ихатасы урынын узгач ук юллар кисешәдер,—дигән иде.—Шуннан унга каерылырбыз.—Һәм, борылып туксан адымнар чамасы киткәч (Габдияр бу санны, сукырайгач адымнарым кечерәйде, дип, йөз унга житкерде):—Авыл ягында юан каен күренәдер, анын кәүсәсендә, шулай ук авыл ягында, зур оры бардыр,—дип аңлаткан иде.—Шул тирәдә ял итеп алырбыз. Чәйләрбез, термоска чәй тутырдыгыз ич.

Каен төбендә утырганда да Габдияр, оныклары эт белән куышып

уйнарга теләсәләр дә, Йомшакҗанның бәен кулыннан ычкындырмады. Каен төбенең җирдән кыйгач күтәрелгән юантык тамырлары арасының ниндилеген күнеленә сендерергә тырышып капшап утырырга онытмады карт.

—Шул тирәдә юан тупыл да бардыр,—дип әңгәмәгә катышсыз рәвештә кыстырды Габдияр.—Кисмәгән булсалар.

Кисмәгәннәр икән тупылны. Оныклары шунын янына таба йөгергәч, эт тә алар артыннан тартылды, әмма олы хуҗасынын сак-салмак атлавына җайлашырга мәҗбүр булды—Габдиярга адымнарын санарга кирәклеген Йомшакҗан белә алмый лабаса.

Бу сәфәр узган җәй башындарак булган иде. Кыш кергәнче атнага кимендә бер тапкыр менделәр алар урманга. Габдияр белән Йомшакҗан.

Һәм менә күрмәс карт белән кулавыз эт бергәләп икенче җәйне каршылыйлар. Урманга быелгы сәфәрләр майнын унҗиденче көнендә—юллар кипшереп житкәч башланды. Көннәр явымсыз торды, һәм карт белән эт урман юлын көн саен таптадылар. Моңа Габдиярны инде Йомшакҗан кыстый иде кебек, иртәнге чәйләү бетүен ул тупсага утырып көтәргә, хуҗасын аратирә йомшак чинап ашыктырырга гадәтләнде. Әмма хуҗасы киенеп-әзерләнеп беткәч кенә ишек яңагы янындагырак тәбәнәк чөйдәге каешны-муенчакны, алгы аякларын ниргәләр арасына куеп, тешләп алыр булды.

Бүген көн кояшлы. Урман кичәгедән дә бизәлебрәк каршылар аларны, шулай—вакыт һәм табигать дигәннәрен үз кануннарын нык тоталар. Бүген—җәйнең беренче көнендә—вакыт вә табигать изге карт белән анын гөнаhсыз этен, яшәү бәхетенә чумдырып, сихри-бай урманда рәхәтләндерерләр.

Киттеләр. Күрмәс Габдияр һәм кулавыз Йомшакҗан.

Урманга житәләр булыр—карт шулай чамалады. Эт тартылып баруын кинәт акрынайтты—картнын кулына элмәкләп киертелгән каеш бушады.

—Ни булды, Йомшакҗан?

Эт теш арасыннан гына йомшак чинады. Алар туктамадылар. Ләкин карт кипшермәстән тәгәрмәч изгән эз кырыена сөртенде.

—Йомшакҗан, юлдан тайпыласың бугай. Ни бар? Урманга життектер.

Ләкин эт тавыш бирмәде, тукталып калган картнын аяклары арасына кереп посты. Тик хуҗасының каршына кинәт чыкты да озын халаты итәкләрен тырнарга тотынды. Беренче очрашуда ук Йомшакҗанның Габдияр куенында рәхәтләнүе күнеленә сеңеп калгандыр, ул үсеп житкәч тә шулай иркәләрнергә ярата иде. Әмма бу юлы куенга керергә теләве рәхәт кылырга теләве түгел иде кебек, кабаланып һәм катырак итеп тырный иде Йомшакҗан-Йомгак.

—Здравствуй... исәнме... абз... бабай...

Габдияр, тавышлану-фәлән, хәтта кыштырдау ишетелмәсә дә, тирәюньдә җан иясе булуын Йомшакҗанның үзен тотышыннан, әллә соң, ерткыч җанвар сагалыймы безне, дип юраган иде. Мондый чуар сәламләүне һич тә көтмәгән иде ул. Өстәвенә эндәшүченең сүзләре генә түгел, ә тавышы да ала-кола иде—ни ир заты, ни хатын-кыз тавышы шунда, шулай да хатыннар тавышына тартымрак иде.

Малай чактан ук юлдашы—кул таягы (боларнын ничәмә-ничә тапкырлар алмашынуы саналмаган) белән җиргә төрткәләп алгач кына, карт:

—Хәзергесенә шөкер,—диде.—Алай... Искәрмәстән булды исәнлек соравың. Посканояннан атылып чыктың кебек. Кем...

—Кто мин—потом әйтә. Син Габ... Габдияр будешь?

Юлларында очраучының хатын-кыз булуына шиге калмады картның, тамак кыруы ирләрчә түгел иде урман авызында көтеп торучының. Сәер сөйләшүче хатынны эре гәүдәле, кайсыбер ирләрне бөтәрләп салырдай көчкә ия, кырык яшьләр тирәсендәге кеше итеп күз алдына китерде ул. Үткен күзләре тирәнгә кереп утырган, йөзе исә кызгылт булып тоелды ана. Боларын дөрес чамалады Габдияр. Ә ничек киенгән? Башында артка бәйләгән бизәкле яулыкмы? Кин итәкле күлмәге аяк йөзләренә житәме? Балаитәкле ак алъяпкычтанмы? Боларында ялгышты карт. Хатынның башында тирән берет, өстендә күн пинжәк иде. Хатынның кара киҗе-мамыктан тегелгән чалбарын бот-тубыклары аерып җибәрер кебек иде.

—Нигә ответ бирмисен?

Карт иягеn сыпырды, карчыгы басып биргән (һәм аның кадерле бер төсе булып калган) ак тула эшләпәсен арткарак этәрде дә маңгаен ышкыштырды. Куеныңда ара-тирә чинап-шыңшып куйгалаучы Йомшакжанны эчкәрәк кертте. Башлап этккә эндәште.

—Гаҗәбрәк әле хәлләр, Йомшакжан. Бездән сорау алмакчылар.—Шуннан соң башын хатын тавышы килгән якка күтәрде. Күзләре күрсә, ул хатынның карашындагы ашкыну галәмәтен һичшиксез сизәр иде.—Шуннан, фаразан, мин Габдияр булам, ди. Шуннан ни була икән инде?

—Минем исем—Нифака.

—Мондый исемне беренче ишетәм. Вә сине дә белмим.

—Фәйсални знал?

Габдияр сискәнде, гәүдәсе калтыранды, бу калтырануда куркыну да, өстән күптәнге йөк төшәчәгенә өметләнү дә бар иде. Шулай да карт җавап кайтарырга ашыкмады. Йомшакжанны җиргә төшермәкче булды, ләкин эт тырнакларын хуҗасының киемнәренә батырып карышты, кулавызлык вазифасын үтәргә теләмәде. Карт, таягын сузып суккалап, юл уртасынарак чыкты.

—Җитәсе төшкә җитик без, Йомшакжан.

Габдиярның үзен тотышын илтифатсызлык буларак кабул итте Нифака исемле хатын. Хәтта хәйран саллы йодрыгы йомарланды—хатын-кызга хас түгел хәл, әкәмәт.

—Знал мы син Фәйсални?! Минеке әтине?

—Сөйләшүең элмә-телмә, тотар төше калмаган, теткәләнгән нәмәрсәкәйнең нәкъ үзе.

—Фәйсални зналмы?

—Вафатмыни Фәйсал? Яшьтәш иде. Урыны җәннәттә булсын. Миңа да вакыт житәдер...

Утызынчы елның язгы чәчәү беткән чак иде. Фәйсаллар гаиләсен авылдан сөрделәр. Кулаклар тамгасы сугылды аларга. Соңгысы хаклыдыр да, чөнки алар авылның иң бай кешеләре, хәтта череп баеган кешеләре иде. Йорт-җир тазаның тазасы, рәеш киемнәре гел дә затлыдан, табынга кунак сые көн дә тезелә, Фәйсалның әтисе тарантаска яки кошевкага күк юртак җигә. Кулак дәрәҗәсен билгеләргә шушылар житеп ашкандыр, күрәсең. Анысы, Габдиярлар да ярлылардан түгел иде, һәммәсе дә житеш иде. Ә аларны сөрмәделәр, урта хәллегә санадылар, алар колхозга кереп өлгергәннәр иде.

Фәйсалның әтисе, сөрелү алдыннан, Габдияр исемле күрше малаена бер үтенечен әйткән иде.

—Син төптән нык чыккан, озак яшәрсең,—дигән иде ул.—Сугыш чыга калса да, сугышка алмаячаклар сине. Аксаклыгың мондый афәткә керүдән коткарыр. Фәйсал улым белән икегез мин биргән әйберне урманның үзегез сайлаган төшенә илтеп күмегез. Урынны онытмас өчен, тупыл чыбыгы алып барып кадарсыз. Тупыл тамырны тиз җәя, озын гомерле була. Тик Фәйсал кайткач кына казып алырсыз хәзинәне. Инде дә килеп үзе кайтмаса, варисларыннан берәрсе кайтыр. Вәләкин хәзинә турында берәүгә дә беркайчан да әйтмә. Әманәтем шундый сиңа. Вәгъдәме?

—Ә... ә... яра күргән аяк мине озак яшәтмәсә?

—Савыкты бит аягың, чатаклыгың гына саулыгыңа зыян итмәс. Антмы?

—Ант!

... Габдияр, өй түбәсеннән кар көрәгәндә егылып төшеп, уң аягын сындырган иде, шул сынык ялгыш ялганды да аягы кәкрәеп калды. Өстәвенә шул ук аягына зуп-зур шеш чыкты да шул тишелеп агып йөдәтте. Тимер юл стансасындагы бульнистә духтыр шешнең авызын, тереләй ярып зурайтып, чокый-чокый чистарткан иде. Шуннан соң тәненә пычак тиюдән куркып яшәде Габдияр, күзләренә шуна күрә операция ясатмады.

Фәйсалның кызы—Нифака исемле хатын—аксак һәм сукыр Габдиярдан әлеге хәзинәнең кайда күмелүен күрсәттермәкче икән. Әманәтне үтәргә

вакыт житкән икән. Риза соң монда Габдияр, бик теләп риза. Югыйсә гомере тиздән баеп куюы ихтимал...

—Шулай да хәзинә нәрсәгә салынган соң?—диде Габдияр, ачыклаудаышануда соңгы соравына житте.

—Горшокта!

—Шулай да сөйләшүеннең рәте-башы юк. Чүлмәктә, диген. Надан!

—Чүлмәктә.

—Шулай да аның эчендә нәрсәләр бар?

—Богатство!

—Тагын? Тыныч булчы, Йомшакжан. Әманәтне үтибез бит.

—Молчи, Хилда!—дип этне ачуланды Нифака.—Син генә не хватал!

—Хилдасы ни була тагын?

—Ошибка... Мин үз собакасы исеме әйткән.

—Чүлмәктә ниләр бар?

—Сказала же. Алтын!

—Монысын беләм. Тагын нәрсә? Шунысын мин тәгаен белмим.

—А-а, совсем оныткан. Записка. Аны от имени бабая әти написал. Латинским шрифтом.

—Нигә авылдан эзләмәден мине?

—Әти рассказыннан бу местоны нашла. Сине вчера монда видела. Зачем авылга? Сине бүген здесь ждала. Ышанды, что придешь.

Тупыл белән каенның орлы ягы арасындагы урталыкта иде хәзинә. Ярты метр чамасы гына күмелгән икән. Карт шул тирәләрдә кәсләрнең купкалавын абайлаган кебек булды. Бу хатын монда актарынган ахрысы, дип уйлады ул, ләкин бу хакта сүз кузгатмады.

Нифака чүлмәкнең авызын каплаган калайны ачты, чүлмәк карындыкка төрелгән алтын кисәкләре белән тулы иде. Димәк, чүлмәкне ачып караучы булмаган, шунысы куандырды хатынны.

—Язуын укы.

—Запискаsuccessfully?—Нифака язуны озаклап укыды, тануы шунын хәтле булуы өстенә, эчтәлекне элгәре үзенең беләсе килә иде.—«Зур такта чәй ише сигез кисәк монда».—Хатын аларны берәмтекләп санады.—Все бар. Рәхмәт. «Әманәт...»—диде дә укуыннан туктады Нифака, язудагы, «Әманәт үтәүчегә бер өлеше тиешле», дигән сүзләрне укып бетермәде.

Нифака Габдиярны урман авызынача озатырга булды.

—Моннан йөрми идек без.

—Моннан прямо.

—Монда текә ярлы корган елга бардыр.

—Вон әнә там ул.

—Шөкер, әманәтне үтәдем. Офтанычта калмады...—Эт кинәт әрнеп өреп жибәрде.—Нишләвең, Йомшакжан? Тыныч...

Габдияр сүзен бетерә алмады, көчле куллар аны, дуамал төртеп, ярдан очырдылар. Ул елга төбендәге наратка элгәре башы белән бәрелде, аннары күкрәге белән сыланды. Куенындагы Йомшакжан шулай ук...

*1999*

# ШИГЪРИЯТ



## Әхмәт Рәшит

### Эзли-эзли ул борынгы эзне...

*Хәтер фрагментлары*[1]

… Архивларда яткан фолиантлар,
Хәтерләрдән җуелмаслык моңнар!—
Сөйләгезче миңа—ул бердәнбер
Дөрес фараз кайчан ничек чыңлар?!

Галим әфәнделәр, минем өчен
Һәр кайсыгыз Әбугалисина;
Моңа кадәр мин белмәгән серне
Яшермичә сөйләгезче миңа?!

Мин беләсем килә бөтенесен—
Яхшысын да, яманын да бергә;
Нинди хәлләр булып үтте икән
Бүген без көн күргән ошбу җирдә?

Мин кош булып урап кайтам Җирне,
Эзли-эзли ул борынгы эзне;
Бик күп язмышларга шаһит юллар
Онытмагандыр бит әле безне?!

Мин мөлдерәп карыйм—чагыла күк
Бабамнарның йөзе һәр чалымда.
Әлмисакның бар мизгеле шулай
Җанланадыр кебек хыялымда.

«Да-да» булып, булып, «та-та»[2] булып та без
Йөртелдек микәнни күпме гомер?

---

[1]Әсәрнең журнал варианты.
[2]Да-да, та-та—Кытайның төньягында яшәгән төрки кабиләләр.

Чин[1] чигендә сөңге чыңлаткан сөн[2]
Бәлки миңа баба тиешледер?!

Көннәр, төннәр үтә—хыялымда
Атлар чаба—хөр җайдаклар чаба;
Безме соң бу? Нигә чабабыз без
Көн Иленнән Төн Иленә таба?

Арттан безне кояш куа килә,
Узып китә аннан көлә-көлә,
Без чабабыз. Алда—билгесезлек,
Байрак кына җилфер-җилфер килә.

Кызыл байрак җилдә җилфер-җилфер,
Кан төсеме анда, таң төсеме?!
Хәвеф-хәтәрләрдән саклый-саклый
Дәртләндереп бара бар кешене.

Күп гасырлар кичәр—байракларда
Шул кызыл төс тагын кабатланыр—
Ул рейхстаг түбәсеннән торып
Зур җиңүнең данын сөйләп яныр.

Гази Заһитов[3]ның дан-шөһрәтен
Әллә кемнәр урламакчы иде,
Корыч бабай фәкать урыс белән
Үз гөрҗиен[4] зурламакчы иде.

Ләкин хаклык бит ул без шикелле—
Төртеп тишә ялган капчыкларын;
Татар халкы Алтын йолдызсыз да
Баһадирын танып алкышлады.

Мин бүгенне ялгап борынгыга,
Тарихлардан эзләп дәлил көчен,
Яшәешнең бөек хикмәтләрен
Ачыкламак булам үзем өчен.

Җилдәй җилеп үтә җитез вакыт—
Дала иңләп хөр җайдаклар чаба;
Безме соң бу? Нигә чабабыз без
Көн Иленнән Төн Иленә таба?!

*

Сау бул, Зур Су—синдә дөнья чиге,
Дулкыннарың ялый ялгыз ярны,
Икенче яр бездән ерактадыр—
Эзләп табасы бар, шиксез, аны.

Нинди көч бар безне туктатырлык—
Киртә булса, гайрәт чәчә-чәчә,
Картларга яшь көчләр алмаш булып
Җитәрбез без—соңгы диңгезгәчә!

---

[1]Чин—Кытай.
[2]Сөн—сөннәр яки һуннар тарихта киң билгеле халык.
[3]Гази Заһитов—рейхстаг түбәсенә иң беренче булып Җиңү байрагы кадаган каһарман.
[4]Гөрҗи—грузин.

Кемнәр диеп атаса да тарих,
Төркиләр без, димәк, гел тереләр;
Кайчагында бер үк төслеләр без,
Кайчагында исә гел төрлеләр.

Туганбыз без әмма бер Анадан—
Нәселебез килә Ашинадан;
Мөмкинлекләр безнең чиксез-чиксез,
Ахыргача әле ачылмаган.

Торгын тормыш безгә иш булырмы,
Тамырларда кайнап торса каннар?!
Узасы юл озын—узар аны
Фәкать дәртле пассионар[1] җаннар.

Күк гөмбәзен ябып өстебезгә
Черем иткән чакта (кем дә арый),
Юл турында гына уйладык без,
Ерак йолдызларга карый-карый.

Чөнки безгә язмышлардан узып
Гыйбрәт өчен кирәк сүз әйтәсе,
Егерменче гасыр азагында
Үзебезне кабат күрсәтәсе.

Мәйданнарга чыгып, «Азатлык!» дип,
Йодрыкларны чөеп һаваларга,
Яулыйсы бар ирек вә хөррият
Безгә дәвам булыр балаларга.

Баш иярме татар җиде ятка,
Кол була ул фәкать бер Аллага;
Чөнки Ашинадан васыять булып
Тамырларда ярсу каннар ага.

Без чабабыз. Янар таулар кала,
Сәлам әйтеп без барасы җиргә,
Гейзерлардан күтәрелгән томан
Кызганмыйча фатихасын бирә.

...Төрки кавем исем биргән күлләр,
Елгалар һәм үзәнлекләр кала,
Ә офыклар һаман ымсындыра,
Безнең күзләр явын ала-ала.

Сау бул, Бай Күл[2], сау бул, Әни Суы[3]—
Без китәбез инде ерак-ерак;
Ни өчендер соңгы диңгезгәчә
Ашкындыра безне шашкын йөрәк.

Ясак түләп Җуҗан[4] ханнарына
Интеккәннәр булды заманында;
Йә үзебез өстен чыга идек,
Йә иселдек читләр табанында.

Чөй язулы—әлифбалы булдык,
Уйгур белән тату торган чакта,

---

[1]Пассионарлык—Л. Н. Гумилев билгеләмәсе буенча, кешеләрдә биосфера белән бәйләнешле тере матдә энергиясенең гадәттәгедән күбрәк булуы.
[2]Бай Күл—Байкал күздә тотыла.
[3]Әни Суы—Енисей елгасы.
[4]Җуҗаны—дала юлбасарлары (IV-V гасырлар).

Чәлпәрәмә килде зур каганат,
Яуларга бик артык йөргән чакта.

Сугышкан да булды, килешкән дә—
Үтте инде баштан төрле хәлләр,
Без илгизәр икәнлеккә дәлил
Далаларда калган таш балбаллар.

Күлтәгиннәр, Тонъюкоклар[1] рухын
Уятырлар бер көн, заман узгач—
Танулары авыр ташлардагы
Тамгаларны җил һәм яңгыр югач.

... Комда яки суда эз калмый дип
Сөйләмәгез юкны—кала эзләр;
Шул эзләрдән узар һәр яшь буын—
Ул үзенең чын тарихын эзләр.

Ә әлегә кадим заманнарда
Юлга чыккан хөр җайдаклар чаба—
Иярләрдә без бу!—Без чабабыз
Көн Иленнән Төн Иленә таба.

*

Артта кала чүлләр—ком барханнар,
Елга-күлләр елап кала артта;
Кулда таң билгесе—кызыл тулар[2],
Җитез атлар ак күбеккә баткан.

Ашыгалар Хазар[3] диңгезенә—
Чаба-чаба сусаганнар суга;
Без эзләгән соңгы диңгезме бу—
Омтылдыкмыни соң фәкать шуңа?

Сәламләде аннан Каф таулары[4]
Йолалары якын диеп җанга,
Болгар дигән иллә зур мәмләкәт
Төзештек без анда Кубрат ханга[5].

Тик җәнҗаллы иде тормышыбыз,
Атламадык никтер туры юлдан,
Үз туксанын туксан дияр өчен
Тартыштылар туган белән туган.

Бүре көтүе күк бер булмады,
Байлык туплау иде бар эшләре,
Һәм дөньяның төрле кыйтгасына
Таралышты Кубрат варислары.

Ә без карап шималь йолдызына,
Башка тарафларга юл алганбыз;
Ак каенлы, чал имәнле якта
Урманнарга кереп югалганбыз.

---

[1]Төрки каханлыкның VII-VIII гасырларда яшәгән тарихи шәхесләре.
[2]Т у —байрак.
[3]Х а з а р   д и ң г е з е —Каспий.
[4]К а ф   т а у л а р ы —Кавказ.
[5]К у б р а т —Азов буе Болгарстанның VII гасырда яшәгән ханы.

Идел белән Урал арасында
Калкып чыккан бөек шәһре Болгар,
Иле Болгар... Илне болгатмаган—
Чөнки ил тотардай ныклы кул бар.

Ә шулай да кем без? Болгарлармы?
Кыпчакларлармы? Бәхәс—җитди һаман;
Хазар дисә ул чор яугирләре,
Сез—мөселман дияр Ибне Фадлан[1].

Бик акыллы булып кайберәүләр.
Безнең каннан бүген геннар эзли,
Болак күперенә шигарь язып
Фәкать болгар димәкчеләр безне.

Дөнья бит ул—икең ике түгел,
Бергә-бергә гомер сөргәннәр дә
Кан кардәшләр безгә, кан кардәшләр
Бүген татар булып йөргәннәргә.

Туганнардай якын күреп мине
Кунак итә якут, алтай, кыргыз...
Балкар Кайсын[2] әкә белән икәү
Чөкердәшеп чәйләп утырабыз.

Без—төркиләр, нәсел-ыру бер үк,
Тылмачсыз да аңлашабыз җиңел,
Кан юлында бер үк амплитуда,
Бер үк уйлар белән тулган күңел.

Заман белән заман игезләр күк—
Кичә белән бүген бер үк җептә;
Булганы да, буласы да бергә
Җитәкләшеп бара мәңгелеккә.

Ничек кенә бизәп язылмасын,
Тарих әкияте арзан тора.
Син, шовинист бәндә, белмәгәнең,
Әнә, галим Гумилевтан сора.

Ә ул әйтер, Русь иленең бездән
Һичбернинди «иго» күрмәгәнен,
Татарларның ушкуйниклар[3] кебек
Башкаларны талап йөрмәгәнен.

Худяковтан сора, Баскаковтан—
Алар белә кемнең кем икәнен[4];
Көн Иленнән Төн Иленә килеп
Татарларның ничек көн иткәнен.

... Шаляпинга һәйкәл ачкан чакта
Янәшәмдә ике урыс иде,
Берсе ишарәләп Президентка
«Татарларның Чыңгызханы»,—диде.

---

[1]Әхмәт ибне Фадлан—Болгар иленә ислам дине алып килгән Багдад илчелегенең рәсми вәкиле юлъязмачысы.

[2]Кайсын Кулиев—атаклы балкар шагыйре.

[3]Идел, Чулман, Ука елгалары буйлап килеп җирле халыкны талап йөргән урыс юлбасарлары.

[4]Худяков, Баскаков - тарихчылар.

Ярар ла, дип, сүзе булмасын, дип,
Кем соң хәзер кемдер көен көйләр?!
Әйе, әйе,
Болгары да, Алтын Урдасы да,
Казан ханлыгы да—безнекеләр!

... Татарстан якты көнгә карап
«Азатлык» дип язды байрагына;
Үткәнен дә алды арсеналга,
Киләчәк тә... якын ара гына.

Ак каенлы, сайрар сандугачлы
Үзебезнең ил бу—җанга якын,
Чишмәләре яшәү җырын җырлый,
Йөрәкләрдә дөрли сүнмәс ялкын.

Илбашына дәлил кирәк булса
Аңлатырга безгә ил хәлләрен,
Кашгарыйның «Легать»еннән[1] ала
Меңәр яшьлек татар мәкальләрен.

*

Каенлыкта бүген Сабан туе,
Яше-карты алды аны көтеп,
Җыелыштык менә, калдырдык та
Кырны тургайларга сәхнә итеп—

Әйдә, алар анда бәйрәм итсен,
Безнең өчен мәйдан монда гөрли,
Белик әле, нинди үзгәрешләр
Булды икән үткән яздан бирле?

Былтыр кемнәр батыр булып калган,
Һәм кайсы ат килгән иң-иң алдан,
Хезмәттәге батырлыгы өчен
Кемнәр-кемнәр нинди бүләк алган?

Котлау ява уңган егетләргә,
Уңган киленнәргә котлау ява,
Күңелләр көр—бүген Сабан туе,
Тылсымлы моң—чыңлап тора һава.

Ерак заманнардан күчкән бәйрәм—
Кыза, кыза милли Олимпия,
Олимп тавы исә күңелләрдә—
Ул үзенә каһарманнар җыя.

Антейга тиң Алыплар бар монда,
Ахиллары исә җитез җилдәй;
Сөлгеләрне бәйлә югарырак—
Сөйләп торсын, бәйрәм диеп илдә.

Тантаналар, әнә, бар тарафта:
Калаларда бәйрәм, салаларда;
Бабайларның асыл йолалары
Мирас булып күчә балаларга...

*1999*

---

[1]Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгате төрек» дигән кулъязма сүзлеге күздә тотыла.

# ЗУР ӨЛЕШЕБЕЗ БАР...

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ 1941–1945 ЕЛЛАРДА ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ТОРМЫШЫ

**9 МАЙДА**—халкыбызның Ватан сугышында җиңүенә 55 ел тула. Аны лаеклы каршылау өчен, РФ Президенты указы нигезендә, зур программа эшләнде. Анда каралган чараларның күбесе республикабызда да үтәчәк. Чөнки бу бөек җиңүгә, башка халыклар белән беррәттән, татар халкы да үзеннән зур өлеш кертте. Рейхстагка җиңү байрагын да татар егет Гази Заһитов кадады.

Әмма 80 нче елларның урталарына кадәр бу турыда әйтергә дә, язарга да ярамады. Рәсми идеология нигезендә чын дөреслекне әйтү, гомумән, тыелган яисә өлешчә генә мөмкин иде. Бу бигрәк тә халыкларның чын тарихына карата шулай булды. Мәсәлән, галимнәрнең фәнни-тикшеренү эшләрендә Алтын Урда, Казан ханлыгы дәүләтләренең кайбер аспектларын, бигрәк тә татар халкының этник тарихын өйрәнү нык чикләнгән иде.

Бу язмада татар халкының сугыш елларындагы иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышын яңача яктырту бурычы куела. Нәкъ менә шул елларда СССРдагы милләтара мөнәсәбәтләргә сталинчыл репрессияләр сәясәте аркасында зур зыян китерелә. Мәсәлән, калмыклар, чичәннәр, Кырым татарлары, ингушлар, балкарлар, греклар һәм башка кайбер халыклар туган-торган җирләреннән күпләп күчерүгә дучар ителә. Татар халкына карата исә ачык рәвештә аны рухи яктан кол итү, милли тарихын һәм мәдәниятен юкка чыгару алып барыла. Халыкны идеологик эшкәртү сугыш алды елларында моңача күрелмәгән югарылыкта була, ә сугыш башлангач, ул тагын да көчәйтелә. Радио, газета-журналлар, кинематография эшчәнлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары буларак, нык күзәтүдә тотыла. Агитация-пропаганда эшен оештыру мәсьәләләре партия һәм совет органнары утырышларының көн тәртибеннән төшми. Патриотизм, дошманны тиз арада җиңү, фашизмга каршы көрәштә халыклар дуслыгы һәм бердәмлеге идеяләре белән язучылар һәм сәнгать эшлеклеләренең барлык әсәрләре сугарылган була.

Сталин үзе хакимлек иткән елларда кешеләрнең рухы һәм акылы белән идарә итәргә өйрәнеп җитә. Аны томаланган халык исә юлбашчыны Алла дәрәҗәсенә күтәрә. Совет кешеләре һөҗүмгә, үлемгә Сталин исеме белән бара. Нәкъ менә аның (аларның яраткан остазының) сугышның беренче елларындагы югалтуларга гаепле булуы турында уйлап карарга да җөрьәт итми халык.

Югары партия органнары карарларын халыкка житкерүчеләр булып башлангыч партоешмалар тора. Сугыш елларында Коммунистлар партиясе сафларына яңа әгъзалар кабул итү буенча эш тагын да көчәйтелә. Аеруча милли кадрларга игътибар ителә. Татар коммунистларының туган телдә, гади һәм аңлаешлы итеп халыкның төп массасына сталинчыл җитәкчелек карарларының «дөреслеген» аңлату-төшендерүенә бигрәк тә әһәмият бирелә.

Тылдагы татар коммунистларының саны сугышның төрле елларында төрлечә була һәм ул фронттагы хәлләргә һәм мобилизацияләү планнарының үтәлеше торышына бәйле рәвештә үзгәрә. Шундый мәгълүматлар билгеле: сугыш елларында татарлар Татарстан партия оешмасында—33, Башкортстанда—18, Ульян өлкәсендә 4 процент тәшкил итә[1].

Партия оешмалары җәмгыятьнең сәяси системасында өстен урын ала; алар эшчәнлегенә бердәм җитәкчелек, кушканны катгый үтәү һәм тәртип таләп итү хас була. Партия аппараты гаять зур көч туплый һәм «партиянең теләсә кайсы карары һичшиксез үтәлергә тиеш» дип эш итә.

Хезмәт ияләре депутатлары Советларының роле (алар Конституция буенча, рәсми рәвештә дәүләт хакимияте органнары дип танылса да) нык кимәтелә. Сугыш чоры шартларында хакимият һәм җитәкчелек итү системасының демократиялеген сүздә генә булса да саклау да артык дип табыла. Советлар, нигездә, башкару вазифаларын үти. Шулай булса да, аларның милли составына шактый әһәмият бирелә. Сугыш елларында җитәкче урыннарга, Советлар рәисләре итеп төп (татар) халкы вәкилләрен күбрәк билгеләү турындагы демагогик чакырулар яңгырый. Сугыш чорында ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе Г. А. Динмөхәммәтов була. 1943 елда республикадагы 1682 авыл советының 898ен татарлар җитәкли[2]. Алай гына да түгел: 1944 елда, Татарстан тарихында беренче тапкыр иң югары вазифага—ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре итеп татар кешесе З. И. Моратов сайлана.

Әмма җитәкчелектә татар милләтеннән кешеләр шактый күп булса да, бу бер нәрсәне дә үзгәртми диярлек. Сугыш елларында советлар партия ярдәмчеләре итеп кенә карала; партия һәм совет хакимияте органнары карарлары арасында аерма булмый диярлек.

Совет җәмгыятенең сәяси системасы үсеше сугыш чорында партия һәм дәүләт структуралары кушылуда, гадәттән тыш, Конституциядә каралмаган орган—оборона комитетлары төзүдә күренә. 1941 елның 30 июнендә үк инде, барлык хакимиятне бергә туплау максатында, Сталин җитәкчелегендәге Дәүләт оборона комитеты, ә зур шәһәрләрдә, өлкәләр үзәкләрендә, өлкә буйсынуындагы шәһәрләрдә шундый ук җирле комитетлар төзелә.

1941 елның октябрь аенда Казан оборона комитеты барлыкка килә; аның рәисе ВКП(б)ның Өлкә комитеты беренче секретаре А. Н. Алемасов була.

Сталин кулының һәр ишарәсенә буйсынучы хакимият һәм җитәкчелек системасы тәгәл һәм тоткарлыксыз эшли; ризасызлык белдерүчеләр эзәрлекләнә, агитатор һәм пропагандистларга һәртөрле ярдәм күрсәтелә.

Дошманны җиңүгә сәяси мобилизацияне тормышка ашыру өчен партия органнары мәдәни-агарту учреждениеләре һәм галимнәр, язучылар, сәнгать әһелләренең барлык иҗади мөмкинлекләреннән файдалана.

Татар галимнәренең эше оборона мәсьәләләрен эшкәртүгә юнәлтелә. Көнчыгышка эвакуацияләнгән СССР Фәннәр академиясе фәнни кадрлары—академиклар, әгъза-мөхбирләр, техник хезмәткәрләр—белән бергә алар сәнагать предприятиеләре коллективларына яңа технологияләр булдыруда, ә колхоз һәм совхозларга авыл хуҗалыгында җитештерүчәнлекне арттыруда ярдәм күрсәтәләр.

Күренекле химик, профессор Г. Х. Камай болай дип искә алган: «Фашистлар Германиясенең кинәт һәм көтмәгәндә һөҗүм итүеннән соң мине Мәскәүгә чакырып алдылар. Иптәш Кафтанов миңа оборона химиясе өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшен җәелдерүне тапшырды[3]». Гыйлем Камайның фәнни эше нәтиҗәләре кетгут заводында технологик процессны тизләтү мөмкинлеген бирә, җитештерелә торган хирургик тегү материалларының ассортименты һәм күләме арта; бу исә хәрби медицина өчен гаять әһәмиятле була.

Илдә тотрыклы хәрби икътисад барлыкка китерү өчен, Татарстанда нефть табу стратегик әһәмияткә ия була. Төбәккә нефть сәнагате тууга татар галимнәре, инженерлары, эшчеләре Б. М. Юсупов, Р. Г. Зиннәтуллин, Ф. Х. Байбуров, Г. Х. Хәмидуллин һәм башка бик күпләр зур өлеш кертә.

Авыл хуҗалыгы культураларының югары уныш бирүче яңа сортларын чыгару буенча әһәмиятле эшләр Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында башкарыла. Сугыш елларында Х. Х. Байчурова «Казанская» уҗым арышын, Ш. В. Вәлиев «Казанский 6/4» сортлы арпа, З. Х. Шәрәф «Казанская 64/95» сортлы люцерна, А. А. Абдулбаниев «Татарстан» мәген барлыкка китерәләр; бу исә илне азык-төлек белән тәэмин итү өчен кирәк була.

Партия һәм советлар җитәкчеләрен аеруча гуманитар фәннәр белән шөгыльләнүче галимнәр эшчәнлеге кызыксындыра һәм бер үк вакытта борчый да.

Нәкъ менә шушы өлкәдә халыкның аның идеологик эшкәртү өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Татар тарихчылары һәм филологлары телдән һәм басма чыгышларында совет кешеләренең рухын күтәрергә, аларда җиңүгә ышаныч тудырырга, рус һәм башка халыкларның данлы тарихи традицияләрен күрсәтергә тиеш була, әмма хакимияттәге «аппаратчылар» һәм галимнәр ул традицияләрне төрлечә аңлый. Нәкъ менә шул сәбәпле сугыш елларында татар тарихчыларын «милли характердагы хаталар»да гаеплиләр. Гуманитар юнәлештә эшләүче бер генә галим дә югары инстанцияләр карашына туры килми торган фикер әйтә алмый.

Әлеге чорда яшьләрне кирәкле юнәлештә идеологик тәрбияләүгә аеруча игътибар ителә. Бу вазифаны мәктәп һәм югары уку йортлары укытучылары башкарырга тиеш була; аларның күбесе бер үк вакытта халык арасында агитация эше дә алып бара.

Катлаулы шартларга карамастан, сугыш чорында татар мәктәпләре саны арта. 1940/41 уку елында Татарстандагы 3510 мәктәпнең 1641е татар мәктәбе булса, 1944/45 уку елында мәктәпләрнең гомуми саны 3718гә, ә татар мәктәпләре 1791гә җитә[4]. Әмма мәктәпләрдә төп игътибар туган телне яки татар халкы тарихын өйрәнүгә түгел, ә совет патриотизмы (күпчелек очракта рус тарихы мисалларында) тәрбияләүгә юнәлтелә. Укучылар рус язучыларының каһарманлык турындагы әсәрләрен, рус халкының хәрби үткәнен өйрәнә. Милли каһарманнар образлары укытучылар игътибарыннан читтә калып килә. Дәрестән тыш вакытта төрле хәрби-оборона һәм физкультура түгәрәкләре эше киң җәелдерелә.

Балаларның укуын ташларга мәҗбүр булуы укытучыларның идеологик эшен кыенлаштыра. Төрле сәбәпләр: авылда һәм промышленностьтагы эшләрдә катнашу, өс һәм аяк киемнәре булмау, авырулар аркасында балалар мәктәпкә йөри алмый.

Педагогик кадрлар белән тәэмин итүдә дә киеренкелек туа. 1941/42 уку елында республикадагы 8444 Y-X класслар укытучыларының тик 1517се—югары, ә 352се тәмамланмаган урта белемгә ия була[5]. 1943/44 уку елында мәктәпләрне тәэмин итү өчен 2536 укытучы җитешми. Шунысы аерым искәртелә: аларның 889ы татар яки татар телен белүчеләр, башлангыч классларда укучыларга гына булса да материалны туган телдә аңлатырга сәләтле булырга тиеш[6].

Югары мәктәптә студентларга марксизм-ленинизм рухында дөрес юнәлеш бирүгә нык игътибар ителә. Сугыш башланганнан соң, барлык югары уку йортларында «Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы» дигән мәҗбүри курс укытыла, сәяси икътисад (политэкономия) фәне кертелә. Мәҗбүри фәннәргә килгәндә, укыту планнарына оборона характерындагы яңа фәннәр кертелә башлый, мәсәлән, университетның химия факультетында—шартлаучы һәм агулы матдәләр; география факультетында—хәрби топография; медицина институтында—хәрби хирургия һ. б.

Сугыш елларында Татарстанда 13 югары уку йорты була; аларда 9355 кеше укый, шуларның 914ең (10%) татарлар тәшкил итә[7]. Татарлар иң аз укый торган югары уку йортлары түбәндәгеләр була: авыл хуҗалыгы институтында—11, ветеринария институтында—29, юридик институтта 37 татар кешесе белем ала[8].

Югары уку йортларына укырга кергән татар яшьләренең саны аз булу ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитетында борчылу тудыра. Республикада югары белем бирү мәсьәләләре тикшерелгән бюро утырышларының берсендә татарларның студентлар арасында аз процент тәшкил итүенең сәбәбе «вуз директорларының татар яшьләрен укырга җәлеп итүгә җавапсыз каравы, бу эшне үз агымына куюы[9]» дип билгеләнә. Партия Өлкә Комитеты татарлар арасында профориентация эшен (һөнәри юнәлеш бирүне) көчәйтүне таләп итә.

Мондый карарлар, милли кадрларны үстерүдән бигрәк, партиянең урындагы органнары абруен күтәрү максатында кабул ителгәндер. Шулай булса да, сугыш елларында, совет чорында беренче тапкыр буларак, 1944 елда КДУның тарих-филология факультеты составында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла.

Сугыш татар халкының мәдәни тормышына авыр йөк булып ята. Бронь системасы иң сәләтле иҗат көчләрен саклап калырга мөмкинлек биргән булыр иде, әмма сталинчыл җитәкчелекнең үз планнары була. Татар зыялыларының нәкъ шундыйлары сугыш кырларына җибәрелә. Сугышның беренче елында гына да Татарстан Язучылар берлегенең (53 кеше) яртысы (25 кеше) сугышка озатыла.

М.Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, Г. Кутуй, А. Алиш, М. Мостафин һәм башка күп шәхесләр сугыш корбаннары була[10].

Татар язучыларының зур төркеме (15кә якын кеше) 1942-1943 елларда фронт газеталары редакцияләрендә даими үлем куркынычы астында эшли. Төньяк-Көнчыгыш фронтта «Ватан өчен» газетасында Х. Госман, Ш. Мөдәррис; Калинин фронтының «Алга, дошман өстенә» газетасында Ш. Маннур, А. Шамов; Беренче Украина фронтының «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясендә Ә. Ерикәй, Р.Ишморат, М. Садри[11] әдәби хезмәткәрләр булып эшли.

Тылда калган язучыларга (К. Нәҗми, Т. Гыйззәт, Ф. Хөсни һ. б.) массалар белән элемтәләрне киңәйтергә, районнарга чыгарга, әдәби-художество кичәләре, укучылар конференцияләре үткәрергә, матбугатта һәм радиодан пропагандистик чыгышлар ясарга кушыла. Моннан тыш әдәби әсәрләр дә иҗат итәргә кирәк була, аларның пропагандистик характерда булуы хуплана.

Татар прозасында сугыш елларында кече формалар: очерк, хикәяләр өстенлек ала. Бигрәк тә К. Нәҗминең «Артиллерист Сөләйман», Г. Бәшировның «Сержант Хәйруллин», И. Газиның «Кышкы төндә», Ш. Камалның «Марат» хикәяләре; Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары», Г. Кутуйның «Рөстәм мажаралары», Х. Госманның «Ялкынлы йөрәк» повестьлары киң таныла.

Республика шагыйрьләре сугыш елларында 25кә якын поэма һәм йөзләгән шигырьләр иҗат итә; алар арасында бигрәк тә Ф. Кәримнең «Идел егете», «Партизан хатыны», Ш. Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап», К. Нәҗминең «Хәят апа» әсәрләрен укучылар үз итә.

Драматургия өлкәсендә татар язучылары күп кенә яңа пьесалар тудыра. Аларның иң популяры—М. Әмирнең сугыш елларында колхозчылар хезмәте турындагы «Миңнекамал» пьесасы була.

Язучылар бу чорда беренче чиратта совет кешеләренең фронтлардагы батырлыгын һәм тылда үз-үзләрен аямыйча хезмәт итүләрен чагылдырган әсәрләр яза. Сугыш чорының башка сюжетларына сталинчыл пропаганда тарафыннан сорау, ихтыяҗ булмый; төп юнәлештән тайпылу язучыларның үзләре өчен дә хәвефле иде. Шуңа күрә сугышның трагик яклары, кешеләрнең газап һәм михнәтләре, хәрби тоткынлыктагы кешеләр язмышлары тасвирланмый кала.

Каһарман-шагыйрь Муса Җәлил хаклы рәвештә сугыш чоры татар әдәбияты символы булып санала; ул үзен һәм татар халкын фашистлар тоткынлыгында иҗат иткән «Моабит дәфтәрләре» шигырьләр циклы белән дөньяга танытты. 1953 елга кадәр М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре «кара исемлектә» иде. Озак еллар буена җентекле тикшерүләрдән соң гына аларның исемнәре акланды. СССР Югары Советы Президиумының 1956 ел, 2 февраль Указы белән М. Җәлилгә (үзе үлгәннән соң) «Советлар Союзы герое» исеме, ә бер ел үткәч, 1957 елда, Ленин премиясе бирелде.

Сәнгать тә бу чорда идеологик пропаганда чарасына әверелә. Рәссамнарның роле күргәзмә агитацияне киң җәелдерүдә гаять зур була. Аларга сәяси плакатлар эшләү һәм киң халык массаларына идея йогынтысы ясауның нәтиҗәле чарасы буларак «Сатира тәрәзәләре»н («Окна сатиры») чыгару тапшырыла. Татар рәссамнары бу эштә актив катнаша. Күп кенә учреждение һәм агитпунктларда Б. Альменовның «Фашизмның канлы сатраплары», «Фронтка—икмәк» һ. б. плакатлары эленеп тора. Рәссам Р. Сәйфуллин күбрәк сатира жанрында эшли, фашизм башлыклары Гитлер, Геринг, Геббельстан ачы көлүче плакатлар иҗат итә. Моннан тыш, «Татхудожник» берләшмәсе әгъзалары хәрби объектларны маскировкалауга, мобилизация пунктларын, госпитальләрне, сынлы сәнгать күргәзмәләрен җиһазлауга да җәлеп ителә.

Татар рәссамнарының осталыгы яңа әсәрләр иҗат итү аша да үсә. Шул чор һәм югары оешмалар таләп иткәнчә, алар башлыча хәрби темаларга иҗат итә. Д. Булат «Советлар Союзы герое Батыршин подразделениесы штык атакасында», Г. Рахманкулова «Фронтовиклар анасы Саражиева портреты» дигән картиналар яза. Скульптура жанрында күренекле татар сәнгатькәре С. Ахун эшли; ул «Ләгънәт!» һәм «Җиңү» дигән скульптура композицияләре тудыра. Бакый Урманче ул елларда Алма-Ата шәһәрендә яши, «Җинеп кайтыгыз», «Госпитальдә», «Снайпер Афанасьев портеты» дигән картиналар яза.

Татар рәссамнарының үз йөзләрен югалтмаска һәм сугыш алды елларында

барлыкка килгән традицияләрне саклап калырга омтылуына карамастан, сугыш чорында татар сынлы сәнгате шактый зыян күрә. Үз эшенең осталары булып житешкән, шулай ук яңа иҗат планнары белән рухланган яшь рәссамнар сугыш кырыннан әйләнеп кайтмый. Фронтларда Н. Вәлиуллин, Г. Мусин, Р. Әбжәлиев, Л. Зыятдинов, Ф. Сәетов һәм башка күп рәссамнар үлеп кала. Исән калу бәхетенә ирешкән рәссамнар Х. Якупов, М. Госманов, Л. Фәттахов иҗатында сугыш темасы күп елларга төп тема булып әверелә; байтак вакыт үткәч кенә алар башка сюжетларга да мөрәҗәгать итә башлыйлар. Сәнгатьнең барлык төрләреннән татар сынлы сәнгате генә озак вакыт аякка басып, үсеп китә алмый, бу күп яктан кадрлар мәсьәләсе белән бәйле була.

Татар музыка сәнгате сугыш елларында шулай ук иҗтимагый заказ үтәргә, кешеләрне сугышчан һәм хезмәт батырлыкларына рухландырырга тиеш була. Татар композиторларының бер өлеше башта ук мобилизацияләнә. Х. Абделмәнов, Х. Вәлиуллин, М. Латыйпов, И. Шәмсетдинов, Ф. Яруллин сугышларда катнашалар. Тылда калган композиторлар да оборона тематикасына иҗат итә.

Сәнгатьнең барлык башка төрләрендәге кебек үк, композиторлар кече форма һәм жыр, маршларга күбрәк игътибар итәләр. М. Мозаффаров музыкасына «Ватан өчен!», «Сугышка, иптәшләр», Ж. Фәйзинең «Канга кан!» жырлары еш башкарыла. Сугыш елларында С. Сәйдәшевнең симфоник оркестр өчен язылган «Ватан» һәм тынлы оркестр өчен Суворов маршлары; шулай ук Ж. Фәйзинең поход маршы, М. Мозаффаровның симфоник оркестр өчен маршы популяр була.

Шуның белән беррәттән, бу чор татар композиторлары иҗатына жанрлар төрлелеге, эре музыкаль формаларга мөрәҗәгать итү дә хас. Сугыш елларында Н. Жиһановның «Илдар», «Түләк»; М. Мозаффаровның «Зөлхәбирә» опералары, Н. Жиһановның «Фатыйх», «Зөһрә» балетлары языла.

Шушы чор татар музыкасы яңа жанр—музыкаль комедия барлыкка килү белән дә үзенчәлекле. Композитор Ж. Фәйзи 1942 елда Т. Гыйззәт либреттосына «Башмагым» һәм 1944 елда Ә. Фәйзи либреттосына «Акчарлаклар» музыкаль комедияләрен иҗат итә. Боларның беренчесе опера театры репертуарында әле хәзер дә саклана.

Әмма сугыш елларындагы уңышлар кайтарып булмаслык югалтулар белән чиратлаша. Татар музыкасы һәм мәдәнияте өчен шундый югалтуларның берсе фронтта яшь һәм талантлы композитор, беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы Фәрит Яруллинның үлүе була. Корбаннарга комсыз сугыш халыкның иң яхшы улларын юк итә. Ф. Яруллин 1943 елның көзендә сугышчан задание үтәгәндә һәлак була. Беренче милли балет, бу жанрдагы иң яхшы әсәр буларак, татар музыкасы тарихына кереп кала.

Халыкны идеологик яктан эшкәртү өчен иң яхшы мөмкинлекләрне барлык заманнарда, әлбәттә, мәдәни-агарту һәм тамаша учреждениеләре бирә. Сугыш елларында да музейлар, китапханәләр, мәдәният йортлары шундый эштәлекле күргәзмәләр, тематик кичәләр үткәрә; радиодан тапшырулар оештырыла, кинофильмнар күрсәтелә. Театр коллективлары зур көч куеп эшли. Татар театры спектакльләрендә тамашачылар, персонажлар кичерешләрен үз итеп, үзләренең тормыш авырлыкларын һәм борчуларын онытырга телиләр. Мондый шартларда партия органнары театрлар репертуарларын тикшереп, аларга тиешле юнәлеш биреп тора.

Татар театрының репертуары сугышның беренче елларында партия аппаратчылары күрергә теләгәннән шактый ерак тора. Бөек Ватан сугышы турында язылган актуаль пьесалар әле булмый, чөнки тормыштагы хәлләрне иҗат әһелләренең аңлап житүе өчен вакыт кирәк. Театр сугышка кадәрге, патриотик һәм оборона темасына язылган спектакльләрне кире кайтара башлый. 1943 елның гыйнвар аенда гына Татар академия театрында Ватан сугышы темасына Н. Исәнбәт иҗат иткән, совет кешеләренең сугыш фронтларындагы батырлыкларын гәүдәләндергән «Мәрьям» спектакле сәхнәгә куела (режиссеры Ш. Шамильский). Бер ел үткәч, 1944 елның апрелендә, татар театры М. Әмирнең «Миңнекамал» пьесасын куя (режиссеры Х. Уразиков).

Опера һәм балет театрында патриотик тема өстенлек итә. Сәхнәдә сугыш темасын чагылдыруга беренче омтылыш 1942 елның 7 ноябрендә татар композиторы

Н. Җиһановның «Илдар» операсын (М. Җәлил либреттосы) кую була. Опера сюжетының төп мотивы—фронттагы дуслык темасы. Моннан тыш, сугыш чорында Н. Җиһановның М. Җәлил либреттосына язылган легендар-патриотик «Алтынчәч» һәм Н. Исәнбәт либреттосына иҗат ителгән «Түләк» оперлары куела, алар халыкның чит ил яулап алучыларына каршы көрәшен чагылдыралар.

1945 елның 12 мартында Ф. Яруллин тарафыннан Ә. Фәйзи либреттосына сугыш алды елларында ук язылган беренче татар балеты «Шүрәле»нең куелуы әлеге театр тарихында иң күренекле вакыйгаларның берсе буларак урын ала.

Башка республика һәм төбәкләрдә дә татар театрлары актив эшли. Мәсәлән, Ырынбур өлкәсендә сугыш еллары дәвамында өлкә татар колхоз-совхоз театры халыкка хезмәт күрсәтә. 1943 елда ВКП(б) Өлкә комитетының сәнгать бүлеге башлыгы болай дип билгели: «Өлкәдәге бердәнбер милли татар театры өлкәнең татар халкына хезмәт күрсәтте. Театрның иҗади һәм татар халкы арасында үткәрә торган массакүләм сәяси эше аның казанышы булып исәпләнергә тиеш[12]».

Тамаша-күңел ачу учреждениеләренең сугыш елларындагы иң әһәмиятле эш формасы—аларның концерт эшчәнлеге. Концертлар мобилизация пунктларында, госпитальләрдә, колхозларда оештырыла. 1941 елдан башлап, сәнгать әһелләре фронт бригадалары составында алгы сызыкка чыга. Татар артистларыннан Х. Әбҗәлилов, Г. Болгарская, М. Булатова, Ф. Ильская, Камал III, Г. Кайбицкая, М. Рахманкулова, Ф. Туишев һәм башка бик күпләр тамашачылар мәхәббәтен казана. Туган як моңнары, татарча җырлар сугышчыларның күңелләренә шатлык һәм сагыш сала, еракта калган туган йорт турында уйлар кузгатып җылыта, исән-сау кире әйләнеп кайтуга өмет уята.

Сугыш елларында татар театрлары өчен яңа милли кадрлар әзерләү эше дәвам иттерелә. 1944 елда Казан театр техникумы үзенең эшен яңадан башлап җибәрә; А. В. Луначарский исемендәге Мәскәү театр сәнгате институты каршында—татар студиясе, П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршында—татар театры өчен вокалчылар, татар опера һәм балет театры каршында—хореография студияләре ачыла.

Әйтеп үтелгәнчә, бу чорда барлык мәдәни учреждениеләр идеология бурычларын үти. Халыкның аңын массакүләм эшкәртү максатына тиз генә ирешелми. Сугышның башында дошман белән аяусыз бәрелешләрдән югалып калган сталинчыл җитәкчелек баштарак бераз идеологик ташламаларга да бара. Хакимияткә совет кешеләренең ил өчен авыр чорда дини традицияләргә таба борылулары, һәр халыкның хәзинәсендә саклана торган милли каһарманнар образларын торгызулары белән килешергә туры килә.

20 нче еллардан соң беренче мәртәбә дини сәясәттә җылылык тойган татар халкы, рухланып, аны тормышка ашыра башлый. Республика милли архивында саклана торган документларда татар авыллары кешеләренең җитәкче органнардан мәчет биналары ачуны рөхсәт итүләрен соравы күренә. Эш шунда: атеистик кампания киң колач алган чорда, дини учреждениеләр ябылып, аларның биналары мәдәни ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен бирелгән була. Шундый сорау белән ТАССР Югары Советы Президиумы Г. А. Динмөхәммәтовка Аксубай районы Иске Ибрай авылы, Яңа Чишмә районы Кулмаксы авылы, Әлки районы Чаллы авылы картлары мөрәҗәгать итә[13]. Халыкка мәчеткә йөрергә, гыйбадәт кылырга, дини ихтыяҗларын үтәргә рөхсәт бирелә.

Татар зыялылары, үз әсәрләренең сюжеты сыйфатында, үз халкының үткәне турындагы материаллардан файдалана башлый. Тарихчы һәм әдәбиятчылар күптән онытылган тарихи катламнарга рухланып мөрәҗәгать итәләр, шул исәптән Алтын Урда дәүләте тарихында һәм Идегәй образында патриотизм темасының көчле яңгырашын табарга омтылалар.

Әмма ирекле уйлау һәм сөйләү мөмкинлеге озакка бирелмәгән икән. Сугышның барышы Советлар Союзы файдасына үзгәрүгә үк, хакимият элеккечә үк ирекне кыса башлый.

Сталинчыл цензура кысаларына сыймаган «ирекле иҗат»ка омтылу татар мәдәниятенә икенче яктан зыян китерә, чөнки ул ВКП(б) ның 1944 елгы «Татарстан партия оешмасында массакүләм-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары» дигән, яманаты чыккан карарга сәбәпче була. Анда җирле партия

органнары милли факторга артык игътибар юнәлтүдә гаепләнә. Карарда күрсәтелгәнчә, «Татарстан Өлкә Комитеты тарих өлкәсендә идеологик эшне Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыру белән чикләнә, язучылар һәм сәнгать әһелләре эшчәнлеге белән житәкчелеге канәгатьләндерми, зыялылар арасында идея-сәяси тәрбияләүне оештырмый» һ. б.

Карарда «Татарстан тарихын фәнни эшкәртүне оештырырга, кайбер тарихчы һәм әдәбиятчыларның Татарстан тарихын яктыртуда милли характердагы житди кимчелек һәм ялгышларын (Алтын Урданы артык мактау, Идегәй турындагы ханлык-феодаль эпосны популярлаштыру) төзәтергә; рус, татар һәм СССРның башка халыкларының чит ил басып алучыларына каршы бердәм көрәшен тикшерү һәм яктыртуга аеруча игътибар итәргә...[14]» тәкъдим итела.

Әлеге документ татар халкына карата булган милли сәясәтне күп елларга билгеләде. Шушы вакыттан башлап халык тарихы югары хакимият раслаган идеологик схема буенча өйрәнелә, вакыйгаларны дөрес яктырту мөмкин булмый. Тарихчылар һәм язучыларның һәр адымы «зурайту пыяласы» аша тикшерелә. Татар халкы тарихы һәм мәдәниятенең тулы катламнары тыелуга дучар була. Югары уку йортлары, урта мәктәпләр программаларыннан Алтын Урда һәм «Идегәй» дастаны турындагы материаллар ашыгыч рәвештә алына. Татар зыялыларының рәсми идеологиядән аз гына читкә тайпылулары да милләтчелек дип бәяләнә һәм җәзага тартыла.

**Айсылу КӘБИРОВА,**
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре.*

ИСКӘРМӘЛӘР:

[1] Очерки истории партийной организации Татарии.—Казан, 1973; Башкирская областная организация КПСС в цифрах (1917-1987): Стат. жыентык.—Уфа, 1987.—172-173 б; Ульяновская областная организация КПСС в цифрах.—Саратов, 1985.—79 б.
[2] ТР ТПД ҮДА. 15 нче ф., 5 нче тупланма, 1367 нче эш, 11 б.
[3] Комсомолец Татарии.—1970.—20 март.
[4] 25 лет Татарской АССР. 1920—1945.—Казан, 1945.—82 б.
[5] ТР ТПД ҮДА. 4034 нче ф., 25 нче тупланма, 303 нче эш, 15-16б.
[6] ТР ТПД ҮДА. 15 нче ф., 5 нче тупланма, 698 нче эш, 56 б.
[7] Шунда ук. 717 нче эш, 72 б.
[8] Шунда ук. 69-73 б.
[9] Шунда ук. 73 б.
[10] Гыйльманов З. И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне.—Казан, 1977.—222 б.
[11] Айнутдинов А. К. Летопись подвига: Исторический очерк по страницам фронтавых газет.—Казан, 1974.—8 б.
[12] Татары в Оренбургском крае: Материалы научно-практической конференции.—Оренбург, 1997.—65 б.
[13] РТ Милли архивы. Р—3610 нчы ф., 5 нче тупланма, 5 нче эш; 1, 7, 12, нче б.
[14] Коммунистическая партия в период Великой Отечественной войны (Июнь 1941-1945 гг.: Документы и материалы.—М, 1961.—226 б.

# ШИГЪРИЯТ

## ЯШЬЛЕККӘ ТУГРЫ ШАГЫЙРӘ



*Резеда ханым Вәлиеваны мин инде күп еллар беләм, әмма ул һич тә үзгәрми төсле: һаман шул ук яшь, көләч йөз, елмаюлы, ягымлы караш, әлмисактан бирле килгән, үзенә бик табигый килешеп торган ихлас назлылык... Кыскасы, урысча да сүз кулланып әйтсәк, женственность... Якты, нурлы аурасы бар дип әйтәләр андыйлар турында—бүгенге астраль фән телендә; үзебезчә генә әйткәндә, пәриләребез яраша , мәҗлесе хуш, рәхәт, дип тә өстиләр. Мин моны Резеда ханым белән бергә китап нәшриятында бер бүлмәдә утырып эшләгән яшьлек елларыма таянып та әйтәм. Ә Резеда Тафкәлүн кызы Вәлиева (Хәлилова) 1930 елның ямьле маенда күп шагыйрьләребез туып-үскән мәрхәмәтле Башкортостанның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында дөньяга килгән икән. Укытучылар гаиләсендә. Урта мәктәпне ул атаклы Салават исемен йөрткән районда, Каратау авылында тәмамлый. Аннан—уртак мәркәзебез Казан, университет, татар теле һәм әдәбияты бүлегендә уку (1947—1952 еллар. Ул Г. Ахунов, Ф. Хатипов, Н. Юзеев һ. б.—булачак зур әдипләр, галимнәребез, милләт хадимнәре белән сабакташ була. Матур хәл: һәр чыгарылыш-группа саен күпме асыл уллар, кызлар тәрбияләнгән бу факультетта!), аннан—30 елдан артык Татарстан китап нәшриятында, яшьләр-балалар редакциясендә эшләү. Әйе, редакторлык хезмәте. Тау-тау кульязмалар уку, тәрҗемә өлкәсендә тәҗрибәләр. Н. Верзилинның «Робинзон эзләреннән» исемле мавыктыргыч китабы, А. Барто, С. Михалковларның шигырь җыентыклары... Ямьле Йөрүзән, Әй буйларыннан илһам алып яза башлаган Резеда илленче елларда көндәлек матбугатта күренә башлый. Ә 1960 елдан—бер-бер артлы шигырь, поэма, балалар өчен әкият китаплары басылып чыга: «Минем дусларым», «Нәниләргә бүләк», «Канатлы җайдак», күләмлерәк «Зәңгәр иртә», «Шиңмәс чәчәкләр», «Зәңгәр алан әкияте» һ. б. 1983 елда ул СССР Язучылар союзына алынды...*

*Ә шулай да, минем карашка, Резеда соңгы ун елда активрак, нәтиҗәлерәк эшләде, шуңа да киңрәк танылды бугай. Бик күп матур җырлар яңгырый башлады аның сүзләренә. Көйләрен—Казанда да, Уфада да язалар. Очрашуларда да еш була ул—авылларга, мәктәпләргә бик теләп йөри, әсәрләнеп, бөтен җаны белән балкып, шигырьләрен, әкиятләрен укый. Белеп әйтәм: укучылар бик ярата үзен, бик җылы каршылыйлар. Әллә шундамы икән аның яшьлеге, дип тә куям. Укучыларың, яратучың булу—зур бәхет түгелмени? Ә бу юбилеен Резеда ханым «Саумы, Сөю» исемле матур сайланмасы һәм әле яңа гына дөнья күргән «Нәниләр китабы»—балалар өчен шигырь-әкиятләр, сценарийлар, җырлар тупланмасы белән каршылый. Онытып торам: узган ел аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем дә бирелде.*

*Бу шатлыкларга без дә ихлас кушылабыз, әлбәттә! Һәм яшьлекнең, матур, мөлаем, якты наз иясе булуның серен белгән шагыйрәне бүген:—Әйдә, тагын озак еллар шулай яшь, дәртле булып кал, иҗат ит, шатланып һәм безне дә шатландырып яшә. Бергә булыйк!—дип котлыйсым килә минем. Моңа сез дә кушылырсыз, мөгаен, дусларым!*

**Рәдиф ГАТАШ**

# Резеда Вәлиева

## СҮНМӘ ӘЛЕ, ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫМ

### Көмеш күлле туган ягым

Күл буйлары тугай-тугай,
Тугай саен бер тургай...
Шул тургайлар сайравыннан
Хыялый булам бугай.

Минем туган ягымның да
Күлләре көмеш иде.
Туган якта үткән гомерем
Гүя матур төш иде...

Көмеш күл суларын иңләп
Аккошлар йөзәр инде.
Көмеш күлле туган ягым
Үзәгем өзәр инде.

Шул күлләргә төшәр идем,
Сандугач булып кына.
Сайрар идем иртә-кичен
Талларга кунып кына.

Таң җилләре исәр иде
Кунган талымны иеп.
Чәчләремнән сөяр иде,
Сандугачкаем, диеп.

Көмеш балыклар уйныйдыр
Көмеш күл суларында.
Көмеш күлле илем калды
Урал-тау буйларында.

Илем килсә күз алдыма,
Көмеш нурларга тулып,
Моң саркыла күңелемнән
Сагышлы җырлар булып...

### Уллар үстердем мин...

Уллар үстердем мин сөеп-сөеп кенә,
«Балакайлар», «бәбекәйләр»,—диеп кенә.
Яулык бәйләп, алъяпкычлар киеп кенә,
Алларында йөреп биеп-биеп кенә.

Үсте алар «әни» сүзен иртә әйтеп,
Тел белмәгән малайларга тел өйрәтеп.
Җырлый белеп, бии белеп, көйли белеп,
Туган телдә матур итеп сөйли белеп.

Үсеп җиткәч, бер көн килеп, нәрсә күрәм:
Өйләнгәннәр туган телгә арка белән.
Үз телләре читтә калган, онытылган,
Икесе дә татар атлы урыс булган.

Урыс булган! Кайда минем биргәннәрем,
Үз телемдә елаганым-көлгәннәрем?
Туган телнең иң-иң гүзәл сәйләннәрен
Тезә-тезә биләүләргә төргәннәрем?..

Күңелемнән шулай уйлыйм, авыр сулыйм,
Яшьсез генә үксеп кайчак эчтән елыйм.
Һәм юатып куям тагын үз-үземне:
«Биргәннәрең кайтыр бер, дим, бул түземле.
Бу заманда балаң белән ниләр булмас,
Ана сөте белән кергән—онытылмас.
Йөрәкләрдән биргән калыр йөрәкләрдә,
Үз җимешен бирер ул, дим, кирәк мәлдә».

Дөрес килде минем фараз иткәннәрем,
Өзгәләнеп ялварганым-көткәннәрем:
Үз өемдә үз телем, үз көй-моңнарым,
Җаннарыма ява ләйсән яңгырлары...

Җаннарыма ява ләйсән яңгырлары,
Иң-иң катгый бу киңәшем шуннан бары:
Килерең дә язмыйм дисәң туган телдән,
Сабыеңа бир син аны туган көннән.

Тоеп үссен балаң туган телнең тәмен,
Аның аша белсен дөньяларның гамен.
Үссен аның гүзәллеген, моңын тоеп,
Туган телен бар телләрдән өстен куеп.

Туган җир һәм туган тел һәм туган ана—
Бары шунда гына газиз булыр аңа!..

## Юллар дәшә мине

Гел юлларга дәшә мине
Тынгылар белмәс җаным.
Очар кошлардай ашкынып,
Юлларга чыгам тагын.

Зәңгәр күкләр көтә мине,
Дәрья-диңгезләр көтә.
Очына йөрәк, ярсына,
Их,
Юлларга ниләр җитә!

Юлга чыгам, юлга чыгам,
Талпынып, очам гына.
Хыял-кошым дәшә тагын
Зур юллар кочагына.

Зур юлларда тормыш кайный,
Кайгы-шатлык янәшә.
Язмышым гел юллардандыр—
Җаным юлларга дәшә.

Юлларым хәвеф-хәтәрне
Уратып үтәр сыман.
Авыр юллар азагында
Бәхетем көтә сыман.

Үрләр үтеп, сулар кичеп,
Авыр юллардан киләм:
Ак язмышым, хак язмышым
Язам үз кулым белән...

## Сүнмә, өмет йолдызым...

*Күңелнең бер мизгеле*

И күңелем, кайчан гына
Бәхтеңнән шаша идең,
Илһамың канатларында
Күкләргә аша идең.

И, ул җырлар җырлый-җырлый
Үткәргән көн-кичләрем.
И, ул шашкын хыялларым,
И, ул татлы хисләрем!

Кайда сез? Кай кыяларда
Чәлпәрәмә килдегез?
Кайсы ачы давылларда
Калтыранып үлдегез?

Без көйләгән моң-җырларның
Кайтавазлары кайда?
Кайда алар хаклык, гаделлек,
Бармы алар дөньяда?

Кая бакма, ачы халәт,
Үчләнеш, каргыш, талаш.
Күбәләктәй бу җаннарга
Бармы җылы бер караш?!

И, сызлый, сызлый күңелем,
Тилмереп җылы эзли.
Калтыранып үлә җаным
Бу мәхшәрләргә түзми...

Бармы бу җирдә мәрхәмәт,
Бармы изге бер йөрәк?
Кай яклардан эзлим аны,
И, Тәңрем, тизрәк өйрәт.

Җылыныр иде җаннарым,
Бу халәт үтәр иде,
Өмет утын тергезергә
Бер караш җитәр иде.

Юк бит, юк! Сүнә өметләр,
И, бичара күңелем.
Гаделлек, дуслык, туганлык—
Бар да сатыла бүген.

И, сызлый, сызлый күңелем,
Тилмереп җылы эзли.
Калтыранып үлә җаным,
Бу мәхшәрләргә түзми...

Ә күктән, зур вәгъдә белән,
Елмаеп Кояш көлә...
Сүнмә әле, өмет йолдызым,
Җиһанда язлар килә!..

## Моңлы җаным минем—халкымнан

—Нигә моңлы җырларыгыз? дисез,—
Бәхетсезме әллә Сез бүген?
Халкым моңлы минем, ахыры, шуңа
Моң ярата бигрәк күңелем...

Әнкәемнең бишек җыры белән
Моң саркыган сабый аңыма.
Шуңададыр күңелем моңлы булган,
Моңнар якын бигрәк җаныма.

Кечкенәдән үзенә әсир иткән
Халкым моңнарының аһәңе
Сүрелмәде гомерем буйларына,
Күңелемнән китми яшәде.

Моңлы Тукай, «Рамай», «Зиләйлүк»ләр
Сабый чактан җаным тетрәткән,
Шулар булды, ахры, җырларымны
Моңнар агымына юнәлткән.

Моңнар булып агыла күңелемнән
Үз халкымның кайгы-сагышы.
Күз яшьләре, шатлык-кайгылары,
Гасырлардан килгән язмышы...

Бер куана күңелем, бер моңая,
Хисләр дулкынына бирелеп.
Тормыш ничек, җырларым да шулай,
Кайгы-шатлык бара үрелеп.

Картайсам да, арып-талчыксам да,
Мин җырлармын һаман, һич тынмам.
Эзләмәгез гайре сәбәпләрен,
Моңлы җаным минем—халкымнан.

## КАЛӘМДӘШЕБЕЗ



*Рәниф Шәрипов исеме журналыбыз укучыларына яхшы таныштыр дип беләбез: нәкъ менә «Казан утлары»нда басылып чыккан шигырьләре белән шигърият сөючеләргә мәгълүм булды ул. Көндәлек матбугатта поэмалары да басылып, әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйть тарафыннан җылы каршыланды («Фатыйма» һ. б.). Хәзер Рәниф Шәрипов—«Тәрәзәдәге утлар», «Ян, учагым» (балалар өчен), «Күк һәм күңел йолдызлары», «Йорт иясе» исемле шигырь китаплары авторы. «Уеннан—уймак» дип аталган драма әсәре дә бар. Хикәяләр яза, тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Ул—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, әдип Шәйхи Маннур исемен йөрткән премия лауреаты. Май аенда Рәнифкә 50 яшь тула. Кукмара районының Аман-Оштарма авылында туып үскән, Арча районының Субаш-Аты авылында балалар йортында тәрбияләнгән, Казан химия-технология институтында укыганда армиягә алынган Рәниф флотта хезмәт иткәндә, авырып, I группа инвалид булып кайта. Әмма күңелен төшерми, тормышта үз урынын табу өчен, Фәнис Яруллин, Гакыйл Сәгыйровлар кебек, рухи батырлык таләп иткән юлны сайлый—бөтен барлыгын иҗатка, шигырьгә багышлый. Ул хәзер Казанда, табибә Люция апасы гаиләсе тәрбиясендә яши.*

Җиргә егарлык кайгыны
Күтәрерлек көч тапканмын...—

*Әнә шулай язган, иҗат дәрте, туган халкына хезмәт итү уе белән янып яшәүче көчле рухлы каләмдәшебезне юбилее белән котлап, укучыларыбыз хозурына аның яңа шигырьләр бәйләмен тәкъдим итәбез.*

---

**Рәниф Шәрипов**

### Казан утлары

**Аяз төндә җәяү соңга калсаң,
Алдыңда юл булса нибары,
Күк читендә, таң нурлары кебек,
Балкып торыр Казан утлары.**

**Таш коймалар, таш урамнар анда,
Хәтер белән Вакыт сугышы.
Җилләр булып урамнарда йөри
Гасырларның ерак сулышы.**

Түбә саен, яу билгесе кебек,
Чит патшаның алтын чукмары.
Янәшәдә ятим бер манара—
Күкне тишеп калган ук бары.

Манаралар ауган канга батып,
Җылы мәетләргә абынып.
Нигезенә кабер ташы салган—
Яши икән кемгә табынып?

Төнгә калдык, соңга калдык инде,
Бер генә юл алда, нибары
Күк читендә, соңгы өмет кебек,
Балкый әле Казан утлары.

Ә тарихны төзәткәләп булмый,
Күбәләктәй—утка ашкынып.
Мәңгелеккә бездә бу Хакыйкать,
Нигезләрдә калган таш кебек...

## Ташып чыккан моң

Җырлый-җырлый әни оек бәйли
Керосинлы лампа янында.
Тышта буран кайчак тынып кала,
Җыр туктагач, куба тагын да.

«Чишмәләр дә акмый тыңлады»,—дип,
Күтәрдеме мине шигъри моң?
—Нинди көй бу, әни?
—«Рамай», улым,
Ник елыйсың? Йокла, инде соң...

Йомгак белән башны башка куеп,
Йоклап киттем, бүтән дәшмәдем.
Кипте тиздән—тарихлардан килеп
Ташып чыккан саф күз яшьләрем.

Җилкендереп һәм тетрәтеп җанны,
Таян, диеп, шушы терәккә,
Моңнар фәрештәсе бер каурыен
Кадап киткән нәни йөрәккә...

*

Ачма, иптәш, күңел ишегемне,
Ташып чыгар хисләр һәм моңнар.
Мин курыкмыйм үзем,
ләкин Җирдә
Дуслар гына белгән серләр бар.

Узма, дустым, күңел түрләремә,
Иркә-назлар анда
ояр корганнар.
Мин ышанам сиңа,
Тик сөйгәнем белән
Икәү генә белгән серләр бар.

Төшмә, җаным, күңел базларыма,
Язгы бозлар анда, тынган бураннар.
Мин яратам сине,
Ләкин миндә
Үзем генә белгән
серләр бар...

*

—Сүнәм дә тагын кабынам,
Туйсам да кайчак—сагынам,
Күрсәм дә, бик еш абынам,
Мин—мәхәббәт.
Ә син кем?
Иреннәрең синең ник тозлы?

—Кабынып, сүнә алмаган,
Сагынып туя алмаган,
Абынып, тора алмаган,
Мин—ялгызлык...

## Өмет

Ишкәк сынгач, канлы куллар белән
Ишәсе дә икән, ишәсе.
Ватты кяфер бәреп көймәләрне,
Югалды нур—кадер кичәсе.

Азгын, бозык дөнья бәндәләре—
Бата-калка әле йөзәбез.
«Кыйбла—яр!» дип талпынабыз да бер,
Өметләрне тагын өзәбез.

Без өметсез түгел әле, Раббым,
Ярлыка Син, безне, якла Син.
Әнә, кемдер, көймә ватыгы, дип,
Суза безгә кабер тактасын...

*

Мәңгелек сер, гомерлек «чир»
Сыкрый күңел түрендә:
Сискәнеп, үксеп, иреннәр
Иреннәргә үрелә.

*

Каһәрләнеп, рәнҗетелеп, тик торганда,
Качар юлсыз тар почмакта кыйналганда,
Карусыз ат котырынып бер тибенер,
Юаш эт тә, ахыр чиктә, тешли белер.

*

Ахырын һәм башын белми араларның,
Вакытын һәм яшен белми дөньяларның,
Әкрен генә галәм буйлап агып барыш,
Ә күңелдә Галәм хәтле чиксез сагыш...

*

Төшкә давыл керде, җилтерәтте мине
Аяусыз һәм явыз көч булып.
Бик еракта, чын давылда кемдер
Сыендымы миңа төш булып?

*

Яр буенда тамырлары ярым ачык,
Яфраклары өстә сары уттай яна—
Ялангач һәм бәйләп куйган адәм кебек,
Агач үзен каплый алмый азаплана.

*

Бүләгеңне алмыйм. Җан иясе—
Хөр хәрәкәт өчен туган ич!
Читлектә кош, чылбырда эт тоту
Минем кулдан килми торган эш.

*

Шигъри күңел шундый инде,
Хыялдан хыял туа:
Кемдер яулык болгый дисәм,
Ул тик тәрәзә юа.

*

Аптырама сүз ишеткән саен,
Ниятең, шәт, изге юлдадыр.
Нәрсә әйтелсә дә сүз—ни генә?
Кем әйтә аны—хикмәт шундадыр

*Җинүнең 55 еллыгына*

# БАТЫРЛАРЫБЫЗНЫ БАРЛАР ЧАК

...Инде менә ничәнче тәүлек йокысызлыктан җәфа чигәм. Бүген дә шулай. Аптырагач, торып, кунакханәдә үзем тукталган бүлмәнең тәрәзә капкачларын киереп ачып җибәрәм. Сызылып май таңы атып килгән чак. Йөземне иртәнге саф-җылы җил иркәли. Ә тәрәзәм каршындагы зур бакчада – Россия Саклану министрлыгының Үзәк архивы урнашкан урында (әлеге мәйдан тимер челтәрле биек коймалар белән әйләндереп алынган, эчке ягында сакчылар йөреп тора) – үзәкләрне өзеп-өзеп сандугачлар сайрый...

Сандугачлар... Әллә алар да, минем кебек, йокысызлыктан җәфа чигәләрме? Әллә җырчы кошлар, Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булганнарның якты истәлекләрен, олы рухларын бинигаһа кадерләп, аларга үзләренең кабатланмас сихри моңнарын багышлап, мәңгелек сакка басканнармы? Әллә сандугачлар яу кырыннан кайтмый калганнарның үлмәс җаннарымы? Җырлары әллә исәннәргә– безнең буынга –әйтер сүзләреме, өн-авазларымы? Әллә каһарман якташларыбыз эзләреннән меңнәрчә чакрым юллар үтеп, бирегә – Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендәге Үзәк архивка – баш күтәрми эшләргә килүчеләрне хуплап, шулай үзләренчә сәламлиләрме?..

Һай, телләрен-уйларын белсәң иде шул җырчы кошларның... Ә инде йокысызлыктан интегүемә килсәк, аның сәбәбе бер генә – архивта эзләнүләргә багышланган киеренке һәр көн нинди дә булса тетрәндерерлек хәлләр, сискәндерерлек фактлар белән очраштыра. Очраштыра да шул чор вакыйгалары эченә өермәдәй-ташкындай бөтереп алып кереп китә, йокыны-ялны, ашау-эчүне, бар дөньяны онытттыра... Әйе, дары исе сеңгән, чит-читләрен ялкын өтеп алган, канга манчылган ул документлар җанга һич тә тынгылык бирмиләр. Күпме каһарманнар, үзләренә "икенче гомер" бүләк иткәнне көтеп, архив киштәләрендәге калын томнар аша сүзсез генә безгә карап торалар. Әрнү дә, өмет тә чагыла кебек аларның өнсез "карашларында..." Шушы архивта саклаучы, тарихи дәреслекне раслаучы миллионнарча том гаять мөһим, бәһа биреп бетергесез ул документларның зур күпчелегенә әле эзләнүче-тикшеренүчеләрнең куллары бөтенләй тимәгән. Әнә шул "айсберг-боз"ны аз гына булса да "эретү" – билгесез батырларны барлауда тыйнак кына үз өлешемне кертү нияте белән чираттагы ялым вакытында һәр елны диярлек киләм мин бу архивка. Ашкынып-дулкынланып киләм...

Архив... Иң элек шул искиткеч серле, тылсымлы, хикмәтле "мәгарә"гә беренчеләрдән булып юл күрсәткән остазларыма ихлас рәхмәтемне әйтеп, тирән хөрмәтемне белдереп үтим әле. Менә алар : вафат булган рухташларымнан – үтә дә нечкә күңелле, тынгысыз җанлы Гази Кашшаф, Самат Шакир, Зәки Әхмәтҗанов, Фәргать Нуруллин, Әмир Ганиев, галимнәрдән Җәмил Гыйльманов, Альберт Айнетдинов; исәннәрдән – бөтен гомерен шушы гаять кирәкле эшкә багышлап, Хәтер сагында уяу торучы Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафин, Мәрди Рафиков, Шәриф Байгильдин, Имам Хәсәнов, Чәчкә Закирова, Нургали Булатов, Мәгъсүм Гәрәев, Әльмира Әдиятуллина, Дамир Гарифуллин... Әлеге фидакарь җаннар безнең кебек сугыштан соң туган буын вәкилләренә дә "архив вирусы"н гомерлеккә йоктырдылар. Арабыздан бик яшьләй киткән талантлы каләмдәшебез Газиз Кашапов-Үзиле, тарих фәннәре кандидаты Сәмигулла Хәйретдинов, исәннәрдән әдибә Сәйдә Зыятдинова, күп томлы "Хәтер китабы"н чыгаруда аеруча нәтиҗәле эшләүче Анатолий Иванов, Михаил Черепанов, эзтабарлардан Әхәт Садриев, Рәшит Миңнегалиев, Гомәр

Хажиев, Рифат Җәләлиев, Гомәр Мөбарәкшин, Камил Арифуллов, Рашат Низамиев, Ирек Бәдертдинов, Рафис Могыйнов, Атлас Гафиятов һ.б. бик күпләр Бөек Ватан сугышы елъязмасын тулыландыруда үзләреннән зур өлеш керттеләр. Алар архивларда казынып, сугыш булган урыннарны аркылыга-буйга инләп, шул дәһшәтле чорның тетрәндергеч сәхифәләрен ачтылар, моңарчы билгесез булган батырларны эзләп таптылар. Батырлар дигәннән, алар арасында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгәннәр һәм ахыр чиктә әлеге олуг исемгә лаек булганнар аерым урын биләп тора...

Советлар Союзы Герое дигән иң югары дәрәҗәле исем моннан 66 ел элек – СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1934 ел 16 апрель Карары нигезендә булдырыла. Шул ук елның 20 апрелендә мәртәбәле мондый исем иң беренче итеп А.В.Ляпидевский, С.А.Леваневский, В.С.Молоков, Н.П.Каманин, М.Т.Слепнев, М.В.Водопьянов, И.В.Доронин кебек аеруча тәвәккәл-батыр очучыларга бирелә. Тарихи язмалардан укып белгәнебезчә, 1934 елның 13 февралендә Чукот диңгезендә, бозлар арасына кысылып, "Челюскин" пароходы бата. Күренекле академик О.Ю.Шмидт житәкчелегендәге арктик экспедиция әгъзалары (экипаж белән бергә барлыгы 111 кеше), шулай итеп, хәрәкәтләнүче боз өстендә, үтә дә кырыс поляр кыш хакимлегендә калалар. Челюскинчыларны эзләп табу һәм коткару эшенә исемнәре югарыда әйтеп үтелгән очучылар үзләре теләп алыналар... Ниһаять, 5 апрельдә А.В.Ляпидевский дрейфтагыларны табу бәхетенә ирешә һәм очкычы белән боз өстенә "кунаклап", беренче рейста ук унике кешене материкка исән-сау алып кайта. Аның фидакарьлеге башка очучыларны да канатландыра. 13 апрельдә инде челюскинчыларның барысы да коткарыла (алар арасында ике бала һәм жиде хатын-кыз да була)...

1934 елдан алып Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәрге чорда барлыгы 626 кеше Советлар Союзы Герое дигән олуг исемгә лаек була. Араларында Татарстан Республикасында туып үскән төрле милләт вәкилләре, шул исәптән 9 татар да бар (кара: "Герои Советского Союза", М., "Воениздат", 1984, 28 бит). Хәзер кайбер якташларыбыз белән якыннанрак таныштырып үтик әле.

Шулар арасыннан Чирмешән районында туып-үскән мордва егете Павел Алексеевич Цаплинны (1906–1937) иң беренче итеп тирән ихтирам хисләре белән телгә аласыбыз килә.


*П. А. Цаплин*

...1936 елның 16 июлендә Испаниядә монархистик фашистлар фетнәсе башлана. Генерал Франко гаскәрләренә ярдәмгә итальян һәм немец фашистлары ашыга. Алар Испаниягә бихисап корал, хәрби кирәк-яраклар һәм тулы хәзерлектәге хәрби частьләрен җибәрәләр.

Моңа җавап итеп, бөтен дөньяда Испания патриотларына карата теләктәшлек хисе үсә бара. Әлеге республиканы саклау, кара көчләргә каршы тору өчен күп кенә илләрдән ирекләләр отрядлары килә. Совет ирекләләреннән дә 2065 кеше туплана, шуларның 351 е танкист була.

Капитан Цаплин 1936 елгы Октябрь парадында (7 ноябрь) катнашканнан соң, Кызыл мәйданнан ук, үз теләге белән, Испаниягә китә. 20 ноябрьдән инде ул, танк ротасы командиры сыйфатында, Мадридны саклаучылар белән бергә фетнәчеләргә каршы сугыша. Шул чорда яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен кыю офицер, СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1937 ел 2 гыйнварындагы Карары нигезендә, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

1937 елның 13 февралендә франкочы гаскәрләрнең һөҗүмнәре туктатыла. Республикачылар үзләре контрһөҗүмгә күчә. Капитан Цаплинның танклары, тимер ташкын булып, дошман өстенә ыргыла. Җиңү арты җиңү яулаган мизгелләрнең берсендә, көтмәгәндә генә, рота командирының куәтле корыч машинасына снаряд килеп тия. Цаплин авыр яралана, әмма рота белән җитәкчелек итүне дәвам иттерә.

Анын экипажы соңгы снаряд, соңгы патрон беткәнче сугыша. Аннары капитан, дошман кулына калдырмас өчен, танкны үзе шартлата һәм частенә әйләнеп кайта... Ләкин яралары аңа озак яшәргә мөмкинлек бирми. Берничә көннән П.А.Цаплинның җәсәден, хәрбиләрчә зур хөрмәт күрсәтеп, Испаниянең Арчен шәһәре каберлегенә җирлиләр...

Интернациональ бурычны үтәгәндә күрсәткән каһарманлыгы өчен, СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1937 ел 27 июнь Карары нигезендә Мордва Афонькасы авылы егете Павел Алексеевич Цаплинга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелә. Республикабызда иң беренче булып!..

Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребез дә сынатмый. Нәсел тамырлары белән республикабызның Биектау районы Ямаширмә авылыннан булган, Донбасста туган Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршинны (1914–1947) гына алыйк. Ул 1938 елның җәендә Приморье краеның Хасан күле янында, япон самурайларына каршы көрәштә үзенең исемен мәңгелек данга күмә.



*Г. Ә. Батыршин.*

... 29 июльдә Япониянең Квантун армиясе гаскәриләре, чикне бозып, Заозерная һәм Безымянная биеклекләре районында безнең заставаларга һөҗүм итәләр. Башка сугышчан иптәшләре кебек, чик сакчысы Г.Батыршин да үзенең отделениесе белән самурайларга каршы батырларча көрәшә. Ахырдан ул авыр яраланган сигез сугышчыны һәм застава начальнигын дошман кулына төшүдән коткарып кала — аларның һәркайсын, берәм-берәм үз аркасына салып, күлнең икенче ягына чыгарып куя. Яшьлегендә оста йөзүче булуы, житезлеге-тапкырлыгы әнә шул чакта бик тә ярдәм итә аңа.

13 көн буе дәвам иткән сугышлар барышында японнар үзләренең бик күп солдатларын, офицерларын югалталар һәм 1938 елның 11 августында СССР белән вакытлы килешү төзергә мәҗбүр булалар. Чик сакчыларыннан аеруча зур батырлык күрсәткән 22 кешегә, шул исәптән Гыйльфан Батыршинга да, аның якын дусты Иван Чернопяткога һәм алар хезмәт иткән застава начальнигы П.Ф.Терешкинга, СССР Югары Советы Президиумының 1938 ел 25 октябрь Указы нигезендә, Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелә. Шул ук Указ белән әлеге мактаулы исемгә тагын бер милләттәшебез — Саратов өлкәсендә туып-үскән пулеметчы егет Кәрим Мусяк улы Яһудин дә лаек була. Ул бер бәрелештә дошманның 60 лап солдатын һәм офицерын сафтан чыгара...

1939 елның 30 ноябрендә башланып, 1940 елның 12 мартында тәгәлләнгән совет-фин сугышы вакытында да якташларыбыз сынатмыйлар. Шулар арасыннан төрле дәрәҗәдәге иң гаярь хәрбиләр — Казан шәһәреннән М.В.Дмитриев, М.П.Кирпонос, А.М.Коняев, Д.Е.Строганов, А.А.Чупуренко, Алабугадан С.П.Спирьков, Балтачтан Х.И.Ибраһимов, Б.С.Рәхимов, Х.С.Сабиров, Баулыдан И.Д.Зиновьев, Мамадыштан Г.Я.Нигъмәтуллин, Минзәләдән Г.В.Вәзетдинов, Б.А.Винокуров, Теләчедән А.К.Ксенофонтов Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар. Тугандаш Башкортостан Республикасында һәм Саратов өлкәсендә туып-үскән милләттәшләребездән С.Н.Майский белән И.М.Кудашев та Алтын Йолдыз кавалерлары булып әвереләләр...

1941–1945 елларда немец-фашист илбасарларына каршы 1418 көн вә төн дәвам иткән Бөек Ватан сугышы һәм Ерак Көнчыгышта Япониянең кораллы көчләрен, Квантун армиясен тар-мар итү өчен барган көрәш (1945 елның 9 августы – 2 сентябре) безнең ил — СССР дигән зур дәүләт өчен аеруча житди сынау чоры була. Дошманны җиңү хакына күпмилләтле бердәм халкыбыз ким дигәндә 27 миллион кешесен корбан итә. (Дөресен генә әйткәндә, бу өлкәдә серлелек пәрдәсе тулысынча ачылмаган әле. И.В.Сталин 1946 елда, мәсәлән, "Правда" газетасы хәбәрчесенә биргән

интервьюсында: "...немецлар белән сугыш вакытында, оккупация чорында һәм немец каторгасында Советлар Союзы үзенең жиде миллион кешесен югалтты", – дип белдерә... Н.С.Хрущев исә 1961 елда Швеция Премьер-министры Т.Эрландерга жибәргән хатында Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булучыларның санын егерме миллион итеп күрсәтә... 1990 елда – М.С.Горбачев илгә житәкчелек иткән чорда – бу сан егерме жиде миллионга житте...

Чит ил тикшеренүчеләренең әлеге мәсьәләгә карата үз карашлары бар. Америкалы социолог Н.Тимашевның 1948 елда ук игълан ителгән белдерүеннән күренгәнчә, СССР әлеге сугыш вакытында утыз жиде миллион ярым кешесен югалткан булып чыга. (Кара: "Родина" журналы, 1991, 6–7 кушма сан, 139 бит.) Ә инде Мәскәүгә килеп, бу мәсьәләне утыз ел буе өйрәнгән Англия галиме Ж.Эриксон: "...Икенче Бөтендөнья сугышы Советлар Берлегенең кырык тугыз миллион кешесен алып китте", – дип белдерә. Халыкларны газиз ватаннарыннан куганда үтерелгән һәм төрмәләрдә, ГУЛАГ биләмәләрендә миллионлап кырылганнар саны бу исәпкә керми...

Шулай да... Сугышта һәлак булганнарга багышлап "Хәтер" китаплары чыгарылу, партизаннар хәрәкәтендә, дошманга каршы яшерен оешмалар эшчәнлегендә катнашучылар, шулай ук әсирлектә булган, коллыкка куылган кешеләр турында яңа мәгълүматлар табылу, мәңге кереп булмастай тоелган серле архив ишекләренең ачылуы безнең көннәрдә якты өметләр уята. Һәлак булганнар һәм чын батырлар турында Галижәнап Вакыт үз сүзен әйтәчәк әле!..)

Бөек Ватан сугышы елларында яу кырында, дошман тылында, диңгездә һәм күктә тиңдәшсез фидакарьлек үрнәкләре күрсәткән 11.633 кешегә Советлар Союзы Герое дигән олы исем бирелә. Алтын Йолдызга ия булучылар арасында Татарстан уллары һәм кызлары да йөзәрләп санала.

Әлеге каһарманнар – чын мәгънәсендә халкыбызның зур горурлыгы, рухи ныклыгы-мактанычы. Еллар үтү белән аларның һәркайсының шәхси батырлыгы белән кызыксыну үсә-көчәя бара. Сугыш елларында ук инде республикабызның танылган язучылары, журналистлары һәм галимнәре батырлар турында материаллар туплый башлыйлар, алар турында "Кызыл Татарстан", "Красная Татария" газеталарында, "Совет әдәбияты" журналында әдәби-публицистик язмалар бастыралар. Татарстан китап нәшриятында аерым жыентыклар булып та чыга аларның ул әсәрләре. Төрле фронтларда татар телендә нәшер ителүче газеталарның хәрби хәбәрчеләре дә бу өлкәдә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр – каһарманнарыбыз турында йөзләгән очерк-зарисовкалар ижат итәләр...

Соңыннан, шуларга нигезләнеп, сугыштан соң – 1946–1947 елларда – башта урысча, аннары татар телендә беренче тапкыр "Батырлар китабы" дөнья күрә. Аны чыгаруда күренекле язучы Кави Нәжми башлап йөри, төзүче-мөхәррире дә үзе була. Алсу тышлыгына Алтын йолдыз медале, лавр яфраклары, милли бизәкләр төшерелгән, батырларның рәсемнәре урнаштырылган һәм чорына күрә яхшы ук бизәлгән әлеге китап (рәссамы – Байназар Альменов) 10 мең данәдә басыла. 224 битле I томга 56 Герой турында очерклар тупланып бирелә. Аларның авторлары арасында без Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Галиев, Габдулла Гомәрев, Мәрьям Дибаева, Әхмәт Ерикәй, Бруно Зернит, Риза Ишморат, Газиз Иделле, Гази Кашшаф, Мәхмүт Максуд, Шәрәф Мөдәррис, Гамир Насрый, Мөхәммәт Садри, Гали Хужиев, Мәхмүт Хөсәен, Әхмәт Юныс кебек өлкән каләмдәшләребезне күрәбез.

"Батырлар китабы"ның тагын да күләмлерәк II томы да хәзерләнгән була. Ләкин ул, хәзергә билгесез сәбәпләр аркасында, үз укучысы кулына барып ирешми...

Әмма батырлар турындагы чын хакыйкать, кар астындагы кайнар чишмә кебек, барыбер үз юлын таба. 1963 елда Татарстан китап нәшриятында тарихчы эзтабар Л.И.Ханинның урыс телендә "Герои Советского Союза – сыны Татарии" дигән китабы басылып чыга. 167 Герой турындагы очерк-зарисовкаларын туплап бирә ул биредә. 1966 елда әлеге китапның татарча басмасы да дөнья күрә – бу юлы инде каһарманнарның санын 171 кешегә житкерә Леонид Иванович...

1982, 1984 һәм 1985 елларда Татарстан китап нәшрияты батыр якташларыбыздан 211 кеше турында урыс телендә "Герои Советского Союза – наши земляки" дигән өч томлыкны халык игътибарына житкерә. 1990 елда исә әлеге томнар татар теленә тәржемә ителеп, "Советлар Союзы Геройлары – якташларыбыз" дигән исем

астында 680 битле саллы гына китап булып басылып чыга. Аңа, 211 каһарман турындагы очерк-зарисовкалардан тыш, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребездән 91 кеше турында кыскача мәгълүматлар кертелә, фотосурәтләре урнаштырыла. Бу өлкәдә тарих фәннәре кандидатлары Ж.И.Гыйльманов, А.К.Айнетдинов, Татарстан китап нәшриятының ул чактагы баш мөхәррире урынбасары Н.К.Габитов, эзтабар язучы Ш.Ж.Рәкыйпов, отставкадагы полковник С.Ә.Таһиров, якташыбыз, СССР Саклану министрлыгы Үзәк архивы начальнигы урынбасары, полковник Ә.Х.Фәйзуллин үзләреннән аеруча зур өлеш кертәләр...

Бөек Җиңүнең 55 еллыгын лаеклы төстә каршылау һәм билгеләп үтү турында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнын 1999 ел 11 май Указы һәм ТР Министрлар Кабинетының 1999 ел 20 август Карары батырларыбызны барлау юнәлешендә тагын бер әһәмиятле адым ясарга рухландырды. Татарстан китап



*Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров (уңнан сулга), баш мөхәррир Харрас Әюпов, бүлек мөдирләре Расим Әмирханов, Равил Рахмани, Рушан Шәмсетдинов (баш рәссам), Рафис Корбанов, Булат Хәмидуллин «Батырлар китабы»ның яңа басмасын чыгару хакында фикер алышалар. 1999 ел.*

нәшрияты, Республикабызның Язучылар оешмасы, Баш Архив идарәсе, Татар энциклопедиясе институты, музейлар, "Хәтер китабы" нәшрияты, хәрби комиссариатлар, ветераннар советлары белән берлектә, "Батырлар китабы"ның энциклопедик характердагы яңа басмасын хәзерләү эшенә ныклап тотынды. Нәшрият директоры Д.С.Шакиров тәкъдиме буенча, төрле чыганаклардан эзләнә торгач, Советлар Союзы Геройларыннан барлыгы 378 кеше турында кызыклы-гыйбрәтле мәгълүматлар тупланды. Аларның зур күпчелеге Татарстанда туган яисә биредә укыган, эшләгән, яшәгән. Республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез дә онытылмады. Нәтиҗәдә, батырлар турында беренче мәртәбә тулы мәгълүматлы шундый уникаль басманы дөньяга чыгару мөмкинлеге туды. Элек нәшер ителгән китаплардан аермалы буларак, "Батырлар китабы"ның яңасына Алтын Йолдызлы каһарманнарыбыз турында Россия Саклану министрлыгы Үзәк архивында саклаучы Бүләкләү кәгазьләрендәге язмаларның кыскача сөземтәсе кертелде (алар дәүләтебезнең берьюлы ике телендә — татар һәм урыс телләрендә янәшә бирелде), фоторәсемнәре урнаштырылды. Батырларыбыз турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүматлар алырга теләгән кешеләр өчен һәр сәхифә ахырында әдәби чыганаклар да күрсәтелде.

Әлеге басманы хәзерләгәндә зур ярдәм күрсәткән Россия Федерациясенең Хәрби фәннәр академиясе президенты, армия генералы, хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы, академик М.Ә.Гәрәевка, Россия Саклану министрлыгы Үзәк

архивының элеккеге җаваплы хезмәткәрләре – полковник Ә.Х.Фәйзуллинга, подполковник А.Г.Янкевичка, өлкән фәнни хезмәткәр – уку залы мөдире В.А.Кеменевага һ.б. иптәшләргә ихлас рәхмәт сүзләрен җиткерәсебез килә. Каләмдәшләребездән Шамил Рәкыйпов, Зәет Мәҗитов (хәләл җефете Наилә ханым белән), Харрас Әюпов, Солтан Шәмси, Рафис Корбанов, әтиле-уллы Лирон һәм Булат Хәмидуллиннар, Нургали Булатов, Раиф Бариев, Фирая Зыятдинова, Наилә Вәлитова, Роза Заһидуллина, Гәүһәр Хәсәнова, Илшат Хәлиуллин, Наил Таиров, Азат Низамиев, Татар энциклопедиясе институтыннан Флера Гулова, Татарстан Җөмһүриятенең милли китапханәсеннән өлкән библиограф Зөбәрҗәт Нуриева һ.б. шулай ук бу гаять мөһим эшкә үзләреннән зур өлеш керттеләр...

"Батырлар китабы"нда 1945 елның 30 апрелендә төнге сәгать унберенче яртыда – урыс М.А.Егоров белән грузин М.В.Кантариядән алда – рейхстаг түбәсенә иң беренче булып 79 нчы укчы корпус Байрагын менгезеп кадаган татар егете, өлкән сержант Гази Казыйхан улы Заһитов (1921 – 1953) турында да сәхифә бирелә. Үзәк архивта эшләгәндә өлкән әзтабар әдибебез Шамил ага Рәкыйпов тапкан каһарманыбыз ул! Хәер, бу тынгысыз язучы, искитмәле тарихи-документаль әсәрләр тудырып, бер үзе генә дә дистәләрчә батырларыбызга икенче гомер – мәңгелек яшәү бүләк итте. Аның каһарманнары арасында Алтын Йолдызлы очучы кызларыбыз Мәгүбә Хөсәен кызы Сыртланова, Ольга (Ләйлә) Александровна Санфирова, легендар партизан Иван Константинович Кабушкин, татарлардан иң беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршин, күренекле хәрби эшлекле, генерал-полковник Василий Николаевич Гордов, Бүләкләү кәгазендәге бер хәрефнең дөрес язылмавы аркасында үзенең Герой икәнлеген дә белмичә үлеп киткән Хәсән Заман улы Заманов, ил күләмендә Николай Сергеевич Орлов буларак билгеле татар егете Гатаулла Мирзаһит улы Минаев һ.б. бар...

Әйе, архивтагы эзләнүләр көтелмәгән ачышлар ясарга да этәрә. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән якташларыбыз, милләттәшләребез бермәбер күбрәк булган икән безнең. Архивта моңарчы тикшеренүчеләрнең куллары кагылмаган үтә җитди документлар белән танышканда шундый фикергә киләсең. Әйтик, Татарстанның Әлки районы Баллыкүл авылы егете – III Украина фронтының Николаевск ныгытылган районына караган 10 аерым пулемет-артиллерия полкының пулемет расчеты командиры, гвардия сержанты Хафиз Зариф улы Зарипов (1906–1944) яу кырында күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары өчен, Советлар Союзы Герое исеменә өч мәртәбә (!) тәкъдим ителә. Әмма аның фидакарьлеге тиешенчә бәяләнми.

Шундый ук сүзләрне Аксубай районының Козловка (Дмитриевка) авылында туган өлкән сержант Филипп Николаевич Мазилинга, Арча районының Носы авылы егете – капитан Әсгать Зиннәтулла улы Зиннәтуллинга, Кукмара районының Бөтләнгер (Аксыбы) авылыннан китеп, Карелия җирендә батырларча һәлак булган шагыйрь җанлы лейтенант Нух Идрис улы Идрисовка, Мамадыш районының Урта Кирмән авылында яшәгән разведчик Мәүләви Галимҗан улы Галимовка һәм тагын дистәләрчә якташларыбызга карата да әйтергә мөмкин. Алтын йолдыз кавалеры булырга лаеклы бу затларга, ни кызганыч, төрле дәрәҗәдәге орденнар гына бирелгән...

Әмма батырларны туган төбәкләрендә онытмыйлар. Әйтик, Нух Идрисовка 1988 елның 16 октябрендә, тууына нәкъ 70 ел тулган көндә, үз исемен йөрткән Түбән Өскебаш урта мәктәбе (Кукмара районы) каршында мәһабәт һәйкәл (бюст) куелды. Якташлары аның янәшәсендә Татарстанның Бөек Ватан сугышы чорындагы иң яшь Советлар Союзы Герое, Җиңү парадларында катнашкан гвардия полковнигы Сабир Әхтәмҗан улы Әхтәмовка да шундый ук һәйкәл торгызды .

Легендар полк улы, соңыннан Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган Камил Фаяз улы Шакировны да зурлады халык. 1990 елның 9 маенда Зур Сәрдек авылына мәгърур һәйкәл булып кайтты ул. Кукмаралылар хәтеренә мәңгелеккә кайтты...

Мамадыш районында да бу юнәлештә мактауга лаек эш алып барыла. Биредә район хакимияте башлыгы булып Татарстан халык депутаты, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин эшләгән чорда (бүгенге көндә ул Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе ) шәһәр үзәгендә "Хәтер" паркы булдырылды. Шул паркның нәкъ урта бер җирендә "Батырлар аллеясы"на нигез салынып, анда Татарстанда туган милләттәшләребез арасыннан иң беренче Советлар

Союзы Герое исеменә лаек булган Гафият Ярмөхәммәт улы Нигъмәтуллинга (1915–1945), шулай ук Иван Тихонович Максимов, Михаил Кириллович Москвин, Михаил Андреевич Просвирнин кебек каһарманнарыбызга да һәйкәлләр куелды. Сугышта сигез улын — сигез лачынын югалткан тыл батыры Фатыйха апа Әхмәдиевага һәм аның кебек балаларын яу кырында җуйган барлык милләт аналарына, тирән хөрмәт билгесе итеп, ап-ак таштан символик һәйкәл салдыручы да Ә.С.Гобәйдуллин булды.

Хәзер эстафетаны районның яңа житәкчесе Фарук Ислам улы Идиатуллин, аның урынбасары Шамил Нурулла улы Хәсәнов уңышлы дәвам иттерә. Бөек Җинүнең 55 еллыгын тантаналы төстә билгеләп үткән көннәрдә биредә мәшһүр композиторыбыз, бөтен дөньяны гизгән "Шүрәле" балеты авторы — матурлык хакына яшәгән, иҗат иткән һәм явыз көчләргә каршы көрәштә 29 яшендә яу кырында шәһит киткән Фәрит Заһидулла улы Яруллинга да һәйкәл торгызылачак. Район үзәгендә, тиздән үз исеме биреләчәк музыка мәктәбе каршысында...

Югарыда телгә алынган батырларны олылаучы һәйкәлләрнең төп авторы — күренекле скульптор Әлфәрит Хәйрулла улы Әбдерәшитов (паспортында язылганча итеп әйтсәк, Альфрет Хайруллаевич Абдрашитов. ). Аларны ул үзенең хәләл җефете Луиза ханым, уллары Альберт һәм Гадел белән берлектә иҗат итте. Гомумән, бу скульптор сугыш һәм хезмәт батырларына багышланган күп кенә монументаль әсәрләр тудырды, халкыбызның бөек батырлыгын киләсе гасырларда яшәячәк яңа буын кешеләренә җиткерү өчен үз-үзен аямыйча эшләде. Һәм бу хәзер дә шулай...

Батырларыбызның күп булуы күңелле күренеш, әлбәттә. Егерменче гасырны тәгәлләп, өченче меңъеллыкның ишеген шакыганда: «Сугышларсыз гына яшәсәк иде киләсе елларда!»—дигән изге бер теләк уяна. Алдагы гасырларда яу кырында һәлак булган батырлар бөтенләй булмасын иде. Безгә, менә кадәр булган каһарманнарыбызны данлап һәм хөрмәтләп, тыныч тормышта матур гомер итәргә язсын иде!..

* * *

...Архив бакчасында сандугачлар сайрый...

Ашкынып-дулкынланып тагын Архивка юл тотам. Чын Тарих белән очрашырга, Үлемсезлек чиген атлаган каһарманнар белән күрешергә, Үткән белән Бүгенге арасына мәңге җимерелмәслек изге күпер салырга...

Шунысы сөендерә: бу юлы безнең кебек "ветераннар" белән бергә Архивта эшләргә яшьрәк буын эзтабарлары да бара!.. Димәк, буыннар чылбыры, хәтер дисбесе өзелмәс. Батырлык елъязмачылары, монарчы билгесез булган гаҗәеп сәхифәләрне ачып, каһарманнарыбызның сафларын көчле рухлы яңа шәхесләр белән тагын да тулыландыра төшәрләр әле...

**Шаһинур МОСТАФИН,**
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары,*
*эзтабарларның «Хәтер яктысы» берләшмәсе җитәкчесе.*

*Җиңүнең 55 еллыгына*

# УРМАН КИСТЕ КЫЗЛАР...

*Кайда сез, безне ерактан*
*Таный алганнар,—*
*Без офыкка күмелгәнче*
*Озатып калганнар?*
*Кайда сез?*

Хәсән Туфан.

«Кая барыйм, нишлим? Кемнәргә калдырыйм сезне?»

Бу—әни тавышы. Колхозга килгән наряд буенча ул күрше Мари республикасының Суслонгер урманына эшкә китәргә тиеш. Ә өйдә берсенә—алты, икенчесенә өч яшь тулар-тулмас ике бала—апам белән мин. Без икебез дә, өстәвенә житмешне тутырып килгән әби дә, тамак шеше белән авырыйбыз. Әни шуңа бәргәләнә, чарасызлыктан тилмереп елый икән. Районнан килгән вәкил үз күзләре белән өйдәге хәлне күргәч, ничектер йомшарды, әни бу юлы урман кисәргә китмәде.

Үз-үземне белә башлагач үзәкләремне өзгән беренче хатирәм бу: «Кая барыйм, нишлим?»—әни тавышы.

Еллар үтеп, Бөек Ватан сугышы чорында хатын-кызларның фидакарь тырышлыкларын, башларына төшкән ачы газапларын күрсәткән бик күп тарихи документларга да юлыктым мин. Шуларның берсендә болай дип әйтелә: «Горький, Киров, Казан, Ярославль, Калинин, Октябрь, Пенза һәм башка тимер юлларны кирәк кадәр утын һәм агач материаллары белән тәэмин итәр өчен Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы 3590 кеше һәм 1670 баш ат жибәрергә тиеш... Бу эшкә күбрәк хатын-кызлар һәм фронтка яраклы булмаган ирләр тартылсын».

Датасы—1942 елның 12 феврале. Аңа Сталинның якын көрәштәше Л. Каганович кул куйган.

Татарстан бу боерыкка буйсынмый кала алмый, әлбәттә. Тиз арада, дошман Мәскәүгә килеп житүгә, безнең Татарстан иң якын тылга әйләнә, фронт заказларының күбесе монда үтәлә. Ә аларны фронтка ташыр өчен паровозларга күпме утын, Казанның үзендә эшләнгән хәрби самолетларга гына күпме фанера һәм башка материаллар кирәк. Агачка булган ихтыяжны канәгатьләндерү өчен Татарстанда оештырылган 12 урман хужалыгы эшенә эшче кулларны кайдан алырга? Эшкә яраклы ирләрнең барысы да фронтта ич.

Соңгы елларда мин сугыш вакытында урман кисүче хатын-кызлар турында байтак истәлекләр жыйдым. Шуларның берсе—Әтнә районы Күәм авылыннан Котдус Мортаза улы Мостафин сөйләгәннәрдән:

«Сугыш елларында Әтнә һәм Кызыл юл районнарына Казан шәһәрен утын белән тәэмин итү бурычы йөкләтелгән иде. Утынны Мари Республикасының Шелангер урманына барып кисәргә кирәк. Безнең Күәм авылы (К. Маркс исемендәге колхоз) 12 бригадалы. Һәрберсеннән 2 шәр ат жибәрелә. Алар киселгән агачны урманнан алып чыгып торырга тиеш. 20-25 ләп хатын-кыз. Бер кеше—пычкы кайраучы, бер кеше—бригадир.

Боларның һәркайсына авыл Советына чакырып районнан килгән махсус мобилизация кәгазе тоттыралар. Ул кәгазь Дәүләт Оборона комитеты исеменнән жибәрелгән һәм анда язылганнар үтәлмәгән очракта, сугыш чоры законнары буенча һәркемнең жавапка тартылуы кисәтелгән. Колхоз кеше башына бер көнгә бер кило бәрәңге, атларга печән бирә. Күп вакыт ул өшегән бәрәңге була әле.

Урман эшенә кеше жыю, авылдан чыгып китүләр әле дә онытылмый. Авыл

кара кайгыга бата... Урман кисүнең нәрсә икәне һәркемгә мәгълүм, чөнки исән-сау әйләнеп кайтырга да тулы ышаныч юк бит әле. Шунлыктан киткәндә елау, күз яше чиксез иде.

Барып житәбез. Биллән кар ерып, хатын-кыз урман кисә. Һәр кеше 4-6 кубометр утын кисәргә тиеш. Нормада шулай каралган. Өс-баш юк ул чакта, аякта чабата. 1-2 көн эчендә өс-баш тетелеп төшә. Без киселгән утынны ат белән 8-9 чакрым ераклыкка ташыйбыз. Көнгә ике әйләнәбез.

Хатын-кызның чыдамлыгына әле дә хәйран калырлык, ул бичараларга, үз нормаларын үтәү өстенә, төннәрен киселгән агачны вагонга төятәләр бит. Һәр авылга бер вагон. Ачык платформа булса тагын бер хәл иде. Зур ябык вагоннарга төяргә туры килә күбрәк, аларга төяү—үзе бер газап. Житмәсә, ике, күп булса өч сәгать вакыт бирелә. Йа Алла, күрде инде хатын-кыз бичара, күбесе үсмер кызлар бит әле. Ир заты да чыдый алмас иде бу газапка.

Мари хатыннарының урман кискәнен күрмәдем, әмма алар безне бик кызганалар, киемнәрне киптереп бирергә тырышалар иде, рәхмәт үзләренә. Һәр өйдә 7-8 кеше тора иде.

Шул авыр хезмәттә норма тутырсаң, 600 грамм ипи була, ә кайвакыт ашханәгә дә кертеп ашаталар».

Кызганыч, урман хужалыкларының барысында да ашханәгә кертеп ашатулар булмаган икән шул. Туган авылым Яңа Шимбер (Әтнә районы) хатын-кызларының Суслонгер урманында ачка тилмерүләре хакында бик күп истәлекләр тыңлаганым булды. Ач көйгә урман кисүләре хакында алар еламыйча сөйли алмыйлар иде. «И, ул Суслонгер урманнары,—дип искә ала иде мәрхүмә Хажәр апа,—өйдән алып килгән бәрәңгене санап, һәр көн өчен бүлеп куя идек. Туйганчы ашаулар кайда ул. Имән чикләвеге, өшегән миләш ашый идек. Үзәккә үткән онытылмый ул, олан. Сафи Гайшәсе: «Бәгырьләрем, әйдәгез шул столовый дигәннәренең исен генә иснәп торыйк»,—дип тилмерә иде. Шулай да норманы тутыра идек».

Менә тагын бер истәлек:

«Мин 1948 елга кадәр урман кистем,—дип сөйләде Иске Шимбер авылы кызы Хәйруллина Әкрам апа,—Либадан, Шелангер, Помары, Саба, Иябаш, Лаеш урманнарында әче тирләрем күп чыкты. Кайчан агач басып үтерер икән, дип йөри идек инде. Мин туганыбыз Зәйнулла абыйның кечкенә кызларына актык сынык икмәгемне адарынып кына исән кала идем... Ирләр күтәрә алмаслык агачларны вагоннарга төяү дисеңме; аякта чабата, суык табаннардан эчкә йөгерә. Бервакыт нәзер әйттем: суыкта өшеп үлмәсәм, өйгә кайткач, өч көн мич башында утырыр идем. Аллага шөкер, ул тәмуг урманыннан исән кайттым, нәзеремне үтәдем».

Мондый истәлекләрнең тагын берсен, озак еллар Казан педагогия институтында әдәбият белемен укыткан галимә, филология фәннәре кандидаты Мәдинә Шәйхи кызы Жәләлиева сүзләрен китермичә үтә алмыйм:

«Студент еллар сугыш вакытына туры килде. Без күргән жәфаларны сөйләсәң—тел, язсаң—кәгазь чыдамас. Югары уку йортларында укучы кызларны урман кисәргә жибәрәләр иде. Мари урманнары безнең күз яшьләрен хәтерлидер. Башта агачларны кисәбез дә, 2-2,5 метр итеп турыйбыз. Шуннан соң, тачкаларга салып, елга буена чыгарабыз. Өс-баш начар, ашарга житми. Әле дә хәтеремдә: октябрь-ноябрь айлары, коточкыч салкын. Без чыгарган агачларны, бозлы суга яртылаш кереп, Кырым татар кызлары салга төйиләр иде. Ярда милиционер тора, тунсалар да чыгып йөгерә алмыйлар. Йа Алла, ул кызлар хәзер исән микән? Хәзер шул газаплар берәм-берәм чыга инде. Бармы безнең буынның бер сәламәт кешесе? Шул газаплар бәрабәренә ни алдык?»

Архивта сакланган байтак документлар да ул чор хатын-кызларының тиңдәшсез батырлыгы хакында искә төшерә.

«Кызлар өчәр норма тутыралар,—диелә бер документта.—Сокольски сал агызучылары барысы да Татарстаннан. Хатын-кызлардан аерым фронт бригадасы төзелде. Иң алдынгы стахановчылар шулар». Кызганыч, кызларның исемнәре язылмаган. Аларның исемнәрен барлау, фидакарь хезмәтләре хакында бәян итү тарихчыларыбызның изге бурычыдыр, дип саныйм. «Хатын-кызлар ирләр белән ярыша,—диелә икенче бер документта.—Социалистик ярышта Чепья районының «КИМ» совхозыннан килеп, Шәмәрдәндә урман кисүче Әхмәтшина Хәдичә беренче урынга чыкты һәм исемле сәгать белән бүләкләнде».

Әйтеп үтик: хатын-кызлар гына урман кисмәгән. Алар янында фронтка яше житмәгән үсмерләр дә, сугышка яраксыз ирләр дә эшләгән. Хәтта жинаятьчеләр белән бергә эшләргә туры килгән вакытлар да булган икән. Шул унайдан, кызларыбызның тагын бер сыйфатына сокланып, рәхмәт әйтеп үтәсе килә. Ул да булса—татар кызларының үз намусларын саклавы. «Сугыш беткәнче Биектау, Юдино станцияләрендә вагоннарга агач төядем. Сугыш беткән көнне дә Юлинода утын төйи идек,—дип искә ала Арча районы Иске Иябаш авылыннан Ягъфәрова Мөслимә апа.— Сугыш беткәч, Суслонгер янындагы 71 разъезда торф чыгардым. Көндез эшләп арып егылабыз, кирәк булса, төнлә дә чыгабыз. Эшләдек шул, көчне кызганмадык. Барыбыз да авыл кызлары, егетләргә туры карарга да ояла идек. Бервакыт, станциягә солдатлар килә дип ишеткәч, бөтенебез урманга кереп качтык. Аякта чабата, алар кузгалып киткәнче су эчендә басып тордык».

Кызларыбызның сафлыклары хакында Казан медицина колледжының татар теле укытучысы Мөсәмирә ханым Сәлиева да сокланып сөйләгәне бар: «Сугыш вакытында Кира урманнарын күп кискән минем авылдаш апаларым. Бер елны аларга уголовниклар белән янәшә эшләргә туры килгән. Аларның кем икәнлекләрен белеп алгач, кызлар йокларга ятканда да бер-берсенә баулар белән бәйләнеп ята торган булганнар. Шалаш авызына комган, буш банкалар тезеп куялар икән дә, ул-бу сизсәләр, барысы да сөрән салып, кычкырып, бөтен урман хужалыгын аякка бастыралар икән».

Хатын-кызларыбызның тәүлегенә уналтышар сәгать эшләүләре хакында уйлыйм да тан калам. Араларында бер генә кеше дә тамак хакына намусын сатмаган. Нинди матур, олы жанлы шәхесләр булганнар икән безнең хатын-кызларыбыз!

«Хөрмәтле Тәминә ханым,—дип яза Аксубай районы Яңа Дума авылыннан Румия Мирзина.—Авылыбыз кызларының сугыш елларында ни кичергәнен исәннәренең өйләренә кереп язып алдым. Язмамны радио аша тапшыра алсагыз, бик сөенер идек. Җылы сүзгә шатланып яшәгән изге жаннарга шул житә ич. Сугыш башлангач, авылның 8 кызына: Зәйнәп Нуретдинова, Һәдия Хатыйпова, Рәхимә Гыйләжетдинова, Саимә Минһажева, Миңниса Миңлевәлиева, Бәдәр Нигъмәтуллина, Сания Галиева һәм Нуржиһан Минаповаларга хәрби комиссариаттан хезмәт армиясенә алынулары турында хәбәр килә.

Яңа Дума авылы халкы, кан-яшь түгеп, 16-17 яшьлек кызларын Мәскәүгә, хәрби заводка эшкә озата. Бер авыз сүз урысча белмәгән кызлар Мәскәү өлкәсе Загорск районында урман эчендә урнашкан хәрби заводта корал эшли башлыйлар. Мәскәү янында каты сугышлар барган көннәрдә фашистлар заводны бомбага тоталар, заводның көле күккә оча. Бәхеткә, кызлар исән кала. Алар кире тылга, үз авылларына жибәрелә. Кайткач, һаман урман кисәләр, колхозда ни авыр эш бар, шуны эшлиләр.

Тик язмышлары читтә булган, күрәсең. 1943 елда Енисей елгасының уңъяк ярында Красноярск шәһәрендә ГЭС төзелә башлый. Бу төзелешкә яңадан шул ук кызлар китә. Алар белән бергә Иске Кармәт авылыннан Хәлимә һәм Хәйрелбанат Гыйльмановалар, Кыязлыдан Шәмсежиһан Сиражиева һәм Бәян Сибгатуллина; Карасудан—Зәмзәмия, Иске Ибрайдан Зәкия, Маһирә, Нургаян исемле кызлар жибәрелә. Намус белән тырышып эшләгән бу кызлар, 1944 елны жыелышып, Кремльгә, Калинин исеменә саф татар телендә хат язалар: «Без, бер төркем татар кызлары, Сезгә зур үтенеч белән мөрәжәгать итәбез. Безнең туган якларыбызга кайтып тормыш корасыбыз, бала үстерәсебез дә килә. Монда исә татар егетләре юк. Әгәр рөхсәт итсәгез, без үз авылыбызга кайтып китәр идек».

Озакламый кызларга урысча жавап хаты килә. Җавап кыска һәм катгый: «1943 елгы Указ нигезендә кайда жибәрелгәнсез, шунда яшәргә тиешсез».

1946 елда ирекле йөрү турында указ чыккач кына өйләренә кайта алган бу бичара кызлар.

Сугыш афәте аркасында гына түгел, үз хөкүмәтебез тарафыннан да жәбер-золымны күп татыган татар кызлары. Әтнә районы Түбән Көек авылы кызы Габдрахманова Майсәвәр, ачлыкка чыдый алмыйча, урман кисәргә киткән жиреннән бер генә тапкыр утырып чәй эчәргә өенә кайта. Тик артыннан ук бастырып кергән милиционерлар турыдан-туры аны төрмәгә алып китә. Мескен кыз Майсәвәр өен бүтән күрә алмаган, төрмәдә жан биргән. Чувашстанның Батыр районы Шыгырдан авылы кызы Салихова Гөлжиһан да шундый язмышка дучар булган икән. Сигез баласын фронтка озаткан Сәгъди мулла кызы булган ул. Кира урманыннан мунча

кереп, əти-əнисе янында бер утырып чəй эчəргə дип кенə кайткан 18 яшьлек кызны, ясаган чəен дə эчертмичə, төрмəгə озатканнар.

Ə күпме яшь гомер өстенə урманда агач төшеп киселгəн. Тагын документларга мөрəҗəгать итəм: 1942 ел. Иске Əдəм урманында—Тельман районы кызы Садыйкова Фəүзия (кызганыч, авыл исеме язылмаган); Билəр урманында—Мөслим районы Октябрь авылыннан Гатауллина Минлеҗиһан, Сафина Мəүридə; Чирмешəн урманында—Мостафина Миннур; Шəмəрдəн урманында—Латыйпова Хасия; Куйбышев урманында—унсигез яшьлек Вафина Хəдичə (Камский исемендəге колхоздан), «Париж Коммунасы» колхозыннан 17 яшьлек кызлар—Мөхəммəдьярова Фатыйма, Кəримова Гөлзиялəр өслəренə агач төшеп үлеп калалар. Халык үз балалары турында бəетлəр дə чыгарган. Туган авылым Яна Шимбердə яшəп, инде мəрхүмə булган Фатиха апа дəфтəрендə сакланган «Киме кызы Мəрзия бəете»ннəн бер өзек китерəм. Ул яшь-яшь көе урманда үлеп калган кызлар рухына дога булып барсын иде:

Туганнарым, күрмəдегез,
Алсу иде каннарым.
Суслонгер урманнарында
Чыкты минем җаннарым.

Шома яфрак, матур яфрак
Бары имəндə генə.
Минем газиз җаным чыкты
Кайтам дигəндə генə.

Апаем, син бик елама,
Зинһар инде, сабыр ит.
Җəйгə чыккач, җирлəр кипкəч,
Каберемне карап кит.

Тукай районы Боерган авылы кызы Вəсимə Гатауллина (хəзер Казанда яши) истəлеклəрен мин «Керербез дə югалырбыз тайга урманнарына» дип атар идем.

—Урман кисəргə мин 1952 елның көзендə киттем. Авылдан Мəсхиямал Нəфыйкова белəн икəү, Чебенледəн Зəйтүнə, Мəймүнə, Зөбəрҗəт, Гөлфинə, Колыштан Кəшфелҗиһан белəн Фаягөллəр бар иде. 18 чакрым ара узып Курьяга бардык, аннан ни өчендер Красный Борга көймə белəн чыгардылар. Югыйсə, тегесенə дə, бусына да туктый иде пароход. Əнилəр елый-елый озатып калды, чөнки алдагы елда Сəмыйх Нəсифуллин белəн аның хатыны, авырлыкка түзə алмаганга, урман кисүдəн качып, туган җирлəренə өч ай буена кайтканнар иде.

Пермьгə кадəр бардык. Аннары кечерəк пароходка утыртып алып киттелəр. Пожва дигəн пристаньдə төшеп калдык. Коми Пермяк округы Кудымкар районы Лучниково дигəн авылга китереп ташладылар. Икенче көнне делянкага алып киттелəр. Урман буйлап өненнəн уянып чыккан аю йөри икəн, сак булыгыз, тотып ашамасын, дип кисəтеп куйдылар. Кыш көне ерактан гына ул аюны күрдек, ə бүрелəрнең улаганы көн саен диярлек ишетелə, лəкин алар кешелəргə якын килмəделəр.

Шулай итеп, урман кисəбез. Ул чакта «Дружба»лар юк, пычкыны иелеп тартасың-тартасың, кулларның көче житми, бил авырта, гел бер якка кыегаеп эшлəгəнлектəн баш-күзлəр сызлый. Тирлəп эшлисең дə чишенеп атасың, салкын тия. Ипине таяк очында учакта жылытып ашыйбыз. Шул елны безнең леспромхозда дүрт кешене агач басты. Ə безне бу авыр эштəн алып, кискəн урманны чыгару өчен юл көйлəп торырга куштылар. Кар көрəп, чана юлына су сибеп, катырып тордык. Чаналар озын, 5-6 метрлы чанага ат сыртыннан биек итеп агач төйилəр. Без атларны, алар безне кызганып елый.

Еларлык та шул: башта шакмаклы юка шəл (соныннан урын җəймəсе бəйли башладык). Өстə телогрейка, аякта ыштыр-чабата. Чабата брезент белəн тышланган, киндерəлəре тезгə житə, шуна нибары өч пар чабата тузды. Ямый-ямый кия идек. Ашарга такы-токы. Өйдəн киткəн пот ярым он, күпмедер тун май. Кайнап чыккан бəрəңге шулпасына (суына) он туглап май сызгыртып салабыз—менə дигəн аш була.

Эш хакына 450 сум акча бирəлəр, бу ул чакта зур акча иде. Лəкин без такы-токы ашап ситсы, кызыл мал жыябыз—өйгə баеп кайтасы килə. Сагындыра, кич утырганда елап та алабыз. Бервакыт мин хатка:

Керербез дə югалырбыз
Тайга урманнарына.
Искəн жиллəр сəлам булыр
Калган туганнарыма—

дип жыр язып салган идем. Өченче сыйныфта укучы сеңлем: «Түтəй, бүтəн андый жыр язма, əнкəй бик елый».—дип язды.

Шулай да яшьлек үзенекен итə. Клубка «вечер уйнарга» чыгабыз. Урыс егетлəре

озата кайта башлагач, курыктык. Безнең хужа хатын Настя түти егетләрне куып җибәрә, үз кызларына да бик кырыс иде. Ә анда татар кызларына бик кыргый тоелган гадәтләр яши. Мәсәлән, кызның ирсез тапкан ике-өч баласы булмаса, аны кияүгә алучы да юк. Бервакыт начальникка: «Өйгә егетләр килә»,—дип зарланган идек, ул шаккатты. «Кыз килеш кияүгә баралармыни?! Бала табып карамагач, егет булачак хатынының сәламәтме, түгелме икәнен каян белсен, бәлки ул нәсел үрчетүгә сәләтсездер»,—ди.

Икенче шаккаттыргыч хәл шул булды—марҗалар ыштансыз йөри икән. Дөрес, урманда ышык, җил юк, ләкин 40-50 градус салкын. Агачлар шартлап сына. Марҗалар көне буе гежгелдәп йөриләр дә, эштән кайткач сәндерәгә менеп тә җылына алмыйлар.

—Нигә ыштан кимисез?—дип сорыйбыз.

—Нам нилзя, грех—диләр. Без моны берничек тә аңлый алмый идек.

Тел белмибез. Кайвакыт әллә нинди көлке хәлләргә калып бетәбез. Чабатасы тишелгәч, бер кыз күршеләргә шөшле сорарга кергән.

—Вәт такуй инструмен нады. У твоего мужика ес, дай пожалусты,—дип бармагын кәкрәйтеп күрсәтә икән.

—Ах, стерва, моево мужика захотела! А сама прикидывается скромной!—дип куып чыгарган теге кызны марҗа хатыны. Тишек чабатасын күтәреп кергәч кенә көлә-көлә шөшле биреп чыгарган. Шөшлене урыслар кочедык дип йөртә икән...

Сталин үлгән көнне без эштә идек. Юл көпшәкләнгән, урман чыгарып булмый, салга агызыр өчен агач каезлыйбыз. Биш минут яланбаш тоттылар. Киноларда күрсәткәнчә, үз-үзләрен белештерми илереп елаучылар булмады. Әтинең энесен тулай торакта урын-җирләрен тапшырмый авылга кайтып киткәне өчен төрмәгә утыртканнар иде, шунда үлеп калды. Абый турында уйлап эчтән еладым шул чагында.

Нинди генә кошлар сайрамый иде ул урманда! Язгы көннәрдә генә түгел, кыш буе сайрадылар алар, кыш буе безнең монсу күнелләрне юаттылар, гөлкәйләрем. Песнәкләр, кызылтүшләр, чыпчыклар. Ниндидер бер кош хәтта февраль аенда бала чыгара икән. Чатнама суыкта ялангач кош балалары ничек түзә икән, менә хикмәт.

Ниһаять, беренче пароход төште, безгә дә кайтыр вакыт житте. Бәрәнге районыннан бер мари кызының вечерда:

Скоро-скоро мы домой,
Скоро мы, как кошки.
До свидания, леспромхоз,
Соломенные подушки!—

дип такмак әйткәне хәтердә. Перьмнән Бөгелмәгә кадәр 15 көн сыер вагонында кайттык. Бөгелмәдән Минзәләгә—кайда тәпиләп, кайда машинада, кайда атта 3-4 көн кайттык. Күзкәйгә житкәч, чемоданнарны калдырып җәяү йөгердек. Шулай да ул авыр елларны хәзер сагынып искә алам. Яшь чаклар, матур чаклар иде бит.

Сугыштан исән-сау кайтканнар өстенлекләр, ташламалардан файдаланды, балаларына фатирлар, машиналар да алып бирделәр заманында. Тик менә фронт өчен, җину өчен хәләл көчен, бөтен саулыгын җуйган хатын-кызларга ничек, кем кайтарыр икән иләмсез бурычны? Агач асларында калып үлүчеләрнең гаиләләренә ник булмады икән ул ташламалар? Ник язылмый икән аларның исемнәре Хәтер китапларына? Кайда соң гаделлек?

... Кайчакны мин, шул документларга карап утырганда, урманнарда агачларның сыкрап шыңгырдаган тавышларын ишеткәндәй булам. Әллә шушы ил язмышы сыналганда агач асларында газиз җаны чыккан кызларның ачыргаланып кычкырган бәхилләшү авазы микән бу сыкрау? Рәнҗеп китсәгез, кичерегез, кызлар! Кичерегез. Сезгә бары «бәгъре өзек» милләтебезнең юксынуы вә йөрәк җылысы итеп мәрхүм әдибебез—Дәрдмәнднең шигырен һәйкәл итеп куясым килә:

Гөрләгән сулар башында,
Тынлагыз, шунда үтәр—
Йөрсә сыкрап тан-сәхәрләр
Мон-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнжемим, зинһар күтәр!
Рәнжемим, зинһар күтәр!

**Тәэминә БИКТИМЕРОВА,**
*тарих фәннәре кандидаты.*

*Дин һәм тормыш*



Мирза Мәхмүтов

# КОРЪӘН СҮЗЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

*«Күктә Аллаһ, җирдә Иблис, мин—малай!*
*Берсе: «Дин»—дип, берсе: «Мин!»—дип тарткалай...»*

*1917 елгы революциянең салкын җилләрендә халыкның «Кемгә ышанырга?», «Кемгә иман китерергә?» дип зиһене таркала башлаган, иман нигезләре ишелеп төшәргә торган заманда Шәехзадә Бабичның бу сүзләре илебездәге рухи афәтне бүгенге чор күзгесендә күрсәтә шикелле. «Кемгә ышанырга?» соравы бүген дә һәр гаиләдә яңгырый.*

*Коръән—мөселманнарның, шул исәптән татарларның да күңеленә изге Сүз булып сеңгән һәм аларның рухи дөньясын тутырган китап. Укыгач, пакъ сөлгегә төреп, киштәгә куеп сакланган язмаларның иң кадерлесе. Элек-электән Коръәнне гарәпчә укый белә торган кешегә астан өскә карый торган булганнар... Моңарчы татар әдәби телендә Коръән булмаган, халык сүрә-аятьләрне гарәпчә яттан бикләп намазларда укыган.Дини белем чыганагы булып ана телендә бер Ногмани хәзрәт Коръән-тәфсире хезмәт иткән. Аерым сүрәләр, аерым аятьләр, хәдисләр, вәгазьләр, аңлатмалар мәдрәсәләрдә дә, гаиләдә дә кулланылган. Әлбәттә, соңгы 10-15 ел эчендә татарча да, урысча да ислам турында бик күп уку әсбаплары китап киштәләрендә урын алды. Сиксән милләт телендә укыла торган Коръән тик татар телендә генә юк иде. Ниһаять, 2000 елның башында татар телендә бер юлы ике Коръән басылып чыкты.*

*Әйе, бүген ана телебездә басылып чыккан Коръән-Кәрим китабы кулыбызда. Аның турында бик кыска гына мәгълүмат биреп, тәрҗемәсе тирәсендә фикер йөртәсе килә. Коръәннең беренче нөсхәсен атаклы язучыбыз* ***Рабит*** *әфәнде* ***Батулла*** *тәрҗемә иткән, икенчесен—****Фәрит*** *хәзрәт* ***Сәлман.*** *Яңа басмалар шатландыра: тәрҗемәнең икесендә дә текст бер үк биттә гарәпчә һәм татарча янәшә бирелгән. Татар дөньясы өчен яңалыкмы бу? Әйе, яңалык!*

## Коръәннең татар мәдәнияте өчен әһәмияте нәрсәдә?

Кеше күнелен үзенә җәлеп итәр өчен, аның аңына нинди генә белем салмаганнар. Бер-берсенә хилаф дини мәсләк бар, бар фәнни идеология, аларны сугыштырудан кешеләр рухиян зыян гына күрә. Кеше фәнгә таянамы, дингә таянамы—барыбер; аның **иманы** (ул ышану, инану дигәнне

анлата)—рухи таянычы, өмет баганасы, мәсләге булып тора. Халыкның бер өлеше фәнне түгел, динне иман итеп кабул иткән икән, бик мәгъкуль («... ләком динуком, вә лийә дин...» (109:6)[1]—«сезгә үз динегез, миңа үземнеке»). Ирекле илдә адәм баласы йә бусын, йә тегесен сайлап ала икән, моның бер дә зыяны юк, тик кеше имансыз гына калмасын. Ирекнең, хөрриятнең мәгънәсе дә сайлап алырга мөмкинлек булуда. Һәрхәлдә, зыялылар, кешенең психологиясен аңлап, халык белән бергә булырга, аның акылын, фикерләү сәләтен үстерергә, рухи дөньясын киңәйтергә тиеш түгелме соң? Тиеш, әлбәттә. Мондый вазифа галимнәргә, зыялыларга гына түгел, имамнарга да йөкләтелгән.

Коръән—гарәпчә язылган Аллаһ сүзе, һәр мөэмингә турыдан-туры Аның мөрәҗәгате диелә. Ләкин ул Сүзне теләсә кайсы татар ишетми, чөнки тел белми, имамнар гына арадашлык кылып, ул Сүзне кешеләргә житкерергә тырышалар. Әмма аларның фәнни дә, дини дә әзерлеге хәзерге татар кешесенең интеллектуаль дәрәҗәсенә муафикъмы?. Мәдрәсә шәкертләре белән бергә җәмәгатьчелек тә бер ише имамнарның ан-белем дәрәҗәсе белән канәгать түгел, дип матбугатта еш яза башладылар. Галимнәр фәнни белем бирергә тырышалар, имамнарның бер ишесе, ана телен ватып-сындырып булса да, дини белем тарата. Нәтижәдә, халыкка тәгълим-тәрбия ике юлдан бара шикелле. Соңгы йөз ел эчендә киң мәгърифәт, фәнни белем алган халкыбыз кемнең сүзенә ныграк колак салыр икән? Бергәлек юк. Тотрыклы иман да юк.

Бу проблеманы хәл итүдә телнең әһәмияте гаять зур: тел аралашу коралы гына түгел, ул—фикерләү коралы да, кешенең хис-тойгысын белдерү ысулы да, аларны берләштерү шарты да. Фәнни уй—белемне кешеләргә дөрес аңлаткан шикелле, дини белемне дә шулай ук дөрес аңлатырга тиешбез. Халыкның тел культурасын, фикерләү культурасын үстерү өчен, шик юк—мөгаллимнәр һәм имамнарның ана теле остасы, нотык-вәгазь остасы, мантыйк-логика остасы булу төп шартларның берсе. Алай гына да түгел, укымышлы, киң карашлы, тирән белемле, глобаль фикер йөртә белүче галимнең чын зыялы булуы зарури! Төрле телләргә Изге китапларны тәрҗемә итүчеләрнең күбесе нәкъ шундый зыялылар, югары культура ияләре.

Мәгълүм тәртиптә тәсбих төймәләре тезелеп киткән шикелле, телдә дә аерым сүзләр логика кагыйдәләренә буйсынып килгән хәлдә генә чынбарлыкны ачык һәм дөрес чагылдыралар, теге яки бу фикернең эчтәлеген кеше аңына дөрес житкерәләр. Бусы чит телдән ана теленә тәрҗемәгә күбрәк карый, чөнки төрле телләр бердәм логика кануннарына буйсыну белән бергә, һәрберсе үз грамматикасына да буйсындырылган. Чит телдә булган фикерне ана телен бозып, аны чит тел грамматикасына буйсындырып тәрҗемә иткән чакта тел тәртибе генә түгел, шул телдә фикерләү тәртибенең дә бозылуы мөмкин. Бу инде хакыйкатьне дөрес күрсәтмәү дигән сүз.

Коръән аятьләрен тәрҗемә итүгә дә шул ук сүзләрне әйтеп була. Яна басмалар хәзерге татар әдәби телендә язылган, димәк, ана телендә укый белә торган һәр кеше Коръәннең эчтәлегенә керә, аның тирән мәгънәсенә төшенә ала дигән сүз. Димәк, тәрҗемәчеләрнең эше мактауга лаек һәм халык аларны үзенең рәхмәтеннән мәһрүм итмәс, дип ышанам.

## Коръәннең эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт?

Бик кыска итеп әйткәндә, Коръән күпходалыкка, мәжүсилеккә, потсанәмнәргә табынучыларга каршы көрәш коралы ул. Аның ижтимагыйикътисади, сәяси һәм рухи нигезләре бар. Димәк, «Алла бер» дигән идея белән «күпходалык» идеясе бер-берсенә хилаф, алар туры килмиләр, алар арасында булган идеологик көрәш, ягъни ике мәсләк (мировоззрение, идеология) каршылыкларын бетерү һәм адәм баласына чын **хакыйкатьне ачу**—Коръәннең

---

[1]Сүрә һәм аятьләрнең тәртип саны (2:20 - әйтик, икенче сүрә, егерменче аять, 6:8 - алтынчы сүрә, сигезенче аять).

төп вазифасы булып чыга. Коръән-Кәрим—изге китапларның иң соңгысы[1].

Коръәннең асылында тирән фикер ята: яһүдиләр, мәсихиләр (христианнар) һәм мөселманнар өчен **Ходай**, **Тәңре** бер, аның исеме—**Аллаһ**. Мусага ул Тәүрат китабын иңдергән, Даудка—Зәбурны, Гайсәгә—Инҗилне, Мөхәммәд пәйгамбәргә (салла Аллаһу галәйһи вә сәлләм)—Коръәнне. Мөхәммәд—актык пәйгамбәр.

Китаптан китапка Алла үзенең берлеге турында кабат-кабат әйтеп килгән («тәүхид»). Кешеләргә үз фикерләрен Хак Сүз белән җиткерер өчен ул халыкларга пәйгамбәрләр (рәсүл, нәби) җибәргән. Ләкин кешеләр рәсүлләргә (Адәм, Нух, Мусаларга) ышанмаганнар һәм элеккечә кыргыйлыкта яши биргәннәр—иске заманнарда кан катнаштыру йоласы киң таралган була, күтләклек (гомосексуализм), нәҗеслек чәчәк аткан, кешене корбан итеп чалганнар, кеше үтерү,аллашу, урлашу гадәти хәл булган, сугышып кан коеп яшәгәннәр. Коръән боларны харам (ярамас) кылган, тыйган (6:137; 7:84), ул кешеләргә гаделлектә, инсафлыкта яшәү өчен хокук нигезләре, кагыйдәләр системасы (шәригать) биргән.

Изге китап—әдәп-әхлак кагыйдәләре бирә, гаиләдә, сүздә, сугышта, үч алуда һ. б. эшләрдә ризалык (консенсус), үзара килешү булырга тиешлегенә басым ясый (4:128, 135), намуслы сәүдә турында бик күп төгәл киңәш-нәсихәтләр бирә (2:282), күңел сафлыгы, инсафлык, гаделлек турында сөйли (5:8). Исламга чаклы, җаһилият дәверендә, хатыннарны күп итеп алу, аларны рәнҗетү, малларын талау һ. б. хөкем сөргән. Коръән хатын алуны дүрт белән чикләгән, хатын аерып җибәрүне катлауландырган; ятимнәрнең хакын ашаучыларга карата тәртип керткән, бу гадәт тыелган (5:90). Коръәннең асылында шулар ята.

Аллаһның сүзен Мөхәммәд пәйгамбәр (салла Аллаһу галәйһи вә сәлләм) гарәп халкына җиткерә. Ул кабиләдәшләрен, Мәккә гарәпләре булган көрәешләр кабиләсен мәҗүсилектән ваз кичәргә, баш тартырга чакыра, 300ләп пот-санәмнәрне ташлап, Алланың берлегенә ышанырга, итагатьле булырга өнди. Чөнки хакыйкать—яна **дин—исламда**. Ул диннең үз тәгълиматы һәм кешенең тормыш рәвешен үзгәртерлек үз кагыйдәләре бар. Яшәү рәвешенең асылында гаделлек, мәрхәмәтлек, шәфкатьлелек, инсафлык, юмартлык, сафлык, риясызлык ята, дип тәсдикълана.

Мөселман булыр өчен Аллаһның хак сүзенә инанырга, ана табынырга, итагать кылырга, ахирәт барлыгына ышанырга һәм тиешле фарызларын үтәргә, башкарырга кирәк. Коръәндә әйтелгәннәргә ышанмаган кешеләрне пәйгамбәр табигый афәтләр һәм хәтәр тәмугъ уты белән кисәтә, Алланың каргышы белән, төрле җәза белән куркыта да белә.

Кыямәт көнендә һәр кеше тереләчәк һәм Алланың хозурына, хөкеменә киләчәк, кемнең күпме **савап**, күпме **гөнаһ** кылганы шунда хисапланачак, үлчәнәчәк. Тәмугъның төрле катламы, төрле рәвешле җәзасы барлыгын аңлата, шуның белән куркыта. Мәсәлән, Нух пәйгамбәрнең язмышы турында сөйли, аның пәйгамбәрлеген танымаган кабиләсе туфанда һәлакәткә дучар була (11:89; 32:23). Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә ышанмаган кеше-халык Аллаһның ачы каргышына, табигать афәтенә дучар булачак, ди. Җаһилияттән чыга башлаган халык боларның барысына да ихластан ышанган, әлбәттә.

Бүгенге кеше өчен Коръәннең файдасы нәрсәдә соң? Изге китап кешене бүгенге язмышы турында уйланырга мәҗбүр итә. Тагын басым ясап әйтик, Коръән элек булган кыргыйлыкка каршы чыга: мирас бүлү тирәсендә канлы көрәшне бетерә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала, кагыйдәләр кертә, ришвәт бирү-алуны, риба (процент)ны, аракы эчүне харам кыла. Бүгенгечә әйткәндә, Коръән **гуманизм** идеяләрен тарата (2:123-185), мин-минлеккә, мөнафикълыкка *(икейөзлелеккә)* каршы чыга (2:206). Уйлап карыйк әле, элек булган кыргыйлык бүген дә илебездә хөкем сөрә түгелме соң? Вәхшилек, мөнафикълык, көпә-көндез картларны талау, сабыйларны көчләү, мал бүлешеп кеше үтерү—бүгенге халәт түгелмени?

Коръәндәге гуманизм идеяләре кешеләрнең аңына ничек җиткерелә соң? Куркыту белән беррәттән, пәйгамбәр Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә

[1]Инглизчәгә тәрҗемәсендә Ришад Халифә (USA, 1992) аны «The Final Testament», дип атый, ягъни, Коръән—«соңгы васыять» («Последний завет», т.е. после Ветхого завета—иудейского, Нового—христианского завета).

төрле-төрле бүләкләр, нигъмәтләр, рәхәт, бәхетле тормыш вәгъдә итә. Пәйгамбәр сүзен тынлаучыларга, Аллаһның берлегеН танучы кешеләргә, Аллаһы Тәгаләгә иман китерүчеләргә, аның кодрәтенә ышанучыларга бүләк булыр, ул бүләкләрнең беренчесе һәм иң зурысы Аллаһның нигъмәтедер, ягъни җәннәттер. Мона ирешү өчен һәр кеше туры юлдан барырга, Аллаһның берлеген таныpга, игелек кылырга тиеш. «Игелек кылуда ярышыгыз» диелә 2 сүрәнең 147 аятендә. Димәк, үтерү дә, кире терелтү дә—барысы да кешене куркытып та, өметләндереп тә бу дөньяда игелекләр кылуга чакыру, шуңа мәҗбүр итү, мотивация бирү (32:12). Ахыр чиктә—куркытулар, янаулар, өндәүләрнең дә максаты бер—алар инсаниятка, гуманизмга,кешелекле булырга чакыра.

## Коръәннең кешелек дөньясы өчен әһәмияте

Коръән мөселманнар өчен генә, дин әһелләре өчен генә түгел, ул дин, фәлсәфә, тарих белән кызыксынучы барлык кешеләр өчен дә кирәкле китап. «Коръәннең әһәмияте нәрсәдә? Коръән нигә кирәк?»—дигән сорауларга кыска гына бер җавап бар: ул кешеләрне һәлакәттән кисәтә (17:9). Планетабызга атом-төш һәм экология катастрофалары яный, адәм баласы үлем коралларын камилләштереп дөньяны һәлакәткә алып бара... Бу хәлдән котылу юлы бар микән?

Шуңа охшашлы сорауларга борынгылар да җавап эзләгән икән. Коръән кешеләрне тел һәм милләте ягыннан аермый, аларның барысын да бертигез мөселманнар итеп карый. Шул нигездә Коръән төрле телдә сөйләшүче халыкларны берләштерә, халыкара тынычлыкны сакларга, милләтара ыгы-зыгыны бетерергә өнди һәм шуңа ирешер өчен **туры юл** күрсәтә.

Җыеп әйткәндә, Изге Китапның әһәмияте чиксез зур. Ул—кешелек дөньясының узганы, фикер йөртүе, дөньяга карашы, мәсләкләрнең үзгәреп кору тарихы. Коръәннең әһәмияте—һәр кешенең, кабиләнең, халыкларның тормышын мәгълүм идея нигезендә тәртипкә салуда. Ул—белем чыганагы, хак, хокук, шәригать нигезе. Кеше үзенең хис-тойгыларын аңлап гамәл кылырга тиеш, ди. Ягъни, Коръәндәге әдәп-тәртип, әхлакый нормалар, борынгы халыкка бирелгән киңәш-нәсихәтләр, кагыйдәләр хәзер дә зарур, чөнки бүген дә кеше кешене рәнҗетү, мыскыллау, җәзалау, күпләп үтерү һ. б. шуның кебек хәтәр җинаятьләр бер дә бетми, арта гына бара. Коръән хайвани гадәтләрдән ваз кичү, нәҗеслектән чыгу, хатын-кызның хокукларын яклау, ятимнәрнең хакын саклау, кешеләрнең яшәү рәвешен гаделлеккә, инсафлыкка корып үзгәртү юлын күрсәтә.

Коръән—дөнья әдәбиятының борынгы үрнәге, шул ук вакытта ул фәлсәфә китабы да. Монда кешелек дөньясының язмышы, Җир йөзендә кешенең тоткан урыны турында фикер йөртүләр, Кешегә, аның яшәү рәвешенә, фигыль-гамәленә карап бәя бирүләр зур урын алып тора (2:282). Шуңа күрә Коръәнгә дин күзлегеннән генә карау җитми, аңа фән күзлегеннән дә карарга кирәк.

## Коръән һәм милли идеология

Бу сорауга алда җавап бирә башлаган идем, дәвам итәсе бар. А. Пушкин Коръәнне укып чыккач: «... да притечем и мы ко свету, И да сойдет с очей туман»,—дип язган. Күзебезне ачып карыйк әле, яктылыкка чыгыйк, дигән, ягъни даһи шагыйрь Коръәнне белем, хакыйкать чыганагы итеп кабул иткән, андагы хикмәтләрне үзләштерергә чакырган.

Диннең идеология, мәсләк икәнен беркем дә инкарь итә алмый. Рухи дөньябыз нәрсәгә корылган? Белемгә, иманга. Тик шунсы бар—кемгә иман китерергә соң? Элек Аллаһы Тәгаләгә һәм патшага иман китергәннәр. Аннары сыйнфый көрәш мәсләгенә, коммунистлар идеясенә. Гасыр ахырында янадан дингә йөз тоттык, урыслар православиегә, татарлар—исламга. «Артыңа кара да шөкер кыл, алдыңа кара да фикер кыл». Тирән тарихлы мәдәниятебез нәрсәгә

корылган иде? Элек-электән үк—халык иҗатына һәм исламга, аның тәгълиматына, фәлсәфи хикмәт—фикерләренә.

Бүген галимнәр физика, химия динне инкарь итми, дип тә әйтәләр. Рухи бушлыкта калган чорда фәнни белемгә дини белем өстәлсә, кемгә зыян китерер икән? Әлбәттә, элекке идеяләр сөременнән чыкмаган кешенең башында бүген бу хәл төрле сораулар тудыра. Мәсәлән, рухиятнең әчтәлеге—дин, иман гынамы, әллә рухият динсез дә була аламы? Кешенең рухын баеткан, ана илһам биргән, рухи дөньясын барлыкка китергән илаһи сүз белән янәшә әдәби сүз, моң да бар ич. Музыка, рәсем, образ, сурәтләр, гомумән, сәнгать исламның әхлакый тәгълиматы белән ничек тоташалар, кебек сорауларга да галимнәр күптән җавап эзлиләр, философлар арасында да бәхәсләр сүнеп тормый. Эзләнү тукталмаска тиеш...

Үткән гасырда ике бөтендөнья сугышы булуы кешенең кыргыйлыктан әле һаман чыга алалмаганын дәлилли түгелме соң? Кешенең рухи пакълеге, гаделлеге, инсафлыгы, шәфкатьлелеге турында фикерләр сүрәдән сүрәгә күчә. Мәсәлән, (5:8,90) аятьләрендә Коръән элекке кыргый гадәтләрнең күбесен харам кылган мал-мөлкәтне, мирасны гаделлек белән бүлү тәртибен керткән; ятимнәрне рәнҗеткәннәр икән, Коръән аларның үзләрен дә, хакларын да яклаган. Мәсәлән, (6:137) кешене корбан итү тыелган һ.б.ш. Без барыбыз да шуларны сабый чактан ук белергә тиеш түгелме соң?

## Әдәп—әхлак турында

Адәм баласының үзен ничек тотуы Аллаһы Тәгалә теләгәнчә була аламы икән? Коръән бу хакта нәрсә ди соң? Кеше иң элек бик мәрхәмәтле булырга тиеш, башка кешеләрнең, бигрәк тә ятимнәрнең өлешенә кермәскә, киресенчә, аларга булышырга, ярдәм кулы сузарга тиеш, ди. Шул чакта гына кеше чын мөэмин мөселман була ала. Адәм баласы комсыз, зәһәр булмасын иде, диелгән Коръәндә; ул башка кешеләргә йомшак күңелле булырга, аларны рәнҗетмәскә, күрешкәндә ачык чырай күрсәтергә тиеш. Һәр кеше олыларга ихтирам белдерергә, ата-анасын хөрмәт итәргә, үзенең намусын сакларга, харам эштән сакланырга, оялырга, хурланырга тиеш, ярамаган эш эшләргә тиеш түгел, харам гамәл кылмаска, тыелган нәрсәләрне башкарудан баш тартырга тиеш һ. б. ш. Менә шушы фикерләр Коръәннең беренче битеннән башлап азагына хәтле дәвам итә. Болар барысы да аять артыннан аять, сүрә артыннан сүрәләрнең мәгънәсен ача торган Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле, күңелләргә кереп урнашырлык тәэсирле Сүзе белән аңлатыла.

«Коръән вәгазь һәм нәсыйхәтләрдән тора...» (80:11) диелгән; ләкин башка диннәрдән аермалы буларак, Коръән үгет-нәсыйхәт, куркыту белән генә чикләнми—тәртип бозган өчен җәзасын ахирәттә, теге дөньяда гына түгел, бу дөньяда, көндәлек тормышта ба бирә. Мәсәлән, зина кылган өчен 100 таяк суктыралар (24:2), нахак сүз, гайбәт тарату, нахакка гаепләү өчен—җәза бирелә (24:29,33). Үгет-нәсыйхәт бирә һәм Кыямәт көне турында кисәтә (80:11). Коръән һәм исламның көчле ягы—иҗтимагый, социаль проблемаларны хәл итү юлларын күрсәтү, беренче нәүбәттә—ярлыларны, юксылларны яклау. Ислам гарәп булмаган башка халыкларны да шул ягы белән үзенә җәлеп иткән һәм хәзер дә җәлеп итә (башка диннән исламга күчү тенденциясенең күп илләрдә көчәя баруы шуны күрсәтә).

## Коръәнне ничек өйрәнгәннәр?

Халыкларның бер өлеше Коръәнне исламга керер, иманлы булыр өчен өйрәнгәннәр, икенчеләре—исламга каршы торыр өчен. Европалылар Коръәнне урта гасырларда ук укый башлаган. Христиан дин әһелләре аны «ересь» диләр, буш бер уйдырма дип, ничек кенә хурламыйлар; галимнәр исә бу мәсләк нигезле, дип уйланалар. XII гасырдан башлап, Изге китап башта латин теленә, аннары хәзерге француз, алман, инглиз телләренә тәрҗемә ителә һәм 1716 елны урыс теленә дә килеп керә (француз теленнән тәрҗемә ителгән). XIX йөздә,

мәсәлән, Саблуков, христиан дине хасиятеннән чыгып, XX гасырда Крачковский— фәнни максат белән Коръәнне урыс теленә гарәпчәдән тәрҗемә иткәннәр.

Татарлар Коръәнне элек ничек өйрәнгәннәр? Нинди китаплар укып дин турында белем алганнар? Мәдрәсәләрдә Изге китапны, «иман шарты», «һәфтияк» шикелле уку китапларын һәр көнне укып ятлый торган булганнар. Өйдә дә Коръән укылган, мәчеттә—мулла сүзе алдан йөргән. Биш вакыт намаз кылганда вак сүрәләр яки озын сүрәләрнең аятьләре бик күп мәртәбә кабатланып ятланган. Коръәнне гарәп телендә ятлаганнар. Гасырлар буе күнелдән бикләү, ятлау ысулы булган. Коръән сүзен халыкның зиһененә сендергән. Әле хәзер дә гарәпләрдә, әйтик, 6-8 яшьлек сабыйларның бер ишесе 500 битлек китапны яттан белә.

Совет чоры, аның сәясәте, совет мәгариф системасы исә халыкны диннән читләштерде, яшьләрне дәһри (атеист) итте. Хәзер бу дәһриләргә иман кирәк, дибез, чөнки ул физика, химия белеме белән генә күнелгә керми икән. Бүген бик аз санлы мәдрәсә шәкертләре генә Коръән сүрәләренең мәгънәсен анларга өйрәнәләр. Ләкин авыр да инде бу гарәп теле! Алар өчен дә ана телендә басылган Коръән кирәк!

Гаҗәп хәл! Изге дип саналган, Кешенең бөтен күңел-тойгыларын сыйдырган Коръәнне татарлар урыс телендә укыйлар, өйрәнәләр, шул нигездә дин турында фикер йөртәләр иде. Ник дисәгез, беренчедән, татар телендә Коръән юк иде; икенчедән, татарларның күбесе ана телен белми, бернинди китап-фәлән укымый! Ә инде латин хәрефенә күчкәч, татарча укучылар саны, һичшиксез, тагын да кимиячәк, әлбәттә.

## Коръән теленең үзенчәлекләре турында

Коръәнне татарчага тәрҗемә итү бик кыен икәнен анлар өчен аның теле турында бераз әйтәсе бар. XX гасыр башында урыс крестьяннарының күбесе сөйләм телендә 800 сүз белән чикләнгәннәр, диелә. Укымаган татарлар да шул ук чамада булганнардыр. Фәнни белемгә ия булу, кешенең сүз байлыгын арттыра, тел культурасын, фикерләү культурасы үстерә.

Хәзерге укымышлы урыс кешесе сөйләгәндә кимендә 4-5 мең сүз куллана (актив сүзлек). Укымышлы татар да шулай уктыр, дип уйлыйм, гәрчә әдәбиятта булган 35—40 мең сүз күпләргә таныш булса да (пассив сүзлек). Борынгы төрки-татар телендә сүз күп булмаган, әлбәттә. Унөч-ундүрт йөз ел элек булган рун язмаларын бүгенге татар укый алмый, чөнки тел үзгәргән, сүзләрнең мәгънәләре бүтән. Мәсәлән:

... Иллек будун эртем,—
Илем амти каны?..
Каганлык будун эртем,—
Каганым каны?

Тәрҗемәсез анлашыламы? Юк, әлбәттә:

... Дәүләтле халык идем,—
Илем инде кайда?
Патшалы халык идем,—
Каганым кайда?

Әле XX гасыр башында гарәп-фарсы һәм төрек сүзләре тулган татар язма телен гади халык ачык анлый алмаган. Тукайлардан башланып китеп, йөз ел эчендә телебез үзгәрә—сүзлеге арта, грамматикасы камилләшә. Башка халыкларның теле 200—300 ел эчендә төрле шивәләрдән бүгенге милли әдәби телгә әверелә[1]

[1]XYI гасырда Мартин Лютер—Рим католиклар чиркәвенә каршы чыгып дингә реформа ясый: Инҗилне (Библияне) латин теленнән немец теленә тәрҗемә иттерә. Еллар үтү белән шул тел халык арасында тарала. Немецләр төрле шивәләрдә генә түгел, бердәм әдәби телдә дә сөйләшергә гадәтләнәләр. Шулай итеп, хәзерге немец әдәби теле барлыкка килә һәм саклана, дип санала.

Нәкъ шундый ук рәвештә гарәп әдәби теле дә барлыкка килә, тик бу хәл күп гасырлар элегрәк һәм көчлерәк дәрәҗәдә була; Коръән сүзләрен бозып әйтергә ярамый, үзгәртү гөнаһ санала, гарәпләр Коръәнне гасырлар буена көн саен укып яшиләр. Шул рәвешчә гарәп телендә гаять бай сүзлек сакланып, үсеп килә. Кайбер төшенчәләргә бер түгел, уннарча, хәтта йөзләрчә сүз табыла, ягъни синонимнар ишәя. Мисал өчен, «дөя» («тәвә») төшенчәсен белдерер өчен гарәп телендә 400 сүз бар диләр, арслан төшенчәсен 200 ләп сүз аңлата. Аллаһы Тәгаләнең дә 99 исеме бар. Гарәп теле синонимнарга бик бай тел, шуна күрә бу телдә тирән фәлсәфи фикерләр дә, гыйльми төшенчәләр дә ансат аңлатыла, рифмалар тиз табылып, шигъри юллар да бик табигый рәткә салына.

Гарәп теленең озын тарихы бар: гарәпләрнең шивәләре милли әдәби телгә әверелүе 1400 ел элек башланган, дип әйтеп була, чөнки Коръән теле халык арасында тарала башлау белән, гарәпләрнең мәдәнияты үсә башлау белән бердәм телгә әверелә.

Хәзерге гарәп әдәби теле белән Коръән теленең аермасы юк түгел, азмыкүпме бар, әлбәттә. Бу ни дигән сүз? Бу—гарәп кешесе Коръән телен укып (ишетеп) яхшы ук аңламыйлар дигән сүз. Ләкин башка телгә тәрҗемә итүче, кагыйдә буларак, әдәби телне дә, Коръән телен дә укымышлы гарәп кешесе кебек үк белә алмый, әлбәттә. Шуңа күрә тәрҗемә итүнең кыенлыклары күп була.

Коръән теленең үзенчәлекләре бар, дидек, алар нәрсәдән гыйбарәт? Беренчедән, ул борынгы тел. Шулай булгач, хәзерге гарәп әдәби телен өйрәнеп алган кеше әлеге үзгәрешләргә сөртенә. Бусы—сүзләрнең мәгънәви үзгәрешләре дә, грамматиканың үзенчәлекләре дә. Икенчедән, Коръән—Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән бербөтен язуга тупланган Аллаһ сүзе, диелә, уй-фикерләр, кагыйдәкүрсәтмәләр китабы. Инҗил (Библия) төрле чорда төрле кеше тарафыннан язылган 74 кечкенә-кечкенә китаплар мәҗмугасы.

Бүген миллиардтан артык мөселманнарның күңелен яулаган, аларның рухи таянычы булган, тәрҗемәчеләрне кыен хәлдә калдырган Коръән теленең тагын берничә үзенчәлеге турында әйтми булмый.

**Сүз көче**. Кешене берәр нәрсәгә ышандыру, берәр фикер-идеягә инандыру өчен төрле аһән, тавыш, интонация белән һавада яңгырап, йөрәктән-йөрәккә күчкән Сүздән дә көчле корал юк, диләр. Коръәндәге һәр сүзнең мәгънәсе шул сүрәдәге темага, аятьтәге фикергә бәйләнгән. Борынгы чүл гарәпләренең акылына сыймаслык вазгыятьләрне тасвирлаган сүзләрнең мәгънәләре тирән, җитмәсә алар кабат-кабат аңлатыла һәм шул рәвешчә кешенең күңеленә кереп утыра. Коръәндәге Сүзнең куәтенә хәйран калып, даһи шагыйрь А. С. Пушкин болай дигән: «... Не я ль язык твой одарил могучей властью над умами?»

Мөхәммәд пәйгамбәр Алланың сүзләрен еш кабатлый һәм һәрберсенең мәгънәсен тарихи мисаллар китереп ача. Мәсәлән, Нух пәйгамбәрнең халкы ник туфанда һәлак булган? дип риторик сорау бирә дә үзе үк аны болай дип аңлата: чөнки кешеләр Нухның пәйгамбәрлегенә ышанмаганнар, ул китергән хакыйкатьне кабул итмәгәннәр. Муса пәйгамбәрнең халкын фиргавен нигә эзәрлекли? Чөнки фиргавен Ходайның берлеген аңлый алмаган һ. б. ш.

**Сүз байлыгы.** Коръән теленең беренче үзенчәлеге шунда ки, андагы лексика синонимнарга бай дигән идек; теләсә нинди мәгънәне яки мәгънә төсмерен чагылдыра торган Алла, дин, фикер, җан, рух, нигъмәт, гаделлек һ. б. шуның шикелле кешенең **фикерләү сәләтен** югары күтәрә торган **абстракт** төшенчәләр һәм терминнар күп. Бусы да гарәп теленең көчен, инандыру мөмкинлеген күрсәтә.

Икенчедән, китапларның тексты язма телдә, ягъни грамматик кагыйдәләргә буйсындырылган телдә була. Ул шигъри яки прозада (чәчмә) аңлатыла. Коръән ниндирәк телдә язылган соң?

**Сөйләм теле.** Коръән теле әдәби язма тел түгел, ә бәлки Мәккә мәҗүсиләренең көраеш халкына җиткерергә тырышкан Алла сүзе, вәгазь сүзләре; ягъни Коръән тексты—Мөхәммәд пәйгамбәрнең вәгазьләрен язып алган сөйләм теле. Алай гына да түгел, Инҗил теленнән аермалы буларак, Коръән телендә сюжетлар бер буйдан, бер-беренә бәйләнеп түгел, өзек-өзек тезелә, факт һәм вакыйгалар бер-берсенә бәйләнмичә, эзлексез рәвештә бирелә, хәтта вакытвакыт мәгънә берлеге дә югалып кала. Сөйләм теле—грамматик кагыйдәләргә

буйсынып бетми торган халыкның җанлы теле ул[1].

Сөйләм теленең үзенчәлеге сүз өзеп әйтүләр, сюжеттан читләшүләрдә, синтаксис нормаларын бозып сөйләүләрдә чагыла. Җөмләдә логик басым ясау, төрле-төрле интонация белән әйтү дә сөйләм телендә үзенчәлекле була. Өченчедән, Коръән текстлары күбесенчә диалог, сорау-җавап формасында бирелә. Дүртенчедән, текстта бик күп тарихи аналогияләр очрый, чөнки Мөхәммәд теге яки бу тезисны тыңлаучыларын ышандырырлык итеп әйтер өчен, аларга мәгълүм булган фактларны күрсәтә, дәлил итеп тарихи аналогияләр китерә, төрле вакыйгаларны тасвирлый, аларга аңлатма бирә, аларны чагыштырып күрсәтә.

Шуңа күрә Коръән теленә ассоциатив фикерләү хас: сүз теге яки бу җирле вакыйгага, шул халыкта гына булган яшәү рәвешенә, гореф-гадәтенә бәйле булган төшенчәне белдерә; мәсәлән, безгә мәгълүм булмаган кабиләләр, шәһәрләр, елгалар, таулар исемнәре, дөяләр, ком сәхрәсе күренешләре турында булган подтекстлар бар. Бер яки берничә аятьтәге фикер вакыт-вакыт әйтелер-әйтелмәс шикелле беленер-беленмәс формада бирелә. Тәрҗемәче подтекстны укучыга аңлаешлы итәр өчен, андый җөмләләрнең «серен» ачарга өйрәнмичә булдыра алмас. Моның өчен төшенчәне логик яктан үстерү, төзәтү зарур, ягъни интерпретация ысулын кулланырга кирәктер.

Бишенчедән, берничә җирдә җәннәт һәм җәһәннәмнең сыйфаты сурәтләнә (Данте шул сурәтләрне «Божественная комедия»сендә күрсәтә, диләр). Алтынчыдан, кешенең хакын яклап **хокук** нормалары бирелә, шәригать нигезләре аңлатыла (мирас бүлү кагыйдәләре, хатын-кыз һәм ятимнәр хакын яклау һ. б.). Җиденчедән, харам булган эш-гамәл, азык-төлек, эчемлекләр турында язулар белән рәттән мөселман кешесенең яшәү рәвеше аңлатыла. Боларның һәммәсе дә кешенең зиһененә сеңдереп аңлатырлык сүз һәм терминнар белән бирелә һәм болар барысы бергә Коръән теленең үзенчәлекләрен тәшкил итә.

Коръән—пәйгамбәрнең күз алдында тыңлап торучы конкрет кешеләргә мөрәҗәгать сүзе. Алар, әлбәттә, Мөхәммәд белән элек очрашканда сөйләнгән вакыйгалар, персонажларны, сөйләгән сүзләрне азмы-күпме хәтерләп белеп торучылар, алар «ярым сүздән» аны аңлаучылар. Шуңа күрә дә текстта әйтелер-әйтелмәс сүзләр дә бар, киная һәм элек әйтелгәннәрне искә төшерүләр дә байтак... Хикмәт Коръәндәге теге яки бу вакыйганың әһәмияте булуында түгел, аның мәҗүсилеккә каршы дәлил булып торуында, Аллаһы Тәгаләнең берлеген тәсъдиклавында. Тыңлап торучыларны яки әңгәмәдәшләрне инандыру көче—Сүз, Аллаһ Сүзе (Кәләму Аллаһы).

## Нәхү кирәкме соң?

Чит телдән тәрҗемә иткәндә без сүзләрнең мәгънәсен белеп кенә дөрес тәрҗемә итә алмыйбыз. Грамматиканы, морфология (сарыф), синтаксисны (нәхү) белү кирәк. Сүзләрнең генә мәгънәсен белеп тәрҗемә итүдән «чыктым аркылы күпер»ләр хасыйл була. Сүзнең төрләнүе, җөмләдәге урыны, башка сүзләр белән бәйләнеш ысулы, хәтта логик басым да сүзнең дә, җөмләнең дә мәгънәсен үзгәртә, һич булмаса, яна мәгънә төсмере кертә.

Нәкъ менә шундый хәлләрдә сөйләм теленең үзенчәлекләре ачыла, шуның белән ул язма телдән аерылып тора һәм тәрҗемә итәр өчен кыенлыклар тудыра.

Коръән текстын тәрҗемә итүче гарәп теле грамматикасын да, татар теле грамматикасын да тигез, яхшы белергә тиеш, шулай булмаса тәрҗемәче атлаган саен диярлек йә гарәп җөмләсенең мәгънәсен, йә татар теле синтаксисын һәм стилистикасын вата. Тәрҗемәчегә нишләргә?

---

[1]Аермалык язма тел белән сөйләм теле арасында гына түгел, грамматика белән логика арасында да бар, диелә логика фәнендә. «Грамматический строй не является полным тождеством логического строя. Грамматический строй—это структура слова и формы связи и сочетания слов в предложении. Логический строй—это структура мыслей, формы сочетания и связи мыслей в рассуждении. *(Н. И. Кондаков. Логический словарь, М, 1971, с. 321.)*.

Мондый хәлдә тәржемәче вакыт-вакыт теге яки бу фигыльнең грамматик формасын яки алмашлыкның кемгә караганын белә алмыйча аптырый. Элек заманда тыңлап торучыларга ап-ачык булган нәрсәләр бүгенге гарәп укучыларында да сораулар тудыра. Житмәсә, Коръән текстында, сөйләм теле булгач, тыныш билгеләре юк, тәржемәче җөмләнең башы кайда да, ахыры кайда икәнен аера алмыйча интегә. Изге китаплар тәржемәсенә хас кыенлыкларның бер иешесе сүзләрдә дә, әйтемнәрдә дә аллегория, метафора, символизм, күппланлык, полисемантизм күренешләре булуда. Терминология, үзенчәлекле изгелек лексикасы тирән игътибар итүне таләп итә.

**Диалог**. Коръән тексты фикерне тоташ бәян итүче сөйләм теле генә түгел, ул—диалог. Пәйгамбәр алдында тыңлап торган кешеләргә Коръән сүрәләренең эчтәлеген аңлата. Аларның сорауларына җавап бирә, үзе риторик сораулар куя да, үзе үк аларга җавап та бирә... Сорау-җавап формасында бәян ителгән текстта пәйгамбәр төрле образлар тудыра, шулай итеп тыңлаучыларның дикъкатен җәлеп итә генә түгел, метафора, чагыштырулар кулланып, аларның күз алдына рәсем-сурәтләр китереп күрсәткән кебек була; ә рифмалап төзелгән аятьләрне көйләп сөйләү исә кешене күбрәк дулкынландыра, күңелгә аеруча нык тәэсир итә.

Берничә мисал китерик. «Аллаһ яманлык эшләргә кушмас. Белмәгән көенчә Аллаһка каршы сөйләргә ничек җөрьәт итәсез?»—ди Мөхәммәд (7:28). Коръәндә: «Аллаһ турында ялган сөйләгән, Аның аятьләрен ялганга чыгарырга маташучы кешедән дә кәбахәтрәк берәү бармы икән?» (7:37). «Аллаһка тиң күреп табынган ялган тәңреләребез кайда?» шикелле риторик сораулар күп. Сез Салихның Раббы тарафыннан күндерелгәнлеген беләсезме *(ышанасызмы)*? (7:75)—дип сорадылар. Тегеләр исә: «Шик юк ки, без аңа ни индерелсә дә ышанабыз»—диделәр. «Алар могҗизаларны инкарь иттеләр. Бак, фетнәчеләрнең ахыры ни белән бетте?» (7:103). Шундый сораулар аятьтән аятькә күчә бара. Мәсәлән, «Мин аларга юри михнәт *(сынау вакыты)* бирәм, әмма минем җәзам бик тә хәтәр булачак. *(Мөхәммәд)* тик *(алда куркыныч җәза барлыгы турында)* кисәтүче генә. Күкләр һәм Җирдәге төзек тәртип *(белән идарә итүче Аллаһ икәнлеге)* турында уйлап бакмадылармы? Аллаһ яраткан һәр нәрсәгә игътибар итеп, әҗәлнең киләчәгенә ышанып карамыйлармы? Шулай булгач, алар *(Коръәннән башка)* тагын нинди китапка ышанырлар икән иде?» (7:183,184).

Коръәндә Мөхәммәд кем беләндер әңгәмә корган булып сөйләшә, сораулар куя, аларга җавап итеп дәлилләр китерә. Мәсәлән, (10:15) *(Аллаһы Мөхәммәдкә әйтә)*: «Аятьләребезне дәлилләр белән ап-ачык итеп укыгач, *(Ахирәттә)* Безнең белән кавышырга теләмәгәннәр *(мөшрикләр)* сиңа»: «Юк! Безнең өчен син башка бер Коръән китер яки монысын *(безнең файдага)* үзгәрт»—дисәләр, син әйт: «Аны алыштыру яки үзгәртү минем көчемнән килә торган нәрсә түгел. Мин вәхи булып *(иңдерелеп)* килгәннән башкасына табынмам. Әгәр дә Раббыма каршы баш күтәрсәм, шик юк ки, Хәтәр көннең газабыннан куркам»—диген (26:91).

Алардан: «Күкләрне һәм Җирне кем яраткан? Кояшны, Айны буйсындырып йөртүче кем?»—дип сорасаң, алар мотлак: «Аллаһ,—дип җавап бирер. Шулай булгач, нигә соң алар (иманнан) йөз чөерәләр? (29:61)

**Образлы шигъри юллар**. Коръән теленең өченче үзенчәлеге—шигъри тел, рифмаланган проза, гарәпчә аны «сәҗгъ» диләр. Борынгы гарәп шигырь законнары безнең поэтик нормаларыбыздан ерак тора. Шуңа күрә ул тәржемәдә генә түгел, гарәпчә укыганда да гарәп булмаган кешегә сизелми. Мәсәлән, «Фатиха»ны белмичә, мәчеткә йөргән кешеләр юк. Ләкин кем аның рифмасын шигъри дип әйтер? «Әл-хәмду-лилләһи раббуль-галә**мин**, әр-рахмәнир-ра**хим**, мәлик йәумид-**дин**, иййәәкә нагбуду вә иййәәкә нәстәгыйн, иһдина-сыйрата-ль мөстә**кыйм**. Шулайрак язганда, **«иин»** иҗекләре кабатлануы күренеп тора. Ләкин гарәп колагы өчен генә. Әмма рифма, кагыйдә буларак, сүзгә, җөмләгә мәгънә төсмере кертә, теге яки бу аятькә логик басым ясый. Ә инде көйләп укылса, эчке ритмикасы да барлыкка килә һәм тыңлаучының хиссиятен уята, күңелен дулкынландыра, үзенә җәлеп итә.

Табигатьнең гаять матур күренешләрен сурәтләп, эчке ритмикалы бай җөмләләр белән фикерне житкерү Коръән сүрәләрендә аз түгел. Мәсәлән, (81:1-14) аятьләрендә болай диелгән: «Кояш бөрешеп сүнгән заманда, йолдызлар сүнеп, егылган чакта, таулар кубарылып хәрәкәткә килгәндә; буаз дөяләр

караучысыз калгач, кыргый хайваннар бер урынга тупланган чакта, дингезләр дөрләп яна-яна бер урынга коя башласа, җаннар үз тәннәре белән кушылган заманда; тереләй җиргә күмелгән сабый кыз баладан, ни сәбәпле сине шулай кылдылар, дип сорар вакыт житкәч; *(гамәл)* дәфтәре ачылып, *(җинаятьләр)* фаш ителгәндә; Күк урыныннан купкан мәлдә, хәтәр ялкынлы җәһәннәм артыгы белән кызганда; җәннәт мөэминнәргә якынайганда, менә шул чакта һәрбер кеше үзенең кылмышлары белән үзенә ни хәзерләгәнен бик яхшы аңлар».

Шулай ук күтәренке рух белән әйтелгән сүзләр бүгенге укучыга да көчле тәэсир итә. Мәсәлән, (89:1-4) аятьләрендә: «Атып килгән таң белән ант итәм; Ун кичәнең изге исме белән ант итәм; Җөп саннар белән так саннар изге булсын; алмашынып торучы көн вә төн белән ант итәм. Башында акылы булган кешеләр өчен ант итәрлек дәлилләр түгелмени болар?».

Сөйләм теленең бу формалары тыңлап торучыларга, әлбәттә, тәэсир итми калмаганына без ышанабыз. Шулай итеп, Коръән тексты сөйләүче белән тыңлаучыларның әңгәмәсе булып чыга, уртак фикерләү юлы белән хакыйкатьне дәлилләүгә әверелә. Андый чакта сүзләр белән белдерелгән мәгънәләр ансат аңлашыла, кешене үзенә җәлеп итә, ышандыра, аның аңына сеңдерелә.

## Тәрҗемәләр нинди була?[1]

Халыклар тормышында үзара мөнәсәбәт, бер-береннән өйрәнү-тәрәккыятьнең, үсешнең бик зур чыганагы булып санала. Ул багланышның төп ысулы—Габдулла Тукайчарак итеп әйтсәк—»тел, ләгать вә әхлак илә алмашу». Фикер, белем алмашуда телдән-телгә тәрҗемә итүнең әһәмияте гаять зур.

Кешелек тарихында галимнәр тәрҗемә мәсьәләсенә күптәннән игътибар иткәннәр һәм ничек итеп дөрес тәрҗемә итү турында төпле фикерләр әйткәннәр. Безнең эрага чаклы I гасырда Борынгы Римның атаклы галиме Цицерон борынгы грек теленнән латин теленә тәрҗемә итү турында болай дигән: «Чит телдә әйтелгәнне тәрҗемә иткәндә формасы да, эчтәлеге дә, сүз тәртибе дә сакланып, барлык фикерләре бөтен тирәнлеге белән бирелергә тиеш, сүзләр исә үз теленең тәртибенә туры китереп алынырга тиеш...» *(С. С. Толстой. «Как переводить с английского языка», М., 1960, 12б.)*

Татарлар күп гасырлар буена чит телләрдән, башлыча, гарәп, фарсы, төрки һәм урыс телләреннән әдәби, дини, фәнни эчтәлекле китапларны бик күпләп тәрҗемә иткәннәр һәм бу өлкәдә зур тәҗрибә туплаганнар. Алай да, тәрҗемә турында бер-ике сүз әйтеп китмичә булмас. Тәрҗемә кагыйдәләре арасында бер бик әһәмиятлесен искә төшерер өчен күрсәтик: «Тәрҗемә хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз булмаска тиеш,—ди С. С. Толстой,—оригиналдан калька тыела. Ягъни тәрҗемәче аерым сүзләрне түгел, ...аерым җөмләләрне түгел, авторның фикерен бөтен нечкәлекләре белән бирергә тиеш».

Тәрҗемә теориясендә булган төп кагыйдәләр түбәндәгедән гыйбарәт. **Эквивалент юлы**—төп нөсхәдәге сүз яки гыйбарә тәрҗемә ителә торган туган тел сүзе яки гыйбарәсенә туры килү: мәсәлән, гарәпчә «китап» сүзе татарча да «китап», гарәпчә «мәдинә», «ражул» татарча «шәһәр», «ир» һ. б. ш. **Аналог юлы**—төп нөсхәгә бик якын булган сүз яки гыбарә табу: мәсәлән, гарәпчә «җәмил» татарча «чибәр» («матур», «гүзәл» дип тә әйтеп була); гарәпчә «салих» татарча «яраклы» («туры килә», «файдалы» дип тә әйтеп була). Эквивалент һәм аналог нигезендә тәрҗемә итү кыен түгел, дип санала.

Иң зур кыенлыклар мәгънә ягыннан чит сүзләргә туган телдә сүз табылмаганда (аның гомумән булмавы да мөмкин) килеп чыга. Мондый хәлдә тәрҗемәчеләр **адекват** юлы белән тәрҗемә итәләр. Адекватның өч ысулы бар:

[1]Тәрҗемәләр турында бай әдәбият бар: мәсәлән, Крупнов В. П. Лексические аспекты перевода. «Высшая школа», М., 1984; Миньяр-Белоручев Р. К. Общая теория перевода и устный перевод. М., 1980; Чужакин А., Палажченко П. Мир перевода или вечный поиск взаимопонимания. «Валент», М., 1997.

төшенчәнең логик үсеше (аңлатмалы тәрҗемә, ягъни интерпретация); формасы белән кире яктан килү, ягъни **антонимнар тәрҗемәсе**; өченчесе—**компенсация юлы**, ягъни төп нөсхәдәге фикерне башка чаралар белән, бүтән сүзләр белән бирү. Компенсация юлы белән чит телдән тәрҗемә иткәндә текстның нечкәлекләре югала торган очракларда әйтемнәр, мәкальләр, идиомалар һәм башка махсус гыйбарәләр тәрҗемәсе кулланыла (С.С. Толстой, 14—16 б).

Сүзлекләрдә, әлбәттә, хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз дип аталган тәрҗемә ысулы кулланыла, ягъни һәр сүзгә икенче телдә шундый ук мәгънәле сүз табыла. Сүзгә-сүз һәм җөмләгә-җөмлә ысулын юлга-юл (подстрочный) дип тә атыйлар. Бу алым шигырьләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә күбрәк кулланыла; чөнки, гадәттә, икенче телле шагыйрь беренче телне белмәве дә мөмкин, ул сүзгә-сүз тәрҗемәдән беренче телдә әйтелгәннең мәгънәсен отып алып, шигырьне үз телендә калыплаштыра. Мондый тәрҗемәне иректе тәрҗемә дип тә атыйлар. Иң кыйммәтле тәрҗемә, әлбәттә, эквивалент, аналог һәм адекват кагыйдәләре нигезендә **мәгънәви** тәрҗемә, ягъни бер телдә әйтелгәннең икенче телдә төгәл мәгънәсен бирергә тырышу.

Боларның барысы да әдәби текст, фәнни текст, сөйләм телдә булганнарны тәрҗемә итү юллары. Әмма бу урында бер сорау туа: Коръән шикелле «Изге китаплар»ның тәрҗемәсе нинди булырга тиеш соң? XX гасырның уртасына чаклы мөселманнар, кагыйдә буларак, Коръәнне тәрҗемә итәргә алынмаганнар, чөнки тәрҗемә иткәндә изге сүзнең мәгънәсен ялгыш бирү ихтималыннан шикләнгәннәр.

Шуңа күрә мөселманнар Коръәннең тәфсирен (аңлатмалы тәрҗемәсен) генә кулланырга тырышканнар. Мәсәлән, гасыр башында татарлар арасында киң таралган Ногмани тәрҗемәсе шундыйлардан санала. Аны гасыр ахырында кириллица хәрефләре белән тагын бер басмасын чыгардылар *(«Әль-Коръәну-ль-кәрим», Коръән тәфсире, Казан, 1996, 684 б).*

## Тәрҗемәнең нинди үзенчәлекләре бар?

Алдарак Коръән теленең үзенчәлекләре турында сүз барганда тәрҗемәнең кыенлыклары турында әйтелгән иде. Аларның лексика һәм грамматикадан башка сәбәпләре дә юк түгел.

Мәгълүм ки, Һинд океаннан Атлантик океан ярларына хәтле сибелеп яшәгән бүгенге гарәп халыклары сәяси һәм икътисади яктан бердәм халык түгел: гарәпләр 22 илдә яши. Сөйләм теле ягыннан караганда да бердәмлек юк: һәрбер гарәп илендә үз шивәләрендә сөйләшәләр, һәр илдә радио-телевидение тапшырулары җирле телдә башкарыла, әкият, шигырь һәм җыр турында әйтәсе дә юк. Мисырлылар үз шивәләрен яраталар, Сүрия, Ливия кешеләре әдәби телгә якынрак телдә сөйләшәләр, Мәррәкәштә, Алжирда үзгә сөйләм.

Ләкин гарәпләрне берләштергән нәрсә—күп гасырлар буе шомарып килгән әдәби тел. Аны саклап калучы—Коръәннән башка бик бай матур әдәбият та бар. Борын-борын заманнардан ук бер үк телдә укып килгән гарәпләр төрле илләрендә бүген сүзгә бай әдәби телдә бер үк төсле укырлык китаплар, газитә-журналлар чыгаралар.

Алай да, хәзерге гарәп әдәби телендәге кайбер сүзләрнең мәгънәләре Коръәндә булган сүзләрдән аерылып тора, чөнки күп гасырлар дәвамында сүзләр дә азмы-күпме алмашынган яки аларның мәгънәләре, һич булмаса мәгънә төсмерләре үзгәргән. Мәгълүм булганча, һәр халыкның үз тарихы, үз тормыш шартлары, яшәү рәвеше, үзенчәлекле үзаны, үзенә генә хас гореф-гадәтләре, үзенең ассоциатив фикерләү ысуллары була. Ул гореф-гадәтләргә бәйле мәгънәләр, элек булып та хәзер булмаган нәрсәләр белән ассоциатив фикер йөртү һәм сүзгә салынган мәгънә үзгә нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Мисал өчен «фәкыйрь» сүзе хәзерге гарәп телендә «ярлы», «юксыл» мәгънәсен белдерә. Коръәндә исә бу сүз башка мәгънәдә кулланыла: галим-голямә, белем эстәүчеләр, Алла сүзен таратучылар мәгънәсендә килә (текст

буенча—аларның көндәлек икмәк эзләп табарга вакытлары юк, шуңа күрә байлар аларга ярдәм итәргә тиеш. Хәзергечә әйткәндә—«спонсорлык» идеясе). Икенче мисал: «нижмә» сүзе әдәби телдә «йолдыз»ны белдерә, ә Коръәндә ул «үләннең» бер төрен дә аңлата. В. Порохова нөсхәсендә очраган ялгыш тәржемәләрнең берсе итеп әнә шуны күрсәтәләр. Ләкин лексик «караңгылык» моның белән генә чикләнми.

Коръән Сүзен тәржемә итү җиңел эш түгеллеген күрсәтер өчен берничә үрнәк китереләчәк. Мәсәлән, икенче сүрәнең 138 нче аятендә болай диелгән: «Сыйбгата Аллаһы вә мән ахсән минә Аллаһы сыйбгатан вә нәхну ләһү гаабидуна». Бу җөмләне ничек тәрҗемә иткәннәр?

«Аллаһның күркәмлеге. Кем Аллаһтан күркәмлерәк белән гүзәлрәк икән? Һәм без аңа гыйбадәт кылучылар!» (Ф. Сәлман).

«Аллаһның нурына урандык. Аллаһның нурыннан да гүзәлрәк нурны кем бирә ала? Без *(бары тик)* Аңа гына *(гыйбадәт кылабыз)* буйсынабыз, диген» (Р. Батулла).

Бер үк аятьнең ике вариант тәрҗемәсе килеп чыкты. Кайсысы дөрес? Берсе дә төгәл тәрҗемә түгел шул (соңрак моны күрсәтәчәкбез).

Һәр милләтнең аңында дөнья чынбарлыгы үзенчә чагылыш таба, һәм ул чагылыш телне дә үзенчәлекле итә. Мәсәлән, урысча «дождь идет» диләр. Ләкин татар кешесе яңгыр «килә», «бара» яки «йөри» дип әйтми, бу табигый күренешкә татар телендә аерым фигыль бар: «яңгыр ява». Шулай ук «птица поет» дигән төшенчәгә дә татар телендә аерым караш: татарның аңында кеше генә «җырлый» ала, кошлар җырламый, «сайрый», ягъни бу күренеш тә аерым фигыль белән аңлатыла.

Шундый ук мисаллар башка телләрдә дә бар, шул исәптән гарәп телендә дә. Шуңа күрә ике телне дә бер үк дәрәҗәдә яхшы белгән кеше генә төгәл тәрҗемә итә ала, дип әйтәләр. Ә инде 1400 ел элек Коръәндә әйтелгән сүзләрнең үзенчәлеген белеп бетереп буламы икән? Фикер йөртү үзенчәлегенә мисал: Коръәндә (17:29) «Кулыңны үз муеныңа бәйләмә» диелгән. Аның мәгънәсе—«саран булма». 11 сүрәнең 40 аятендә борын заманнарда «мич кайный» гыйбарәсенең мәгънәсе «су ташкыны башланды», «туфан башланды» мәгънәсендә йөргән.

*Дәвамы киләсе санда.*

## Авторлар игътибарына

Редакциягә бары тик машинкада басылган кульязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр **210 x 297** ле форматтагы ак кәгазьгә кара төстәге тасма аша ике интервал калдырып басылырга тиеш.

Бер биттә иң күбе—**30** юл, һәр юлда—бары тик **60** (сүз араларын да исәпләп) тамга була.

Кәгазь битендә сулдан—**25** мм, өстән—**20** мм, уң яктан—**10** мм, астан **25** мм чиста ара калдырыла.

Әсәрнең исеме һәм бүлек исемнәре төп тексттан астан да, өстән дә өчәр интервал белән аерыла.

Кызыл юл өч хәреф урыны кадәр бушлык белән ясала.

Күләме ун биттән арткан кульязмалар ике нөсхәдә җибәрелергә тиеш.

Әсәр компьютер ярдәмендә җыелган очракта, мөмкинлегегез булса, дискетын алып килү сорала.

Редколлегия таләпләренә җавап бирә алмаган һәм шунлыктан журналда басылмаячак кульязмалар анализланмый, рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

Бүтән басмаларда дөнья күргән әсәрләр кабул ителми.

**Фәридә Хәсәнова**

# РЕНАТ ХАРИС ШИГЪРИЯТЕ

## Шагыйрьнең иҗат биографиясеннән

Ренат Харис алтмышынчы елларның урталарында ук үз шигъри авазын ишеттергән, шигырьдәге үзенчәлекле кыю эзләнүләре белән әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә юнәлткән һәм бәхәсләр уяткан шагыйрьләребездән. Аның тәүге җыентыгы «Җир һәм Кеше» исеме белән «Беренче карлыгачлар» сериясендә дөнья күрә (1968 ел). Бүгенге көндә ул—30 лап шигырь җыентыгы авторы. Шулар арасыннан рус телендә лаеклы яңгыраш алган 7 җыентык, чуваш һәм башкорт телләрендәге җыентыклары («Юрату сукмаке» һәм «Яктылык тәме»), татар, рус, инглиз телләрендәге робагыйлары басылган «Шигырь язган каләм белән» җыентыгы, әдәбиятыбызда Тукайлар чорыннан килгән бер матур традицияне дәвам итеп, балалар өчен язылган «Лап-лап» шигырьләр китабы, «Хисемнең исеме», «Күзгә мәхәббәт» кебек мәхәббәт лирикасы, «Хәбәр», «Тоткасыз ишек» кебек шигырьләр җыентыклары һ. б. бар. Китапларның басылу даталарына игътибар иткәндә, шагыйрьнең һәр ел саен бер җыентык чыгарып баруына тап буласың. (Шунысын да мәгълүм итик: Ренат Харис әле күптән түгел генә шагыйрь Дәрдмәнднең «Агарган кыл» исемле җыентыгын әзерләп бастырып чыгаруга иреште.).

Ренат Харисның шигырьләре шулай ук төрле елларда «Новый мир», «Огонек», «Юность», «Дружба народов», «Москва», «Молодая гвардия», «Октябрь» һ. б. үзәк журналларда дөнья күрде.

Тәнкыйтьчеләр аның шигъри әсәрләре заманча үткен яңгырашлы булуы, образлы фикерләүдәге яңача алымнары, кыю метафоралары һәм чагыштырулары, форма өлкәсендәге оригиналь табышлары белән җәлеп итүен билгеләп үттеләр. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен төрләндерү, шигъри сүзнең җегәрен, эчке куәтен арттыру, чорның олы проблемаларын лирик чаралар ярдәмендә үтемлерәк итеп җанландыру юнәлешендә өзлексез эзләнә, фикер-хисне укучыга сурәтле итеп җиткерү өчен халык иҗаты символикасыннан һәм әдәбият-сәнгатьтәге шартлы алымнардан мул файдалана.

Ренат Харис—киң колачлы шагыйрь. Аның иҗат биографиясендә 18 поэма (шулар эчендә «Зөләйха» һәм «Идегәй» драматик поэмалары, «Өч үбешү» поэмасы, «Гармунчы», «Шөкер», «Бүре кузе», «Сабантуй», «Ат иярләү» һ. б. поэмалар), «Бизәк», «Каурый каләм», «Дәрдмәндкә назыйрәләр», «Яралар» һ. б. цикллары, «Тула эшләпә», «Вәлит сәгате» хикәятләре, «Кеше», «Казан» ораторияләре һәм кантаталары, күпсанлы җырлар бар.

Ренат Харис татар культурасы тарихында оратория жанрын башлап җибәрә. Ул «Кеше» ораториясе текстын иҗат иткәне өчен 1972 елда Муса Җәлил исемендәге премиягә, ә 1997 елда исә «Хисемнең исеме» дигән китабы өчен Тукай исемендәге

Дәүләт премиясенә лаек булган шагыйрь. Боларның барысы да аның хезмәт сөюче, күп яклы, зур шагыйрь булуын тагын бер мәртәбә раслый.

«Иҗатымда—эшемнең, эшемдә иҗатымның йөзен кызартмадым»,—дип раслый алган *(«Мәдәни җомга»,—1996 ел, 2 декабрь.)* шагыйрь Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары булып эшләде. Аңа хәтле 1971-1973 елларда ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре, 1973-1982 елларда Татарстан культура министры урынбасары, 1982-1989 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булды.

Гадәттә, йөк атын мактамыйлар, йөк атын гел камчылап кына торалар. Ренат Харис иҗатына да тәнкыйтьчеләр битараф түгел. Аеруча аның «Замана эзләре» җыентыгына язылган кереш сүзне (Нил Юзиев), «Чехов базары» поэмасына (Н. Хисамов), «Хисемнең исеме» җыентыгына (Т. Галиуллин) мәкаләләрен күрсәтеп китәргә кирәк. Ренат Харисның Максим Горький исемендәге музейда график рәсемнәр күргәзмәсе ачылгач, аның турында газеталарда сәнгать белгече Розалина Шаһиева («Рәсемле робагыйлар»), Халык рәссамы академик Харис Якупов хезмәтләре («Рәсем ясаган кулым белән») басылып чыкты.

Дөрестән дә, Ренат Хариска табигать тарафыннан һәртөрле талант күпләп бирелгән, аның иҗатында «илаһилык билгеләре ярылып ята», дип әйтүе белән сәнгать белгече Р. Шаһиева бик тә хаклы. Шагыйрьнең иҗат кредосы түбәндәге шигырь юлларында яңгыраш таба:

Өч илаһи көчемне
бергә туплауда гына
мин бәхетемне күрәм:
кылыч, каләм һәм төрән!

*(«Кол Гали монологы»)*

Ренат Харис үз шигырьләрен эстетик зәвыгы югары булган укучыга юнәлтә. Дөресрәге, аның эстетик зәвыгын һәм күңел дөньясын үз иҗат тәҗрибәсе белән баетырга омтылыш ясый шагыйрь.

## Шигырьдә металогик алым

Әдәбият—образлы фикерләү дөньясы. Шагыйрь, прозаик яки драматург никадәр образлы фикер йөртсә, ул тудырган әдәби әсәр укучы яки тыңлаучы күңеленә шулкадәр ныграк тәэсир итә, камилрәк һәм матуррак тоела.

Поэзиянең кешеләрдә уй-тойгы тудыру өчен хезмәт итүен искә алган хәлдә, теге яки бу шагыйрьнең образлы сурәтләүгә омтылуын аңлату кыен түгел. Бу максатка ирешү барышында сүз остасы аеруча поэтик шигырь жанрында телнең лексик сурәтләү чаралары аша сүзләрне күчерелмә мәгънәдә куллана. Сүзләрне образлы итеп күчерелмә мәгънәдә куллану металогик дип атала.

Металогик алым тропларны куллана белүгә нигезләнә. Троп (грекча—«әйләнмә»)—сүзләрне күчерелмә мәгънәдә куллану. Бу чарага чагыштыру, метафора, эпитет, метонимия, синекдоха, симфора, гипербола, юмор, ирония, литота, аллегория, әйләнмә, перифраз алымнары керә.

Ренат Харис—шул ук вакытта реализм юнәлешендә иҗат итүче шагыйрь. Ә «реализм» чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерү һәм танып-белү функциясен билгеләүче төп төшенчә ул.

Реализм юнәлешендә иҗат итүчеләр социаль тормыш, җәмгыять һәм шәхес арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне сурәтлиләр. Моның дөреслеген раслау өчен шагыйрьнең бер поэмасын искә алу житә. Ул да булса «Чехов базары». Поэмада шагыйрь хәзерге тормышның җыйнама сурәтен күрә.

Тормыш начарайган саен, гаҗәп,
Матурая бара базарлар...
Соңгы вакытларда еш уйлыйм мин
Шул турыда ныклап язарга.

*(«Чехов базары»)*

Әйе, халык тормышын чынбарлыктагыча чагылдырганы, фәлсәфи тирәнлеге,

сәнгатьчә нәфислеге белән укучыны сокландыра бу әсәр. Автор монда кеше белән җәмгыять арасындагы катлаулы бәйләнешләрне яңача һәм гадәти итеп тасвирлауга ирешә.

Шагыйрьнең сурәтләү чараларыннан эпитетларны куллану үзенчәлекләренә тукталыйк. Эпитет (грекча «ачыклагыч», «өстәмә» дигән мәгънә)—образлы ачыклагыч сүз. Ләкин эпитетларны әйбернең сыйфатын белдерүче гадәттәге аергыч белән бутарга ярамый. Аергыч әйбер һәм күренешнең билгесен генә ачыклый алса, эпитет эш һәм хәрәкәтне дә образлы итеп бирә ала. Эпитетлар күптөрле булалар һәм алар сурәтлелек тудыруда бүтән тел-сурәт чаралары белән катнашып килә. Эпитетларнын аеруча метафорик, метонимик төрләрен аерып чыгаралар. Көнкүреш телендә исә логик эпитетлар—гадәттәге аергычлар байтак. Логик эпитет булып туры мәгънәсендә кулланылган сүз килә һәм ул бер әйберне икенчесеннән аеру хезмәтен генә үти. Мәсәлән: «кояшлы көн», «томанлы көн» «алсу алма». Аергыч ролен үтәүче бу сыйфатлар логик эпитет булалар, туры мәгънә белдерәләр.

Образлылык сүзнең ялгыз торуында түгел, күп вакыт контекстта ачыклана. Гадәттә, логик эпитет янәшә сүз белән берлектә сүз-сурәт барлыкка китерә. Мәсәлән:

Тояклары сары сөяк,
бәкәлләре буз кебек ак.
сыйфатлары нәфис, озын,
сөлек кебек бу кызыл ат
әкияттән чыккандыр дулап.

*(«Ат»)*

Шагыйрьнең иң күп эпитетлары булган шигырьләре аның атлар турында: «Ат», «Ярсыган ат», «Яткан ат», «Ат җиккәндә». Ни өчен? Лирик геройның ат яратуына җавап менә бу юлларда түгел микән?

Ияр атны дәүләт итә,
тәхет илне ат итә.

*(«Ияр һәм тәхет»)*

Һәм тагын ат турында:

Таяк аргамаклар көтүенең
күзгә керде җылы тузаны
һәм йөрәктә янә иярләнгән,
юлга әзер атлар кузгалды.

*(«Болытларның бүген агы ага»)*

«Юлга әзер атлар»—логик эпитет, янәшә торган «йөрәктә янә иярләнгән» күчерелмә мәгънәле сүзләре белән метафорик эпитет килеп чыккан. Ә «таяк аргамаклар» малайларның таякны ат итеп уйнауларына ишарә итеп, метономик эпитет булып килә. «Таяк аргамаклар көтүенең җылы тузаны күзгә керү»—киңәйтелгән метафора була.

Шулай ук шагыйрь эпитетларның иң матурларын персонажның портретын биргәндә куллана:

Барыбыз да, бөтерчектәй, вальс әйләнгәндә,
Кайберләребезнең хисе хискә,
күбебезнең сүзе сүзгә генә бәйләнгәндә,
аккош кебек ак муенлы,
иң нечкә билле, иң төз аяклы,
иң сылу гәүдәле кыз
басып кала бирде ялгыз.

*(«Яшьлегемнең моңлы өч хикәяте»)*

Шагыйрь үзенең «Чал сандугач» шигырен мондый юллар белән башлап җибәрә:

Яфрагына сары төшкәч
чәчәк аткан гөл ич син!

Чәчәк аткан гөл—туры мәгънәле сүз тезмәсе, гәрчә аннан урта яшьләрдәге хатын-кыз образы күз алдына китерелсә дә. Ә менә «яфрагына сары төшкәч чәчәк аткан гөл»—образлы сүз тезмәсе. Үз вакытында мәхәббәтен очрата алмаган хатын-кыз образын автор шулай тасвирлый. Ләкин «гөлгә» барыбер «сандугач» куна. Ул—«чал сандугач». Лирик герой үзен шулай дип атый һәм логик һәм метафорик эпитетлар, шулай ук метафора аша үзенен характерын, портретын сурәтләп бирә.

Мин—давыллан, утлардан
канатын талаттырап,
назлардан, үкенечләрдән
йөрәген канаттырып,
сине күргәч,
китә торган
кошларга кушылмаучы

Миңа дигән
Мина дигән
соңгы илһамчы тамчы
синдә икәнен күрүче
һәм күзләрдә калучы,
сары күзләрдә дә язгы
жырлар жырлый алучы!

*(«Чал сандугач»)*

«Сары күзләр», «язгы жырлар» логик эпитетлар булса, «күзләрдә калучы сандугач», «сары күздә язгы жыр жырлый алучы сандугач»—метафорик эпитетлар, «чал сандугач» үзе—метафора. «Канатын талаттырып, йөрәген канаттырып, китә торган кошларга кушылмаучы чал сандугач»ны сурәтләүдә шагыйрь катнаш эпитетлар куллана. Бу төр сурәтләү чарасын ул ике тропны бергә кушып ясаган. Бу шигырьдә тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев әйткән «шигъри сүзнең жегәре» күренеп тора. Дөрестән дә, һәр сүзгә мәгънәви бер йөк ышанып тапшырылган һәм, алар янәшә килеп, кеше табигатенең кабатланмас бер халәтен чагылдыралар. Реалист шагыйрь буларак, Ренат Харис кешенең эчке дөньясына, шатлык-кайгысына, сөенеч-көенечләренә аеруча нык игътибарлы:

Жылы булды минем тормышым.
Кайнар булды минем гомерем.
Якты булды минем яшәвем,
Сүнми торган тере күмер мин.

*(«Дару исе сеңгән шигырьләр»)*

Ренат Харис фикернең көтелмәгәнчә яңгыравына ирешү юлында уңышлы эшли. Шагыйрь сүзләрнең көтелмәгән, кеше «күрмәгән» янәшәлегеннән файдалана белә. «Алар ясалма шигърият дөньясына тере, мәгънәле сүз алып килделәр. Бу шагыйрьләрнең жанга якын, тормышның үзеннән сирпелеп чыккан канатлы гыйбарәләре халык теленә күчеп, күнелләрдә тәңгәл яңгыраш тапты. Баксаң, чын шигърият йөрәк биеклегендә икән! Шушы бик гади хакыйкатьне, шактый каршылыклар аша үтеп аңлатып биргәч, үз каланчасына кунаклаган күпме шагыйрьләр шыбыр-шыбыр жиргә коела башладылар һәм күңел кылларын яңача көйләп, бердәм агымга кушылып киттеләр» (Галиев М. Догалы еллар.).

Шагыйрьнең мәңгелек язларында «миләүшәле таңнары» бар. Болгар һәм Русь килешүенең 1000 еллыгына багышланган «Ант суы»нда «сүзле өне, хәтерле туфрагы, арка терәкле килешүе», «кашык йөртәчәк һәм халыклар бердәмлегенең жилеме» булачак килешүе. Ә «Мулланур» поэмасында «кан-яшьле шигыре», «стаканлап һава сату» кебек сүз-сурәтләрне очратырга мөмкин.

Һәр метафора тормышның ниндидер бер күренешен төгәл поэтик сурәт итеп күз алдына бастыра, аңа тасвирлама да, бәя дә бирә. Шундый метафоралардан «үле хыял», «сынык өмет», «сәрхуш әхлак» кебек метафораларны атарга була. Шагыйрь үзенең метафора остасы икәнен белә кебек, юкка гына аның лирик герое үзен «лирик сәүдәгәр» дип атамый.

Сирәк урман. Түбән кояш юмарт,
Алсу карда зәңгәр шәүләләр.
Баеп калыйм әле гомерлеккә—
Булыйм әле лирик сәүдәгәр.

*(«Лирик сәүдәгәр»)*

Хәзер шагыйрьнең тропларның иң гади һәм иң таралган төрләреннән берсе булган чагыштыру алымыннан файдалану үзенчәлекләренә игътибар итик.

Чагыштыру ул—нинди дә булса күренешне ана охшаш үзенчәлеге булган икенче күренеш белән чагыштыру, охшату. Чагыштырулар сөйләмгә җанлылык бирә, автор яки персонаж сөйләменең эмоциональлеген арттыра.

Сувар—йорт бәгенен урыны
таза казнада сынган теш
урыны кебек каралып калды.

*(«Ант суы»)*

Мин сезгә, дуслар, ышанган идем,
мылтык ядрәгә ышанган кебек.

*(«Камил Якуб»)*

Җәелеп үскән алмагач
Колачлы шагыйрь сыман.
Алмагач алмасы күпкә,
Шагыйрь җыр күпкә сына.

*(«Җәелеп үскән алмагач»)*

Шагыйрьнең иҗатында шигырьнең һәр юлында үзгә чагыштыру кулланганнары да очрый:

Һәм Кәрамнын бавырына
ноябрьнен салкын дымы
эрегән тоз булып акты—
ул оят төсле кызарды,
аптырау төсле агарды,
ул хурлык төсле күгәрде,
ачу күк чатнап яктырды.

*(«Ат иярләү» поэмасы)*

Болардан тыш шагыйрь иҗатында камыллы кырның «энекәш башы кебек такыр» булуын, җәлладның «кыз йөзедәй алсу алма ашап торуын», мәхәббәтнең «сапер кебек» гомергә бер генә ялгышуын, «базар булып айкалган күкләрне», «гомер кебек сикәлтәле юл»ны күрергә мөмкин. Менә тагын оригиналь сүз-бизәкләр:

Мин үземне шатлык санап
сина китердем үзем...
Тораташка әйләндерде
боз кебек ике сүзен.

*(«Тораташка әйләндерде»)*

Биралмады Идел тынычлык,
басалмады җаннын ярсуын...
Дингез дулкынылай ымсыну...
Шлюздагы кебек тарсыну...

*(«Су төбе»)*

Бу чагыштырулар афоризм дәрәҗәсендә көчле янгырый. Алар инде фикер һәм форманың чарланганлыгы турында сөйли.

Троплариын кызыклы һәм бай төре—метонимиягә тукталыйк. Метонимия (грекча «исем алыштыру»)—күренешне, предмет яки төшенчәне үз исеме белән атау түгел, ана вакыт, урын, яисә материалы белән тыгыз бәйләнештә торган икенче нәрсә исемен бирү ул.

Татарстан урамнарын
үкчә белән шакый-шакый,
татар халкы тарихына
ничә Сәйдәш, ничә Бакый,
ничә Җиһан, ничә Җәлил,
атлый бүген сиздермичә?!
Тукай хаклы: үлгәч кенә
татарда даһи дан эчә.

*(«Сәйдәш яры»)*

Бу шигырь юллары белән автор, берьяктан, халыкта даһи шәхесләргә исән чакта житәрлек игътибар булмавын билгеләп үтсә, икенче яктан, татар жиренең талантларга бай икәнен ассызыклый; шулай итеп, сәнгать осталарының һөнәрләрен атамыйча гына, аларны укучы игътибарына мәшһүр шәхесләр исеме аша житкерә. Шагыйрьнең менә бу шигырендә әйбернең материалы атала:

Зәһәрләнеп исә бозлы жил.
Ачу белән карый тәрәзләр
«Ярый шунда» итеп төзелгән
Тугыз катлы төссез кәрәздән.

*(«Зәһәрләнеп исә бозлы жил»)*

Кеше гомере озынлыгын шагыйрь менә ничек бирә:

Үлемнән дә һәрберебез курка,
Шуна килә яшәп каласы.
Матур итеп бер үтмәкче кеше
Кендек белән кабер арасын.

*(«Шөкер»)*

Шагыйрь тормыш дөреслеген объектив чагылдыра, чынбарлыктагы күренешләрнең нәкъ үзәген тотып ала белә, ул кулланган метонимияләр шуны образлы итеп яңгырата.

Хәзер дә бит иртән торасын да,
радионы тизрәк ачасын.
Симермәгәнме дип, төн чыкканчы,
пенсиянең арык акчасы.

*(«Шөкер»)*

Ренат Харис шигърияте̇ндә һәр сүзнең үз максаты, үз урыны бар:

Базар жиле ак чәчләрен талкый...
Чалкан ята жирдә бүреге.
Тиен ташлый кайсы өстән генә,
Кайсы, рәхмәт, сала үрелеп.

*(«Чехов базары»)*

Бу очракта вак акча төшенчәсе «тиен» белән алмаштырылган.

Базар мөнәсәбәтләре, илдәге сәясәт һәм икътисадның тотрыксызлыгы китереп чыгарган ямьсез күренешләрне автор үткен поэтик сурәтләр белән чагылдыра, бу очракта да аңа метония алымы «ярдәмгә килә».

Хәер бирә илнең киләчәге...
Гармун уйный илнең үткәне...
Шушымыни сугыш кырларында
Жиңүченең өмет иткәне.

*(«Чехов базары»)*

Бу юлларда Т. Галиуллин әйткәнчә, «Ренат Харис лирикасында беренче ике юл, шигырьнең «бисмилласы» әһәмияткә ия».

Метонимияләр куллануның төп максаты бер: әсәрдә мөмкин булганны, иң кирәклесен анык итеп, сурәтле итеп күрсәтү. Ә Ренат Харис сүздән сурәт ясауда виртуозларча эш итә. Мәсәлән, «Шөкер» поэмасындагы ветеран монологында метонимиянең бер төренә хас булган әсәр урынына аның авторын әйтү урын алган.

Алда күргәннәрне сөйли китсәм.
Житмәс иде Айның тәүлеге.
Сөйләп тормыйм. Бар дөресен язган—
Алып укы Нәби Дәүлине.

*(«Шөкер»)*

Бу шигырьдә ирония аша читләтеп әйтү алымы бик оста файдаланылган. Р. Мостафин

билгеләп үткәнчә, «Алгы планга шигъри әсәрнең эшләнеше, поэтик янгырашы килеп баса. Ә бу инде таланттан тора. Моны шагыйрьләр үзләре дә аңлый. Г. Афзал, мәсәлән, «эзоп теле» белән сөйләшкәндә, мәгънәлерәк иде сүзебез», дип юкка гына әйтмәгән.

Шигырьдә һәр сүз, һәр детальнең әһәмияте бар. Ә Ренат Харисның «детальләре» беркемгә дә охшамаган. Аның лирик герое «Җир белән Күк арасында тәмам әлсерәп яши», «кеше кыяфәтендәге җебегән бер болытмын дип хафалана», «тамчы-тамчы гомер кимү»е белән килешми, «бөек назга сузыла һәм ирешәм дигәндә генә «йөрәгенә яшен суга». Шагыйрь үзе бу турыда болай ди: «Минем үз принципларым бар—нинди генә сокландыргыч, кызыктыргыч булмасын, башка язучылар тапкан, тотып алган шигъри детальләрне, күзәтүләрне, чагыштыруларны үземнең әсәрләремә үземнеке итеп кертмәскә. Әлбәттә, эпиграф итеп алырга, йә булмаса, авторын күрсәтеп файдаланырга мөмкин».

Т. Галиуллин Ренат Харисның «шигырьләре фәлсәфи эчтәлекле, тәэсирле, җир шары кебек йомры, карлыгач канаты кебек сыгылмалы»,—дип яза *(Мәдәни җомга.— 1997 ел, 21 март.).* Шагыйрьнең бу үзенчәлеге поэтик сурәтнең иң югары ноктасы—симфора алымын кулланганда ачыла. Симфора (грекча «тәнгәл китерү, берләштерү»)—әйбергә яки күренешкә хас хәл-әхвәлне читләтеп әйтеп (кайсыдыр ягына ишарә итеп), нәрсәне дә булса турыдан-туры әйтмичә нәфис итеп сурәтләү алымы,—метафораның иң югары формасы.

Гадәти метафорада предметны образлы күзаллау аерым билгеләрнең охшашлыгына нигезләнсә, симфорада, бер яктан караганда, метафоралык югалып, охшашлык билгеләре нәфис автологиягә якыная; икенче яктан, симфора табышмакның җавабы кебегрәк рольне үти, ягъни турыдан-туры әйтелмәгән предметның образлы күзаллавын китереп чыгара. Шагыйрьнең «Әй замана» шигыре тулысынча симфора алымын кулланып иҗат ителгән.

Олау әкәм-төкәм сыман,
җикеренсәк тә атка...
Көпчәк бетеп ыңгыраша,
ат та күбеккә баткан.
Олаучыны әй сүгәбез,
әрләшәбез үзара...
Ә арбабыз элеккечә—
әкәм-төкәм күк бара.
Уйланабыз... Киңәшәбез—
нәрсәдән бу, нилектән?..
Олау шуышып шуыша
бозга тамган дегеттәй.
Ялтырады яп-якты уй,
башлар китте әйләнеп...

дилбегәнең
унын
сулга
алмаштырып бәйләдек!
Рәхәт булып китте безгә
(эш үзгәрә юктан да)...
Ныклабрак карасак,
олавыбыз туктаган...

Беренче карашка сүз олау, олаучы, көпчәк, ат, дилбегә, арба турында гына бара кебек. Арба әкәм-төкәм кебек бара, олау бозга тамган дегеттәй шуыша, «бу нәрсә?»,—дип сорыйсы килә. Бераздан бу табышмакның җавабы табылган кебек була. «Дилбегәнең унын сулга алмаштырырга кирәк икән!» Ләкин ни мәгънә? Олау барыбер алга бармый. Шулай итеп, шагыйрь илдә бүгенге көннәрдә барган сәяси вакыйгаларны «эзоп теле» белән сурәтләп бирә. Илдә җитәкчеләр дә алмашына, ләкин «олау» барыбер туктап тора. Ә «Борылышта» поэмасында шагыйрь туктап торуның сәбәпләрен ача:

Борылырга кирәк сонгармый
фикерләүдә, эштә, хыялда.
олавыбыз шунсыз һич бармый.

Бу симфора шагыйрьнең башка шигырьләрендә дә очрый:

Күз нурыннан көмеш тасма үрсәм дә,
сизмәгәнмен, үргәнмен ич тимер аркан,
бәйләгәнмен шул арканга тормышымны,
чанамыни, чорлар аша аны тартам.
Бер-бер артлы алмашына юлбашчылар—
чанам табаннары килә шыгыр-шыгыр...
*(«Күзне йомып»)*

Бу шигырь дә тормышны кәрван, олау, арба, чана символлары аша бирү алымын дәвам итә.

Аллегория—кинаягә корылган язу алымы—тагын «Кәрван» шигырендә урын алган.

Кояш бата.
Ай калка,
Җемелдәшә йолдызлар...
Юллылар алга атлый.
Нишли икән юлсызлар?
Бик авырдыр аларга,
Юлдан сапкач көндезен:

Кай тарафка китәргә,
Юл итәргә кем эзен?
Йолдыз сүнәр...
Ай батар...
Таң атар...
Кояш чыгар...
Ни әйтерләр кәрванга
Адашкан юлбашчылар?..

Бу шигырьдә сүз гадәти табигать күренеше һәм юлчылар турында гына бара кебек. Әмма юлчылар «юллылар» һәм «юлсызларга» бүленәләр. Юллыларнын кем икәнлеге анлашыла, ә «юлсызлар»ның портеты менә нинди:

Үле хыял, сынык өмет, сәрхуш әхлак
Яңа гасыр аяк баскан бусагада.

*(«Үле мәче, сынык байрак»)*

Өченче строфадагы «табигать күренешләре»ннән соң килгән күп нокталар (әйтеп бетермәү) бу процессның әле озакка сузылачагына ишарә буларак кабул ителә.

Шагыйрьнең шәхес һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлау барышында кулланган сурәтләре күптөрле. Мәсәлән, экспрессив эффект тудыра торган оксюморон чарасын алыйк.

Яна Заман килә... Килә җәя җәеп...
Күзебезгә тәрәп ата бик күп гаеп.
Урамнарда йөри күпме тере мәет!
Берсенә дә чыкканы юк моңлы бәет—
берсенә дә!..

*(«Берсенә дә»)*

Аһ илаһи бу комсызлык!
Аһ мәҗүси бөек ялган!

*(«Өч үбешү»)*

Оксюморон (грекчадан «үткен мәгънәсезлек»)—капма-каршы мәгънәдәге сүзләрдән торган тезмә, тәкъбир.

Шагыйрь иҗатында перифраз алымыннан куллану очраклары да бар. Перифраз («әйләндерү-алыштыру» дигән мәгънәдәге грек сүзеннән)—метонимик алыштыруга нигезләнгән тропларның бер төре. «Чехов базары» поэмасында супербазар менә ничек тасвирлана:

Җәмгыятьнең барометры ул.
Лакмус кәгазе дә, бизмән дә...
Җилкән дә ул, кораб-дәүләт шаулап,
«Черт знает куда» йөзгәндә.

«Әмирхан Еники» шигырендә дә монсу Чехов урамындагы иске өйне «өй түгел, йөрәктәге татлы яра» дип атап, шагыйрь перифраз куллана.

Рафаэль Мостафин шагыйрьнең иҗаты турында болайрак әйтә: «Ул бүгенге көн кешесен кызыксындырган әйберләр турында яза, замандашы белән бер сулышта яши, аның һәр шигыре диярлек, яңаны тасвирлаудан битәр, яңа бер ачыш та. Ренат Харис шигърияте, мин әйтер идем, ул—новатор, авангард, яңа фикри мөмкинлекләрне ачучы шигърият».

Без металогик алымны ачу барышында метафора, метонимия, чагыштыру, эпитет, перифраз, оксюморон, символ, симфора кебек чараларга игътибар иттек.

## Шигырьдә автологик алым

Хәзерге поэзия иҗтимагый акыл хәзинәсен тагын да тирәнрәк үзләштерү формаларын эзли. Литва шагыйре Э. Межелайтис сүзләре белән әйткәндә: «... исән калыр өчен поэзия... «акыллырак», фәлсәфирәк була бара... Берни дә эшли алмыйсын, чоры шундый...» Р. Фәйзуллин әйткәнчә» «... фикергә сусау артты. Югары эстетик хәзерлекле укучы хис-эмоциясен генә түгел, ә акылын да бар куәтенә эшкә җигә».

Сүзләрне туры мәгънәдә поэтик итеп куллану «автологик алым» дип атала. Бу очракта уй-кичереш үзе поэтик була, тропларның кирәге калмый. Мәсәлән:

Сине сагынган чагында
Мина өем тар кебек.
Чыклы таңда күлгә төштем—
Анда шәүлән бар кебек.
Бер өянке суга кергән—
Яфраклары кар кебек.
Ул да салкын су телидер,
Ялгыз калган,
Сагыну утларында янган,
Өзелеп сөйгән яр кебек.

*(«Сине сагынган чагында»)*

Бу шигырь туры мәгънәдәге гади сүзләрдән һәм күчерелмә мәгънәсен югалткан әйтелмәләрдән генә тора. Шуңа карамастан, әсәр көчле хис егәрен үзенә сыйдырган. Тыштан бик гади, «җырлап тора торган» юлларда хис-кичерешләрнең яна төсмерләре сәнгатьчә поэтик яңгырашка әверелгән. Шигырь текстлары арасында табигать күренешләренен (пейзажларнын) үзләренен үк поэтик уй-тойгыны чагылдыруы белән очрашырга була:

Кар астына су төшә.
Бозлар калка инештә.
Күнел ачык кочак кебек—
Күнелгә яз килешә.
Таллар башы кызара,
Дулкынлангыч көннәр килә
Егетләргә, кызларга.

*(«Таллар башы кызара»)*

Шагыйрьнен хатын-кыз матурлыгына сокланып язылган шигырьләренә аерым тукталасы килә. Алар арасыннан «Хатын-кызнын юлын кисмә», «Сүрән көн дә якты була», «Тынлыктан чыгулары авыр», «Әй хатын-кыз!» һ. б. ларны күрсәтергә булыр иде. Лирик герой өчен хатын-кыз илһам чыганагы гына түгел, бәлки «беркайчан да җырлап бетермәслек, туйдырмаслык гүзәл җыр» булып тора. Авторның мондый шигырьләре гади сүзләрдән һәм катлаулы поэтик бизәкләрсез булулары белән игътибарны үзенә җәлеп итә. Мондый шигырьләрне укыганда «ир кешенен кем икәнен белергә теләсәң, аның хатын-кызга булган карашын аңла» дигән әйтем искә төшә.

Мин күпме сокландым
кайсынын күзенә,
кайсынын күнеленә,
кайсынын биленә,
буена-сынына,
төз аяк-кулына,
кайсынын чәченә!..
Матурлык барысына
нигәдер,
ничектер
бөртекләп чәчелгән.

*(«Мин күпме сокландым»)*

Шагыйрь бу шигырендә градация алымын эмоциональ-мәгънәви яңгырашны көчәйтү өчен кулланган.

Хатын-кызнын юлын кисмә—
аңа аркылы төшмә,
болай гына йөриме ул,
бара-кайтамы эштән.
Кайда гына атласа да,
ак ният белән атлый.
Иң олы гөнаһ кылса да,

ул ахыр чиктә хаклы.
Кара мәче йә буш чиләк
була күрмә юлында...
Хатын-кыз язмыш Алласы,
тормыш аның кулында.

*(«Хатын-кызның юлын кисмә»)*

Авторның лирик персонажы матурлык һәм мәхәббәт төшенчәләрен барыннан да өстен күрә. Шуңа күрә дә ул болай яза:

Җинүче булып яшәдем,
Яшәп тирләдем, пештем...
Мәхәббәт кагылган иде—
Шатланып әсир төштем.—

*(«Вәсвәсәләр бик күп булды»)*

Ренат Хариста җирне олылау хисе турыдан-туры күзгә ташланып тормый. Туган җир аның өчен—елмаю, иҗат итү өчен илһам чыганагы. Туган җир темасы шагыйрьдә Татарстан һәм авторның туган ягы Буа төбәге белән үрелеп тасвирлана.

Туган җиремдә яшим мин.
Димим алтын, димим көмеш—
рухым имин.
Мин туган җиремдә яшим.
Туган җирдән елмаюым.
Туган җирдән күз яшем.

Яшим мин туган җиремдә,
Анда минем сүз эзем дә,
Кайнап тамган тирем дә.
Туган җиремдә
Мин—җирдә.
Җир—миндә.

*(«Җир—миндә»)*

Туган җир турындагы тагын бер шигырьгә игътибар итик:

Югарыга үрләгәндә
аяк ышанып атлый.
Ә түбәнгә төшкән чакта
Аптырый—җирне тапмый.

Җир түбәндә, тик бар аны
Табалмый таптаучылар.
Рәхәтләнеп: «Җир бар!»—дия
Тик үргә атлаучылар.

*(«Югарыга үрләгәндә»)*

Шагыйрьнең фәлсәфи рухтагы шигырьләрендә авторның бүгенге тормышны, кешеләрне әйбәт белүе сизелә, әмма ул күренешләрнең әхлакый сабак, мәгънә бирердәйләренә генә игътибар итә.

Әйтелмәскә тиеш яла сүзең
бер ычкына икән телеңнән,
үз намусың синең гомер буе
телем-телем булып теленә.

*(«Яралар» циклы»)*

Тукталасын һәм тынлыйсын...
Нинди галәми рәхәт!—
Кычкырган каргыштан көчле
Пышылдап әйткән рәхмәт.

*(«Бер яшибез»)*

Җай гына башланган һәр эш
Тәмамланмый җай гына...

*(«Җай гына башланган эш»)*

Шагыйрь афоризм дәрәҗәсендәге фикерләрне күбрәк авыл тормышыннан ала кебек:

Халык шундый: тирли-пешә
үзен әзерли кышка.
Ә җәйгә ул әзерләнми,
җәйгә әзер тумыштан.

*(«Көтелмәгән көн»)*

Бар нәрсәдән олы булып була,
Ләкин җанны һәрчак ак тоткан
Бу икмәктән олы булып булмый,
Пагърәк булмаган күк пакълектән.

*(«Икмәк тоткан кул»)*

Ә менә бу юлларда авторның тормыш фәлсәфәсе, фикер киеренкелеге игътибарны аеруча җәлеп итә:

Бернәрсә дә соңгы тапкыр булмый...
Бөтен нәрсә бары чиратта...

Инде бетте, инде булмас, диеп.
Этеп куйма мине еракка.
Бернәрсә дә тәүге тапкыр булмый.
Һәрбер яна—бары кабатлау.
Очраттынмы мине—тагын бер сүз
Жырга кайтты, диеп канатлан..

*(«Бернәрсә дә соңгы тапкыр булмый»)*

Ренат Харис шигырьләре укучыдан актив рухи халәткә көйләнгән булуны, актив мөнәсәбәтне таләп итә. Шул очракта гына укучы аның әсәрләреннән үзе өчен эстетик матурлык ачылуын тоя.

Р. Харис шигырьләренең көче нәрсәдә? Бәлки, философик гомумиләштерүдәдер.

Әйе, Ренат Харис—фикер поэзиясе шагыйре, фәлсәфи лирика остасы булуын «Тылмач» шигырендә дә раслый:

Хыялны күкләргә чөйде
Яфракларлардагы рәсем.
Яшел сызымнарда күрдем
Яшәеш фәлсәфәсен.

Бу фәлсәфәне «жанландырып» «Алмагач монологы»на да кертә:

Әллә инде ят тамырга
Береккән бер агачмы мин?
Алма биргән өлешем генә
Минем әллә алмагачмы?

Шагыйрьнең афористик дәрәжәгә кадәр житеп чарланган шигъри юлларына игътибарны юнәлтик:

Без күнегеп беткән инде
Зурны ватып исәпләргә.

*(«Татарлар»)*

Кайчан кайда күтәрә алган
Хаклыкларны ваклыклар?

*(«Кемне кысып маташасыз?»)*

Хәзер төрле ахмаклыклар
Чәчәк аткан замана.

*(«Бизәксез чорда яшибез»)*

Тукран чукый черек имәннең кайрысын.
Бездә кайры астындагы корт кайгысы.

*(«Империя таркалганда»)*

Берни эшли алмый күнел—
Ул шатлыкка һәрчак әзер,
Газапка әзер түгел.

*(«Газаплар-газапланулар»)*

Бу юллардан шундый нәтижә килеп чыга: әйе, поэтик фикер—үзенә күрә дөньяны танып белү коралы шул ул! Поэзиягә менә нинди олы миссия йөкләтелгән!

Шагыйрьнең табигать күренешләрен, предметларны жанландырып язылган шигырьләре арасында «кешенең моң-зарын сөйләвеннән куркып, өйгә кермәгән кар», «өскә үсмәсен әле дип, баш ботагын кискәч, ян-якка үсә торган өянке», «маңгай була алырлык» карама яфрагы бар. Лирик герой үзе дә алар белән сөйләшергә каршы түгел. Өземләрдә китерелгән фразалар, әлбәттә, жанландыру алымына корылган—чөнки автологик методка бу алым да чит түгел.

Сәнгатьле сүз чаралары ярдәмендә төзелгән әдәби чынбарлык структур яктан бербөтен була. Бу структур бөтен сүзләрдә бирелгән мәгънәне генә түгел, бәлки, сүз, юл араларындагы, шигырьгә кермичә, әйтелмичә калган фикерне дә, эчтәлекне дә белдерә. Шагыйрьнең бик күп шигырьләре яңа замана алып килгән күренешләр турында тирәнрәк уйланырга мәжбүр итә.

Аз сүз белән күпне аңлату юлын шагыйрь акчарлаклар образын тасвирлау вакытында да куллана:

Аермасы аз булса да
зурлык, аклык ягыннан
елга акчарлакларының
диңгез акчарлагыннан,
аермасы бар икән шул,
аермасы бар икән—
берсенә бер яр, берсенә
ике кысан яр икән.

*(«Акчарлаклар»)*

Бу шигырендә шагыйрь барысын да әйтеп бетермәгән, укучыга уйланырга, үзенчә нәтиҗә ясарга урын калдырган (әйе, поэзия шундый инде ул!) М. Гайнетдинов билгеләп үткәнчә, «шигырьне артык туры мәгънәсендә аңлау аны банальләштерү, газета мәкаләсенә тиңләү булыр иде». Менә бу шигырьдә дә шул ук «әйтеп бетермәү» бар:

Карга бассам, кыш булам мин,
Җәй булам, чәчәк тотсам.
Чор-дәверләр тамырына
Әйләнәм, юлга чыксам.

*(«Бар тырышканым»)*

Лирик персонажның табигать белән бердәмлеген раслаучы юллар бу. Туган җиргә сокланып туя алмый ул:

Кунак килсә, чәе дә бар,
мае да бар бу җирнең
һәркемне шаккатырырлык
җае да бар бу җирнең.

*(«Сусап кил»)*

Лирик герой табигатьне ярата, аның өчен «һәрбер агач, үлән—һуш китәрлек әңгәмәдәш».

Сөйләшер—тик тамырына
кагылырлык итеп эндәш!

*(«Һәрбер агач, һәрбер үлән»)*

Шагыйрьнең берничә шигырендә алмагач образы килеп керә. Нури Арсланов истәлегенә багышланган бер шигырендә алмагачны ул «чын шагыйрьнең көндәше» дип атый. Башка шагыйрьләр каен, имән образларына ешрак игътибар итсәләр, Ренат Харис өянке һәм карама агачына өстенлек бирә:

Өскә үсмәсен әле, дип,
Баш ботагымны киссәң,
Мин бит ян-якка үсәм!..
Киңлеккә китмәсен, диеп,
Ян якларымны киссәң,
Мин куелыкка үсәм!..
Куелыкка үсмәсен, дип,
Ябалдашымны киссәң,
Мин тамыр якка үсәм?..
Бәгыренә чабыймчы, диеп,
Казып тамырыма төшсәң,
Кабрең өстендә үсәм!

*(«Өянке»)*

Шагыйрьнең үз әйтүе буенча, ул өянке образына татар халкына хас сыйфат-ларны сала. Татар халкының нинди генә авырлык, җәбер күрсә дә, яшәүгә ышанычын югалтмыйча, авырлыкларны җиңә барганлыгын күрсәтергә тели. Лирик персонаж үзен карама дип хис итә, ни өчен?

Җан агачым мәгърүр имән түгел.
Елак тал да, ахры, тар ана,
Минем агач—берминди балта да
Яра алмый торган карама!

*(«Бәхетлерәк була алмас идем»)

«Сүзләр үзләре генә бернинди поэтик кыйммәткә дә ия түгел», дип саный рус галиме В. В. Виноградов. Шуна күрә шагыйрь үзенең әсәрләрендәге хисләрен аерым сүзләргә генә түгел, бәлки сүз тезмәләренә сала. Әнә шундый тоташ поэтик сөйләмдә ул сайлаган сүз яки әйтелмә тезмәләре янадан-яна мәгънә һәм сәнгатьлелек төсмерләр белән янгырый. Икенче бер галим Г. О. Винокур билгеләп үткәнчә, поэтик сөйләмдә «һәрбер механик күренеш жанланып кына калмый, анда очраклы элементлар да законлаша».

## Шигырьнең поэтик синтаксисы

Телнең синтаксик чараларын әсәрнең сурәтлелеген көчәйтү өчен файдалануга поэтик синтаксис диләр. Поэтик синтаксиска төрлечә кабатлаулар: анафора, рәдиф, рефрен, анэпифора, эпанафора, акромонограмма, шулай ук градация, синтаксик, параллелизм, антитеза, хиазм, риторик сорау һәм риторик эндәш, эллипсис, инверсия, күп теркәгечле һәм теркәгечсез сүз тезмәләре, фраза бүленү, әйтеп бетермәү алымнары керә.

Шагыйрь Р. Харис кайбер шигырьләрендә борынгы греклар да, хәзерге европалылар да период дип йөрткән, башта тиндәш өлеше, аннары йомгаклау өлеше булган сөйләм формасын-тезем алымын куллана. Периодның беренче өлешендә интонациянең күтәрелгәннән-күтәрелә баруы, икенче өлештә исә аның түбән төшүе, сөйләү нинди югарылыкта башланган булса, шул хәлгә әйләнеп кайтуы күренә.

Чигәдәге һәр чал чәчне саный китсән,
Һәр чал чәчкә берәр эшне сәбәп итсән,
Һәр сәбәптә гаепләне торсан барлап,
Күнеленнән сүксән аны каргап-каргап,
Барып житсән атасына-бабасына,
Анын туган авылына, каласына,
Туып үскән йорт нигезен ватсан вак-вак...—
Чигән түгел, бөтен башын булыр ап-ак.
Ә йөрәккә кара төшәр шунда тап-тап...

*(«Чигәдәге һәр чал чәчне саный китсән»)*

Бу шигырьдә һәр юл (янәшә рифма) буеннан-буена рифмалашучы формалар ала—алар шарт фигыль, хәл фигыль, исем, рәвеш сүз төркемнәре. Период ахырда фәлсәфи эчтәлекле йомгаклау белән тәмамлана. Шагыйрь ижатында периодка мисаллар шактый, менә тагын берсе:

Туу белән яшьлек арасын
йөгереп, жилеп барасын.
Янып, көеп,
таптап, өеп,
ачып, ябып,
югалтып, табып,
елап, көлеп,
кушып, бүлеп,
ялгап, өзеп,
кунегеп, бизеп—
сизмичә дә каласын

*(«Туу белән яшьлек арасын»)*

Күренгәнчә, шигырь юлларында «ып», «ап», «еп» аффиксларына тәмамланган хәл фигыльләре килә. Бу очракта тартык авазнын үзенә бер төрле эмоциональ янгырашын тоярга була. Шигырьдә басымлы ижекләр булып беренче һәм өченче ижекләр килә. Басым шигырьне жиңеләйтә, аның темпын үстерә, шигырь алга очкан кебек була, период юллары безгә туктарга ирек бирми, бер тында озын катлаулы фразаны әйтеп бетерергә омтылу хисе туа.

Шагыйрьнен башта әйтелгән фикергә исбат рәвешендә килгән тезем-шигыре дә бар:

Һәрвакыт кеше
бирәр нәрсәгә охшаш:
елмайганда—калачка,
елаганда—болытка,
җырлаганда—җилгә,
кайвакытта хәтта берәр илгә,
ел фасылына, чорга.

*(«Көзге»)*

Күренгәнчә, биредә тиндәш кисәкләрне яки тиндәш җөмләне башлап җибәрүче өлеше дә булган период. Мондый синтаксик тезмәне төшенке интонацияле период дип йөртәләр. Менә тагын бер очрак:

Төнлә урамнан барганда
Тәрәзәләрдә ут булмаса—
Өйләр җансыз калган төсле,
Урам җансыз калган төсле,
Шәһәр җансыз калган төсле,
Җир дә җансыз калган төсле,
Үзем ялгыз калган төсле.

*(«Яктылык»)*

Автор кабатлау алымын аллитерация белән бергә үреп тә алып бара:

Язды татар, яза татар, язар,
укыр татар барлык язганын—
бушка китәме соң мең ел буе
җанны тазартуда казгану!

*(«Кан һәм каләм»)*

Китерелгән текстта «з», «с» тартыклары үзенә бер төрле эмоциональ яңгыраш тудыра. Бу горизонталь аллитерация булса, ә менә монысы—вертикаль аллитерация:

Әгәр шатлык җитешмәсә
Һәм баса калса сагыш,
Аксакаллар кинәшен тот—
Кешеләр белән таныш.

Алай да разый булмасаң,
Син ысулны алыштыр—
Үзеңнең шәхесең белән
Кешеләрне таныштыр.

*(«Әгәр шатлык җитешмәсә»)*

Бу шигырь юлларында вертикаль рәвештә кабатланып килгән «ш», «к», «т» авазларының яңгырашын тояргa була.

Строфаның, абзацның җөмләнең бер үк сүз яки сүз тезмәсе белән башлануы һәм бетүе рәвешендә язылган шигырьләр шагыйрь иҗатында байтак (анэпифора алымы).

Синең кулың һаман кайнар әле,
бармак очларында тылсым бар—
кагылдың да кабат эреп акты
йөрәктәге авыр туң сулар.
Актарылды һәм уалды бозлар—
миңа әйткән салкын сүзләрең...
Һәм яз килде кышның уртасына...
Һәм яшәвем минем үзгәрде—
Синең кулың һаман кайнар әле...

*(«Синең кулың һаман кайнар әле»)*

Шагыйрь контекстуаль яктан бер-берсенә мәгънә ягыннан якын торган сүзләрне яки сүз тезмәләрен бер-бер артлы кулланып, эмоциональ яңгырашны арттыра торган градация алымын да еш куллана.

Кеше моңайса,
күк кебек төссез,
җир кебек сүзсез,

су кебек эзсез
була да куя.

*(«Күк моңайса»)*

Бу строфада «з», «с» авазларыннан вертикаль аллитерациясе күренеше дә күзәтелә. Менә тагын бер үзенчәлекле градация—кеше гомеренең мизгелләрен, аның һәртөрле якларын санап чыгу рәвешендә тасвир кылу.

Яшьлек белән картлык арасын
Салмак кына атлап барасың.
Янасың да, көясең дә,
таптыйсың да, өясең дә,
ачасың да, ябасың да,
югалтасың, табасың да,
елыйсың да, көләсең дә,
кушасың да, бүләсең дә...—
сизмичә дә каласың...

*(«Туу белән яшьлек арасын»)*

Төрле мәгънәдәге, әмма бер-берсенә охшаш синтаксик конструкцияләрнең яки шигырь юлларының янәшә куелуы рәвешендәге образлы параллелизм алымы да әледән-әле очрый авторның шигырь текстларында. Образлы параллелизмны ул антитеза буларак яратып куллана.

Тимер кебек тыгыз түгел,
түгел судай сыек мин,
кояш төсле дә була алмыйм,
ай төсле дә боекмыйм.

*(«Сурәтемә 93 нче ел сызыгы»)*

Образлы капма-каршылык тасвиры өчен лексик-морфологик чаралар да ярдәмгә килә:

Буем белән түгел—
уем белән,
йөзем белән түгел—
сүзем белән,
кашым белән түгел—
башым белән,
телем белән түгел—
түлем белән,
өем белән түгел—
көем белән,
гөлем белән түгел—
көлем белән
яулап алачакмын—
үзем беләм...

*(«Буем белән түгел»)*

Биредә югары пафоска корылган шигырь юлларының беренче сүзләре янәшә рифмалашып килә. Ул тулаем берникадәр периодны хәтерләтә (азаккы нәтиҗә). Антитезага корылган һәм сүзгә саран, әмма фикергә бай булган менә тагын бер фәлсәфи шигырь:

Бәхетле дә,
бәхетсез дә ахыр чиктә
бары бер генә бәхет килүен телидер...
Ләкин беркемнең дә
яшәүдән туйю мизгеле
гомер бетү мизгеленә
туры килмидер.

*(«Туры килмидер»)*

Бу шигырьләрне укыгач, Т. Галиуллин сүзләре искә төшә: «Р. Харис әзер калыпларга ябышып ятмый, туктаусыз уйлана, эзләнә. Сибгат Хәким аның иҗатында «җинелчә уйнау» бар, дип язган иде. Әгәр шигырь юллары астында фикер, хис ята икән, нигә уйнатмаска шигырьне?»

Ренат Харис шигырь текстларында аерым сүз яки сүз тезмәләренең төшерелеп калдырылуы махсус стилистик алым буларак каралырга хаклы. Әйтеләсе фикернең болай да аңлаешлы булу очрагында яки фикернең калган өлешен аңлауны тыңлаучы ирегенә калдырганда автор «әйтеп бетермәү» дигән стилистик алымны куллана. Мәсәлән:

Тән керләнә. Мунча кирәк... Чабынасың...
Күз көнләшә... Җан таплана... Яшерәсең...
Фаш итәләр... Оялталар... Тез чүгәсең...
Тел тешлисең, сыгыласың... Баш бирәсең...

*(«Уең белән аякларың тизлеген уз»)*

Бу шигырь юлларында автор бер составлы, билгеле үтәүчеле фигыль җөмләләр кулланган. Ләкин анда үтәүче гомумиләштерелеп бирелә, һәм бу синтаксик алым «әйтеп бетермәү»нең тәэсир көчен тагын да арттыра. Шулай итеп, бу шигырь юллары синтаксик алымнар аша һәркемне «мин дә шулай түгелме» дигән сорау куярга этәрә. Күрсәтелгән поэтик алымнар шигырьне «кыска язу»га китерә.

Без шагыйрьнең иҗат процессында төрле поэтик алымнар куллануына игътибар иттек. Ләкин, нинди генә алымнар кулланылмасын, поэтик әсәр нигезендә барыннан да элек образлылык ята. Сүздән сурәт ясаудагы образлылык беренчел образлылык булса, персонаж образын тудыру—икенчел образлылык. Шуңа күрә, лирик яки эпик поэзиянең текстын структур яктан тикшерү шактый катлаулы процесс. Ә икенче яктан караганда сәнгать әсәре үз эпохасының әдәби жанры таләпләренә җавап биргән очракта гына аның текст төзелешен (структурасын) камил дәрәҗәдә дип була. Ә андый тәмамланган, камил әсәрдә бер элементны да үзгәртергә һәм идея-эстетик фикергә зыян салмыйча гына «детальләрнең» урынын алмаштырырга мөмкин түгел. Шуңа күрә структур чараларны тикшерү барышында образлы алымнарга бик игътибарлы булырга, шулар ярдәмендә шагыйрьнең дөньяны, чынбарлыкны үзенчә күрүен ача белергә кирәк.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: бүгенге укучы нык әзерлекле, әсәрдә шәхесне теге яки бу адымга этәргән сәбәпләрне һәм аларның ахыргы нәтиҗәләрен гомумиләштереп ачып бирүне таләп итә ул. Шуның өчен хәзерге авторга укучыны борчый торган сорауларны ачыкларга, йә булмаса, ул сорауларны укучы алдына куя белергә кирәк. Ә Ренат Харис үзенең әсәрләрендә укучыны борчыган сорауларны куеп кына калмый, аларны ачыклый да һәм әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларны чишүгә этәргеч тә ясый.



*Әбрар Кәримуллинга 75 яшь*

# ФӘННИ БИБЛИОГРАФИЯБЕЗГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Шушы елның 29 маенда Татарстан фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллинга 75 яшь тула.

Дөресен генә әйткәндә, бу күренекле шәхес турында мондый бәләкәй мәкаләгә караганда калын бер китап язу күпкә җиңелрәк булыр иде. Ни өчен дигәндә, аның тәрҗемәи хәле, фәнни-иҗади һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге шулкадәр бай вә күпкырлы ки, аларны бер мәкалә кысаларына сыйдыру һич кенә дә мөмкин түгел. Әгәр: «Кем соң ул Әбрар Кәримуллин?» дигән сорау куелса, ана бер-берләрен кабатламый торган уңлап җавап биреп булыр иде.



*Әбрар Кәримуллин хәрби хезмәттә. Порт-Артур, 1946 ел.*

Хронология буенча барсак, иң элек Әбрар аганың Бөек Ватан сугышы ветераны булуын искә төшереп үтәргә кирәк. Уналты яшендә Сабадагы урта мәктәпне тәмамлагач, ул туган авылы Чәбия-Чүрчидә һәм күрше авылларда тракторчы ярдәмчесе, бухгалтер, укытучы булып эшли. Ә 1943 ел башында аны, әле 18 яше дә тулып җитмәгән егетне, хәрби хезмәткә алалар. Гвардия рядовое минометчы Ә. Кәримуллин—һәрвакыт фронтның алгы сызыгында. Ул өч мәртәбә каты яралана, ләкин дәваланып яңадан сафка кайта. Өйдән чыгып китүенә нәкъ 4 ел дигәндә, күкрәгенә ике «Батырлык өчен», «Германияне җиңү өчен», «Японияне җиңү өчен» медальләре тагып, туган авылына кайтып төшә.

... 1953 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, Әбрар Кәримуллин 11 ел буе Н. И. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәдә эшли, озак вакыт директор урынбасары була. Аның киң колачлы фәнни эшчәнлеге нәкъ менә шушында башланып китә. 1964 елдан бирле галим Г. Ибраһимов исемендәге институтта (хәзер Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли. Менә 10 елга якын инде Республика Дәүләт милли китапханәсендә баш гыйльми хезмәткәр вазифасын да үти.

Ярты гасырга якын дәвам итүче фәнни эшчәнлеге дәверендә Ә. Кәримуллин 400 дән артык хезмәт бастырды, алар арасында кырыклап монография һәм брошюра бар. Иң мөһиме—галим татар гуманитар фәннәре өлкәсендә берничә зур яңа юнәлешкә юл салды. Әле кайчан гына без татар милли китабы турында чынлыкта мәгълүматсыз яши идек. Озак еллар төрле китапханәләрдә эзләнү, архивларда казыну, кулъязма әдәбият һәм басма сүз тарихын беренчел чыганакларга таянып өйрәнү нәтиҗәсендә Ә. Кәримуллин татар китабының күпгасырлык катлаулы тарихын тозек һәм эзлекле бер системага салып бәян итеп чыкты. Аның «У истоков татарской книги», «Татарская книга пореформенной России», «Татарская книга начала XX века»,

«Становление и развитие татарской советской книги» кебек фундаменталь тикшеренүләре безнең илдә генә түгел, ә бөтен дөньяда зур кызыксыну белән каршы алынды һәм югары бәя алды. Алар аша Әбрар Кәримуллин милли китап теориясен үстерүгә дә зур өлеш керткән абруйлы китап белгече булып танылды, бик уңышлы рәвештә докторлык диссертациясе яклады. Бу белгечлек буенча диссертация Советы озак еллар буена илнең бер генә урынында—В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсендә генә эшләде. Әбрар ага сиксәненче елларда бу Советта әгъза да булды. Китап белгечләре арасында ил буенча нибары 6 фән докторы бар иде.

Инде әйткәнебезчә, Ә. Кәримуллин—киң колачлы галим. Ул татарларның һәм гомумән төрки халыкларның килеп чыгышы, аларның башка кабиләләр белән элемтәбәйләнешләре, борынгы мәдәниятләре һ. б. ш. мәсьәләләр буенча күп эзләнүләр алып бара. Шул ук вакытта, ерак тарих белән тирәнтен мавыгудан тыш, бүгенге иң актуаль мәсьәләләрне тикшерүдә дә академик Кәримуллин зур өлгерлек күрсәтә. Ул—татар халкының милли бәйсезлеге, Татарстанның чын дәүләт суверенлыгы, туган телебезнең дәүләт теле буларак югары үсешкә ирешүе өчен армый-талмый көрәшүче кыю публицист һәм җәмәгать эшлеклесе.

Әбрар Кәримуллинның фәнни хезмәтләре һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге безнең илдә генә түгел, бәлки бөтен дөньяда киң билгеле. Ул—Халыкара биографик үзәк (Англия), Америка биография институты редакция советларында хакыйкый әгъза, Гуманизм һәм гаделлек өчен көрәш рыцарьлары конфедерациясенең халыкара парламенты Дәүләт секретаре (Австралия) һ. б. Бу оешмаларның күп кенә дәрәҗәле исемнәренә һәм бүләкләренә ия.



*Әбрар Кәримуллин бер төркем зыялылар арасында. Артта басканнар: (сулдан) Нил Юзиев, Равил Фәйзуллин, Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев. Утырганнар: Әбрар Кәримуллин һәм Мөхәммәт Мәһдиев. (1991 ел).*

Ниһаять, без Әбрар Кәримуллин эшчәнлегенең аеруча мөһим бер тармагына беркадәр кинрәк тукталып узуны зарур дип саныйбыз. Барыбызга да яхшы мәгълүм булганча, Әбрар ага—татар фәнни библиографиясенә нигез салган һәм бу өлкәдә 40 елдан артык җиң сызганып эшләп килүче галим. Мәдәният һәм фән тарихын өйрәнүдә һәм аларны алга таба үстерүдә библиографиянең нинди зур роль уйнавын озаклап аңлатып торуның кирәге юктыр. Образлы итеп әйтергә теләсәк, библиографияне «фән ачкычы» яки «басма сүз океанындагы маяк» дип атап була.

Безнең язма культурабызның һәм басма китапларыбызның мең ел диярлек гарәп графикасы белән яшәп килүен, аларның киң катлам укучылар өчен билгеле булмавын искә алсак, әлеге «ачкыч» һәм «маяк»ның безгә никадәр кирәклеге тагын да ачыграк аңлашылыр.

Библиограф һөнәрен Ә. Кәримуллин университет тәмамлап Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәгә эшкә килгәч үзләштерә башлый. Күпмеңләгән китаплар, газета-журналлар, кульязма чыганаклар дөньясына килеп кергәч тә ул үзенең бу өлкәдә махсус белеме юклыгын ачык тоя һәм Ленинград дәүләт мәдәният институтының китапханә факультетына читтән торып укырга керә. Әбугалисина белән Әбелхарис мәгарәдән чыкмыйча белем алып яткан шикелле, Әбрар да көне-төне диярлек китапханәсеннән китеп тормый. Тиздән аның библиографик хезмәтләре бер-бер артлы мәйданга килә башлый. Алар үзләренең байлыгы, тулылыгы һәм тематик төрлелеге белән тиз арада фәнни-әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәләр. Шул рәвешчә, татар әдәбияты һәм аның тарихы, башка халыкларның әдәбиятлары белән бәйләнешләре; татар теле һәм тел белеме; татар театры; халык иҗаты һәм фольклор фәне; татар галимнәренең һәм әдипләренең персоналияләре буенча укучылар кулына бай библиографик белешмәләр килеп ирешә. Әгәр саннар теленә күчерсәк, шундый картинага тап булабыз: Ә. Кәримуллин библиография өлкәсендә 26 хезмәтнең (шул җөмләдән 19 китапның) автор-төзүчесе булып тора. Болардан тыш, тагын 6 китапта ул фәнни җитәкче һәм оештыручы сыйфатында катнаша. Бу күрсәткечләрдә 60 мең чыганак исәпкә алынган. Әле галимнең матбугатка чыгару өчен тулысынча әзер тагын 4 хезмәте булуын да әйтергә кирәк. Аларда татар әдәбияты буенча 1960-1978 елларда дөнья күргән хезмәтләр (4000 исемдә); революциягә кадәрге «Аң» журналында басылган әдәбиятка кагылышлы язмалар (1000), татар филологиясе буенча якланган диссертацияләр һәм аларның авторефератлары (400) һәм Анкарада чыккан «Kazan» журналындагы материаллар күрсәтелгән. Әбрар аганың революциягә кадәрге татар китапларының 30 меңләп исемнән торган картотекасы да бар. Җыйнап әйткәндә, ул үзенең библиографик эшчәнлегендә 110 меңнән артык басма әсәргә таяна. Шунсын да искәртик: мондый титаник хезмәтнең зур өлешен Ә. Кәримуллин фәнни оешмаларның эш планнарына кертмичә, читтән берниндн ярдәм алмыйча, бары тик үзенең фидакарьлеге бәрабәренә башкарып килә.

Ни аяныч, кайбер «акыллы баш галимнәр» библиография төзүне лаборантлар башкара торган техник эш дип карыйлар, ә үзләрен исә андый «вак-төяктән» өстен торучы теоретиклар санап һаваланалар. Кагыйдә буларак, андыйларның диссертацияләрендә һәм китапларында библиографик наданлык ярылып ята. Бу бигрәк тә чит телләрдәге чыганакларны дөрес күрсәтә белмәүдә чагыла. Әбрар ага гомере буе мондый ямьсез күренешләргә каршы көрәш алып бара. Үзе редакторы яки консультанты булган библиографияләрне «адәм төсенә» кертү белән бергә, ул библиография белеменең нигез принципларын пропагандалау, аларны татар телендәге хезмәтләрдә куллану ысулларын камилләштерү юнәлешендә зур эш башкара. Бернича дистә ел инде, галим Татарстан Дәүләт китап палатасының гыйльми советы әгъзасы, анда әзерләнә торган басмаларның фәнни мөхәррире булып тора. 1957-1963 елларда Казан университеты студентлары белән библиография нигезләре буенча дәресләр дә алып барды. Үз эшенең чын фанатигы булган Әбрар ага Казанда милли библиография үзәге оештыру турында хыяллана. Әйтик, аны Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать яки Энциклопедия институтларында төзеп булыр иде. Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе каршында библиография өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләү өчен аспирантура ачуны да галим күптән хәл ителергә тиешле мәсьәлә дип саный.

Шушы рәвешчә тиешле шартлары һәм мөмкинлекләре тудырылса, милли библиографиябезне үстерү, аны заман таләпләренә якынайту максатында бик зур эш җәелдерү мөмкинлеге ачылыр иде. Хәзерге вакытта без нинди библиографик күрсәткечләргә мохтаҗ? Әбрар Кәримуллин фикеренчә, алар түбәндәгеләр:

—Революциягә кадәрге һәм аннан соңгы татар журналларында басылган мәкаләләр күрсәткечләрен төзү.

—Күренекле татар әдипләренең һәм галимнәренең Библиографияләре сериясен планлы рәвештә чыгарып бару.

—«Татар әдәбияты башка халыклар телендә» дигән күрсәткеч әзерләү.

—Татар теле, әдәбияты, тарихы буенча дөнья халыклары телләрендә чыккан материалларның библиографиясен булдыру.

—Татар музыкасы һәм сынлы сәнгате буенча библиография әзерләү.

—Революциягә хәтле чыккан татар китапларының аңлатмалы күрсәткечен (1722—1917) төзү...

... Әнә шундый олы иҗат планнары белән янып яши Әбрар ага. Ана барлык-барлык хыялларын тормышка ашырырга насыйп булсын иде!

Халыкта «Итекчене итеге юк» дигән мәкаль бар. «Бакча иясенә түтәл юк» дип тә әйтәләр. Бу гыйбарәләр Ә. Кәримуллинга да бик туры килеп тора: күпме галимнәрнең, әдипләрнең библиографияләрен төзегән булса да, аның үз хезмәтләренең күрсәткечләре юк диярлек. Ә бит ул хезмәтләр милли тарихыбызны, телебезне, әдәбиятыбызны, сәнгатебезне өйрәнүчеләр һәм пропагандалаучылар өчен дә, бу мөһим мәсьәләләр белән ихлас кызыксынучыларга да өстәл китаплары булып торырга тиешләр. Шушы «гаделсезлекне» бераз булса да төзәтү йөзеннән, журнал укучыларына Әбрар Кәримуллинның библиографик хезмәтләренең аңлатмалы күрсәткечен тәкъдим итәбез. Кирәкле басманы эзләп табу һәм соратып алу унай булсын өчен, китап нинди телдә басылган булса, аны чыгаруга караган мәгълүматлар да (исеме һ. б.) шул телдә бирелә.

## I. Ә. Кәримуллинның үз авторлыгында гына чыгарган китаплары

**1. Николай Александрович Ливанов: («Библиографический указатель с «Кратким очерком жизни и деятельности» Н. А. Стекольщикова) /КГУ. Научная библиотека им. Н. И. Лобачевского.—Казань, 1956.—29 с.**

Академик Лысенко инициативасы буенча КПСС ҮК тарафыннан эзәрлекләүләргә дучар ителгән күренекле биолог-галим Н. А. Ливановның басма хезмәтләре исемлеге. 250 гә якын хезмәт исәпкә алынган. Хронологик тәртиптә урнаштырылган.

**2. Библиография литературы по татарскому языкознанию (Казанский гос. ун-т. Научная библиотека им. Н. И. Лобачевского.—Казань, 1957.—39 с.**

Татар тел белеме буенча XVIII йөз ахырыннан башлап рус телендә дөнья күргән 976 хезмәт исәпкә алынган. Газета-журнал мәкаләләре кертелмәгән. (Монда керми калган материаллар «Татар тел белеме библиографиясе» дигән басмада урын алган.—Казан, 1958.—Б. 89-100).

Белешмәдә авторның «Сүз башы» һәм «Авторлар, автордашлар, рецензентлар күрсәткече» бирелгән.

Татар тел белеме буенча рус телендә басылган әдәбиятның беренче библиографиясе.

**3. Татар тел белеме библиографиясе. (Казан дәүләт ун-ты. Н. И. Лобачевский ис. гыйльми китапханә.—Казан: Тат. китап нәшр., 1958.—116 б.**

Татар тел белеме буенча революциягә кадәрге хезмәтләрнең исемлеге. Барысы 1088 чыганак теркәлгән. Аларның 973 е татар, калганнары—рус телендә дөнья күргән. Революциягә хәтле чыккан барлык газета-журналларда басылган материаллар тулысынча каралмаган, тел белеменә караган рецензияләр гомуми исәпкә кертелмәгән, рецензияләр төрле хезмәтләр астында китерелгән.

Библиография «Авторлар, рецензентлар, редакторлар» күрсәткече, белешмәне төзегәндә кулланылган вакытлы матбугат исемлеге, авторның кереш сүзе белән тулыландырылган.

Белешмәгә кергән материаллар «Революциягә чаклы чыккан әдәбият», «Революциядән соң чыккан әдәбият» дип ике бүлектә китерелгән. Алар эчендә әдәбият тел белеменең фәнни классификациясе буенча урнаштырылган. Татар тел белеме өлкәсендә эшләгән шәхесләрнең персоналиясе дә бар. Тел турында татар әдипләре хезмәтләре аерым күрсәтелгән.

Бу хезмәт татар тел белеме өлкәсендә беренче фәнни библиография.

**4. Муса Джалиль: (Библиография): (1919-1961) (Казанский гос. ун-т. Научная библиотека им. Н. И. Лобачевского.—Казань, 1961.—77 с.**

М. Җәлил әсәрләре һәм аның турындагы әдәбият күрсәткече. «Татар телендә», «Рус телендә», «Чит илләр телләрендә» дигән бүлекләрдән тора. Шагыйрьнең тормышы һәм эшчәнлеге турында мәгълүматлар китерелгән. М. Җәлил турындагы хезмәтләр авторларының һәм шагыйрьнең тәржемәчеләренең исемнәр күрсәткече бирелгән. Авторның «Сүз башы» бар.

Рецензияләр белән бергә 1000 нән артык чыганак исәпкә алынган.

Шагыйрьнең әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның беренче библиографиясе.

**5. Татар әдәбияты: (Фольклор, әдәбият белеме һәм әдәбият тарихы): Библиография: 1917-1959 (Казан дәүләт ун-ты. Н. И. Лобачевский ис. гыйльми китапханә.—Казан: Тат. китап нәшр., 1961.—216 б.**

Рецензияләрне исәпкә алмаганда, 2445 чыганак тасвирланган. Белешмәне төзегәндә файдаланылган журналлар исемлеге бирелгән. Газета материаллары исәпкә алынмаган. Библиография «Автор, соавтор һәм рецензентлар» күрсәткече белән тулыландырылган. Төзүченең кереш мәкаләсе бар.

Татар әдәбият белеме, тарихы буенча беренче библиографик белешмә.

**6. Татарская литература в переводах на русский язык: (Библиографический указатель: 1917-1960).—Казань: Изд-во КГУ, 1962.—91 с.**

Китаплар, җыентык һәм альманахлар басмалары. Бүлекләр: Авторларның әсәрләре һәм алар турында әдәбият.—Альманахлар һәм җыентыклар.—Әдәбият белеме: китаплар һәм мәкаләләр. Рецензияләрне исәпкә алмыйча, 818 чыганак күрсәтелгән. Авторның «Сүз башы» белән.

Татар әдәбияты әсәрләренең русча тәржемәләре буенча беренче библиографик хезмәт.

**7. Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917-1960/ Казан дәүләт ун-ты.—Н. И. Лобачевский ис. гыйльми китапханә.—Казан: 1962.—106 б.**

Күрсәткечкә 233 әдәби җыентык һәм альманах кергән. Һәр басманың эчтәлеге, авторлары һәм әсәрләре санап үтелгән. Төзүченең кереш сүзе белән.

Татар телендә чыккан әдәби җыентыклар турында беренче библиографик хезмәт.

**8. СССР һәм чит ил халыклары әдәбияты, фольклоры һәм сәнгате: Татар теленә тәрҗемәләр: 1917-1962 /Казан дәүләт ун-ты.—Н. И. Лобачевский ис. гыйльми китапханә.—Фәнни ред. Н. Г. Юзеев.—Казан: ун-т нәшр., 1963.—337 б.**

Белешмәдә аерым китап булып дөнья күргән 1165 басма тасвирланган, 4906 чыганак теркәлгән. Алар «СССР халыклары әдәбиятлары», «Чит ил халыклары



*Әбрар Кәримуллин Американың Гарвард университеты профессоры, Шәрык белгече Ричард Фрайн белән аның эш бүлмәсендә. 1988 ел.*

әдәбиятлары» дигән ике бүлектә тасвирлана. Белешмәдән файдалануны җиңеләйтү өчен рецензентларның, әдәби-тәнкыйть әсәрләренең, тәрҗемәчеләрнең алфавит күрсәткечләре кертелгән.

**9. Татар матур әдәбият библиографиясе: (1917-1960) /Казан дәүләт ун-ты. Н. И. Лобачевский ис. Гыйльми китапханә.—Фәнни ред. И. Нуруллин.—Казан: ун-т нәшр., 1964.—155 б.**

Татар телендә китап булып дөнья күргән әсәрләрнең күрсәткече. Басмалар исемнәре һәм авторлар фамилияләре алфавит буенча урнаштырылган. Җыентык итеп чыгарылганнарының эчтәлеге бирелгән. 500 гә якын авторның аерым китап булып чыккан 1974 басмасы күрсәтелгән, аларның гомуми тиражы 15 миллион тирәсе. Белешмәдә авторлар, төзүчеләр, китапларга кереш сүз язучыларның алфавит күрсәткече кертелгән.

Татар телендәге матур әдәбият басмаларын эченә алган беренче белешмә.

**10. Татар сәхнәсе: Әдәбият күрсәткече: (1917-1967).—Татарская сцена: Указатель литературы: (1917-1967) / Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институты.—Фәнни ред. Һ. Мәхмүтов.—Казан: Татар. китап нәшр., 1979.—332 б.**

Аерым китап булып һәм вакытлы матбугатта татар һәм рус телләрендә басылган 7949 чыганак теркәлгән. Өлешчә чит илләрдә чыккан материаллар да тасвирланган. «Гомуми бүлек», «Татар театры турында», «Татар сәхнә осталары», «Үзешчән сәнгать», «Драматургия, жанр, репертуар» дигән бүлекләрдән тора. Һәр татар театры, шул исәптән колхоз-совхоз театрлары, филармония һәм башка темаларга караган чыганаклар махсус төркемләнә. Татар сәхнә осталары персоналиясе дә кертелә. Татар театры турында Башкортстанда басылган материаллар аерым бүлектә тупланган. Куелган спектакльләргә басылган рецензияләр күрсәткече, авторның кереш мәкаләсе урнаштырылган.

**11. Лев Николаевич Гумилев: (Био) библиографический указатель /Респуб. научная библиотека им. В. И. Ленина Татарской АССР.—Сост. и автор статьи о Л. Н. Гумилеве: А. Г. Каримуллин.—Отв. ред. Р. И. Валиев.—Казань, 1990.—33 с.**

Борынгы төркиләр тарихы буенча фундаменталь тикшеренүләр авторы Л. Н. Гумилевның хезмәтләре хронологик тәртиптә—еллар буенча тасвирлана. 1948-1990 еллар арасында дөнья күргән хезмәтләр исәпкә алынган. Башка материаллар «Шигърият. Шигъри тәрҗемәләр», «Мөхәррирлек, төзү, искәрмәләр» исемнәре астында саналган. Галимнең хезмәтләре буенча бәяләмәләр һәм бәхәсләр, шулай ук Л. Н. Гумилев турындагы әдәбият аерым күрсәтелгән. Барысы 300 ләп чыганак теркәлгән. Галимнең Ә. Кәримуллин тарафыннан язылган тәрҗемәи хәле урнаштырылган. Бу аның СССРда басылган беренче биографиясе һәм библиографиясе.

**12. Татарский фольклор: Аннотированный указатель литературы: 1612-1981.—Татар фольклоры: Аннотацияләнгән әдәбият күрсәткече: 1612-1981. В двух частях—Ике кисәктә /Фәнни ред. Х. Ш. Мәхмүтов.—ТФА. Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институты.—Казан, 1993. I кисәк—136 б. 2 кисәк—134 б.**

Татар, рус һәм Көнбатыш Европа телләрендә басылган 2092 чыганак (рецензияләрдән башка) исәпкә алынган. Алар басылу еллары буенча урнаштырылган. Ел эчендә башта китаплар, аннан вакытлы матбугат материаллары кертелә.

Белешмәдә өстәмә рәвештә жанрлар һәм темалар, шулай ук географик, авторлар, төзүчеләр һәм тәрҗемәчеләрнең исемнәр күрсәткечләре бирелә. Авторның һәм фәнни редакторның күләмле кереш мәкаләсе бар.

Татар халык иҗаты һәм фольклор белеме буенча беренче библиографик күрсәткеч.

**13. Мирза Исмагилович Махмутов: Академик Российской Академии образования. Академик Академии наук Республики Татарстан: Библиографический очерк /Вступ. статья Д. М. Шакировой, М. А. Чошанова.—Сост. А. Г. Каримуллина, он же отв. редактор—АНТ, Отделение социально-экономических наук. Татарско-американский региональный колледж.- Казань, 1996.—74 с.—Библиография ученых Татарстана.**

Хезмәтләр күрсәткече хронологик тәртиптә урнаштырылган. Галимнең тәрҗемәләре, аның җитәкчелегендә якланган кандидатлык, докторлык диссертацияләре исемлекләре, М. И. Мәхмүтов турындагы әдәбият, аның редакциясендә чыккан китаплар, чит илләрдәге конференцияләрдә һәм симпозиумнарда ул ясаган докладлар да күрсәтелгән. Барысы 543 чыганак исеме кертелгән.

## II. Ә. Г. Кәримуллинның җитәкче, оештыручы, төзүчеләрнең берсе буларак чыгарган китаплары

**14. Диссертации, защищенные в Казанском государственном университете: Библиографический указатель /КГУ. Научн. б-ка им. Н. И. Лобачевского.— Составители: И. В. Власова, И. В. Емельянова и др.—Под ред. Г. Н. Вульфсона и И. В. Емельяновой.—Казань: Изд-во КГУ, 1960.—202 с.**

Казан университетында 1934 елдан 1959 елга кадәр якланган барлык диссертацияләр (584) һәм университет галимнәре тарафыннан КДУ дан читтә якланган диссертацияләр исәпкә алынган. Аларның исемнәре Югары аттестация комиссиясе (ВАК) кабул иткән фән тармаклары буенча урнаштырылган. Татар телендә якланган диссертацияләр татарча тасвирланган. Хезмәт диссертантларның һәм фәнни җитәкчеләрнең исемнәр күрсәткече белән тулыландырылган.

КДУ да якланган диссертацияләр турында беренче библиография.

**15. История Татарской АССР: (С древнейших времен до наших дней): Указатель советской литературы: 1917-1959 /КГУ. Научн. б-ка им. Н. И. Лобачевского.—Под ред. С. И. Даишева.—Составители: Е. М. Мишина, М. Х. Ахмадиева, И. В. Власова и др.—Казань, 1960.—320 с.**

Рус һәм татар телләрендәге 5777 китап һәм мәкаләләр шул ук телләрдә тасвирланган. Әдәбият Русиядә тарих фәне буенча кабул ителгән классификация нигезендә тәртипкә салынган. Һәр басманың исеме ике телдә: русча һәм татарча бирелгән. Авторларның, рецензентларның, төзүчеләрнең, тәрҗемәчеләрнең исемнәр күрсәткече бар.

Татарстан АССР һәм татар халкы тарихының беренче фәнни библиографиясе.

**16. Муса Джалиль: Библиографический указатель: 1919-1973 / Казан. гос. ун-т. Научн. б-ка им. Н. И. Лобачевского.—Сост.: Н. А. Ахметзянова, Р. С. Камалова, А. Г. Каримуллин.—Казань. Изд-во КГУ.—1976.—220 с.**

Титул бите һәм сүз башы татар һәм рус телләрендә. Барысы 2691 чыганак (шагыйрьнең әсәрләре һәм аның турындагы әдәбият) исәпкә алынган. Материал басмаларның төрләре һәм жанрлар буенча төркемләнгән. Газета чыганаклары һәм тәрҗемәләр аерым күрсәтелгән. Шагыйрь турындагы бай әдәбият чорларга бүлеп бирелгән. Аның образы гәүдәләнгән әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, исемнәр, әсәрләре тәрҗемә ителгән телләр күрсәткечләре бар.

**17. Каримуллин А. Г., Лаптев Б. Л. Что читал Н. И. Лобачевский: Записки книг и журналов, выданных Н. И. Лобачевскому из библиотеки Казанского университета / Под редакцией проф. В. В. Вишневского.—Казань: Изд-во КГУ, 1979.—127 с.**

Китапханәнең архив мәгълүматлары нигезендә, Н. И. Лобачевскийның 1830-1855 елларда китапханәдән өенә нинди китаплар алып укуы ачыклана. Башлыча алар физика, математика буенча чит ил басмалары, дөнья һәм рус әдәбияты классиклары әсәрләре дә байтак. Барысы 840 чыганак күрсәтелә. Кереш мәкаләдә Н. И. Лобачевский шәхесенә кагылышлы кызыклы мәгълүматлар китерелә. Бу китап фәнни даирәләрдә бөек геометр турында яна сүз буларак бәяләнде.

**18. Мирфатых Закиевич Закиев: (Библиография трудов) /АНТ. Отд-ние гуманитарных наук.—Составители: А. Г. Каримуллин, Г. Ш. Зимагулова, Г.З.Закирова, Ш. А. Каримуллин.—Отв. ред.: А. Г. Каримуллин.—Москва, 1995.—176 с.— Библиография ученых Татарстана.**

Галимнең татар, рус, Русия һәм чит ил халыклары телләрендә басылган 635 хезмәте исәпкә алынган.

Тормышы һәм хезмәтенең төп даталары, фәнни, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге турындагы очерк рус һәм инглиз телләрендә бирелгән. Материаллар «Китаплар, мәкаләләр, рецензияләр», «Фәнни мөхәррирлек һәм төзүчелек эшчәнлеге», «Галим җитәкчелегендә якланган авторефератлар» дигән бүлекләрдә урнаштырылган. М. Зәкиев тәзеткән биналар һәм корылмалар исемлеге бирелгән.

**19. Указатель трудов ученых Института языка, литературы и истории Академии наук Республики Татарстан: 1939-1986 / АНТ ИЯЛИ.—Казань: Изд-во «Фикер», 1997.—504 с.**

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең

рус, татар һәм Көнбатыш Европа телләрендә басылган 5702 хезмәте исәпкә алынган (аларга рецензияләр бу санга керми).

## III. Ә. Г. Кәримуллинның төрле җыентыкларда басылган библиографияләре

**20. М. Гайнуллин хезмәтләренең хронологик күрсәткече һәм аның турында әдәбият // М. Гайнуллин. Татар әдипләре.—Казан, 1978.—Б. 259-278.**

Күренекле әдәбият белгече, профессор, педагог, җәмәгать эшлеклесенең 1977 елга хәтле дөнья күргән хезмәтләре, аның турындагы мәкаләләр теркәлгән (350 гә якын исемдә).

**21. Хронологический указатель трудов Николая Федоровича Катанова // Николай Федорович Катанов: Материалы и сообщения Хакас. НИИ языка, литературы и истории.—Сост. Н. Г. Доможаков.—Абакан: Хакас. кн. изд-во.—1958.—С. 185-215.**

Күренекле тюрколог, Казан университеты профессоры Н. Ф. Катановның (1862-1922) үзе исән чакта: 1885-1921 елларда басылган әсәрләре һәм аның турында әдәбият (300 ләп исемдә) исәпкә алынган.

**22. Нәкый Исәнбәт әсәрләре библиографиясенә өстәмә // Әдип һәм галим / Төз. Х. Гобәйдуллин.—Казан: Татар. китап нәшр., 1969.—Б. 114-123.**

Гөлсем Исәнбәт төзегән библиографиядә әдипнең 1960 елга кадәр чыккан хезмәтләре теркәлә (ләкин тулысынча түгел). Ә. Кәримуллин библиографиясендә шуннан соң дөнья күргән әсәрләр исәпкә алынган. Алар «Аерым басмалар», «Вакытлы матбугат һәм төрле җыентыкларга кергән әдәби әсәрләр», «Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре», «Тәрҗемәләр» һәм «Н. Исәнбәт иҗаты турында» дигән бүлекләрдә тупланган (якынча 200 исемдә).

**23. Сибгат Хәким әсәрләренең сайланма библиографиясе һәм аның турында әдәбият // Сибгат Хәким.—Казан: Татар китап нәшр., 1971.—Б. 178-192.**

Әдипнең 1970 елга хәтле чыккан хезмәтләренең күрсәткече. Гәрчә төзүче тулы библиография тапшырса да, нәшриятта кыскартып чыгарыла (250 ләп чыганак теркәлгән).

**24. Каюм Насыйриның басылып чыккан хезмәтләре // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 томда.—Т. 2.—Казан: Татар. китап нәшр., 1975.—Б. 289-312.**

Беләшмәнең беренче өлешендә К. Насыйриның 1917 елга кадәр чыккан хезмәтләре, икенче өлештә—революциядән соң басылганнары китерелә («Китаплар», «Вакытлы матбугат һәм җыентыкларга кергән әсәрләр», «Каюм Насыйри турында чыккан әдәбият» дигән бүлекләрдә).

Бөек мәгърифәтче турында иң тулы күрсәткеч. Барысы 500 ләп чыганак теркәлгән.

**25. Гариф Ахунов әсәрләренең хронологик күрсәткече һәм аның турында әдәбият // Г. Ахунов. Әсәрләр: Дүрт томда.—Том 4.—Казан: Татар. китап нәшр., 1984.—Б. 461-487.**

Әдипнең 1951-1982 елларда дөнья күргән әсәрләре һәм аның турындагы хезмәтләр (шул исәптән рецензияләр) теркәлгән. Алар хронологик тәртиптә, еллар буенча китерелә. Тәрҗемәләре, автор төзегән басмалар, инсценировкалары, аның турындагы әдәбият аерым бүлекләрдә тупланган. Беләшмәдә якынча 650 хезмәт тасвирлана.

**26. Гомәр Бәширов әсәрләренең хронологик күрсәткече һәм аның турында әдәбият // Г. Бәширов. Әсәрләр: Дүрт томда.—Том I.—Казан: Татар. китап нәшр., 1984.—Б. 492-525.**

Әдипнең 1931 елдан 1983 елга хәтле чыккан әсәрләре тасвирлана, аның тормышына һәм иҗатына багышланган хезмәтләр теркәлә. Алар хронологик тәртиптә (еллар эчендә башта китаплары, аннан җыентыкларда, вакытлы матбугатта чыккан әсәрләре) китерелә. Әдипкә багышланган тикшеренүләр, рецензияләр «Аның тормышы һәм иҗаты» дигән бүлектә урын алган. Якынча 800 ләп чыганак күрсәтелгән.

## IV. Ә. Г. Кәримуллин җитәкче һәм фәнни редактор булган басмалар.

**27. Мишина Е. М. Систематический указатель статей к периодическим изданиям Казанского ордена Трудового Красного знамени университета им. В. И. Ульянова-Ленина: 1815-1947: (Кроме «Ученых записок», «Известий общества археологии, истории и этнографии» и «Казанских вестей») / КГУ. Научн. б-ка им. Н. И. Лобачевского.—Научн. ред. А. Г. Каримуллин.—Казань, 1960.—279 с.**

Казан университетының периодик басмаларында (өстә санап үтелгәннәреннән тыш, аларга аерым күрсәткечләр багышланган) дөнья күргән 4659 мәкалә исәпкә алынган. Авторлар, соавторлар, рецензентлар, референтлар, тәрҗемәчеләр һәм редакторларның исемнәр күрсәткече бирелгән.

**28. Татар китаплары: Библиографик күрсәткеч.—I том: 1917 ноябрь—1929/ ТАССР дәүләт китап палатасы.—Төз. Ә. Хисамова һ. б.—Казан, 1979.—382 б.**

Күрсәтелгән елларда Татарстанда һәм СССРның башка регионнарында басылган китапларның ретроспектив библиографиясе. Анда татар телендә гарәп шрифтлары белән басылган 4089 китап теркәлгән. Шулардан 1017 сенең тиражы ачыкланмаган. Калганнарының гомуми тиражы 15,5 миллион данә. Белешмә «Китап исемнәре күрсәткече», «Исемнәр күрсәткече», «Басылу урыннары күрсәткече» белән тулыландырылган.

**29. Татар китаплары: Библиографик күрсәткеч.—2 том: 1930-1940 / Татарстан АССР дәүләт китап палатасы.—Төз. Ә. Хисамова һ. б.—Казан: Татар. китап нәшр.,—1986.—480 б.**

Белешмәдә барлыгы 5494 басма теркәлгән, шулардан 74 енен тиражы ачыкланмаган. Калганнарының гомуми тиражы—55 миллион данә. Хезмәт «Авторлар, рецензентлар, тәрҗемәчеләр һәм төзүчеләрнең исемнәр күрсәткече», «Китап исемнәре күрсәткече», «Китапларның басылу урыннары күрсәткече» белән тулыландырылган.

**30. Разил Исмәгыйль улы Вәлиев: Библиографик белешмә.—Разиль Исмагилович Валеев: Библиографический указатель /Татарстан Милли китапханәсе.—Национальная библиотека Республики Татарстан.—Сост. Г. З. Закирова.—Казань—Москва, 1996.—256 с., с илл. и I л. портр.—Библиография писателей Татарстана.**

Татар, рус, СССР һәм чит илләр халыклары телләрендә басылган 942 әсәр теркәлгән. Алар басма төрләре һәм жанрлар буенча аерылганнар («Поэзия һәм проза», «Җырлар», «Драматургия», «Публицистика һәм әдәби тәнкыйть», «Интервьюлар», «Автор тәрҗемәләре», «Нәширлек эшчәнлеге», «Аның турындагы әдәбият»).

Тормышы һәм эшчәнлегенең төп даталары һәм кыскача биографик очерк татар, рус һәм инглиз телләрендә басылган.

**31. Фуат Ашрафович Ганиев: (Библиография) / АНТ. Отделение гуманитарных наук.—Ред. коллегия: М. З. Закиев, А. Г. Каримуллин, Ш. Н. Асылгараев.—М., 1996.—96 с. (Биобиблиография ученых Татарстана.)**

Белешмәдә галимнең 219 хезмәте исәпкә алынган. Алар «Китаплар, мәкаләләр, рецензияләр», «Тәрҗемәләр», «Төзүче», «Редакторлык эшчәнлеге» дигән бүлекләрдә тупланган. Ф. Ганиев укыган фәнни докладлар, ул җитәкчелек иткән һәм оппонент булган диссертацияләр исемлекләре, исемнәр күрсәткече урнаштырылган. Тормышы, эшчәнлеге һәм галим турында кыскача очерк рус, инглиз телләрендә басылган.

**32. Сәлам Хатыйб улы Алишев.—Салям Хатыпович Алишев: Библиография / Татарстан фәннәр академиясе. Тарих институты.—Научн. ред. А. Г. Каримуллин.—Вст. статья Р. Ф. Галлямовой.—Сост. С. Шамси, И. Мулюков, Р. Галлямов.—Казан, 1999.—68 б.—(Биобиблиография ученых Татарстана).**

Тормышы һәм эшчәнлеге турындагы очерк—татар һәм рус телләрендә.

Белешмәдә галимнең 235 хезмәте (аларга рецензияләр бу санга кертелмәгән) тасвирланган. Басылган әсәрләр—китаплар, мәкаләләр, рецензияләр—еллар буенча урнаштырылган. Фәнни редакторлык һәм төзүчелек эшчәнлеге, галим турындагы әдәбият аерым китерелгән.

**Хуҗи МӘХМҮТОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## ҮТКӘННӘРДӘН БЕЗГӘ ГАМЬНӘР КАЛГАН

Бу китапны инде бер укыган идем мәллә соң? Яисә анда тасвирланган вакыйгаларны, авторның куанычларын һәм сагышлы борчылуларын үзем кичердемме? Никадәр үз алар безгә—авыл укучыларына. Ә вакыйгаларда катнашкан кешеләр бик таныш түгелләр, безнең дус-ишләрдән кайсы яклары беләндер аерылалар. Без дә «Тарзан» сериалын үлеп ярата һәм шуны тәрәзәдән генә булса да карау өчен күрше авыл мәчетенә йөри идек. Аннары Тарзан булып кычкырулар... Сабакташ малайлардан Габдрахман белән Харис бигрәк килештереп кычкыралар иде. Харис бик матур җырлаучы да шул. Тарзандай кычкырып Карадуган тегермәненең биек субаеннан сикергән чакта су астындагы агач төбенә бәреп башын ярды. Һәм шуннан башсызрак булып калды да бугай. Тегермән дә бетте.

Тагын—язын колхоз басуыннан черек бәрәңге казып михнәтләнүләр... Автор аны йөгертеп кенә язып үтә. Ә мин яз башының өсте генә җебегән, ялан аяк табаны исә астагы бозга басып йөри торган бәрәңге басуларының җелекләргә үтеп калган суыгын әле дә бар күзәнәгем белән тоям... Шулай—туфракның җылынганын көтә алмыйсың. Беренчедән, өйдә бер көнлек тә ризык калмаган, язны болай да үлә-кала гына житкергәнсең. Икенчедән, җирдә калган бәрәңге чиксез түгел, кемдер синнән алдарак җыеп чыгарга мөмкин. Без «кәлҗемәлеккә» ни өчендер күрше удмурт авылы бакчаларына бара идек. «Ни өчендер» дим, чөнки сәбәбен бик озак аңлый алмыйча йөрдем, сизсәм дә, ышанасы килмәде. Авылыбыз татарлары сугыш азагы чорларында бәрәңге дә игә алырлык булмаган мәллә? Ә бит күздән артып язга да калырлык итеп, чыннан да, игә алмаганнар! Менә читтән килеп идарә итүче «җирле» түрәләр ирек бирмәгән, авылдашларга колхозның түләүсез михнәтеннән баш та күтәрергә форсат булмаган. Рус иленең ахмак, әмма гаҗәп дөрес әйтемен—үзеңнекеләрне дөмбәслә, читләр дә өркеп торырлык булсын—дигәнне безнең милләт түрәләре бик әйбәт үзләштергән.

Уйсыз кеше дә бу китапны укыганда узган тормышыбызның сәерлекләре, ул сәерлекләрнең бүгенгебезгә килеп җиткән ямьсез шәүләләре хакында уйланмыйча кала алмый. Хәер, уйсыз-гамьсез кеше укымас та аны. Шундыйлар күбәйгәнгә күрә дә китаплар аз чыга, чыкканнары да начар тарала. Күп әдипләр бу хәлгә, үзләрен укучылар гына түгел, каләмдәшләре дә аңламауга гаҗизләнә, күңеленә рәнҗү төягән хәлдә мәңгелеккә китеп тә бара.

«Гомер тәлгәшләре»н («Мәгариф» нәшрияты, 1999) бәхәссез, каршылыклы фикерләрсез генә дип кабул итүе кыен. Чөнки китап—каршылыклы чорыбыз, «акыл белән аңлап булмый» торган ил чынбарлыгы, гамьнәре үзебезнең дә җаннарыбызда утырган чордашлар хакында. Бу китапка кергән автобиографик повесть һәм хикәяләрдә авторның Норлат төбәгендәге якташлары, әти-әнисе, туганнары сурәтләнсә дә, «Ибрай Гаязы» исемле соңгы хикәясеннән Балтач төбәгенең Таузар авылы кешесе ачык танылa. Гадәти охшашлык кына түгел бу, автор Ибрай Гаязын укучы каршында тулырак гәүдәләндерү өчен чынлап та, «Таузар сыйфаты»н да файдаланган. Моның үз тарихы бар. Нәтиҗәдә, Ибрай Гаязы авторның үзенә генә билгеле бер авылдашы булудан узып, теләсә кайсы төбәктәге укучы өчен кызыклы булырлык әдәби әсәр каһарманына

әверелгән. Китапның бүтән вакыйга һәм персонажлары да авторның киң гомумиләштерүләре, аларга шәхси мөнәсәбәте аша сурәтләнә. Кайчак аның белән бергә борчыласың, күңеллән бәхәсләшәсең, кайчак хуплыйсың—битараф кына каласы килми.

Китапка исем биргән «Гомер тәлгәшләре» повесте «Авылның рухы—мәңгелек» дигән бүлек белән ачыла. Укучы биредә әдипнең туып-үскән Кычытканлы авылыннан мәгълүмат алып кына калмый, авылларыбызның үткәне һәм бүгенгесе, рухи дөньясы хакында аның белән бергә уйлана, чагыштырулар аша гыйбрәтле нәтиҗә ясый.

Беренче нәтиҗә—авторның, галим кешенең, эзләнү мөмкинлеге зур булган академикның да Кычытканлы тарихыннан мәгълүматы күп түгел. Чөнки безнең тарихыбызны эзләп-эзләп тә табып булмаслык итеп яшергәннәр, язма истәлекләрне яндырганнар, читләргә алып китеп таратканнар. «Татар халкының чын тарихы—авыллар тарихы»—ди Тәлгат Галиуллин. Димәк, авылларыбызның үткәненнән тирән мәгълүматыбыз булмау—милләтнең дә тарихсызлыгы, дигән сүз. Ул тарихны торгызу, дөнья буйлап сибелгән истәлекләрне табу һәм күчермәләрен генә булса да халыкка кайтару өчен әле дә бик аз эшләнә, моның белән кызыксынучы да күп түгел, булганнары да—акчасызлар. Анык тарихсыз диярлек калуыбызда Явыз Иван һәм аның тарафдарлары алып барган кыргый сәясәтне генә гаепләү үзенә бертөрле бәлабезгә, үтеп чыгу мөмкин булмаган каршылыкка әверелеп бара. Чөнки шуның аркасында бүтән комачаулыкларны күрмибез. Ә Иваннарны, Борисларны инде берни эшләтеп булмый. Бүгенге көндә «патшалык итеп» ятучы үзебезнең авыл хуҗаларын, күмәк хуҗалык рәисләрен, эшләгән оешма житәкчеләребезне, район хакимнәребезне генә күздән кичерик әле. Аларның кайсысы шушы хезмәт коллективын барлыкка китерүчеләрне, ана көчләрен һәм гомерләрен биреп китүчеләрне белә, хөрмәт итә йә, һич булмаса, белергә омтыла? Юк бит, юк! Күбесе, татар тәкәбберлеге белән, тарихны үзеннән генә башланган дип хис итә һәм менә шушы вак төркемнәрнең манкортлыгыннан тулаем милләтнең тарихсызлыгы алдагы көннәргәчә дәвам итеп китә!

Тәлгат Галиуллинга кушылып авылларны мәңгелек рухы турында уйланудан килеп чыга торган икенче нәтиҗә—рухи тормышның һәр тармагы һәм тармакчыга бер-берсенә нык бәйле икән бит безнең. Бер күзәнәге сүтелә башласа, халык шуна ирек куйса, куркуын, жинелүен сиздерсә, аракыга йә чит дингә әдәбен сатса, бөтенесе жимерелеп-ишелеп бетәргә мөмкин.

«Теге» заманнарда ике йөз хуҗалыклы Кычытканлы авылына биш кулак гаиләсе табып сөрү турында өстән күрсәтмә килә. Бездә аның кадәр байлар юк, дип каршы төшә авыл халкы. Ә бит алай ук ярлы яшәмәгәннәр, ләкин рухи сүтелә башлауга ирек куймау ниятендә булганнар. Йөзен югалтмаган шушы авыл тора-бара илгә ике академик, журналистлар, читтәге нәсел тармакларында фән кандидатлары, күренекле укытучылар, тагын егерме биш-утызлап авыл хуҗалыгы идарәсе башлыклары һәм күмәк хуҗалык рәисләре биргән, Кычытканлыдан Татарстан Дәүләт Советы депутаты сайланган.

Китаптан укыганнарыбызны җөмһүриятнең Норлат төбәгенә каршы «полюс»ындагы Балтач ягы, аның әйтик, Карадуган авылы белән чагыштырсак, шактый үзгә күренешкә тап булыр идек. Бу авылның да тулы тарихы юк. Яктылыкка, карашларны киңәйтерлек мәгърифәткә, рухи биеклеккә күтәрелә́се халыкның хыял канатларын кисү соңрак та дәвам итә: Балтач район советының 1932 ел, 6 март карары белән, 50-60 хуҗалыклы бу авылдан тугыз гаиләне кулак исемлегенә кертеп тар-мар китергәннәр, шул исәптән, «Мәгариф» күмәк хуҗалыгының беренче рәисе, тамырдан шушы авыл кешесе Закир Габсәләмовны, Өчлек карары белән, 3 елга концлагерьга җибәргәннәр. «Гаепле»не 1989 елда гына акладылар.

Әйе, бер тапкыр куркытылып сындырылган, бердәмлеге сыеклатылган, мәхлүкка әвереллерелгән юаш халыкны юмалый-юмалый уч төбендә тоту җинел. «Кулак» сөрүләрдән соң биш ел ярым вакыт узгач, 1937 елның август азагында, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты пленумында элекке райком секретаре, инде партия өлкә комитетының пропаганда бүлеге мөдирлегенә күтәрелгән Фазыл Рәхмәтуллин мондый «перегиб»лар өчен бар гаепне ул чактагы өлкә комитеты секретаре Разумовка сылтаячак. «Разумов чорында буш шау-шу, парадчылык, администраторлык итү, күз буяу, дәүләт һәм партия дисциплинасын әледән-әле бозулар булып торды,—дип сөйләячәк ул.—Партия оешмаларында, бигрәк тә Балтач районында райком секретаре булып эшләгәндә, Разумовка сукырларча ышанып, сәяси асылын аңламыйча, кайчак басымнан куркып, Разумовның күрсәтмәләрен үтәдем. Мисал өчен, 1933 елда икмәк хәзерләү эшендә арттырып җибәрүләрне, «Яңа тормыш» колхозы эшенә карата күзбуяучылыкны алыгыз—болар барысы да Разумовның крестьяннар арасында ризасызлык кузгатуга

юнәлдерелгән корткычлык гамәлләре иде. Һәм Разумовның мондый корткычлык хәрәкәтләрен без аңсыз төстә тормышка ашырдык».

Дөрес, «аңсыз» райком секретареның үзен дә шул елда ук аталар. Әмма авыллар да инде башсыз, хыял-омтылышсыз калган була. Мәшһүр Арча-Әтнәләр белән иген эшендә уңышлы узышып, ингә-иң яшәгән районнан хәзергә кадәр нибары бер (шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин) Язучылар берлеге әгъзасы чыгуны бүтән ни белән аңлатырга соң? Карадуган тирә-якта иң беренче ачылган әйбәт мәктәбе белән дан тотса, читтән килеп анда укытканнардан өчесе тора-бара Русиянең атказанган укытучысы исемен алса да, авылның җирле кешеләреннән бүгенге көндә бер генә күмәк хуҗалык рәисе, мәктәп директоры, оешма җитәкчесе, фән кандидаты, табиб, әдәбият-сәнгать эшлеклесе, хәтта район советы депутаты да юк, югары белем алучылары ике дистәгә дә тулмый.

Әйе, бик теләмәсән дә, чагыштырмыйча кала алмыйсың. Чөнки Тәлгат Галиуллинның Кычытканлысы турында укыган чакта «Татар халкының моңы, көе, гореф-гадәтләре, әхлак кагыйдәләре шундый авылларда саклана»—дигән юлларга юлыкккач, үз авылыңны да, татар яшәгән бүтән кала-салаларны да «шундый» итеп күрәсе килә. Инде рухи хәзинәләребезне барларга бик вакыт: татарлык саклана торган авыллар һәм төбәкләр күбрәк булганда гына милләт сакланачак. Күңеленә бу уйны беркеткән укучы Кычытканлының нилектән «шундый» булуын да белергә тели һәм китап юллары буйлап «сәяхәтен» тагын да бирелебрәк дәвам иттерә.

Милли рух «банкы» булган авыл турында сөйлибез дә, шәһәр хакында хыяллланабыз. «Үз милли шәһәрләре булмаган халык дөньяга танылa, парламентларда янгырый алмый»,—дип расый автор. Моны үзебез аңлап житкермәсәк тә, ятлар аңлый әнә. Һәр гаилә үз ишек алды белән чикләнгән авылларыбызга инде чукындыру заманнарындагыча каныкмасалар да, шәһәрләребезнең рухи дөньясын, телен һәм әхлагын үз йогынтыларыннан ычкындырмау өчен җан тартышып яталар. Әлегә кадәр милли университет ачтырмаулары да шул тартышның читләргә җиңү китергән нәтиҗәседер. Бүгенге тормыш сабакларыннан чыгып, җиңүләренең яңа баскычын да шәйләргә мөмкин инде. Милли университет, ниһаять, ачыла калса да, йә ул Казанның император университеты һәм бүтән югары уку йортларына караганда фәкыйрь булыр, мескен студентлардан һәм әти-әниләреннән «салым» җыймыйча яши алмас... Инде баеп китә калса, түрәләребезнең чит илләрдә, илдәшләр күзеннән еракта, үзләре өчен генә тотылган ял итү урыннары кебек, өстен сыйныфларга гына «белем бирү» белән чикләнер. Җитмәсә, хәзер хакимияттәге урыннары буенча гына гыйльми дәрәҗә алучылар бик күбәйде. Язмышы шулар кулына эләксә, ачыласы милли университетның кемнәргә хезмәт итәчәге күренеп тора. Без мондый уку йорты теләмәгән идек, аны әллә кая алып кереп киттеләр, дип бер-ике дистә милләтче шаулаша бирсеннәр аннары!

«Акыл белән аңлап булмый торган» хәлләргә мөнәсәбәтле, китапка гыйбрәт алырлык бер эпизод кергән. «Ульян өлкәсендә «Ундор» («ындыр»дан үзгәртелгән) ял йорты бар», дип яза әдип. Суы ифрат та шифалы, ди. Баксаң, бу сихәтле эчемлек үзебезнен Тәтештән бара икән. Димәк, суыбыз читләргә акча эшләп ага. Һәм бу хәлгә аз гына да гаҗәпләнәсе юк. Дистә еллар буена җиребез куеныннан күп миллионнарча тонна нефть чыгарып, Татарстанның үзендә шуны эшкәртеп кулланырлык рәтле бер завод та салынмау белән бер инде бу! Кемдер мондый сәясәтне романнар язып мактый, кемдер бер җөмлә белән укучысын уйландыра—һәрберенең милләт һәм заман каршында үз гамәле.

Татар милләте үлгәнме, инкыйраз алдында торамы, әллә йоклаган гынамы—йокласа, аны ничек уятырга, дигән мәсьәлә гасырыбыз башы әдипләрен дә борчып килгән. Әдәбият мәйданын уйлы әсәрләр һәм моңа кадәр тыелып килгән темаларны инли баруга бәйле рәвештә, соңгы елларның рухи җанлануы да гасыр таңындагы проблемаларыбызны тикшерүдән башланды. «Без кем идек, кем булдык, һәм инде кая барабыз?» дигән өч сорау милләтнең акылын тәшкил итүче галимнәрне һәм әдипләрне бигрәк тә борчыды. «Кем идек»ебезне күрсәтү омтылышы тарихи әсәрләрне күбәйтсә, сорауларның соңгы икесен тикшерүгә дә күп әдипләр һәм әдәбият галимнәре җитдилек белән тотындылар. Кем булганыбызны, әдәп-әхлакның кайсы дәрәҗәсенә ирешүебезне шулар хакында борчылып язылган заманча әдәбият кына түгел, яңа авторлар һәм яңа әсәрләр тирәсендә баргалаган аңлаешсыз шау-шулар яисә өшеткеч битарафлык та күрсәтеп тора. Инде татар милләтенең асыл сыйфатларын, пакъ әдәбен, хөр рухын кайтару кирәклеге хакында сүз кузгалган, азмы-күпме гамәленә дә керешелгән икән, бу сыйфатларны гәүдәләндергән, «кызык»лылыгы ягыннан түгел, мөһимлеге, зарурияте белән Көнбатыш телесериалларының ят әдәбенә каршы торырга тиеш булган

әдәбиятыбыз аерым бер игътибар да таләп итәдер.

Тәлгат Галиуллин китабында аның әтисе Нәбиулла әзи хакында әнисе Исламия әби әйткән сүзләр күңелгә уелып кала:

—Ак эзе сызылып калды дөньяда әтиегезнең. Ана охшарга тырышыгыз.

Мәрхүменнән соң гына түгел, дөньялыкта да иренә чиксез хөрмәт белән яшәгән әби мондый тирән мәгънәле сүзләрне әйткәндә, шунысын да уйлады микән: Нәбиулла балалары Тәлгат, Әфхәт, Әсхәт, Әхәт Галиуллиннар әтиләренә охшаулы ир булсыннар өчен гаиләләрендәге парлары да холык-фигыльләре, сабыр акыллары, ирне ир итүләре белән Исламиягә бик якын торырга тиешләр бит әле. Һәм ул сыйфатлар аларга әниләре үрнәгеннән үк кергән, тирән сеңгән булырга тиеш. «Әни илаһи тәэсир көчен сиздермәс, кешегә күрсәтмәс, әтинең минминлегенә тимәс, мәгәр тавышын күтәрми, каршы әйтми генә үз фикерен, сәясәтен уздырыр»—дип яза әдип. Татар милләтендә мондый әниләр күпме, күпчелекме хәзер? Әллә яшьләребезгә бозыклык ана сөте белән үк керә башладымы, шуна күрә тәрбиягә дә бирелми торганнары арта барамы? Шулай икән, әниләр нәрсәдә ялгышты?

Байтак еллар элек Әфган чикләре тирәсенә урнашкан авылда бер таҗик карты әйткән сүзләрнең һич онытыласы юк. «Сез татарлар түгел ич инде,—дигән иде ул.— Хатыннарыгыз өстегездән йөри, сезгә ялган сөйли, тәмсез теллеләнә, аракы эчә, ирләренә кычкыра... Юк, сез татарлар түгел инде».

Читтән торып караганда күңекмәгән күзгә кимчелекләребез җитерәк тә күренәдер: хатын-кызларның, әниләрнең нинди легеннән чыгып бөтен милләткә бәя бирелсә, әллә ни мактанырлыгыбыз юк икән шул. Әмма әдәпсез гамәлләрне, гаиләләрдәге чит кавем мөнәсәбәтләрен ин элек хатын-кыз таратмады, аларның күбесен безнең иплe дөньябызга Бөек Ватан сугышы дигән дүрт еллык җәһәннәмнән ир-атлар алып кайтты. Ә эчүчелекне, караклыкны берсен-берсе яклаучы йөгәнсез түрәләр яшәү нормасына, гөнаһсыз уенга әверелдерде. Сугыштан соңгы елларда авыл түрәләренең район үзәгеннән кайтышлый кибетче өендә ничек төн уздыруларын Тәлгат Галиуллин әйбәт кенә сурәтләгән.

Шул ук сугыш чоры ир балаларны һәм үсмер кызларны завод-фабрикаларда, колхозларда, торф чыгаруда, урман кисүдә җегәрләре житмәслек алҗыткыч эшләргә, ачлыкка, ятимлеккә, шәфкатьсез мөнәсәбәткә дучар итеп, бик күбесен рухи имгәтте, җаннарын корытты. Алардан туып үскән балалар күңел пакьлеге һәм хыял-өметләр, карашлар яктылыгы ягыннан әби-бабаларын һәм әти-әниләренең яшь чагын кабатлый алмаячак иде инде. Милли әдәп менә шушында өзелде, әмма рухи имгәнүләрнең буыннан-буынга күчә барган әхлакый зыянын әле дә беркем исәпләми. Чеченнәр җиренә кат-кат сугыш белән кергән Мәскәү генераллары бу халыкның һаман «сабак алмавына», юашланмавына, йөзләре көләчләнмәүгә аптырыйлар. Әмма сугышның андый гаделсезе генә түгел, теләсә-кайсысы, анда катнашучыларга, хәтта үз ирегең яклап сугышучыларга да, мәрхәмәтсезлек, катылык үрнәге генә бирә, аларны усаллыкка, канга, кемнедер дошман итүгә күнектерә, моның зәхмәтле тәэсире атадан балага күчә. Кичергән җәфалар, ачлык, ялангачлык, мохтаҗлык адәм баласын гомернең, һәр телем икмәкнең кадерен белергә өйрәтә, инсафландыра, сабыр-түзем итә, нечкә күңеллегә, шагыйрьгә әверелдерә, дип ышандырырга тырышучылар үзләре бер дә шундый «тормыш»ка омтылмыйлар. Чынлыкта кешенең күргән җәфасы, рухи гарипләндерелүе күңелне сафландырмый, якты уйларга этәрми, андый яраларның әрнүе чорлар аша оныкларда да кабатлана.

Тәлгат Галиуллин үз авылында әхлакый «сүтелү»нең әле башланып кына килгән чорларын тасвирлый. Инде безнең көннәрдә, шушы авыл журналисты Фәния Хуҗахмәтнең борчылып язуынча, Кычыткanлыда эчүчелек һәм бурлык хәвефле чикләргә җиткән. Заманында көндәлекләр язып, Тәлгат Галиуллин әйткәнчә, кәгазьдә «бушанган» Кычытканлы ирләренең балалары һәм оныклары бүген башкалар кебек аракыда «бушана». Үзгәрешне дәүләт күләмендә карасак, инде парламентларга да милләтнең әдәп сакчылары түгел, акча һәм аракы корольләре күбрәк сайлана. Сәясәтне шулар ясый, кемлегебезне дә дөньяга шулар күрсәтә. Мондый хәлләргә борчылсак, татар әдәбенең җимерелә башлавы кайдан, нинди ялгышларыбыздан юл алды соң әле, дип уйлансак, милләтнең асыл сыйфатларын, мәдәни-әхлакый мирасын сурәтләгән әдәби әсәрләрне укымыйча кала алмыйбыздыр.

Тәлгат Галиуллин повестенең икенче бүлеге «Писарь» Галиулла» дип исемләнә һәм анда әдипнең бабасы сурәтләнә. Сугыш вакытында аның гаиләсе ун кешене берләштергән. Ир-атлар икәү генә—үзе һәм сабый оныгы Тәлгат. Инде шактый картаеп барган, почта таратудан бүтән хезмәткә дә ярамаган Галиулла бабай шул авыр,

мәрхәмәтсез чорда да зур гаиләнең әхлагын үз кулында тота, сүтелергә юл куймый. Моның сәбәбе бер генә: гаиләдә олылар үрнәге, өлкән кеше сүзе илаһи көчкә ия булган, бу сүзне санламау иманлылар өчен зур гөнаһ, халкыбызның яшәү кагыйдәләреннән текә тайпылыш саналган, гаилә шул сабыр әдәбе белән авырлыкларга баш бирмәгән. Бередә гадәтләребезгә сукырларча буйсыну, калтырап тору, куркытылган тавык хәлендә яшәү турында сүз бармый. «Писарь» Галиулла балалары ачык һәм киң карашлы, юлдан тайпылмаслык, тормышларын әйбәт алып барырлык булып житешкәннәр, күп санлы эшчән уллар-кызлар үстергәннәр. Нәбиулла әзи белән аның сеңлесе Зәйнәп апада бер бакча ачарлык бала бар, дип шаярта торган булганнар Кычытканлыда.

Әдип үз әтисен һәм аның даирәсен, әнисен һәм аның мохитен сурәтләүгә повестьта аерым-аерым бүлек багышлый. Нәбиулла—ике сугышта катнашып, соңгысыннан төзәлмәс яра алып кайткан, советларга, Сталинга гомере буена турылыклы калган, шул ышануы белән дә көчле булган гадәти авыл ире, күп замандашларының бер сыңары. Ни өчен сугыштың, дип сораучыларга ул:

—Азатлык өчен,—дип җавап бирә.

—Нинди азатлык инде ул! Сугыш беткәнгә күпме вакыт узды, без һаман хәерче, әнә немец, япон ничек яши!—ди аңа улы.

Ветеран шактый озын гомер яшәп, үз ышануы, үз иманы белән дөньядан китеп тә барган. Бәлки андыйларның бар байлыгы, бердәнбер бәхетедер дә бу. Караклар иле аларның шушы ышануын гына тартып ала алмаган. Бик күп нәрсәдә алданганнар икән, анысы алдаучылар намусында. Гамьнәр үлми, өлкәннәрдән яшьләргә, китүчеләрдән калучыларга күчә, вакытында җавабы табылмаган сораулар күңелләрне гел бимазалап тора. Чынлап та, кемнең, нәрсәнең азатлыгы өчен сугыштылар алар? СССРныңмы? Андый ил юк бит инде, барыбер саклап калып булмады һәм халыкларны ирексезләп бәйдә тоту кирәкми дә иде. Рәсәй дигән илнеңме? Ә аңа азатлык, ирек нәрсәгә кирәк? Дистәләгән милләттән хәерче, исерек бер укмаш ясап ирексезлектә тотсын, Мәскәүчә уйламаганнарны рәхимсез кырсын, туган җиреннән кусын өченме? Җиңүчеләребез бу миһербансыз дәүләткә шундый хокук яулап бирделәрме? Куылучылар, Мәскәү бомбалары астында изелүчеләр арасында Нәбиулла карт кебек җиңүчеләр дә бар ич. Күп миллионнарча гомерләр, кеше җаны күтәрмәслек мөхтаҗлыклар, хәтта алдагы буыннарның да рухи гариплеге бәрабәренә алынган азатлыктан һәм бәхеттән җиңүче халыкка берни калмады бит инде, алда буласы якты көннәргә өметебез дә киселде. Без бүгенге менә шушы тормышка гына лаек идекме? Әдипнең үз әтисенә биргән авыр соравын дәвам иттереп, башына кан сауганчы уйласаң да боларның очына чыгарлык түгел. Әмма уйланмыйча, алдыбызга авыр сораулар куймыйча, сабыр-түземнәр булып та байтак яшәп карадык, тәлгәшләп-тәлгәшләп шуңа бөтен гомеребезне бирдек, алдау-арты алдаулар кичерсәк тә өметләрне өзми килдек—тик әҗеренә ни алдык? Игелексез, рәхимсез дәүләт үзенең котсыз үрнәге белән яшьләрне дә өлкәннәргә, аларның авыр үткәненә, ихласлыгына һәм иманына ихтирамсыз итеп тәрбияләде. Ә күңеле мондый ихтирам хисеннән мәхрүм адәмнең югары әхлак иясе булуы мөмкин түгел.

Повесть-истәлекнең «Апалар, сеңелләр» бүлеге гаиләдәге өлкәннәр белән яшьләр, туганнар белән туганнар мөнәсәбәтен моннан ярты гасыр элекке бала күзе күргәнчә сурәтли, өлкән кеше карашынча гомумиләштерә. Дин дип егылып төшмәсә дә, «писарь» Галиуллин токымы имансыз яшәмәгән, гаиләдә динилек ташып тормаса да, миллилекне, ата-бабаның сыналган изге гореф-гадәтләрен, әдәп-әхлак кагыйдәләрен саклау аркасында Ходай бу күп тармаклы нәселне юлдан язган балалар белән җәзаламаган. Кайберләрендә ара-тирә бала шуклыклары сизелгәләсә дә, «гаилә педагогикасы» ярдәмендә бергә-бергә тәрбияли килгәннәр. Кайчагында тәрбия чарасы тупасрак, авылчарак та килеп чыккан, әмма, чамасы югалмаганлыктан, баланың күңелен катырырлык, зурайгач үч алу тойгысын кузгатырлык булмаган, аталар белән уллар арасында аңлашу югалмаган. Әдип үзе бер хикәясендә «Үчлек—татар кешесенең канында» дип язса да, андый хәтәр сыйфат әхлаклы гаиләләрнең олылар белән яшьләр, ата белән бала мөнәсәбәтенә кагылмаган.

Милли әдәбият киң дөньяга танылырлык үсеш алсын өчен халыкның үз телендә укый-яза белүе, талантлы, югары белемле әдипләре булу гына җитмидер, калыплашкан әдәп-әхлагы да, һичшиксез, кирәктер ахры. Шундый пакъ дәвердә, халык шул әдәпне изге саклаган тотрыклы чорда әдәби җәүһәрләребез дә күбрәк туган. Тәлгат Галиуллин китабы милләтебез әхлагының сафрак елларын хәтердә яңартуы белән кыйммәтле.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.**

*Юмор һәм сатира*

# Шамил Маннап

## Үзенчәлекле сынау

Шагыйрь Зөлфәтнең «Чаян» журналы редакциясенә эшкә килүе шактый үзенчәлекле була. Беренче тапкыр үз кабинетына киң елмаеп килеп кергән шампунь күбегедәй бөдрә чәчле егетне журналның баш редакторы Альберт Яхин ишек төбендә туктата:

—Түргә узарга ашыкма, энем, башта аягыңны яхшылап сөртеп кер!—ди ул.

Зөлфәт аптырап, аякларына карап ала.

—Ботинкаларым чиста бит, бүген генә ваксыладым...—ди.

—Күрәм,—ди баш редактор.—Мин аны әйтмим. Студентлык вакытындагы күпбеләмлек, даһилык, самолюбие кебек сыйфатларыңны ишекнең теге ягында ташлап, шуларга сөртеп кер аягыңны.

Зөлфәт кабинеттан ялт кына чыгып, бераздан янадан керә.

—Булды, Альберт абый. Сез әйткәнчә эшләдем,—ди ул һәм көлеп өсти.—Һо-һо, «Чаян»чыларның адәмчә генә түгел, чаянча булыр инде аларның...

—Менә бу безнеңчә ичмасам! Юкса, синнән алда эш белешергә килгән берничә иптәш минем сынауны уза алмады. Үпкәләп киттеләр. Ә син, энем, эшли алырсың кебек...—ди ул.

Менә шуннан бирле, төгәлрәк әйткәндә, чирек гасырдан артык инде Зөлфәт өзлексез рәвештә «Чаян» белән кулга-кул тотынышып эшли.

## Кайсы бөегрәк?

Драматург Шәриф Хөсәенов үзенең туган көнендә якын күргән каләмдәшләрен кунакка чакыра. Югары кимәлдәге тостлар әйтеп, матур гына утыра болар.

Мәҗлеснең кызган бер вакытында Шәриф Хөсәенов бүлмәдән югалып тора. Шул арада аның урынына түбәтәйле бер абзый кереп кунаклый. Моны күреп, мәҗлесне алып баручы—тамада Аяз Гыйләҗев әйтә тегенә:

—Абзый кеше, ул урын бөек драматургныкы. Ничек җөрьәт итеп утырдыгыз анда?—дип, кучеп утырырга өнди.

—Утырырга хакым булганга утырдым, кучмим, и вчу!—ди абзый.

—Сез кем соң ул кадәр?—дип, янә бәйләнә Аяз Гыйләҗев.

Кәләпүшле абзый үзенең кемлеген танырга мәҗбүр:

—Сез бөек дип мактаган драматургның әнисен кочкан кеше мин!—ди. Баксаң, ул Шәриф абыйның әтисе икән ләбаса!

## «Сез күбәү—мин берәү генә...»

Элегрәк була бу хәл. Татарстан китап нәшриятында Фәнзаман Баттал үзенең «Сакалыңа ут капса...» дигән кульязма китабын нәшер итү хәстәрен күреп йөри. Баш редактор Вакыйф Нуруллинның кабинетыннан чыгып килгәндә нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдинов белән борынга-борын очраша бу. Директор белән баш редакторның кабинетлары кара-каршы гына бит.

—Җыентыгымның язмышы белән кызыксынып йөрүем әле...—ди Фәнзаман.

—Ник соң үземә кермәден?—ди Гарәф Низаметдинович, төксерәк тавыш белән.

—Һы,—ди Фәнзаман,—теге юлысы сезгә кергән өчен баш редактор шул ук сорауны биргән иде. Аңламассың сезне. Мин бит инде икегә ярыла алмыйм. Сез—нәчәлникләр күбәү, мин берәү генә!

## «Тимер борды...»

Шагыйрь Зиннур Мансуровның «Социалистик Татарстан» (хәзерге—«Ватаным Татарстан») газетасе редакциясендә эшләгән чагы. Ул әдәбият вә сәнгатькә кагылышлы материалларны эшкәртә, машинкада бастыра, аннары имзасын куеп, бүлек мөдиренә тапшыра. Бүлек мөдире Рәшит Гариф аларны укый, төзәткәли дә, шулай ук имзасын сырлап, редактор урынбасары иптәш Тимергалинга кертеп бирә.

Берничә көннән соң, киресенчә хәрәкәт башлана: редактор урынбасары әдәби сәхифә өчен сайлап алганнан калган, газетага «батмый торган» кайбер материалларны бүлек мөдиренә кире биреп чыгара, монысы бүлек хәбәрчесе Зиннур Мансурга аткара. Һәм шул вакытта кыска гына итеп: «Тимер борды...»—дип куя. «Тимер борды»,—дидеме, бу инде материалны яклап, бәхәсләшеп торуның файдасы юк дигән сүз.

Инде кире борылган язмаларның яки әсәрләрнең авторларына җавапны Зиннурга бирәсе кала. Башкаларга сылтарга ярамый, ачуланалар. Шуңа күрә Зиннур Мансур үзен юату өчен борын астыннан гына мондый җыру көйли:

«Эшләмәгән шагыйрьләргә әйбәт,—

Ни теләсә, шуны язалар.
Минем генә монда хәлләр хөрти,—
«Тимер борды!»—

дигән хәбәр бар...»

## «Ышануы кыен...»

Шаһинур Мостафинның 50 яшьлек юбилее кичәсендә яшь шагыйрь Рифат Җамал болай ди:

—Мине әдәбият мәйданына Шаһинур абый өстерәп кертте. Рәхмәт аңа...

Шунда ук Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Ринат Мөхәммәдиев тә Шаһинур Мостафинны үзенең остазы дип атый. Ул кайчандыр Мамадышта Шаһинур житәкләгән әдәби-иҗат түгәрәгенә йөргән икән.

Ошбу чыгышларны тыңлап утырган Мөдәррис Әгъләм күршесенә болай дип пышылдый:

—Слушай, Шаһинурның кырмыска кадәр Рифат Җамалны әдәбият мәйданына өстерәп алып керүенә ышанырга була анысы. Тик менә алып гәүдәле Мөхәммәди кадәр Мөхәммәдине өстери алуына ышануы кыен бит, парин...

## Кычкырып ял итү

Туфан Миннуллин яшьтән үк шау-гөр килеп йөрергә яратучы җор вә хөр күңелле егет. Туфан булган җирдә һәрчак шау-шулы әңгәмә булыр, уен-көлке яңгырап торыр.

Бервакыт шулай Язучылар берлеге коридорында үзе кебек яшь «әтәчләр» арасында кодрәтле тавышы белән аерылып торган Туфанны ул вакыттагы Язучылар союзы рәисе Ибраһим ага Гази читкә чакырып ала:

—Карале, Туфан энем, син бер дә житди була белмисеңме әллә? Кычкырып-шаулап йөрүләрең Яңа бистәгә кадәр ишетелеп тора лабаса!—ди ул.

Туфан да җавапка кесәгә керә торганнардан түгел:

—Минем житди вакытымны күрәсегез килсә, язып утырганда килеп карагыз, Ибраһим абый. Ә монда ял итәргә киләм мин!

Ибраһим ага, моңа акыл кертеп булмас, дигән кыяфәттә кулын селти дә:

—Бар инде алайса, теләгән кадәр кычкырып ял ит!—дип, үз бүлмәсенә юнәлә...

## Көн күрсәтми торган баш

«Казан утлары» журналының редколлегия утырышы бара иде. Беркетмә язу эшен Рәшит Әхмәтҗанга тапшырдылар. Ул уртадагы өстәл янына чыгып утырды. Шунда читтәрәк утырган Мөхәммәт Мәһдиев әйтеп куйды:

—Рәшит, аз гына читкәрәк күчеп утырчы. Синең башың аша баш редакторны күрмим.

Бу—Рәшитнең зур якты башына төрттерү иде, билгеле. Рәшит зәңгәр ялкынлы зур күзләре белән Мәһдиевне бер өтеп алды да:

—Моңа кадәр бу баш халтурщик авторларга гына көн күрсәтми иде ләбаса...—дип куйды.

## Шуңа да башың җитмимени?!

«КамАЗ» төзелгән елларда була бу хәл.

Мөдәррис Әгъләм, Чаллыда командировкада булып кайтканнан соң, Зөлфәткә сөйли икән:

—Әй, малай, КамАЗның ашханәсе генә дә ни тора! Берьюлы 900 кешене ашатып чыгаралар. Бер як касса ягыннан—300 кеше, икенче яктан 300 кеше уза.

Зөлфәт башын кашып тора да болай ди:

—Бер яктан 300 кеше, икенче яктан 300 кеше, барысы буладыр... 600 кеше. Ә калган 300 е кайда?

Мөдәррис аптырап калмый:

—Соң, шуңа да башың җитмимени?!—дип, риторик сорау бирә һәм җавабын да көтеп тормастан, бүлмәсенә кереп китә.

---

*Котлыйбыз!*

## Мансур Шиһаповка 60 яшь



Мансур Әхмәт улы Шиһапов 1940 елның 1 маенда Балык Бистәсе районының Яншык авылында туа. Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан театр училищесында, соңрак Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә белем ала.

Г. Камал театрында берничә ел артист булып эшләгәннән соң, ул җитәкчелек хезмәтенә күчә. Әлеге театрда баш администратор, Казан дәүләт курчак һәм Татар дәүләт драма һәм комедия театрларының директоры, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисенең урынбасары булып эшли. Бүгенге көндә Татарстан Республикасының Дәүләт Зур концерт залы директоры.

М. Шиһапов, нигездә җыр жанрында эшләүче шагыйрь. Җыр сәнгате дөньясына ул 1974 елда сугыш тематикасына иҗат ителгән «Мәңгелек ут сөйли» (Р. Гобәйдуллин көе) дигән җыры белән килеп керә. Шулай ук, «Әйләнеп кайтыгыз», «Туй күлмәге», «Мишәр кызы» һ. б. җырлары тыңлаучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Ике җыр җыентыгы басылып чыкты.

М. Шиһапов көчен драматургиядә дә сынап карый. Курчак театры өчен берничә пьеса яза һәм алар сәхнәгә куелып шактый вакыт уйналалар.

Ул Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

## *Укучы сүзе*

* * *

"Казан утлары"н инде бик күп еллар яратып укып барам. Хикәя, роман, повестьларны гына түгел, әдәби тәнкыйть һәм публицистик язмаларны да калдырганым юк. Һәрберсенең эчтәлеген күнелем аша үткәрәм, анализ ясыйм, үземнең уй-фикерләремне алардагы белән чагыштырып карыйм. Соңгы вакытта латин имласындагы язмаларга киңрәк урын бирелә башлау да бик ошый. Алар яңа хәрефләрне үзләштерергә ярдәм итү белән генә түгел, ә күнелдә яңа тойгылар уятулары, яңа мәгълүмат бирүләре белән дә отышлы.

Шулай да сезгә кайбер теләкләрем дә бар. Журналда чит ил әдәбиятына, аерым алганда, фантастикага да зуррак урын бирелсен иде. Әдәби тәнкыйтьне һәм "Укучы сүзе"н дә бераз киңәйтә төшәргә мөмкин булыр иде кебек. Заманча хикәяләрне күбрәк күрәсе килә. "Казан утлары"нда элекке елларда дөнья күргән иң отышлы, иң әйбәт әсәрләрне дә кабатлап басарга кирәктер бәлки. Китапларның тиражы бер-ике меңнән артмаган бу заманда мондый гамәл яхшы әсәрләргә булган ихтыяҗны, бәлки, азмы-күпме канәгатьләндерергә ярдәм итәр иде.

Хәзерге укучыны татар язучысынын авыл тормышы һәм план үтәлеше турындагы әсәрләре генә инде кызыксындырмый. Заманча әсәрләр кирәк. Элегрәк дөнья һәм рус әдәбияты үрнәкләре даими рәвештә китап булып чыга торды. Ләкин хәзер инде алар кеше укырлык хәлдә түгел, тузып, таралып беттеләр. Аларның тиз арада янадан чыгуы да шикле. Менә шул бушлыкны "Казан утлары" бераз тутыра алмас микән! Болар бер минем фикер генә түгел. Журналны даими укучылар без аралашып торабыз, очрашканда күпләр шундыйрак теләк белдерә. Редакциягә беренче тапкыр язуым, килешмәгән җирләре булса, гафу итәрсез.

**Н. Ф. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ**,
*Мөслим, Татарстан.*

* * *

Кадерле татар язучылары! Чын татарча *тирәк* сүзе урынына *тупыл* дип язудан кайчан туктыйсыз инде? Татар гомер буе тирәк дип сөйләгән, тирәк дип җырлаган. Ул бит татар халык иҗатындагы образ, сагыш, моңны гәүдәләндерүче агач! Һич югы "Сарман" җырын исегезгә төшерегез! Катнаш никахтан туган манкортка охшаган "тупыл" сүзе тирәк кебек үк шигъри мәгънәгә, төсмергә ия түгел бит! Сез мине "вакчыл адәм икән" диярсез инде. Ә мин әйтер идем: дөньяда вак-бәләкәй әйбер юк, барысы да мөһим. Башкача тагы ничекләр генә итеп әйтим, аңлатыйм инде?

Мин үзем 74 яшен тутырган кешемен. Озак еллар Үзбәкстанда яшәгәннән соң туган ягыма—Башкортстанга кайттым. Чит җирләрдә туган телемне оныта язган идем инде. Кайттым—шаккаттым. Безнең Башкортстанда яшәүче татарлар туган телне бозмый сөйләргә тырышалар, кадерләп саклыйлар. Ә татарнын Мәккәсе булган Казанда чыгучы гәзит-журналларда еш кына татарчаны бозып, мәгънәсен белмичә, аңламыйча язган сүзләр, тәгъбирләр очрый. Эчне бик пошыра бит!

**З. Д. ГӘРӘЕВ,**
*Аксаково, Башкортстан.*

# Язылырга онытмагыз!

1 апрельдә 2000 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Ул 20 июньгә кадәр дәвам итәчәк. «Казан утлары»ның **индексы—73210, ярты елга язылу бәясе—39 сум.**

Журналга язылуны жиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән жирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга мөмкин. Татар әдәбиятының энциклопедиясе—«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал 73210
(индекс издания)

Казан утлары
(наименование издания)

Количество комплектов:

на 2000 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал 73210
(индекс издания)

Казан утлары
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб.______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб.______ коп. | |

на 2000 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### ВЛАДИМИР ПУТИН ТАТАРСТАНДА

21 мартта Казанга Россия Федерациясе Президенты вазифаларын башкаручы, РФ Хөкүмәте Рәисе В. Путин (26 мартта ул Россия Президенты итеп сайланды) килде.

«Казан» халыкара аэропортында Россия дәүләте башлыгын Татарстан Президенты М. Шәймиев, Премьер-министр Р. Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Казан мэры К. Исхаков һәм башка рәсми кешеләр каршылады.

Шул ук кичтә В. Путин һәм Татарстан житәкчеләре «Рухилык балкышы» дигән иҗтимагый-мәдәни акциядә катнаштылар. Әлеге чара «Яна меньеллыкны каршылап» дигән гуманитар проектны ачып җибәрде.

Кичә ахырында В. Путин һәм М. Шәймиев зур концерт программасында катнашкан республика сәнгать йолдызларына, профессиональ һәм үзешчән коллективларга рәхмәт белдерделәр. «Рухилык балкышы» акциясенең исеме зур мәгънәгә ия,—диде В. Путин,—рухилыкны янартмый торып, без берниндн проблеманы да хәл итә алмаячакбыз».

Икенче көнне Россия Президенты вазифаларын башкаручы В. Путин торак программасын гамәлгә ашыруның торышы белән танышты, Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү Дәүләт комиссиясе утырышында катнашты. «Ту-214» самолеты, шулай ук «Актай» һәм «Ансат» вертолетларының үрнәкләре белән танышты. Көннең икенче яртысында В. Путин һәм Татарстан житәкчеләре Чаллыда Бөтенроссия машина төзүчеләр киңәшмәсендә катнашты, КамАЗда булды.

### ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ЮЛЫННАН

Татарстан Президенты М. Шәймиев галиҗәнаб шәех Мансур бән Зәед әл Нахайянның шәхси чакыруы буенча Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә визит белән барды.

3 апрельдә М. Шәймиев Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең тышкы эшләр буенча дәүләт министры шәех Хәмдән бән Зәед Әл Нахайян белән очрашты һәм Татарстан белән БГӘ арасында ихтимал хезмәттәшлекнең төрле мәсьәләләренә кагылышлы сөйләшүләр булды.

4 апрельдә М. Шәймиев БГӘ финанс министры шәех Хәмдән бән Рәшид Әл Мәкдум белән очрашты. Озакка сузылган әңгәмә барышында машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, төзелеш тармакларында үзара хезмәттәшлек итүнең төрле якларын тикшерделәр. Шәех Хәмдән бән Рәшид Татарстанның социаль-икътисади хәле, безнең республикага инвестицияләр салу, Татарстан территориясендә дә, БГӘ җирләрендә дә уртак проектларны тормышка ашыру мөмкинлекләре белән җентекләп кызыксынды. Очрашуларда БГӘ оборона министры шәех Мөхәммәд бән Рәшид Әл Мәкдүм, БГӘ коммуникацияләр министры Әхмәт бән Хөмәед Әт-Тайер; Татарстан ягыннан—тышкы элемтәләр департаменты директоры Т. Акулов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Әхмәтов, сәүдә һәм икътисади хезмәттәшлек министры Х. Салихов, мөфти Г. Исхаков һ. б. катнашты.

«КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Иван Костин Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә «КамАЗ» автомобильләрен сатуны арттыру мөмкинлекләре турында сөйләшүләр алып барды.

### ИСЛАМ ДИНЕ ЮБИЛЕЕ

Мәскәүнең МХАТ театры бинасында Россия территориясендә Ислам диненең тарала башлавына 1400 ел тулуга багышланган юбилей чаралары башланды.

Бәйрәм тантанасын Россия мөфтиләре Шурасы рәисе, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе шәех Равил Гайнетдин ачты. Аның әйтүенчә, юбилей тантаналары Россия Федерациясенең күп төбәкләрендә узачак, бәйрәм кысаларында Халыкара Ислам конференциясе,

мәчетләрдә тантаналы гыйбадәт кылулар булачак. Моннан тыш, Россиядә Ислам диненең тарала башлавына 1400 ел тулу турында документаль фильм төшереләчәк, Ислам дине энциклопедиясе, мөселман архитектура сәнгате альбомы бастырып чыгарылачак.

Бәйрәмне ачу тантанасында катнашып, Мәскәү мэры Юрий Лужков Россиядә Ислам дине тарала башлауның 1400 еллыгын бәйрәм итү Россия халыкларын туплауга, яшь кешеләрдә тарихка һәм традицияләргә мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итәр дигән ышаныч белдерде. Бу олуг җыенда Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов чыгыш ясады. Ул Татарстан җитәкчелеге исеменнән юбилей датасын бәйрәм итү уңаеннан җылы тәбрикләүләр җиткерде.

Кичәдә РФ хөкүмәте министры Рамазан Абдулатипов, Мәскәү шәһәр Думасы Рәисе Владимир Платонов, Татарстанның Россия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиле Назиф Мириханов, Мәскәү татар төбәк милли-мәдәни автономиясе президенты Рәсим Акчурин һәм башка хөрмәтле кунаклар булдылар.

Юбилей тантанасында Татарстан сәнгать осталары катнашты, Түбән Каманың «Җидегән чишмә» коллективы чыгыш ясады (җитәкчесе Р. Галиев) һәм Чаллы татар дәүләт драма театры «Йосыф» исемле спектакль (җитәкчесе Әюпов) күрсәтте.

* * *

Мәскәүнең «Татар язылучылар клубы» чакыруы буенча «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин 5-6 апрельдә Мәскәүдә булып кайтты. Планлаштырылган очрашулардан тыш ул, Россия Дәүләт Думасында Татарстаннан сайланган депутатлар белән очрашты, Ислам диненең Россия территориясендә тарала башлавының 1400 ел тулу тантанасында катнашты. Ул шулай ук Татарстан вәкиллеге хезмәткәрләре белән очрашып, «Казан утлары» журналын тарату мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшүләр үткәрде.

### АКСАКАЛ РӘССАМ ЮБИЛЕЕ

28 мартта Татарстанның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда Татарстан, Россия һәм СССРның халык рәссамы Харис Якуповның 80 еллык юбилеена багышланган шәхси күргәзмәсе ачылды.

Музейның алты залына урнаштырылган һәм 150 ләп эшне үз эченә алган экспозиция Татарстан сынлы сәнгате аксакалының күпкырлы иҗат эшчәнлеген чагылдыра.

Татарстан Республикасы Вице-премьеры И. Хәйруллин юбилярны Президент һәм Хөкүмәт исеменнән котлап, күпкырлы хезмәтләре һәм республиканың мәдәни үсешенә зур өлеш керткәне өчен, ана рәссамның «Рәсем сәнгате—минем мәхәббәтем» исемле истәлекләр китабының беренче экземплярын тапшырды.

Шул ук көнне кичен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Харис Якуповның юбилей кичәсе булды.

### БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ ТАНЫЙЛАР

Россия тарихчы-архивчылар җәмгыяте үзәк советының Мәскәүдә узган V пленумында Татарстанның архив хезмәтенә югары бәя бирелде. Биредә матди-техник базаны ныгыту, архив технологияләрен компьютерлаштыру эшләре яхшы оештырылган, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Дамир Шәрәфетдинов һәм галим Илдус Гыйззәтуллинның «Гасырлар авазы» журналы өчен әзерләгән «Мирсәет Солтангалиев. Сайланма хезмәтләр» китабы өченче премиягә лаек булды һәм диплом белән бүләкләнде.

### 55 ЕЛ УЗСА ДА ХӘТЕРДӘ

Берләштерелгән дәүләт музеенда «Бөек Ватан сугышы елларында Казан» дип аталган күргәзмә ачылды.

Анда тупланган Советлар Союзы каһарманнарының әйберләре, өс киемнәре, бездә эшләгән очкычларның макетлары, «Спартак» мех комбинаты җитештергән төрле киемнәр һәм М. Җәлилнең хәтер залындагы «Моабит дәфтәрләре», «Хәтер китабы» тупланмасы, Гвардия байраклары, Германия эләмнәре һәм кораллары, һичшиксез, дәһшәтле елларны искә төшерә.

### ОЧРАШУЛАР, ЧЫГЫШЛАР

* * *

3-4 март көннәрендә бер төркем язучылар М. Хәбибуллин, Р. Фәйзуллин, Ф. Галимуллин, К. Минлебаев, С. Шәмси Теләче районында булдылар. Алар Олы Мәтәскә авылы мәктәбендә Фатих Хөснигә музей ачу тантанасында, Түбән Кибәхуҗа мәктәбендә язучы М. Максудның 100 еллыгына багышланган очрашуда катнаштылар. Икенче көнне әдипләр Теләче мәдәният йортында райондашлары—язучы, «Идел» журналының

баш мөхәррире Рашат Низамиевның 50 еллыгына багышланган әдәби тантанада чыгышлар ясадылар. Бу очрашуда Теләче район хакимияте башлыгы Илдар Низамиев катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

Чаллыда яшәүче язучыларыбыз А. Хәлим һәм Ф. Бәйрәмова Самара өлкәсендә булып кайттылар. Алар өлкәнең Кинәле-Чиркәс районы телевидениесенең оештырылуына биш ел тулу унае белән үткәрелгән кичәдә катнаштылар, район хакимияте башлыгы В. Гәрәев белән очрашып, милли мәдәниятне күтәрү мәсьәләләре турында әңгәмә уздырдылар. Алар, шулай ук, Самараның яна мәчетендә булдылар, өлкә татар газетасы «Бердәмлек»нең ун еллыгы уңаеннан Киров исемендәге мәдәният сараенда татар җәмәгатьчелеге белән очраштылар, чыгышлар ясадылар.

* * *

Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакировка 65 яшь тулу уңаеннан Мәскәүдә аның бенефисы булып үтте. Тантанада Татарстан Республикасының Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиле Нәзиф Мириханов, РФ хөкүмәтенең департамент җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин, «Фатыйха» фонды президенты Илшат Сәфәргалиев катнашты.

* * *

Журналыбызның редколлегия әгъзасы, Казан университеты профессоры Хатыйп Миннегулов Санкт-Петербургта булып кайтты. Ул анда галимә Н. А. Розенбергның «Идел буе һәм Урал төбәге халыклары художество культурасының үсеш закончалыклары» темасына культурология фәннәре докторы дәрәҗәсен алу өчен язылган диссертациясенә рәсми оппонент булды. Ул шулай ук Санкт-Петербургтагы «Чишмә» татар-башкорт җәмгыяте вәкилләре алдында татар милләте, фән һәм әдәбиятының үткәне, бүгенге хәле, киләчәге хакында чыгыш ясады.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

7-8 апрель көннәрендә шагыйрьләр Р.Низами, Р. Гаташ һәм җырчы Ф.Салаховалардан торган иҗади төркем Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә булып, «Илһам чишмәләре» исемле шигъри фестивальдә катнашты. Инде дүртенче ел уза торган, Башкортстан, Татарстан, Чувашстан вәкилләре катнашындагы бу бәйрәмдә күренекле шагыйрьләргә Фатих Кәрим исемендәге әдәби премия бирелә. Быел ана журналыбызның бүлек мөхәррире шагыйрь Рәдиф Гаташ та лаек булды.

* * *

Музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен композитор Батыр-Болгари Луиза Миңнегали кызына «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Ватан өчен башларын салган яудашларга куелган дан монументында сынчы Васил Маликов ясаган һәйкәл күренеше.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы-публицист Шаһинур Мостафин.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Ркаил Зәйдулла.** Хикәяләр, әдәби-публицистик мәкаләләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.—336 бит. Тиражы—3000 данә.




80 еллар башында әдәбиятка килгән Ркаил Зәйдулланы күпләр шагыйрь буларак беләләр. Соңгы 5-6 ел эчендә ул кызыклы хикәяләр язып бастырды һәм үзен талантлы прозаик, публицист итеп тә танытты. Бу китап нәкъ шуны раслый да. Өч бүлектән торган китапның беренчесенә «Тәңре кылычы», «Хан һәм шагыйрь», «Шаһгали» кебек тарихи хикәяләр»; икенчесенә—хәзерге заманга багышланган егермеләп хикәя (кайберләре «Казан утлары»нда басылган иде); ә өченче бүлеккә—авторның Ил, Тел, Дин темаларына публицистик эссе-уйланулары урнаштырылган. Китапта, шулай ук, «Ельцин түбәтәе» кебек сатирик әсәрләр белән дә таныша аласыз.

Китапның мөхәррире—Ф. Зыятдинова, рәссамы—В. Фомин.

**TATAR FOLK TALES** (Татар халык әкиятләре.)—Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1999.—128 бит.




Татар язучыларының Пен-үзәге, «Мәгариф» нәшрияты белән берлектә, инглиз телендә «Татар халык әкиятләре» китабын бастырып чыгарды. Бу китапка аеруча киң таралган әкиятләр тупланган. Алар арасында «Камыр батыр», «Шомбай», «Турай батыр», «Су анасы», «Шүрәле» кебек әкиятләр бар.

Әлеге китап Халыкара Пен-клубның быел май аенда узачак 67 нче Бөтендөнья конгрессы уңаеннан чыгарылган. Татар Пен-үзәге анда катнашучы илләрнең вәкилләренә шушы китапны бүләк сыйфатында таратты.

Басманы дөньяга чыгаруда Татар Пен-үзәгенең президенты Туфан Миңнуллин, аның вице-президенты Разил Вәлиев, Пен-үзәкнең башкаручы директоры Әхәт Мушинский һәм «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев катнашты. Инглиз теленә Елена Вышинская тәрҗемә итте.

24 март көнне Татарстанның Милли китапханәсендә бу китапны тәкъдим итү булды.

Индекс 73210




Шаһинур Мостафин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)